ISSN 0206—4189

# КАЗАН УТЛАРЫ

10. 1998






**“Казан янындагы сугыш. 1552 ел.”** ***Немец рәссамы В. И. Вениг рәсеме. XIX гасыр.***

# Казан утлары
# Qazan utlarь

1998

**10**

**(912)**

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

**Татарстан хөкүмәте,**
**Татарстан Язучылар берлеге,**
**редакциянең хезмәт коллективы**

Баш мөхәррире
**Равил Фәйзуллин**

**Идарә:**
Гариф Ахунов, Харрас Әюпов, Нәҗип Бакиров, Хәлим Гайнуллин, Тәлгат Галиуллин, Миркасыйм Госманов, Аяз Гыйләҗев, Флүс Латыйфи (*баш мөхәррир урынбасары*), Салих Маннапов, Туфан Миңнуллин, Хатип Миңнегулов, Ринат Мөхәммәдиев, Нажар Нәҗми, Рашат Низамиев, Булат Солтанбәков, Ренат Харис, Розалина Шаһиева.

**Мөхәррирләр:**
Мансур Вәли, Наис Гамбәр, Рәдиф Гаташ, Алмаз Гыймадиев, Шамил Маннапов, Шаһинур Мостафин, Марс Шабаев.

**Гамәли хезмәткәрләр:**
Тәслимә Сибгатуллина, Гөлзадә Фәйзуллина, Лилия Гатауллина, Альбина Әхмәтова, Флера Сабирова, Тәгъзимә Шиһабиева.

**Исәп-хисап бүлеге:**
Асия Рәхимова.

✉✉:
420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
☎☎:
Баш мөхәррир — 49-36-60.
Баш мөхәррир урынбасары — 49-36-09.
Җаваплы сәркәтип һәм компьютер үзәге — 43-56-12.
Бүлекләр: шигърият, фән, сәнгать — 49-36-61, чәчмә әсәрләр, хатлар, тәнкыйть — 49-36-63, корректорлар — 49-36-65.
Исәп-хисап бүлеге — 43-56-12.

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ
1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

*Бу санда*

**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Роберт ӘХМӘТҖАН. Үр төшкәндә. *Шигырьләр.* ... 5
Аяз ГЫЙЛӘҖЕВ. Тәмәкене ташладык, рәхәт яши башладык. *Киноповесть* ... 11
Айдар ХӘЛИМ. Исхакый каурые. *Шигырьләр* ... 73
Фәйзи ГАЛИЕВ. Әтнә — күңелем бишеге. *Документаль повесть* ... 79
Эльмира ШӘРИФУЛЛИНА. Таллар җаны. *Шигырьләр* ... 117
Муса ГАЛИ. Көнә килгәч. *Шигырьләр* ... 129
Алмаз ГЫЙМАДИЕВ. Балалар өчен хикәяләр ... 183

**ТӨРЕК ХИКӘЯЛӘРЕ**

Өмәр СӘЙФЕТДИН. Балачак үкенече ... 120
Нәҗдәт ӘКИҖИ. Карамук ... 122
Мәмдүх Шәүкәт ӘЗӘНДАЛ. Хезмәт төбе — хөрмәт ... 126

**ПУБЛИЦИСТИКА**

Фәүзия БӘЙРӘМОВА. Тәгәри китте йомгагым... *(Хаҗ көндәлеге)* ... 132

**Г. ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ДӘҮЛӘТ ПРЕМИЯСЕ БУЛДЫРЫЛУГА 40 ЕЛ**

Казанышларыбыз елъязмасы ... 149

**СӘНГАТЬ**

Татар театр ярата *(Шәүкәт Биктимеровка 70 яшь тулу уңаеннан)* ... 155

**ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ**

Фәрит Бәшир. Юлын белгән — арымас *(Нурихан Фәттахка 70 яшь)* ... 166

**АБДУЛЛА АЛИШНЫҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ**

Абдулла Алиш турында Х. Гыйльметдинов, Ә. Бикчәнтәева, Г. Латыйп истәлекләре ... 177

Укучы сүзе ... 188
Иҗтимагый — мәдәни тормышыбыздан ... 189

## В НАШЕМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

"Проза и поэзия": киноповесть А. ГИЛЯЗОВА "Счастливая жизнь... без табака", документальная повесть Ф. ГАЛЕЕВА "Атня — колыбель души моей", рассказы А. ГИМАДЕЕВА; стихи Роберта АХМЕТЗЯНОВА, А. ХАЛИМА, Э. ШАРИФУЛЛИНОЙ, Мусы ГАЛИ.
Рассказы турецких писателей.
"Публицистика": путевые заметки о паломничестве в Мекку Ф. БАЙРАМОВОЙ.
"К 40 - летию создания Государственной премии им. Г. Тукая": "Летопись заслуг" — лауреаты премиии с 1958 по 1998 г.г.
"Искусство": статья "Татары любят театр" посвящена к 70 - летию актера театра им. Г. Камала Ш. Биктимерова.
"Литературная критика": статья Ф. БАШИРА посвящена к 70 - летию видного писателя Н. Фаттаха.
"К 90 - летию Абдуллы Алиша": воспоминания современников.
"Слово читателя".
Дневник общественно - культурной жизни.
На наших обложках: "Ромашкинская сторона". Репродукция с картины М. Усманова; поэтесса Б. Рахимова.

## IN OUR ISSUE:

*The magazin edits monthly*

" Prose and poetry ": The film- story of A. GILAZOV "A happy life without tobacco", the dokumentary story of F. GALIEV "Atna — the cradle of my heard", A. GIMADIEV'S stories; the verses of R. AKHMETZANOV, A. HALIM, A. SHARIFULLINA, M. GALI.
The stories of Turkish writers.
"Publicism": The travelling notes of F. BAIRAMOVA.
"Commemorating the 40th Anniversary of creation state prize of G. Tukai": "The chronicle of deserts" - laureates of prize from 1958 to 1998 yr.
"Art": The article "Tartars like the theatre", devoted to 70th Anniversary of SH. Biktimirov.
" Literary criticism ": F. BASHIROV'S article devoted to 70th Anniversary of N. Fattakh.
"Commemorating the 90th Anniversary of Abdulla Alish": the memoirs of contemporaries.
"Reader's word"
The diary of social and cultural life.
In our covers: the reproduction from M. Usmanov's picture; the poet B. Pakhimova.

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән житешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 49-36-62 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итергә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 22.09.98 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108¹/₁₆.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Тиражы 11238. Заказ Я-453.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2
© «Казан утлары», 1998 ел.

# ШИГЪРИЯТ



## Роберт Әхмәтҗан

### ҮР ТӨШКӘНДӘ

**Хәтер көне**

**Уян, уйлан элек, ихлас җаным, —**
**Бөек Хәтер көне килеп җиткән.**
**Уяндыкмы соңлап — язмышларда**
**Татарның бу хәтәр көне икән.**

**Булмаган да гүя ул кыямәт —**
**Хәтерсезләр бирә алмас җавап.**
**Хәтерлеләр хәтта мәрткә киткән,**
**Әллә безне хәтерсезгә санап?..**

**Килде ул Көн, шакый диварларга,**
**Йөрәкләргә шакый, хәтерләргә.**
**Шәһит җаннар кайткан мәйданнарга...**
**Мадәт бирче барын хәтерләргә!**

**Без ул чакта булган туфрак кына,**
**Үстергән лә безне Хәтер, тартып:**
**Тез чүккәнче Иблис тәресенә,**
**Кылычлардан чапкалану артык.**

**Туфрак биргән, күкләр үзенә алган**
**Кол Шәрифтәй фида җанлы ирне.**
**Бугазлардан сызылып аккан каннар,**
**Кан ашлаган без шытасы җирне.**

**Туфан булып калыккан ул җирдә,**
**Яугирләрен сагынып сыза Казан...**
**Хәтерсезләр саткан Татар илен,**
**Сатлык язмышлары безгә калган.**

**Диварларга сеңгән җаһилләрнең**
**Намазларың буган ят авазы.**

Таңнан-таңга йөри офыкларда
Сөембикәләрең кайтавазы.

Җан яфрагың дәшә оныкларга, —
Моны, кандаш, һич тә син онытма:
Яшел курпы булып тишелгәнбез,
Шытып чыккан — офыктан-офыкка!

Инде, торып, бил турайтыр өчен,
Җитсен, ыруым, олуг көчең генә.
Бу туфракта бер шытсаң да ярый,
"Хәтер" сүзен әйтер өчен генә!

Үткәннәрең өчен үкенсәк тә,
Киләчәгең барсын бик еракка...
Ошбу көздә очкан хәтер-яфрак
Тәһлил әйтеп төшсен
бу туфракка!

* * *

Менә кайда киңлек! Йөз чакырымнар
уч төбендә ята!..
Тау битләрен яңгыр яңа юган,
Юллар зәңгәрләнеп калган хәттә.

Шуларның мин берсен сайлыйм, анысы
мине туган якка алып кайта.

Тау битенә ятам. Йөземә иелә кылган,
югалдым ла ак кылганнар арасында.
Җәй өлгерде. Шаулый, җем-җем итә
җиләк чәчәкләре — паласында.

Калыйм шушы җирдә. Кузгалмыйча,
җирем-күгем гомер тату якта.
Табигатьнең елышып күкрәгенә,
фани тормыш торсын — теге якта.

Күпме еллар кичеп, шушы тауда,
мәдхияләр язып, күпме яшәп,
күз алдыма кайдан калкып чыкты
моңа чаклы бер күрмәгән чәчәк?!

Шул чәчәкне әнкәм каберенә
куйдым. Калдым онытып дөньясын...
Тау астында, Иске Зират итәгендә
йомран сызгырды.
Әле яңа казыган оясы.

Җир малае! Син дә хәбәр салдың...
Яшисеңме син дә, и, якташым?
Иңкү тулып йөгерә сүсән уты,
ак диңгезе уйный акбашның...

Туган җиргә бер орыну хисе, —
тәнең буйлап көчә изге тойгы!
Тамырлары тирән, бик еракта...
Изгеләр өстендә яңгыр койды,
аерылды болытлар ике якка,

гөлдер-гөлдер китте җылы күкрәү.
Юл уңае кайтып килешемә,
тукталдым да Изгеләр чишмәсенә,
уелып аккан агыйнешемә,
сәҗдә кылдым, күкрәүләргә кушылып:
изге җирем!
насыйп булсын
көмеш салырга
синең өлешеңә!

Тудык!
Инде яшәргәдер, шөкер.
Күңел буам ерылды. Анда акты кояш.
Күк тирбәлде таллар кочагында.
Ишегалды тып-тын. чыкмый әнкәй...
Ут тергезәм
сүнгән учагымда...

Балачагым,
Тәрбели өсләреннән,
ничә еллар
каршы йөгерә миңа!..

## Яшь курпылар

*Волхов юнәлешендә һәлак*
*булган кабере билгесез әтием*
*Вәли Әхмәтвәли улы ядкяре.*

Күзләр җитмәс дөнья төпкелендә
шушы киңлекләрдә — синең аваз:
— сез кай җирдә улым?
— Без бирedә,
туган илдә бүген синсез
илле бишенче яз...

Ишетеләә, кабат:
— Сез кай җирдә?..
— Хәтер кыйбламаңа кара,
кайт бирегә, —
тот йөзеңне якты җырга, язгы җилгә,
ак каеннар яктысына, —
аякларың кайтып басар
туган җиргә!..

Күңел кыйбламаңа кара,
ничәмә-ничә еллар анда, —

ерак ара...
Җирдә быел... мең тугыз йөз туксан сигезенче
ел бара —
"Юлбарыс" елы календарьда!

Миңа, шөкер, тулды алтмыш.
Сөт тешләре шыта кайбер оланнарда...
Җирдә якты! Яшь курпылар калка анда
чалгы җыры аланнарда!

Узса да бик күп гомерләр,
ак өметләр бөреләнә җирдә,
җилфердиләр гүя таңгы җилдә
энкәй юып элгән
ап-ак керләр!
Әй, гомерләр...

Күренерләр төсле әллә кайдан,
хәтта Айдан күренерләр
шул ак керләр!
Чиксез галәм асларында
сине чакырып җилфердиләр
туган илгә:
"Кайда булыйк?
Без — бередә,
туган Җирдә...ә!.."

* * *

Хәтерлим мин Остаз кайткан көнне.
(Узган юллар чыккан йөзенә)
И, башкае — кырау. Ялгыз дуадактай
Моңлы иңрәү иңгән сүзенә...

Аң-таң булып, карап йөрде Илен, —
Шушымы соң аның үз иле?
Аның өчен Казан һәр тарафта —
"Элладаның алтын стиле!.."

Гомеркәйләр искә төшә ласа,
Нечкәрә шул йөрәк хисләре!
Җан канаткан Назон сөргенлеге,
Даладагы сагыш кичләре..

Далаларда утлар яна да бит,
Ә йөрәккәй дөрли көчлерәк.
Ут өстенә тамган йөрәк маем,
И, шигырем, синең төслерәк!

Далаларда учак калды янып,
Башлар ялгыз янып ялыкты...
Кайтып җитте! Өнме, төшме?..
Шул көз
Шигърияттә
Туфан калыкты!

## Юлда

Юлымда мин. Гомер буе
үр менә атым.
Бардыр, түбән төшкән чакта,
утырыр хаккым?

Ә син, энем, үр төшкәндә
чабасың арттан.
Юк шул синең үргә каршы
җигелеп тарткан!

Ат та арык, үр менгәндә
утырып барма.
Сулаганда да шыгырдый
иске бу арба...

Юл читләре яшел борчак,
өзим кузагын.
Айкый малкай яшел кырны,
борып күз агын...

Ике яклап агылып кала,
и, яшел борчак!..
Бездә — корсак... Ә малкайда
дуга, ыңгырчак...

Бушан, камыт, чөелдерек,
бушан, ыңгырчак, —
мин, малкайны сөендереп,
ашатам борчак.

Рәхмәт әйтеп, селки башын,
гүя эш кырып,
нәрсә дисен, и, җанашым,
куя пошкырып...

Шулай, энем, җитте бугай
нокта куяр чак.
Онытма син, авыз иттек
без бер чак борчак.

## Багышлаулар

• • •

*Миргазиян Юныска,*
*язучыга, сәяхәтчегә, галимгә —*
*70 яше уңаеннан, соклап.*

Дулкын сыртлы иксез-чиксез
киңлекләргә елыш...
Син Европам, син Азиям минем,
Миргазиян Юныс.

Занзибарлар кайдалыгын безгә
табышырга булыш.
Океаннар җилен кайтардың син,
Миргазиян Юныс!

Сиңа аквариум түгел,
Океан — олы тормыш.
Штурвалыңны ныграк кыс,
Миргазиян Юныс!

Инде килеп, Исергәптә
безнең Колумб тумыш.
Татар корабы — океанда, —
Миргазиян, булыш!

Тугыз баллы Тормыш...

* * *

*Шамил Шәкүр ядкяре*

Тау өстендә тургай, җилкән сыман
Ак болытлар йөзә кабарып.
Шул тауларга икәү без менәбез —
Беребез — "Герцен", беребез — "Огарев".

Шигырь укып, учак яктык шунда,
Ә ул учак гомер яначак.
Шул таудан без төштек олыгаеп, —
Калды бугай шунда
балачак.

## ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР



Аяз Гыйләҗев

# ТӘМӘКЕНЕ ТАШЛАДЫК, РӘХӘТ ЯШИ БАШЛАДЫК...

КИНОПОВЕСТЬ

Кояш нурларына күмелеп утырган шәһәрнең үзәк урамы буйлап бер егет йөгерә. Чаба гына! Ашыкканнарны да, иренеп кенә селлин-селлин атлап баручы үшәннәрне дә куып уза тора. Торнаныкы кебек озын торыклары велосипед кигиләре кебек туктаусыз хәрәкәттә, аларга күз дә иярми. Урамдагылар аңа ихтиярсыз игътибар итәләр: кем кыска калдырган куе сакалына, ирен читләренә дагаланып ябышкан куппы мыегына карап кала, кем өстенә сыланып торган зәңгәр костюмына күз төшерә, аякларындагы өр-яңа “Адидас” кроссовкаларына да игътибар итүчеләр юк түгел! Карыйлар да сокланалар, сәерсенәләр дә: йөгерү вакытын егет бераз сәеррәк чакка сайлаган түгелме? Кояш офыктан шактый биеккә күтәрелеп, иң аулак, кысан йорт араларына да нур үтеп өлгергән. Шәһәр диңгез ягасында утырса да, урам һавасы нык ук кызган, бакча куләгәләрендә дә шактый бөркү диярлек. Сәгать телләре аргы почмакта да, бирге чатта да унынчы яртыны күрсәтәләр. Әллә иртәрәк торган, әллә төнге тынгысыз дежурлыктан кайтып баручы милиционер егетне сыңар күзе белән генә карады да алаптай зур авызын жилпуч-учы белән каплап, тәмләп иснәде.

Кыз белән очрашырга шулай чабамы әллә бу егет? Биек-биек өч аяклы өстәлләре тротуарга ук чыгарып куелган бәләкәй генә кафе янына килеп житәрәк вәкарь белән генә йөргән, нәзек биленә уч төбе хәтле генә алъяпкыч япкан, чүмәлә чәче өстенә агач көрәк дәүмәлеге куппы ак таж бастырган официантка кыз егетне еррактан ук абайлап, көтеп алды, елмайды, тык-тык басып, уйнаклап каршысына чыкты. Бөтен хәрәкәтеннән, йөзендә кабынган балкыштан аңлаешлы — аңа егетне күрү бәхет, рәхәт иде. Тик егет туктылып тормады, чабыш адымнарын чак кына акрынайтты да сизелер-сизелмәс кенә баш какты, сүрән елмаюын ниндидер тәкәбберлек, һавалану алыштырды. Кыз һич тә мондый үзгәрешне көтмәгән иде бугай, егеткә куркынып карады. Юк, кыз янына ашыкмаган икән егет!

Моннан да чибәррәк кыз янына бара дип уйласак, бу егетебез шәһәрнең барлык сылуларына хужа булырлык жинел аяк, чуар йөрәклеме әллә? Кыяфәтенә карап бер дә алай димәссең, физиономистлар аңа карап “уйчан, житди характерга ия”, дигән нәтиҗә ясарлар иде. Кызны гажәпләндерде егет, ул аның артыннан бер-ике адым тартылып та карады,

кая ул оча гына теге! Борын тишекләре киңәйгән, иреннәре тыгызланып кысылган, йодрыклары да йомарланган икән әле житмәсә! Егет тәжел эш белән шулай ашыгамы? Әллә бәла-казага тарыган берәүгә хәбәр илтәме?! Үлем-житем бармы? Ул арада кафе янына буш такси килеп житте, яшел уты мелт-мелт итеп, утырырга чакырды. Шофер тәрәзәдән баягы кызга сәлам бирде. Кыз җавап биреп тормады, йөгереп киткән егеткә кулы белән төртеп күрсәтте.

— Кая чаба икән ул алай? — дип кычкырды.

Шофер да егетне белә икән, тиз генә аны куып җитеп янәшәсеннән әкрен генә бара башлады. Егет машинага борылып та карамады. Ни йомышы бар шоферның бу егеттә? Әллә теге нәүмизләнеп калган сылу кызга игътибарсызлыгы өчен әрләргә җыенамы? Салкынлыгы өчен кисәтү ясыймы? Кызның абыйсымы әллә? Тукта!

— Чапма, Алим, барыр җиреӊ юклыгын беләм.

Шактый кырыс яңгыраган үз исемен ишетсә дә, егет шоферга әйләнеп карамады.

— Әй, син нәрсә? — диде шофер кабынып. — Минем түгел, синең миңа җитмешбиш тәңкә бурычың бар! Әй, әй!

Бер мәлгә генә егет акрын барган машинаны узды, шофер аның гадәт-холкын яхшы белә идеме, артыгын сорап тормады, борылды да ян урамга кереп китте.

Ә көн матур! Диңгез буе шәһәрләрендә генә була торган саф, үтә күренмәле ачык һавалы иртә! Менә талгын җил исте, агач яфраклары биешеп, шыбырдашып алдылар. Шул җитә калды: асфальт урамнарга сеңеп яткан эссе нур ташкынын наян җил үзе белән ияртеп алып китте. Егет йөгергән шәпкә якасы белән җилләнеп куйды.

Иртәдән агач күләгәсенә оялаган бәхетле җаннар бар шул! Менә монда, җиләс күләгәле сыра ларегы тирәсенә байтак кеше сырылган. Өстәлләр. Өстәлләрдә биек-биек балчык кувшин-савытлар. Савытларда күпереп, күбекләнеп торган салкын сыра. “Иртәдән башлап сыра чүмерәләр, эшлексезләр!” Алимның кайнар маңгаена бер сыр сузылып ятты да, ул бу “бозык” урынны тиз-тиз узып китте. Йөнтәс арык беләкле, какча яңаклы, тар күкрәкле берәү (сыра эчеп симерергәме исәбе: каршысына ике кувшин бастырып куйган!) аңа кычкырып калды:

— Кил, үзем сыйлыйм! Алтарайга тәңкә ярым оттым!

Ул текәлебрәк карады: кайда белештеләр алар бу йолкыш белән?! Ә-ә, мебель кибетендә грузчик булып бергә эшләгәннәр иде!

Аңа да эндәшеп тормады егет, мыскыллы карашы белән үзен дә, сыралы өстәлен дә “аударды” да, чабыш аты кебек башын текә тотып, үз юлында булды. Газета сатучылар, морожный тартмалары, тагын әллә нинди сәүдә нокталары, вак-төяк товарлар, чуар рекламалар, елгыр сатучылар берәм-берәм артта калдылар. Егет тәмәке ларегы янына килеп шып туктады. Чакыручы, кул изәүче дә юк иде, чынлап торып тукталды. Җан-фәрманга шәһәр кичкән егет, чакырсалар да беркемгә дә горур башын имәгән кеше тәмәке тартырга җыенамы әллә?! Унган тимерче мехы кебек тигез эшләгән мул үлчәүле үпкәләренә шул агулы газны тутырырга җыенамы? Юк икән, сатып алырга җыенмый, карый да карый гына! Ә-ә, тәмәке тартмалары, сигарет каплары җыючыдыр әле ул! Бар бит, андыйлар хәзер шәһәрдә генә түгел, авылларда да очрый, һәркем нәрсә булса да комарланып җыя, барлый, туплый, җыйганын саранларча кадерләп саклый, сакларга остарып килә, бик сирәк, ышанычлы кешеләргә хәзинәсе белән мактанып та ала! Бу егетнең дә шөгыле шулдыр әле, мөгаен, әнә ич, тәмәке ларегын өч мәртәбә әйләнеп чыкты. Урамасаң да ап-ачык күренеп тора, ларекның ишек ягы гына такта, үтә күренмәле ларек, бөтен киштәләрдә шыгрым тулган! Сигарет капларын, кабызгычларны, озын-озын папиросларны, алтын кәгазьләр белән билләрен буган купшы, мактанчык сигараларны испан кызларының аллы-гөлле җилпәзәләренә охшатып таратып ташлаганнар. Салават күпере уйный, күз явын

алырлык! Әйләнә егет, әйләнә, сатучы кыз башта аңа сокланып, аннары шикләнеп, ниһаять, куркынып ук карады. Егет бар дөньясын онытып, йотылып, ачкүзләнеп күзәтә иде ларектагы тарту запасын! Кыз кәгазьләр арасыннан яшереп куелган милиция сыбызгысын сиздермичә генә бармак арасына кыстырды. Урын аулак диярлек, монда шәһәр бетә, иртән кеше аз йөри, талаучы булмасын бу кыска чәчле егет! Егетнен чәче кыска булуына беренче тапкыр әнә шул кыз игътибар итте.

Ә ул... Зур күзле кызга күтәрелеп тә карамады, бөтенләй күрмәде дә бугай, бусы бөтенләй гаҗәп, акылга сыймаслык хәл иде. Кыз бик чибәр, хәзерге заманда үтә сирәк очрый торган чын аксыл чәчле, текә, мул күкрәкле, кызыктыргыч йомры беләкле иде. Кыз үз бәясен бик яхшы белә, ирләрнең игътибарына күнегеп өлгергән, күзен бер сирпесә дә, иң тотанаклы ирләрнең йөрәгенә вәсвәсә сала иде, тартканы-тартмаганы кич-көндезләрен, бал тирәсендә сырышкан комсыз шөпшәләр төсле гел шушы тирәдә урала торган иде. Юри чиратта торалар явызлар, күзләре белән аны ашыйлар... Ә бу... мөмкинлек булып та, кызга күтәрелеп тә карамады! Ларекны өч әйләнде югыйсә, өч! Кызның хәтере калды, егет аңа пар булырлык дәрәҗәдә матур иде. Һәм кыз, егет-җилән очраганда үзен гел өстен чыгарып гадәтләнгән кыз, әче елмаеп, юри боргаланып, бүген аңа үзе дәште:

— Ә мин сезне беләм, — диде ул.

Егет затлы сигараларга карап каткан иде.

— Исемегез Алим. Моннан ерак та түгел сезнең бертуган абыегыз яши!

Егет ишетмәде, ул чуар сигарет капларындагы алтын суы йөгерткән язуларны укый иде.

— Минем эшем кичке җидедә бетә! — диде кыз, соңгы тапкыр өметләнеп.

Егет кырт кына борылды да тагын чаба башлады. Кыз пыяла рамны ныграк күтәреп, башын тышка чыгарды, калакка эләгеп өч-дүрт бөртек кадерле чәче өзелгәч, җыламсырап:

— Бәхетсез, турсык! — дип кычкырып калды.

Әлбәттә, кыз ялгышты! Үпкәләү, рәнҗү тойгысы күзнең явын ала, сукырайта, дөрес бәя бирергә комачаулый, бер дә турсыкка тартымлыгы юк иде егетнең, тәненә ятып торган костюмы тиешле урыннарын бик матур һәм өметле калкытып тора иде. Сакал-мыегы да мул, куе чигә чәчләре дә чак кына бөдрәләнеп тора иде. Бәлки шуларның барысын да электән үк чамалап йөргән кыз (ә кибетчеләрдә кешеләрне аңлау аерата нечкә һәм үткер була!) егетнең игътибарсызлыгын кичермәгәндер?!

Ни булса да булды, егет шәһәр читенә чыкканчы байтак үткер күзләр аша узды, шактый гына кушаматлар да алып өлгерде.

"Авызыңа керергә торган калҗаны каба белмисең!" — диде аңа официантка кыз.

"Бөтен танышларына бурычлы булса да, башны текә тота!" —диде таксист.

Сыра эчүче арык бер генә сүз юллады: "Ахмак!"

"Турсык!" диде аңа чын аксыл чәчле блондинка.

Ниһаять, егет йортлар кысасыннан чыкты, шәһәр яңы башланды. Җимеш бакчалары, куерып, бөдрәләнеп утырган янбакчалар, ишегалларында эт оялары, коелар, биек-биек чуар-чабар телевизор антенналары, гаражлар, йозаклар, тагын әллә нәрсәләр, тагын әллә ниләр башланды. Бер ишегалдында өч-дүрт үсмер зәңгәр төтен һәм кара тавышлар чыгарып, мотоцикл тырылдаталар. Таза икән Алим, күпме җир узып, чабыш тизлеген киметмәде, йөгерде дә йөгерде һәм бер капка турысына килеп туктады.

Кызык иде бу капка! Биек иде, баганалары нык, такталары ырып бер-берсенә тыгызлап кертелгән, бер җирендә тишек-тошык, кытыршылык юк, һәммәсе таза, нарат тактадан. Мәңгелеккә исәпләп эшләнгән. Ә капканың ике ягында да чалыш-чолыш, тәбәнәк, иске-москы такталардан

әтмәлләнгән коймалар! Бөтен ихатаны шундый ватык-мотык койма ураган! Ә капка кара материягә салган ак ямаулык кебек балкып күренеп тора. Капка төбенә килеп туктагач, егетнең беренче тапкыр тыны кысылды, ул туктап, дымланган маңгаен сыпырып, һушын җыеп торды. Капканы этеп карады, эчтәге шомлы тынлыкны ерткалап, күренмичә генә авыр авызлы эт ырылдады, тимер келә шылтыраса да, капка ачылмады. Алим тәбәнәк койманы сикереп тә уза ала иде, алай да сабырын җыеп, тагын капкага орынды. Бикле икән! Көпә-көндез! Ул койманың иң тәбәнәк турына килде. Шактый биек, янкормалар белән төрле якка бүселеп чыккан йортның йомык тәрәзәләренә карады, килгән юлына борылып күз салды, ике кулыннан колаша ясап, нык, таләпчән тавыш белән:

— Әзи! — дип кычкырды.

Җавап урынына эт тагын ырлады, аның активлыгыннан егет хуҗаның өйдә булырга тиешлеген чамалады, эт куркак, алай да хуҗасына ярарга бик тырыша иде. Егет баягыдан да катырак тавыш белән тагын бер тапкыр кычкырды:

— Әзи, дим!

Чарлак катындагы шактый киң тәрәзәнең пәрдә почмагы күтәрелде, аннан йокылы, шешенгән йөз күренеп калды. Пәрдә ябылды, лып та лып аяк тавышлары ишетелде, бераздан икенче каттагы, инде кечерәк тәрәзәнең пәрдәсе тартылды — аннан ачулы кысык күз ялтырады, аяк тавышлары ныграк яңгырады, ниһаять, беренче каттагы — нәни генә, тыгыз тимер рәшәткәле тәрәзә ачылды.

— Нәрсәгә акырасың? — диде кырыс тавыш.

Бу тавышка ияреп, эт тагын бер кат ырылдап куйды. Өйалды ишеге шыгырдады, аяк тавышлары ишегалдында таралды, капка ике күз сыярлык дәрәҗәдә генә ачылды, абый кеше тагын да кырысрак итеп, кимсетергә теләп:

— Ник килден? — дип сорады.

— Йомыш бар! — Алим, капканы тизрәк ачарга теләп, түземсезләнеп кулын ярыкка тыкты. — Сөйләшергә кирәк!

— Үзең генәме?

— Күрмисеңмени?

— Күрәмме-юкмы, сораганга җавап бир.

— Кем белән йөрим ди тагын? Йомышым андый түгел.

Абзый ике куллап тотып торып, капканы кысылып узарлык кына ачты, Алимны үткәреп җибәргәч, як-якка килбәтсез колаклары асылынган йомры башын ярыкка тыкты, унга да, сулга да күзен тәгәрәтте, япкач, капканы учы белән сыйпап алды. Капканың авыр тимер биге җәяләр эченә лып кереп сенде. Аннан соң гына болдырдан ерак та түгел юанаеп җәелгән ак кәүсәле тирәк янындагы артсыз эскәмиягә барып утырды. Күзе өстенә үк ишелеп төшкән эре бөртекле калын кашлары туктаусыз кыймылдады.

— Акча китерденме? — диде ул.

— Юк әле.

— Бурычыңны кайчан өзәсең?

— Түләрмен дидемме? Түләрмен дә! Кулыннан эш килми дип яманлыйсың инде? Булдыра алмас дисең?

Энесенең тавышында моңарчы ишетелмәгән тантана авазлары-аһәңнәре абайлап, абыйсы күтәрелеп карады. Алим кулын бөере тирәсендә йөртеп, бераз артка тайчынып, көлемсерәп аңа текәлеп тора иде. Абый дигәннәре аягүрә басты.

— Түләтмичә калдырмам, боерса. Кайчан, дип өзеп сорыйм мин синнән? Түләвен түләрсең, каерып алырмын. Йорттан чыгып китүеңә өченче ел бара! Күпме гомер әҗәт белән яшисең! Мин синнән процентлар ала башламыйм тагын!

Бурыч кешене изә, шәхес буларак кечерәйтә, бурыч — рухи бөлгенлек, кемгәдер ирекле баштан коллыкка яллану, түбәнәю, дәрт сыеклыгы,

ни кадәр чабып тыны беткән егет абыйсы алдында еш-еш сулыш ала башлады, хәтта мышнады, маңгаена тере бөрчекләр булып тир тамчылары таралды. Тик бу хәл бер мизгел ара дәвам итте, егет ят, кыргый тавыш белән абыйсына кычкырды:

— Түлим дидем ич мин сиңа! Көт!

Аскы катның тимер рәшәткәле нәни тәрәзәсендә хатын-кыз шәүләсе чагылып калды. Тоныкь, ямьсез һәм котсыз шәүлә иде...

Йорт хуҗасы чыннан да Алимның бертуган абыйсы, "әзи" дип йөртә ул аны, әллә кайчан илен-көнен ташлап чыгып киткән Нижгар мишәре, җомга көннәрне касмакланып беткән бәрхет кәләпүшен чамасыз йомры баш очына утыртып, ашар алдыннан "бисмилла", корсак шыплап тулгач, кикереп "аллаһе әкбәр!" дип җибәрә торган, бөтен татарлыгы, мөселманлыгы шушы ике сүзгә сыеп беткән, чит илләрдә йөк ташыган совет судносында унтугыз ел эшләп, кыты-мыты сәүдә гөнаһларыннан соң, эшеннән куылып, шушы диңгез буе шәһәрендә аерым йорт салып кергән, ике кыз, бер малай үстереп тараткан, хәзер хатыны белән генә яшәп ята торган Харис исемле кеше иде. Диңгез белән көчләп аерганнан соң ул бөтен дөньяга, дөньядагы һәр кешегә ачулы, үчле, кемнәргәдер кара йодырыгын күрсәтә-күрсәтә төрле кәсепкә ябышып карады, сыра сатарга кереште. Диңгезче, танышларыннан хурланып, аннан чыкты: маклерлык итте — квартбюрода елга якын йөреп маташты, ошатмады. Фатирда кеше тотты, мантымады. Соңгы елларда нутрия үрчетергә тотынды. Тире иләргә өйрәнде, хатынын бүрек, яка тегәргә мәҗбүр итте. Хуҗалыгын нык кына аякка бастырды. (Биек капка шул төшемле чор истәлеге!) Моннан дүрт ел элек яман чир чыгып бер атна эчендә җәнлекләрен кырып салды. Зур каза күрде Харис, йокысыз калды, дөньясын, алласын-мулласын тагын да ныграк, тозлап-борычлап сүкте. Төрле илләрдә, төрле халыклар белән аралашканга егермеләп телдә сүгенергә өйрәнгән иде. Хәзер шулар файдага ярады, җиде бабасын каргады. Тәвәккәлләп, тагын иске кәсебенә тотынырга ниятләгәндә, исенә төшеп, ветврач белән киңәште. "Сезгә урын алыштырырга кирәк, бу туфракта, бу җирдә нутрия асрарга ярамас!" — диде врач. Өч катлы йортны, күпме көч сарыф итеп алган җирне, хуҗалыкны ничек алай тиз генә алыштырасың? Иреннәрен канаганчы кысты Харис, чыдады, тормышта җинел яшәүнең башка ысулларын эзли һәм язмышның елмайганын көтә башлады.

Төп йортта төпчек Алим калган иде. Колхозда эшләп йөрде, әниләре вафат булгач, йорт-җирне сатып, вак-төяк җиһазларны арзан гына бәягә таратып, шушы шәһәргә күчеп килгән иде. Дөресрәге, аны абыйсы чакырып алды.

"Кул арасына керерсең, эшкә үрәнерсең, буш итмәм... Өйләндерермен, ул якка да күзнең үткенлеге җитәрлек", — диде ул, ятимлектән боегып калган энесенә. (Сүз җаеннан гына әйтеп үтик, Харисның хатыны үтә чыккан бер ямьсез иде. "Ярар! — диде ул өйләнгәндә, — ярты гомере диңгездә уза торган кешегә ни пычагыма чибәр хатын!"

Килү унаенда Алимның планнары томанлы иде, алай да егет күчәргә тиз ризалашты, илләрдән илләргә гизгән, чит шәһәрдә, агай-эне ярдәменнән башка да хуҗалык корып җибәрә алган, моряк Харис гадиерәк агай-эне арасында үзенә күрә бер авторитет иде! Сирәк-мирәк кайткан чакларында, элеккеге елларда, чит илләрнең чуар кәгазьле арзанлы шәрабләре белән Нижгар мишәрләренең исен китәрә торган иде ул!

Абзасының ялчысы көненә төшеп баруын чамалап, моннан ике ел элек Алим араны кырт кисеп, йорттан чыгып китте, заводка слесарь булып урнашты. Эшкә керүенә, алда булачак мул эш хакына ният тотып, бик ялынып, ялварып абыйсыннан дүрт йөз сум бурычка акча алды. Харис — беркемгә дә бер тиен көтәчәккә бирми торган ата карун, энесенең ялваруына бирешкте. Бәлки энесенең өй саткан акчасының соңгы тиеннәренә кадәр үз кесәсенә кергәнен уена китергән чагы булгандыр? Алим исә аларны хәтерләп, ваксынып тормады: "Бик тиз түлим мин

сиңа акчаңны! Магнитофон сатып алырга кирәк!" — дип аңлатты.

Хезмәт хакын чибәр генә ала башласа да, Алим әҗәтеннән тиз генә котыла алмады, магнитофон янына электропроигрыватель кирәк булып чыкты, кыйммәтле диск-табалар, кассеталар, ленталар өстенә заманча кием-салым, джинсы чалбар, яхшы курткалар авыл кытлыгыннан чыгып ычкынган егетне сукырайттылар, порт тирәсендәге ыгы-зыгылы, ялтыравыклы базарда ул тәмам аңгыраеп, исәнгерәп калды. Кем биреп торса, шуннан бурычка алды, сорарга читенсенмәде, "өч айдан, бер айдан түлим!" — дип, нигезсез вәгъдәләр бирде — сүзендә тора алмады, кредиторларыннан качып, икенче берәүләргә бурычка батты. Быел язга чыкканда аның ике мең сумга якын бирәчәге бар иде инде. Иң күбе Харис әзисенә — төп-төгәл дүрт йөз сум!

Харисның җайсыз вакыты, акча ягыннан кысанлык татымаса да, күңеле китек чак, тормышы кылдый-былдый барган көннәр, энесенең буш кул белән килүен дә, һич тартынмыйча ботын ерып туп-туры карап торуын да өнәмәде ул. Өнәмәде генә түгел, шомланды, яманга юрады. Төп-төз, биек буйлы энекәше каршысында кырау тигән кузак хәлендә басып тору да мәртәбә түгел! Җитмәсә, Алим авызыннан һич уйламаган сүз чыкты:

— Әзи, миңа акча кирәк, — диде ул.

Әзинең күзе аларды, салынкы кашлары җимерелде, иреннәре ишелеп төшәм, ишелеп төшәм дигән төсле дерт-мерт килделәр. Ул кычкырган тавышка өйдән хатыны чыкты, битен күрсәтмәс өчен яулыгы белән томалап, аяк табаннарын ышкытып кына якынлаша башлады. Эт тә кура арасыннан чыгып аңа иярде.

— Акча!? Син акылыңнан шашкансың! — дип кычкырды Харис.

— Миңа акча кирәк һәм син аны биреп торасың! — диде Алим.

— Бу йортта акча сугалар дип беләдер ул сантый! — Ниһаять, кыптырдап алар янына килеп җиткән хатынның да теле ачылды.

— Мина акча кирәк! Бу юлы соңгысы. Бер ай да үтмәс әҗәтләремне түләрмен.

Харисны туктатырлык түгел иде, ул шашкан кыяфәт белән, кулларын бутап, төкереген чәчеп кычкыра башлады.

— Дурак! Чучка! Кара җәяүгә калган тинтәк! Костяга бурычы бар, Ленадан алып торган. Теге официантка кызны беләсең ич, кафеда! — Бу сүзләрне ул хатынына карап әйтте. —Тулай тороктан куалар. Комендантка да бирәчәге бар! Егетләргә, кызларга!.. Аны тиздән милиция белән эзли чыгачаклар! Төрмәгә тыгачаклар! Шундый чакта исәрләнеп тагын теләнергә киләме?! Күрче син моны!? Мең сум!!!

— Куып чыгар үзен!

Эт кайчандыр Алим белән дуслашып, җәйләрен бакчада, агачлар астында йоклап йөргән эт, хуҗаларына кушылып өзек-өзек өрә башлады. Аның белән генә тукталмады, егетнең чалбар балагын умырып тешләде. Егет аны тибеп очырды, эт, койрыгын бот арасына кыстырып, чиный-чиный җәһәт оясына кереп посты. Ир белән хатын шикләнеп, бер-берсенә караштылар. "Ни булган бу Алимга? Чыннан да акылына зәгыйфьлек килгәнме әллә, бичараның?!" Туганнарының шиген бермә-бер арттырып Алим кирәк акчаның суммасын төгәл атады:

— Миңа сездән төгәл мең тәңкә кирәк! — диде.

Бу иң соңгы чик иде. Харис болганчык күз яшьләрен агызып, шаркылдап көләргә тотынды, хатыны нәкъ эт кебек чиный-чиный аңа кушылды, алар пычрак, керле бармаклары белән егеткә төртеп күрсәтә-күрсәтә шактый озак шаркылдадылар. Порт ягыннан теплоход кычкыртканы ишетелде, бу тавыш хуҗаларны айнытып җибәрде, алар гарьчел Алимның шулкадәр мыскыллауга да түзүенә хәйран калып, акрын-акрын көлүдән тыелдылар.

— Беттеме? — дип сорады Алим сабыр гына. — Көлке артыннан ни килерен уйламыйсыз! Менә!

Һәм ул җингән кыяфәт белән зәңгәр чалбарының арт кесәсенә тыгылды, аннан дүрткел итеп бөкләнгән газета кисәге тартып чыгарды.

— Менә укыгыз! Сез бит наданнар. Остап Бендер әйтмешли, кайчагында газеталар да караштырырга кирәк!

Харис артсыз эскәмиягә янадан утырды, шактый таушалган, кат-кат укылган газетага текәлде, яшьле күзе берни күрә алмады. Ул, хатынына карамыйча гына:

— Күзлекне алып чык! — дип боерды.

Ишарә-ымга да сүзсез буйсынырга күнеккән хатын җәлт итеп өйдән күзлек алып чыкты, иелеп иренә тапшырды һәм Харисның иңбашлары аша, арттан торып газетага карады. Бер укыды Харис, ике укыды — берни дә аңламады, беренче мәртәбә хатынының чыраена карады. Ул да иңбашларын җыерып, куырылып шыпырт кына артка чигә башлаган иде, хәзер давыл кубачагын, иренең соң дәрәҗәдә ярсып, акыра-бакыра башлаячагын чамалый иде... Нишләп сураеп каткан инде бу Алим? Ник чыгып китми? Ни көтә?! Бу тынлык юньлегә түгел, тәпәләп ташламасын егетнең үзен! Харисның кулы авыр, йодрыгы унтугыз ел диңгез давылларында ныгыган, байтак теш казналарын, ипи шүрлекләрен җимергән мәшһүр йодрык... Бәла-каза чыкмасын тагын. Хатын ике кулын бутап, авызборының мыймылдатып каенесенә чыгып китәргә кушып карый. Юк, селкенми дә Алим, аңламый да! Китәме соң, әзисенең авызына керердәй булып каршысына ук тыпылдап баскан да, газета кисәген тегенең борын тирәсендә уйната.

— Күп көлдегез миннән, җитәр! Чамасыз мыскыл иттегез — булды! Моннан ары мин сездән көләчәкмен! Имеш, минем йомшак якларым күп. Имеш, минем тоткан юлым дөрес түгел!.. Оһо! Карап карарбыз! Мин бер карауда эшнең ничек икәнен, кай якка борып җибәрергә мөмкин икәнлеген аңладым. Ә син юк! Чөнки син туң баш, черек күчән! Заманча яши белмисең!

Менә ни өчен юл буе берәүгә дә дәшмәгән икән Алим! Менә ни өчен тешен канатырлык кысып, йодрыгын йомарлап килгән! Шушы хәтәр сүзләре авызыннан коелып калыр дип курыккан ул! Уйлары сүз булып йомарланырлар да юлда чәчелерләр дип белгән!..

Үтерсәләр дә берни аңламады Харис, алай да энесенә артыгын күтәрелеп бәрелергә базмады, ми ярымшарларын авырттырып, гомерендә беренче мәртәбә ул газетадагы белдерүне аңларга азапланды. Колагыннан төтен чыкты, маңгаеннан тир акты, күзеннән утлар чәчрәде. Тик барыбер миендә төпле уй уянмады. Газетада профсоюзларның өлкә советы һәм өлкә медицина советының уртак белдерүе басылган иде. Алар бергәләп егерме дүрт көнлек диңгез сәяхәтенә чакыралар... Сәяхәтнең үзенчәлеге шунда, аңа бары тик тәмәке тартуны ташларга җыенган гражданнар гына катнаша алалар һәм егерме дүрт көн дәвамында тәмәкечеләрне утырткан кораб бер генә портка да кереп тормаячак, билгеләнгән вакытта гел йөзеп кенә йөриячәк иде. Сәяхәткә тәмәке алып чыгу катгый тыела дип кисәтелгән һәм иң аста белешү өчен телефон номерлары да теркәлгән иде.

— Юлдан язган идең, хәзер акылыңнан коры калгансың! —дип кычкырды Харис. Тавышында элеккеге үтергеч авазлар юк иде югын.

Инде Алим көлә башлады.

— Акылдан? Бу син, үзеңнең сыек зиһенең белән берни аңламыйсың! Ике куянны атам! Бердән — акчалы булам. Икенчедән, миннән көлгән, ничә айлар мыскыл иткән кешеләрдән үч алам! Менә син, "тәмәке тартуымны ташлыйм!" дип, ничә мәртәбә ант иттең! Коръән тотып! Ташладыңмы?!

Нәкъ шул вакытта Харис яньчелгән чалбар кесәсеннән сытылып, изелеп беткән сигарет кабын алып маташа иде, сигаретын авызына капты, ут элдерергә онытты:

— Иптәш малайлар бәхәсләшә-бәхәсләшә ташлап карадылар. Атна

да узмый, элеккедән шәбрәк пуфылдаталар. Төнлә уянып суыралар, иртән ашаганчы бүлмәләрен төтен белән тутыралар. Монда теплоходка өч йөз егерме кеше утырачак! Тәмәке алып керергә ярамый! Ярамасын! Ә мин алып керәм! Өч йөз егерме кеше шулкадәр вакыт тартмыйча түзәр дип беләсеңме?! Түзәләр пычагым! Алып та керәм, иң кыен, иң кирәк чагында гына, нишлим?..

Харисның миенә бик авырлык белән җылы кан йөгерде, ул кызыксынып газетаны энесе кулыннан йолкып алды, чәнечкеле кысык күзләре әвеш-тәвеш тезелгән хәрефләргә йотылды. Белдерү элегрәк тә ясалган, ахрысы, монда "дәвам итә" дигәннәр... Кузгалырга дүрт көн вакыт калган!

— Синең баш йомрыланган түгелме?

— Бер капчык сигарет алып керәм, — диде егет кистереп. — Иң чигенә, соңгы сырына җиткәч кенә, кыйбат бәягә сатам. Берсен бер сумга!

Киметеп әйтте егет, ул эченнән генә: "Күп алып керә алсам, берәр сумнан җибәрәм, аз туры килсә, икешәр сумнан каерачакмын!" дип ниятләп тора иде.

Акчаны, бәяне ишеткәч, Харис шунда ук үзгәрде, тиз-тиз санап, чутлап чыгарды.

— Ә юк, — диде ул ияген уңга-сулга йөртеп. — Андый ук җүләрләр табылыр дисеңме? Берсен бер тәңкәгә? Бишесен бер тәңкәдән сатсаң да...

Алим кайчандыр укыганнарын, ишеткәннәрен худка җибәреп, абыйсын үгетләргә, җиңәргә, аста калдырырга тырышты:

— Бер төрерлек махра өчен соңгы ризыкларын, актыкка күлмәкләрен саткан бәндәләрне белмисеңме? Ашамыйча ничә көн түзә кеше, су йотмыйча күпме чыдый — болары мәгълүм, мәгәр өч йөз дә егерме кешенең яртысы гына, пусть, шул кадәресе генә булсын, бер атнада ыңгырашып тәмәке эзли башламаса, акыллы башымны кисәргә бирәм!

Егет әле үзе күрмәгән, әле кемнәр икәнен дә белмәгән толпадан, тәмәке ташларга җыенган пассажирлардан көлә, мыскыллый, эченнән генә тантана итә иде. Аның күз алдыннан ул бурычлы булган байтак кешеләр тезелеп узалар, таксист —һәрчак акчалы Костя, официантка Лена, менә бу йөнтәс Харис әзисе... Теплоход пассажирларыннан акча каерып, ул алардан үч алачак! Аларны көлкегә калдырачак, акчалыларны, тормышлары көйләнгән кешеләрне, яшәешләрен җайга салган купчелекне! Нигә әле бер Алим гына интегергә тиеш? Атлаган саен нигә ул гына көлкегә калырга мәҗбүр? Бүтәннәр дә татысыннар көлкегә калуның ни икәнен! Белсеннәр! Тигезләшсеннәр! Бөкре кеше башкаларның да бөкре булуын теләмимени?!

— Бер портка да тукталмагач, ә?! Ничек уйлыйсың?! Тиз тот! Чыгар мең сумыңны!

Егет абыйсын көтелмәгән хәбәр, һич күз алдына китерелмәгән хәл белән җиңеп булачагын чамалаган иде, чыннан да Харис бер мәлгә шинеп, суырылып калды. Тынлык урнашты.

— Бирәсеңме акча?

— Күпме?

— Әйттем ич!

— Бирмим, — диде кинәт Харис. — Мондый акыл бер сиңа гына килер дип беләсеңме?.. Анекдот ишеткәнең бармы?! Картларны бәйрәмгә чакырганнар, "Һәркем үзе белән бер шешә шәраб алып килеп мичкәгә салсын" дигән шарт куйганнар. Мичкә тулгач эчеп карасалар... Саф су икән! Чөнки һәркем "һәй, бер шешә суны беркем дә белмәс әле", дип шешәсенә су тутырып килгән...

Инде Харисның тантана итәр чагы житте, дөресрәге, ул шулай санады:

— Һе, өч җүләргә бер пигамбәр! Гомере буе җилдән бау ишеп йөргән егет өч-дүрт атнадан меңәр сумны каерып алсын әле. Дингездә

ял итеп йөреп! Мең тәңкә өчен беләсеңме күпме тир түгә идем мин?! Акча акмый ул, тама гына!

Алимның чыраена күләгә төште, сүз сүзгә ялганачак, уй фикерне тудырачак, нинди генә акыллы тәкъдим белән килсә дә, абыйсы аны аңлаячак түгел — Алимның дәрәҗәсе нык какшаган чак! Егет әҗәткә баткан! Бурычы бар кеше биреп торучыдан бер чакта да акыллы булып күренә алмый! Һәм Харис салулый-салулый бөтенләй әллә кая кереп китте. Үзенең уңганлыгы белән мактанырга тотынды, юлына аркылы яткан кара язмышын сүкте... Һаваланды, киерелде, мактанды. Юк, тек юк! Алим боларны тыңлап торырга дип килмәгән иде. Ышанып, ышандыра алу көченә өметләнеп килгән иде. Соңгы кат шакуы иде бу капканы! Юк, тек юк! Ул абыйсын үгетләүнең файдасыз икәнен яхшы үзләштергән кеше буларак, сүз куертып тормады, газетаны тартып алды да китәргә юлына юнәлде.

— Әй, кая кузгалдың?

Егет, капканы чыккач та икеләнер, кире борылыр дип көткән иде Харис, борылуын көткән иде. Акча бирмәячәк, рас, мәгәр энесенең, тап-таза, киләчәге бик озын булган кешенең аңа, кипшерә башлаган кортлы гөмбәгә ялынып килүе бик рәхәт иде. Шәһәрдән килә бит, кайнап торган тормыш кочагыннан килә! Аңа, күршеләре дә юньләп сәлам бирми башлаган, янында ябагалы эте белән убырлы карчык кебек хатыны гына калганда, аңа килә, сорап килә, ялынып килә! Тезләнә!

Тик егет борылмады. Килгәндәге кебек үк йөгерә башлады, янтыгына кату чыкты, аяк адымнары авырайды, ниһаять, ул картлар төсле кулын артка куеп, адымын санап кына бара башлады.

Ә көн матур! Тормыш җанлы! Кояш нурлары иң караңгы почмакларга да мул булып явалар, диңгез ягыннан хуш исле җил исеп куя, ишегалларында бала-чага чыр-чуы, үсмерләр футбол мәйданында туп тибәләр. Кыска итәкле күлмәк кигән тулы балтырлы, чибәр хатын кер элә. Ап-ак җәймәләр Алимның күзенә ак флаг булып күренәләр. Тагын җиңелде, тагын бирелергә мәҗбүр булды. Ике көн, ике төн корган планнарын җимерергә абыйсының сыңар сүзе җитә калды: "Бирмим!"

Нурга коенып утырган баягы сукмак буйлап бара егет...

Тик бу баягы Алим түгел инде. Иңбашлары салынган, күз карашы тоныкъ, адымы килбәтсез, җансыз... Баягы тәмәке ларегына житәрәк ул урамның икенче ягына ук чыгып китте. Блондинка чибәрне егетләр ураган иде, ул Алимны күрми дә калды... Урамның бу ягында да хәрәкәт. Чаттан борылып чыккан такси тагын аның белән янәшә бара башлады. Ачык тәрәзәдән тузган чәчле таныш баш күренде...

— Нихәл, дус кеше.

— Ә, Костя, исәнме.

— Күрәм, сөмсереӊ коелган. Кил безнең паркка. Сөйләшәм, эшкә алырлар.

Алим мыскыллап көлемсерәргә уйлаган иде, үз хәлен чамалап, көлкесен яшерде.

— Эх, Костя! Беләм ич, күпме түләселәрен дә беләм, күпме эшләтәчәкләрен дә чамалыйм.

— Башта бер җирдә дә мул яудырмыйлар. Җаен алырсың, өстәмә эш сорарсың. Эш күрсәтсәң, ачка үлмәссең.

— Ачка болай да үлмим! Миңа ул гына аз! Миңа берьюлы бик күп акча кирәк. Менә синдә ул акча бар! Биреп торасыңмы? Ай үтмәс, кире кайтарырмын.

— Начар яшисең, егет! Бозыласың. Башта әҗәтләреңне өз, аннан сөйләшербез.

Машина төчкереп аны узып китте. Ул нидер өметләнгән сыман аны куарга омтылды да адымнары тагын авырайдылар...

Алдагы чатта ул урамның тагын бу ягына чыкты. Баягы кафега якынлашып килә иде. Сыра эчүчеләр янынннан узганда, бу юлы аңа

беркем дә эндәшмәде. Ул шактый ишәйгән чират янынннан тып-тын гына узып китте. Ике-өч атлагач туктады. Бәләкәй алъяпкыч ябынган кыз аны баягыдан да сөйкемлерәк каршылады. Егет, күңеле төшенке булса да, чибәр, сөйкемле иде. Кыз бер төркем апалардан акча алып тора иде, эшен бетергәч, кулын алъяпкычына сөртеп, читтә каңгырап торган Алим янына атылды. Туп-туры:

— Тагын абзаң янына бардыңмы? — дип сорады.

— Әйе, — диде егет.

— Тагын акча сорадыңмы?

— Ә син аны каян беләсең?

— Кыяфәтеңә кара! Күзеңне сүндереп җибәргәннәр. Хәтерлим, сөйләгән идең, "абзый янына соңгы чиктә генә барам", дигән идең. Чиккә җиттеңме?

Байтактан күрешкәннәре юк иде аларның, егетнең кызга бирәчәге шактый, ул аның түли алмаслыгын да, шул сәбәпле күренмичәрәк качып йөрүен дә белә, аңлый иде. Алим монда да бер мәлгә югалып торды, аннан, кинәт, көчен җыеп:

— Лена, син миңа өч-дүрт йөз биреп тора алмассыңмы? —дип мыгырдады.

— Мин сиңа мең тәңкә дә биреп тора алам.

— Нәкъ мең сум кирәк тә!

— Чынмы?

— Ихлас.

— Кирәк икәнлегенә ышандыр.

— Лена, яман эшкә сорамыйм. Яман эш ниятләсәм, яман юл белән юнәтә алыр идем. Хәзер мин абый белән араны кырт кисмәкче булам. Нигә эштән эшкә сикерә дисеңме? Туйдым бурыч белән йөрүдән. Буа, үтерә ул бурыч-борыч мине. Сүземнең кадере юк, санламыйлар мине!

— Барма аларга, йөрмә.

— Туганым бит. Дөньяда бүтән беркемем дә юк.

— Бер миңгә ризалашып, богавыңны салдырыр дисеңме?

— Шул суммага мин үземә ирек сатып алмакчы булам.

Кыз аңа бармак янады:

— Сатып алган ирекнең кадере булырмы?

Аргы баштан өлкән официант кызга кул изәде. Лена язгы тандай алланып, Алимга табарак тартылды.

— Алим, Костя миңа тәкъдим ясады. Син... ни дисең?

— Мин?

Әле генә "сүземнең кадере юк!" дип зарланып торганнан соң, сиңа килеп шундый җитди кинәш сорасыннар әле! Егет тә комач кебек кызарынды.

— Әгәр син "юк, чыкма!" дисең икән...

Бусы инде бөтенләй бәреп екты егетне! Шушы эшлекле, ягымлы кызның язмышын хәл итү аның кулындамы?! Ул Ленага шаккатып карап калды. Әйе, монда уен-көлке белән котылырга ярамый иде.

— Костя әйбәт егет, — диде ул. — Үзеңә кара, Лена.

— Аңа чыгам икән, мин сиңа акча биреп тора алмыйм инде, кадерлем! — диде чаяланып кыз һәм тиз-тиз китеп тә барды.

Моннан соң Алим бөтенләй ашыкмады. Бер кирәк нәрсәсе булмаса да, кибет витриналары каршысында басып торды, җилдән ертылган афишаларны кат-кат укыды. Бакча күләгәсенә кереп утырып карады. Бөтен җирдә, бөтен урам-бакчаларда тормыш дәвам итә, бәбәй арбалары тәгәри, ашханә-кафеләрдә кешеләр тирли-тирли тәмле итеп ашыйлар. Озын күлмәк итәкләре белән урам ташларын себерә-себерә чегән маржалары узып китте, алар челдер-челдер нидер кызып сөйләшәләр. Яшиләр, эшлиләр, кыймылдыйлар, тырышалар... Бакчада утырганда ул чалбар кесәсеннән газетаны тагын тартып чыгарды. Хәрефләрен саный-саный

ижекләп укыды, уйлап утырды, тик юньле генә бер нәтиҗәгә килә алмады. Кая таба авышсан да, кесә буш иде...

Тулай торакның тәрәзәләре киерелеп ачылган. Ап-ак пәрдәләр ялкау гына җилферди, пәрдәләрне кояш кисмәсен өчен пыялаларны иске газеталар белән томалаганнар. Ул бүлмәсенә шома гына узып китмәкче иде, гөнаһ шомлыгы, комендант хатын белән йөзгә-йөз очраштылар.

— Чурашов! — диде комендант хатын. — Сиңа нигә тапкыр кисәтергә кирәк? Эшләмисен дә, чыгып та китмисең. Милициягә җиткергәнне көтәсенме?

— Таисия Павловна, дүрт көнгә түзегез инде! — дип ялынды Алим. — Дүрт көннән соң мине күрмәссез.

— Ну, ну, — диде комендант, егетнең каушавыннан тәм табып.

Алим бүлмәгә керде, тумбочкадан ипи кыерчыгы табып алды, аңа тоз сипте һәм графиндагы җылымса су белән жебетә-жебетә ашарга тотынды. Ипи тиз бетте, су да аз гына калды. Алим ачык тәрәзә төбенә түше белән ятты. Бүлмә өченче катта. Моннан бөтен ишегалды, урамның бер чите күренеп тора диярлек. Күк тә күренә. Күктә яңа туган ай. Торак бүлмәләренең күбесендә ут та яндырмаганнар, димәк, хуҗаларының кеймәсе Алимныкы сыман комга терәлмәгән, кызлар янына да бара алалар, кино, паркларга керәләр. Аның чыгып йөрергә, кеше күзенә күренергә хакы юк: бер урамнан узганда да нигә кредиторын очратты бит ул!

Алим ишек ачкычын борды, ут кабызмыйча гына тәрәзәдән нык сузылып, аскы катка карады. Бер бүлмәдә өч кыз көлешә-көлешә күлмәк кисәләр. Арадан берсе, иң матуры чишенеп ташлады да, күкрәкчәдән генә калып, күлмәк үлчәргә керешге. Алим күзләрен чатырдатып йомса да, кызның кояшта каралган тыгыз тәне, сыгылмалы, нәзек биле, озын, төз аяклары бик озакка кадәр аның күз алдыннан китмәделәр! Ул караватына барып капланды, бераз интегеп яткач, торып магнитофонын кабызды, тавыш көчле яңгырый башлагач, барып кысып куйды. Ут кабызды. Өстәлдә газеталар ята иде. Газета битендә белдерүләр: "Эш тәкъдим итәбез!" "Эшче-слесарьләр кирәк!" "Оргнабор игълан итә..."

"Мин күрсен дип ачып куйганнар!" — дип уйлады егет үртәлеп.

Кесәдәге газета кисәге дә кулга чыкты. Алим, аларның барысын бергә җыештырды да телем-телем умыра-ерта башлады. Кисәкләрне ачык тәрәзәгә ыргытты. Ертык-пыртыклар арган кошлар кебек, салмак кына канат кага-кага төрле якка очып таралдылар. Комендантның усал тавышы яңгырады.

— Кем анда тагын дөнья чүпли?!

Ул тиз генә утны сүндереп тагын караватына барып капланды. Шунда ук ишек шакый да башладылар! Ну бу комендантны! Мондый да җитез, очлы күзле кеше булыр икән! Бер чыгып ычкынса, шушы торак ягына әйләнеп тә карамас иде Алим! Котылсын гына, бу урамнан узмас иде! Күрмәс иде ул аларның тук, канәгать чырайларын! "Ачмыйм!" Ул башыннан ук төренеп, колакларын томалап ятты, шаку аның саен әрсезрәк, көчлерәк була барды. Сикереп барып, ишекне ачып җибәрсә, коридорның сыек яктысында Харис басып тора. Юаш песи сыман, бөкерәйгән, сирәк тешләре ыржайган. Әллә елмая да инде?!

— Ник ачмыйсың?

— Капканны какканда син дә бик очып тормыйсың! — диде һөҗүмгә һөҗүм белән җавап кайтарып Алим. Сагайды. Харисның ниятен сүз башлаганчы ук белеп аласы килде. Гомергә энесе катына аяк басмаган, адресын да юньләп белмәгән кеше, төнгә каршы ишек бавына кагылган икән, "тиккә йөрмәс!"

Бүлмәдәге буш караватларны күрсәтеп, Харис:

— Хуҗалары кайда боларның? — дип сорады.

— Миңа әйтеп йөрмиләр.

— Кая теге газетаңны чыгар әле.

— Ертып ыргыттым.

— Юккарак ашыккансың, юкка.

— Кирәге бетте.

Бер-берсен сынашып, карашып тордылар.

— Әле бая син киттең дә, тынычлык югалды. Күпме бурычым бар дисең?

— Бар булганы үземнеке. Яңадан сиңа ялынып барасым юк.

— Алай кабаланма син, дуамал! Яшь тай гына, чыгымчылап тәртәне сындыра. Сындыра да җилкәсенә камчы ала. Иплэп сөйләш абзаң белән. Туганың бит, бердәнбер якының.

"Кая бора бу, кая?"

Хәзер сак булырга кирәк иде, абзасы буш кул белән йөрмәс! Эшне бозып яки үз файдасына борып җибәрмәсен. Хәзер серен алганчы Алим бер сүз дә әйтмәс! Чыдар, түзәр. Харис кытыршы учы белән күкрәген уа-уа сүзгә керешге.

— Тәмәке аракыдан да кабәхәт нәрсә, беләм. Ничәмә-ничә тапкыр котылырга тырыштым шул нәләттән, булмады. Эчми түзеп була, ә тартуны ташлау юк. Бөтен күзәнәкләрне агулап томалый, явыз!.. Әллә мин әйтәм...

Алар бер-берсенә караштылар һәм Алим үз гомерендә беренче мәртәбә абыйсының ягымлы карашын тойды. Үз итеп, туганнарча җылы итеп карап тора иде карун җан! "Акча исен сизгән!" дип уйлады Алим, алай да сүзне усаллыкка, явызлыкка таба юнәлтмәде, чөнки бар өмете шушы кешедә, абзасында иде. Ул гына коткарса коткара ала аны торткынлыктан! Хурлык базыннан ул гына тартып чыгара ала! Әшәке кеше булса да, явыз булса да, әгәр ул кулын суза икән, шуңа тотыначак Алим. Бүтән чарасы юк. Башка чара калмаган. Бер котылгач, сак булыр Алим, моның ишеләргә кул да бирмәс, сүз дә кушмас, ашаганы аерым, эчкәне читтә булыр!..

— Мондыйрак уйлар төште минем башка, син дә тыңла!

Алим тураебрак утырды, бөтен буыннарына рәхәт кайнарлык йөгерсә дә, аны-моны сиздермәскә тырышты. Абыйсының бөтен планнарны үз файдасына гына борып җибәрүе бар! Сабыр булырга, акыллы һәм сак...

— Син кызык нәрсә уйлап тапкансың, Алим. Сүз дә юк, монда нидер бар!.. Өч йөз егерме кеше тәмәке алып чыгар дип, бая хата әйтеп ташлаганмын! Чыкмыйлар! Хуш, диек, бер өлеше батыраеп алып та чыкты, ди. Ә ярты халык ваемсыз булачак! Гадәт ул безнең — ваемсызлык! "Һәй, бер җае чыкмый калмас әле, ил белән!" диячәкләр! Сәяхәтчеләрнең йөзгә якыны намуслы булачак, тыелган эшкә бөтенләй тотынмаячак! Шуннан артмас! Өчкә берәү намуслы икән, бу бик көчле процент! Инде чынлап торып тәмәкене ташларга ниятләнгәннәре вапще запас турында уйлап та карамаячак. Андыйлар да булыр. Кем ютәлле, күкрәк чире алган, фәлән-фәсмәтән. Тәк. Хуш. Ярый, арада тартырга алып керүчеләр дә очрар, алары да, мин сиңа әйтим, ике-өч пачкадан артыкны алмас. бер-ике көн качып-посып пыскытып ятсыннар, ди. Аннары нәрсә?! Ә-ә, шалкан тавы, суган бавы! Тагын берәрсенең башына килмәс микән андый уй?! Шуны беләсе иде.

— Чокыр авызына килеп абынмасам, минем күнелгә дә андый уй төшми иде! — диде егет бераздан. Алар, киеренке тынлыкта, бер-берсенә карашмаска тырышып, шактый вакыт үткәрделәр. Коридордан кемдер йөгереп узды, гөрләшеп егетләр-кызлар кайтып керде. Бүлмәләр бер мәлгә генә тавыш белән тулды да тагын тынычланды.

— Икәү тотынсак, эшне алып барып чыгарбыз! — диде Харис.

Менә мондый борылышны көтмәгән иде Алим! Ничек икәү?! Әллә абзасының да сәяхәткә чыгып китәргә нияте бармы? Айга якын тәмәкесен тартмыйча түзәргә ризалашып торырмы?!

— Икәү?! — Алим тырышып утырса да, чыдамады, шартлап ярылды. — Тагын мине ярык тагарак янында калдырмакчы буласынмы? Өй саткан акчаны җилгә очырдыңмы?.. Хәзер тагын? Нигә икәү? Миңа кеше кирәкми. Миңа акча кирәк! Мең тәңкә!

— Мондый эшне очлап чыга торган кеше түгел син! Көненә бишкә төрләнәсең! Юньләп кенә кинәшик. Мин дә чыгам. Файда булачакмы әле, юкмы, һәммәсен уртак итәбез. Болай сөйләшик...

Әйе, абыйсы тагын Алимнын бугазыннан алды. Әйе, вакыт кыса, әгәр бүген-иртәгә хәл ителмәсә, егетнең эшкә ашмаган хыялларын төяп кораб дингезгә чыгып китәчәк. Куып тот аннары син аны!.. Башка юл юк, бүтән чара калмаган. Йә муенга элмәк салырга, йә тиз үк акча юнәтергә кирәк! Урлашмаячак Алим... Табар иде, берәү дә төшереп калдырмый... Һәм... жиңелде егет, бирелде, Харис эшнең үз жаена борылганын сизде, энесен авызлыклап, тезгенне кулына алды... Алар мәсьәлә күптән хәл кылынган сыман корабка ничек керү, йөкне нинди әмәлләр белән уздыру турында сөйләшә, уйлаша башладылар.

Алим бик жинел хәл итте:

— Рюкзакка шыплап тутырам да аркага асам! — диде.

— Фу, — диде абыйсы. — Надан шул син! Капчыкка күпме сыя? Мин юл йөреп өйрәнгән. Минем өч чемоданым бар, һәрберсе буаз сыер корсагы хәтле.

— Нигә шул кадәр алырга? — диде Алим куркынып. — Пароходка сыймаслар!

— Егылсаң атның шәбеннән егыл, сөйсәң кызның матурын сөй! — Акча тирәсендә абзасының уе йөгерек, фикере житез икәнен белә иде егет, алай да соңгы сүзләре белән ул аны шаккатырды! Теләсә, йомры сүзләр дә ычкындыргалый икән ул!..

— Зур-зур чемоданнар сөйрәп ничек керербез?

— Китаплар диярсең! Аспирантурада укыйм, — дип шыттырырсың!..

— Китап авыр, ә сигаретлар жип-жиңел! Берәрсе кагылып китсә? Шикләнсә?

— Ай аллам, арага бер-ике кирпеч кыстыр!

— Кирпечен каян аласың?

— Кирпеч тә урлый белмәгәч, ничек тәвәккәлләп шундый эшкә тотынасың? Баткан аяк чыланган! Бер-бер төзелешкә барып кер дә урлап чык! Күрә калсалар, күз яшенне түк: "Әбиемнең билен жылытырга кирпеч кирәк, диген! Кыздырып басарга киңәш итәләр, диген! Эшең бетте, кодагый! Хак әйттең, китап икән, чемоданың саллы булсын. Черки дә ботын тыгарлык итмә! Молодец! Шушы сәгатьтән хәйлә капчыгыңны үзеңнән калдырма!..

Ул абыйсын озатырга чыкканда ай урагы эреп югалган, офыклар каралып куерган, диңгез ягыннан дымлы, рәхәт жил исеп тора, йорт каршындагы бакчада кеше калмаган диярлек, тулай торак тәрәзәләреннән күпчелегендә утлар сүнгән иде. Кергәндә комендант тагын Алимны күрде, аны-моны кисәтеп маташмады, башын чайкап, егетне яратмавын гына сиздереп алды. "Дөрес яшәмисең, егет!" дия кебек иде аның чәнечкеле карашы. Тик егетнең жавап карашында нинди гамьнәр барлыгын бүген абайлый алдымы икән тәжрибәле комендант? юктыр, аңлап ук бетерә алмагандыр. "Дөресме-түгелме, озакламам, тиздән сезнең барыгыздан да котылырмын!" Шулай уйлады Алим, шушы уеннан башы югары күтәрелде, аяк атлавы үзгәрде. Ул тагын иртәнге Алим, кояш нурлары күмеп киткән урамны иңләп, жил юк жирдә жил котыртып баручы көчле егет иде! Бер атлады, ике сикерде, өченче катка менеп житте, ачык тәрәзәдән баягы бүлмәгә сузылып карады. Ут сүнмәгән булса, бу юлы кызларга эндәшмичә калмый иде ул! Сүзен дә табар иде, көлеп жибәрер иде... Тик кызлар бүлмәсенең тәрәзәсеннән дә тыныч караңгылык бөркелеп тора иде. Алай да егетнең нидер эшлисе килде. Сөенечен эчендә генә калдырасы килмәде. Ул караватка атылды, аунады, мәтәлчек ата-ата иләндә аунады. "Озакламам! Котылам! Әр сүзләреннән котылам! Кырын карашлардан котылам! Бурычлардан котылам! Яңача, бөтенләй башка төсле яши башлыйм!"

Күр инде син аны, үзе белән үзе сөйләшәм дигәне —дөньяны шаулатып кычкыра икән ләбаса! Күрше ишекләр ачылды, аннан йокылы

егетләр килеп чыкты, алар шикләнеп Алимга төртеп күрсәтә-күрсәтә:

— Ни булган аңа?

— Әллә саташып уянганмы? — дип сораштыра башладылар.

— Акылдан шашкан! — диде егетләрнең берсе.

— Тилергән! — дип җөпләде икенчесе.

Алим караватыннан мендәр алып аларга тондырды:

— Кем шашкан? Кем тилергән? Минме?! Ярый. Күрербез әле! Сезнең эше тиләләрне җүләргә калдыруым турында ишетерсез! Мин сезгә һәм сезнең ишеләргә сугыш игълан итәм! Бүгеннән башлап мин барыгыз белән дә сугыш халәтендә! Мине яратмаганыгыз өчен дә яратмыйм мин сезне!..

Һәм ул ике-өч сикереп аскы катка төште, җилфердәп урамга чыгып китте. Бүген ул гомуми торакның бер бүлмәсенә генә түгел, торакның үзенә дә, ул урнашкан урамга да, бөтен бер шәһәргә дә сыймый иде. Күнеле белән диңгездә, корабта иде инде. Анда, ниһаять, тоташ җиңү мизгелләре башланачак! Муенына асылынган бурычлардан котылса, бөтенесе үзгәрәчәк. Дөньяга да карашы бүтән булачак, кешеләргә дә, яшәешкә дә, кызларга да, дусларга да. Әлегә бурычлардан башка бер ние, бер кеме юк бит аның! Бер кеме!..

Иртәгесен алар профсоюзларның өлкә советы бинасы янында — Хезмәт сарае ишеге төбендә очраштылар. Харис сабырсызланып аны көтә иде инде. Путевкаларга дигән акча бер кулдан икенче кулга күчте, Харис монда этлеген онытмады:

— Кара аны, акчаларны чәлдереп тая күрмә. Исән кабырганны калдырмам! — диде.

— Шушы вак-төяк белән пычранып тораммы? Миңа күп кирәк, бик күп. Һәм мин аны тәмәкече җүләрләрдән каерып алачакмын. Каерып!

Ул йөгереп диярлек өскә менеп китте һәм икенче каттагы 32 нче бүлмәне бик тиз эзләп тапты. Шакыды, эчкә узды, бүлмә буш, иркен, өстәл артында ак чәчен баш түбәсенә төяп куйган ягымлы гына бер әби утыра. Кәгазьләр караштыра. Башка җан иясе дә, чират та юк. Бу Алимны бераз шикләндерде.

— Белдерү буенча килдегез алайса? — диде әби. — Бик яхшы буласы икән дә... Шундый яшь кешенең явыз тәмәкедән ваз кичәргә теләгене бары тик хупларга гына кирәк тә... Соңгарак калдыгыз! Путевкалар бетте. Соңгысын кичә тутырып җибәрдек.

Алимның өстенә салкын су койдылармыни, ул башта әбинең ни әйткәнен аңламыйча торды, сүзенең мәгънәсе аңына барып ирешкәч, чак кына кычкырып җибәрмәде. Кикриге шиңде егетнең!

— Ничек? — диде ул кан калтырап. — Ә без абый белән...

— Бертуган абыегызмы?

— Әйе. Искиткеч гүзәл кеше. Гомере буе тәмәке уба. Башка яклары әйбәт, тарта менә! Котылырга дигән идек...

— Нинди гүзәл буласы икән! Мондый тәҗрибә беренче мәртәбә үткәрелә. Тәмәкенең зарары хакында врачлар такылдаган сүзләрнең файдасы — нул! Халык ышанмый аларга! Абыегыз белән бергә! Нинди гүзәл тәҗрибә буласы икән!

Әбекәйнең теле сүзгә зарыккан, ә Алимның башында бер генә уй: нишләргә хәзер? Төнлә, йокысыз узган төндә корган матур планнар чәлпәрәмә килде! Ничек элегрәк күрмәде соң ул белдерүне Алим!? Күргәч, билет артыннан ник торып чапмады икән?! Әйе, әйе, иптәшләре газетадагы белдерүләрне ул күрсен дип юри ачып куялар иде... Ул карап тормыйча аларны ерткалап ыргыта иде. Гарьләнә иде егет! Көн саен, атна саен яңа эшчеләр сорап белдерүләр, вәгъдәләр басыла тора, ә ул, байгыш, һаман төпле урын таба алмый. Болай барса, табачак та түгел, ахрысы?! Нишләргә?!

Чү, юлны Харис абыйсы үзе әйтеп бирде түгелме? Ул хәзер парадный ишеге катында көтеп тора... Башка ишекләр юк микәнни монда? Шыпырт кына чыгарга да, син күр дә, мин күр, таярга! Кулда азмы-күпме акча

барында башка шәһәргә ычкынырга! Беразга күздән югалырга, ныклы тормыш башлап җибәрергә, аннары гына, акча туплагач, монда кайтып керергә... Башка юл юк! Качарга, таярга, эз югалтырга! Төнлә иптәшләре алдында артыгын кыланды шул, теле авызына сыймады!.. Ул әбигә карап ясалма, таш елмаю белән авызын ерып артка чигенә башлады, бер адым, ике, бардыр монда арткы ишек! Черный ход! Мондый зур бинада бер генә ишек булмас!

Сискәндереп, аның соңгы котын алып телефон шалтырады. Әби, үз яшенә караганда аерым бер җитезлек белән трубкага тотынды, аның ни сөйләшкәнен Алим аңламады, ишеккә аркасы белән терәлгәч кенә, күзен күтәреп карады. Карчык буш кулы белән аңа чыгып китмәскә ишарәли иде...

— Бәхетегез бар икән, — диде әби, трубкасын куя-куя. — Сиксән өченче каютаны "гаилә экипажына" ир белән хатынга биргән идек, "чыга алмыйбыз!" дип шалтыраталар. Путевка сезнеке!

Алим сикереп өстәл янына барып җитте. Карчыкның арык, зәгыйфь кулын тотып алды, селкә, рәхмәт укый башлады.

— Хәзер беренче катка төшеп акча түләгез, мин шалтырата торам, аннары путевкаларны алырга минем янга менәрсез. Сиксән өченче каюта! Онытмагыз!

— Онытмам, — диде Алим, маңгаена йөгергән салкын тирне сөртеп. Тагын бер минуттан ул карак иде! Абзасының акчасын әлдереп арт ишектән чыгып таячак иде. Коткарды аны телефон! — Онытаммы соң? Миңа нинди яхшылык эшләгәнегезне бәяләмисез, әбекәй, бәяләмисез әле сез! Рәхмәт!

Абыйсын белми икән әле Алим. Ычкынырсың аннан, бар, әнә ул, беренче кат белән икенче кат арасына ук менеп җиткән, дымланган сигаретын чәйни-чәйни сабырсызланып аны көтеп тора иде. Ул бер сүз әйтеп, төшендереп тормады, төтәп торган юеш сигаретны энесенең ирен арасына китереп тыкты.

— Нишлисең? — диде Алим җирәнеп.

— Онытма, син хәзер ата тәмәкече. Монда һәм алда очраган һәр кеше синең кемлегеңне хәтерләп калырга тиеш. Хәтәр эшкә алынуыңны онытма. Һәммәсе ныклы тәртиптә булсын.

Касса тәрәзәчеге алдына әле генә "ата тәмәкече" дәрәҗәсен алган Алим килеп басты. Күнекмәгәнгә сигаретын еш-еш суырды, чәчәде, йөткерде, күзеннән яшь чәчрәп чыкты.

— Япь-яшь кеше! — дип сукранды күзләрен сөртә-сөртә кассир хатын. — Күксәүгә әйләнеп беткән! Мине дә агулап үтерергә маташа! Каһәр суккан тәмәкечеләр! Ник берсе буш авыз белән килсен! Килгәненең берсенең авызында beләк буе сигарет!

Бу сүзләрдән Алимның хәтерендә "мине дә агулап үтерергә маташа", дигәне генә сеңеп калды. "Чыннан да тәмәке агу да бит әле!" дип уйлады ул пошынып. Тик бу уйны бик тиз онытты, акча түләнде, квитанция кулда иде, путевканы алып, әбинең арык, җыерчыклы кулын тагын бер тапкыр кысу өчен бер-ике минут вакыт җитте.

Харис путевкаларны иснәп, тәрәзә янына алып килеп кояшта тотып карады.

— Булды, — диде Алим.

— Булырга иртәрәк. "Башланды", диген.

Юл уңаеннан алар бер кибетне дә калдырмыйча кагылып чыктылар. Блок-блок сигаретларны Харис абыйсы алдан ук чамалап тотып чыккан капчыкка тутырдылар.

Өйгә кайтып җитеп абыйсының өч чемоданын күргәч, Алим сызгырып җибәрде.

— Боларга бер тонна сыйдырып була ич!

— Ә син ни дип уйлаган идең? Кайсы төшең белән? Баерга икән, баерга! — диде Харис.

"Иң мөһиме синнән котылырга кирәк!" дип уйлады Алим.

Өч көн вакыт калган иде. Әзерләнергә кирәк! Харисларга иң якыны кичә иртән Алим күзәтеп узган тәмәке ларегы. Кыз шул ук. Җитез, сылу, Алимны хәтерләп калган икән. Белә. Башка кибетләргә, буфетларга, ларекларга, урамдагы "кырык тартмачыларга" да кагыла Алим, бәяләрне белешә, чутлап карый, кыз янына ларекка да бара.

Башкалар бер дә гаҗәпләнмиләр иде, күпме сораса да, сүзсез чыгарып бирәләр, акчаңны гына түлә! Кыз сәерсенде:

— Тәмәкене ашыйсызмы әллә сез? — дип сорады.

Алим аныклап җавап бирмәде, алай да кызарынды һәм сүзсезлеге белән кызның игътибарын гына арттырды. "Егетнең мине ешрак күрәсе килә, шуның өчен монда йөри, кирәкле-кирәкмәскә дә сатып ала", дип ышанып уйлады кыз.

"Кыюсыз икән, бичара!" дип уйлады ул тагын, "әгәр кыюрак булып танца кичәсенә чакырса, бер дә карышып тормас идем!"

Төзелешкә кереп кирпеч тә алып чыкты Алим.

Иң аска Харис кирпечләрне урнаштырды, аннан иплән, тыгызлап сигарет блокларын тутырды. Чемоданнарны бикләп, бәйләп, идәнгә тезеп куйгач, ул канәгатьләнеп, кулын уа-уа әйләнеп-әйләнеп йөреп алды, тонык, җансыз тавыш белән җыр мөгрәргә дә маташты.

Алим гына тынычсыз иде! Китәр минутлар якынлашкан саен аның күңелендә ниндидер яңа уйлар, моңарчы татымаган хәвефләр арта бара иде. Әгәр уйлаганнары барып чыкмаса? Әгәр Алим абыйсы белән әдәм көлкесенә калса? Хур итеп корабтан куып чыгарсалар аларны?.. Тик әзерләнәсе әзерләнгән, чемоданнар тутырылган, сиксән өченче каютага дигән путевкалар кесәдә иде. Баш тартырга да, чигенергә дә, уйларны үзгәртергә дә мөмкин түгел иде инде... "Тәвәккәлләгән таш йоткан!" дип юатты ул үз-үзен... Тулай торактан бөтенләйгә чыгып китте ул, иптәшләре белән саубуллашмады, алар эштә чакта, аулакта гына, җиңел чемоданын селкә-селкә, болай, йөрергә генә чыккан кеше кыяфәтендә чыгып тайды. Китәсе көнгә каршы төнне ул абыйларында кунды. Йоклый алмады, бик еш ишегалдына "җилгә" чыгып керде, ничә караса да абыйсының бөкрәеп өстәл янында утырганын күрде. Утыра Харис, кулындагы шәмәхә карандаш белән чите китек дәфтәргә үзе генә серен белерлек саннар яза, чутлый, маңгаен җыерып, караңгы тәрәзәгә текәлеп карап тора... Хатыны агач караватны шыгырдатып боргалана, уфылдый. Аның да йокысы качкан...

Санаулы минутлар тиз уза!

Бүген аларның юлга чыгасы көннәре!

Ничек булыр, ничек узарлар, ничек урнашырлар? Абыйсы:

— Кеше җыелып кайнап торган чакка гына барыйк, — дисә дә, Алим аяк терәп каршы төште:

— Нигә кеше күзенә чалынып йөрергә? Алдан ук портка төшик тә, кеше-кара күргәләгәнче каютага кереп утырыйк, —диде.

— Кемнән куркасың син? Куркуны оныт. Акча куркакларны яратмый.

— Әле юлга чыкмаган, кереп утырмаган, без ызгыша да башладык, — дип карышты Алим.

— Тыңла мине! Мине тыңласаң, югалмассың!

Теплоход кузгалырга өч көн калды дигәндә бу моңарчы күрелмәгән "тәҗрибә-сәяхәт" турында бөтен шәһәр сөйли иде инде. Кайберәүләр көлде: "Кая ул, тартуын кем алай итеп ташлый алсын?" — дип шик белдерде. Берәүләр: "Шәп нәрсә уйлап тапканнар, валлаһи! Үзем утырып чыгып, шул җәфадан котылыр идем!" — дип мактады. Теплоход китәсе көнне порт тирәсендә кара болыт кебек халык иде. Китүчеләргә караганда озатучылар күбрәк монда. Алимнын шик-шөбһәләре юкка булган, монда ата — улны, ана кызны белерлек түгел, беркем аларның чемоданнарына да, машинадан төшкәч, мышный-мышный күтәреп килүләренә дә игътибар итмәде.

* * *

Яңа көн. Яңа адым. Яңа шартлар. Алар Алимнан яңа кеше ясарга тиешләр. Әлбәттә, тормышның бөлгенлеккә ябышып торган ныклы бер бөжрасын өзеп ташларга ярдәмгә комсыз һәм әрсез абыеңны чакыру яхшы түгел, тик нишләмәк кирәк?! "Нигә урыннарны аерым алмадык икән, төрле каюталарга?" дип тә уйлап интекте Алим, тик Хезмәт сараенда әби авызыннан яңгыраган "сиксән өченче каюта!" сүзе ул минутта исакылны алган, барын да оныттырган иде.

Икәүләшеп өч чемодан сөйрәп халык арасына килеп кергәч, егет үзенә күрә бер юаныч та тапты. "Бер башың мондый йөк белән ничек әрсезләнеп йөрер идең? Ике кешегә ярый икән!" дип, юанып уйлады.

Юлга чыгар алдыннан кеше иң элек теплоходның исеменә күз төшерер иде, дингезнең тынычмы-түгелме икәнлеге белән кызыксыныр иде. Алим боларның берсенә дә дикъкать итмәде. Ул иң элек җыелган халыкның багажына игътибар итте. Нинди генә чемоданнар, рюкзаклар, сумкалар, дипломнар, бауллар, саквояжлар юк иде монда! Киенгән киемнәре бер төслерәк булса да, кулга тоткан нәмәрсәләре төрле-төрле иде юлаучыларның. Шиккә төшерерлек, сигарет тутырылган булырлык бер генә зур тартма да, чемодан да юк иде арада! Ул кызыксынып китеп, абыйсын да, чемоданнарын да онытты, төркемнән-төркемгә күчеп йөри башлады, кешеләрнең ни сөйләшүләренә колак салды.

Шактый була икән ул өч йөз егерме пассажир! Озатучылар белән бергә кушкач, бөтен шәһәр купкан кебек! Һәм шушы җанлы, хәрәкәтчән, сүзчән толпа өстендә куе болыт булып зәп-зәңгәр төтен бөркелә иде. Сигаретлар чытырдап яна, папирослар зәһәр ачы төтен тараталар, кәкрәеп-бөкрәеп беткән кара саплы челемнәр чыжылдый, беркемнең дә авызы буш түгел, беркемнең дә авызы-теле тик тормый. "Соңгы тапкыр" диядия, сүнеп-янып бетмәгән сигареттан яңага ут элдерәләр, "минем шәбрәк, минекен тартып кал!" — дип юмартланып, бер-берсен сыйлыйлар. Әллә нинди бизәкләр белән чуарлап эшләнгән зажигалкалар рәт буйлап йөри, сокланалар, тел шартлаталар. Тирә-юньдә төтен, озатырга төшкән хатыннар төчкерәләр, диңгез буена ук барып, парапетка түш белән ятып укшучылар да бар. Ике палубалы теплоход та тәмәке тарта: аның торбасыннан да сыек кына төтен чыгып бетерелә.

Алим булачак **к л и е н т л а р ы н** аралап йөри башлады.

Кызыл сакаллы, урта яшьләрдәге пеләшне биш кыз (үз кызлары булса кирәк) озата. Пеләш туктаусыз сигарет суыра, йотылып-йотылып төтен эчә, йонлы борын тишекләреннән өрөзлексез төтен уйнап чыгып тора. Кызлары шаккатып аңа карап торалар, күзләреннән яшь акса да, читкәрәк тартылырга базмыйлар. Алим алар янында тукталып калды. Кызыл сакал аңа шикләнеп карады. "Артык яшь! Тәмәкечегә охшамаган!"

— Сез дә шушы тагаракка язылдыгызмы? — диде сакал.

— Туры килде инде.

— Үзегез теләпме?

— Әлбәттә!

Сакал Алимга сигарет сузды, ул алам дигәндә, чак кына төшереп җибәрмәде, кызлар бер-берсенә карашып аннан көлешеп алдылар.

— Рәхәтләнеп кал! Көйрәт берне! Өйдә чакта көненә өчәр кап тарта идем.

— Өйне сасытып бетерде, — диде өлкән кыз.

— Гөлләребез корыды!

— Ике тапкыр ут чыгарды!

— Өебездә төтенгә песи тормый!

— Ә без чыдарга мәҗбүр!

— Әле ярый сез алтау гына, — диде кызыл сакал, — унау булсагыз мине тотып ашар идегез...

Алимның тәмәке тартканы юк иде элек, ничектер котырып китеп

авызына алгалап шаярмады да, беренче мәртәбә ирене сигарет белән Хезмәт сараенда очрашты. Алай-болай иптәшләре үртәп ана сигарет каптырганда да суырмыйча төкереп ташлый торган иде. Монда чынлап торып пуфылдатырга туры килде! Кызыл сакал аның беренче клиенты булырга тиеш! Кыяфәтенә караганда шактый ашлы-сулы тормышта яшәгәне күренеп тора, әллә ниләр тутырган күн дипломат янында ике баул таралып ята, кыйммәтле йон күлмәге якасыннан бөдрә йонлы күкрәге күренеп тора. Шыплап ниләрдер тутырганнар! Ул ялгыш кына аягы белән тиеп китеп баулның берсен аударды да, иелеп тотып карады. Юк, сигарет юк монда! Икәүләшеп төтен тараталар иде, кызлар кулларын бутап читкәрәк тартылдылар.

— Исе зәһәр!

— Бугазны кыса! — диештеләр алар.

Кызыл сакал аларга күз йөгертеп чыкты.

— Син тәмәкеннән котылып кайт инде, Павлуша, — диде кызларына бик охшаган хатын.

— Юкса өйгә кертмибез! — диделәр кызлар беравыздан.

— Шулар аркасында юлга чыгам, — диде кызыл сакал. — Синең тартуың аркасында кияүгә чыга алмыйбыз, диләр!

Икенче төркемдә ирләр генә. Чырайлары сытык, кашлары җимерелгән, яңаклар суырылып эчкә баткан, бармаклар саргаеп каткан, күзләрдә нур калмаган. Сүзсез генә күзләрен җиргә терәп, командага буйсынган солдатлар кебек нәкъ бер мизгелдә дүртесе дә суыралар. Алим да алар күрсен өчен сакалдан элдергән сигаретын бармак арасыннан күрсәтә-күрсәтә кат-кат суыра. Дүртнең берсе дингезгә ишарәләп:

— Эләктенме йөзмә төрмәгә? — дип сорады.

— Ә сез?

— Безне профсоюз җибәрә. Дүртебез дә бер бригададан! Эксперимент! Монарчы маймыллар, бакалар гына, ара-тирә этләр тәҗрибә корбаны була иде, хәзер безгә ябыштылар. "Тәмәке тартып күпме вакыт уздырасыз да, сезгә ел дәвамында күпме больничный түлибез!" ди бригадир. Ә хәзер әллә кая сикерә алмыйсың! Бөтен җирдә подряд белән куалар!.. Түзелештә эшли идек. Ял бирделәр, көчләп.

Калганнар дәшмәделәр. Муеннар тагын да түбәнрәк бөгелде. Боларның сумка-капчыклары юк дәрәҗәсендә, юынырга-кырынырга алганнар да тынычланганнар. "Әһә, болар Харис абый әйткән ваемсызлар төркеменнән! Бер-бер җае чыгар әле, дип язмышка ышанып, аллага тапшырып юлга чыкканнар!" дип көлемсерәп уйлады Алим. Тик боларның акча ягы да әлләкем түгелдер, болар аның **клиентлары** була алырлармы, юкмы? "Вот в чем вопрос!"

Дүрт кеше исеменнән сөйләгән оратор тагын ниләр өстәр иде, төркем янына чәчен бер якка яткырып тараган, шома гына, елгыр гына ир уртасы килеп житте. Ул олы полиэтилен капчык белән көнбагыш тоткан иде.

— Җыелдыгызмы, егетләр? — диде ул.

Җавап урынына дүрт авыздан көрсенү генә чыкты.

— Дүртебез дә монда, — диде баягы сүзчән.

— Иптәшләр, мин сездән үтенеп сорыйм. Дүртәү икәнсез, берберегезгә ярдәм итегез. Аннары юк-бар шөгыль, карта уйнап, бригаданың данын сатып кайтмагыз. Анда сезне күзәтүчеләр булыр. Хезмәт сараеннан да баралар. Врачлар да, хәтта психиатр-гипнозчы да бара икән! Иван Семенович, син арада олырак кеше. Син нгытып кара, ярыйммы.

— Кәрт тә сукмагач, вакытны ничек уздырырбыз без анда?

— Суга чумып үләрбез! — диде икенче берсе, күзен читкә борып. — Чыдарың калмас монда!

— Газета-журналлар, бассейн... Син, Иван Семенович, начар йөзәсең, нгытып өйрәнеп кайт. Базардан көнбагышның иң шәбен сайлап алдым.

Шәхси бүләгем! Телегез кычыта башласа, чиртерсез. Анда да каютада чакта гына. Палубада ни, ни!

Тора-бара квартетның кырыслыгы кимеде, бригадирны яраталар иде, ахрысы, ул үгетләгән саен, йөзләренә тынычлык йөгерде, аларга бигрәк тә "гипноз" дигән сүз ошады. "Алайса барып чыга икән, тәмәке явыздан котылырбыз, иншалла!" —диештеләр алар. "Син, Сережа, тыныч бул. Сынатмабыз! Безнең хакта начар сүз ишетмәссең!" — диде Иван Семенович дигәннәре.

Алимга исә "гипноз" сүзе бер дә ошамады. Каушатты ул аны! Уйлаган планнары барып чыкмас кебек тоелды. Моннан берничә ай элек Мәскәүдән гипнотизер килгән иде. Сәхнә тутырып кеше җыйды да өч-дүрт җөмлә әйтүгә тегеләр җебеп төштеләр! Тәгәрәп йокыга талдылар, бала-чага булып су чәчрәттеләр. Ике ир, үзләрен мунчада дип белеп, халык күз алдында чишенә үк башладылар. Гипнотизер, кая кадәр чишендергән булыр иде, берсенең трусигы умырылган икәнне күрүгә, мунча чабынуны туктатты... Рухын ала кешенең гипноз, ихтыяр көчен! Ала да үзе теләгән якка каратып ныгыта. Ә хәзергә ихтыяр көче — тәмәкедә. Тәмәке җиңүче, ул шушы өч йөздән артык кешенең язмышына уралган, аннан котылмак юк... Юлга чыкканнарның һәммәсе дә бу яман чирдән котыла алмас, алай да гипноз үзенекен эшләр, ташлатыр, аерыр кайберәүләрне яман гадәтләреннән!

Ялгыз-ялгыз гына басып торучылар да шактый, аларны озатучылар да юк, болары башка шәһәрләрдән килгән кешеләр, чит төбәкләрдән. Алар да кеше күплегеннән, булачак сәфәрнең серле булуыннан аңгыраеп, югалып калганнар. бер-берсенә якын килергә дә,сүз катарга да кыймыйча торалар. "Боларны бөгү җиңел булыр! Болары минеке!" дип уйлады явызланып Алим. Күзәткән саен, йөри-йөри кыюланып китеп, аларның торышларына, йөзләренә карап, ул аларның бу юлга җиңел генә чыкмаганнарын да чамалады. Байтагысы мәҗбүр иткәнгә бу сәфәргә тәвәккәлләгән икән! Ул батырланып, берәүдән:

— Сезне ни-нәрсә мәҗбүр итте бу юлга чыгарга? — дип сорады.

Теге кешенең авызы сөйләшүне сагынган икән, зур теләк белән тырышып аңлатып бирде:

— Ике ел элек хатыным вафат булган иде. Ялгызым яшим. Бала әбиләрдә. Әле ярый ул бар! Күрше йортта гына илле бер тол хатын бар! Шуларның берсенә башта күз салдым, аннары сүз. "Өйләнешик!" — дим. Риза! Тик бер шарты бар: "Тәмәкеңне ташла", — ди. Мин дә ташларга риза!.. Әллә ничә тапкыр ташлап карадым. Үлгән хатыным искә төште исә... кул үзеннән үзе сигаретка үрелә. Менә газетадан шушы хәбәрне укыгач, Нюрага күрсәттем... "Кызыңны алып калам, өеңне карыйм, зинһар, шул агудан котылып кайт!" — ди. Озата да килмәкче иде, каршыларга да килсәң, ике якка акча күп чыга дип, рөхсәт итмәдем...

Алим тизрәк бу кеше яныннан китүне карады. "Юк, моны клиент итеп сайларга ярамый! Киресенчә, моңа ничектер ярдәм кирәк!.. Котылсын иде яман гадәтеннән. Баласын ятим итмәсен иде!" — дип уйлады. Үзе бик яшьли әтисез калып, ныклап аякка басканчы әнисен дә җирләгән булганга, ул бу кешене ифрат нык кызганды.

Кеше дә, беренче очраган юлдашына, рыясыз рәвештә эч серен ачты да салды...

Кемнәр көлә, кемнәр шаяра, кемнәр җырлый иде. Җылаучылар да бар. Кемдер: "Әй, тәмәке, хуш тәмәке, җан ашым!" — дигән кебегрәк такмаклар да әйтә. Бер читтә шешә ялтырап китте, кырлы стакан кулдан-кулга кыйммәтле таш кебек елтырап йөри иде.

Ниһаять, китүчеләр калучылардан гөүлдәп аерыла башладылар. Алимның төркемнән-төркемгә чабып диярлек йөрүен, кемнәргәдер сүз эндәшүен күргәннәр икән, күргәннәр дә игътибар иткәннәр. Егерме яшьләрдәге бер кыз нәкъ каршысына килеп чыккач, Алим да тукталып калды. Кыз да туктады. Кызның да төркемнән-төркемгә йөргәнен күреп,

чамалап куйган иде инде үтә нык сизгерләнгән Алим. Хәзер кызның чыраена текәлеп карады. Аның пудраланган килешле борынын вак кына тир бөрчекләре каплаган, тик бу хәл аны ямьсезләтмәгән, киресенчә, кыяфәтенә, тотышына, эшлекле, ягымлы төс чыгарган иде.

— Сез газетадан түгелме? — дип сорады кыз, кыю гына. Аның тавышы да үзе шикелле үк ягымлы иде.

— Ә үзегез кем буласыз?

— Мин культура институты студенткасы.

— Озатасызмы?

— Юк. Мин шушы рейста хор оештырырга алынган кеше.

— Алайса бергә йөзәбез икән.

— Сез? Кем сыйфатында?

— Сезнең тугры клиентыгыз.

"Клиент" сүзе Алимга ошый да башлаган иде инде. Ул кыланып башын түбән иде.

— Бер дә үҗәт тәмәкечегә охшамагансыз.

— Тартам! Убам гына. Төннәрен йокысыз тартып интегәм.

— Ташларга карар итеп яхшы эшләгәнсез, — диде кыз, үзенең житди вазифасын искә төшереп һәм чая гына кулын сузды. — Рита минем исемем.

Кыз кулыннан егет тәненә серле рәхәт йөгерде:

— Ә безне Алим дип йөртәләр.

— Алим? Ә русча ничек?

— Русча да Алим.

— Гаҗәп исем.

— Гаҗәп кешеләр өлешенә гел гаҗәп исемнәр табылган.

Алим кызлар янында аз-маз мактанып алырга да күп сорамый!

Алар халык агымы ихтыярына буйсынып, теплоходка якынрак килделәр. Алим абыйсының ярсып кулларын бутавын күреп торса да, агым көченә каршы тора алмады, ташкын аларны кыз белән икесен бергә китереп кысты.

— Хорда җырларга килегез. Сезне күргәч, сөендем әле. Яшьләр дә бар икән!

— Ай-яй, вакыт табылырмы икән!

— Көне-төне йокларгамы ният?

— Киресенчә, бер дә йокламаска!

— Ничек?

— Читтән торып укыйм, студент!

— Менә ничек! — Кызның сөенүенә ачыктан-ачык кызыксыну да өстәлде. Ул бу рейска бик каушап чыга иде. Беренче мәртәбә, гадәти булмаган шартларда, укытучы-киңәшчеләреннән башка ул хор оештырырга тиеш! "Житмәсә, катлаулы контингент!" — дип кисәттеләр аңа Хезмәт сараенда.Ританы бу эшкә туганнан туган абыйсы, врач психиатр котыртты. "Ял итәрсең. Ашау бушлай. Житмәсә, өстәмә түләячәкләр дә. Тормыш мәктәбе дә узарсың", — диде ул.

Акчага хирыслыгы юк иде югын кызның, аны бигрәк "тормыш мәктәбе узарсың" дигән сүз тартты. Тагын бер елдан ул завод культура сараенда эшли башларга тиеш. Шефлык иткәндә аны бик яратып калдылар да, тәмамларга бер ел вакыт калса да, институттаРитаны эшкә чакыру кәгазе ята инде...

Сәфәр үзе өчен дә, эше өчен дә ныклы сынау булачак! Ул төркемнән-төркемгә курка-курка гына йөрде. Саубуллашу, хушлашу вакытында кешеләр бик каты кычкырып сөйләшкәнгә бик күпләрнең сере аңа да ачылды. Алим шикелле үк ул да Кызыл сакалны күрде. Квартетның өлкәне Иван Семенович Велягурскийны ул Хезмәт сараеннан ук белеп калган иде. Бригада исеменнән озаталар! Йомыкый ирнең моңсу күзләрен ул да абайлады, барып сорашырга гына кыймады. Йөргән саен, үзенең булачак **ж ы р ч ы — х о р и с т л а р ы н** күз алдына китергән саен аның

эченә суык пошаман төште. "Болар белән мин нишләрмен? Ничек оештырырмын? Тәмам әдәм көлкесенә калып кайтсам, алдагы эш перспективама зыян килмәсме?!"

Яшь, таза, күрер күзгә чибәр егет Алимның арада булуы, аның читтән торып укуы... Ул ни ашыкса да, егеттән тиз генә аерылып китә алмады. Алим белән бергә Харис янына ук барып чыктылар.

— Кайда йөрисең син? — диде Харис гадәтенчә җимерелеп.

— Менә Рита белән таныштык.

— Өлгермәс идеңме?

Бер чемоданга Харис үзе ябышты, икенчесен Алим алды, Рита да өченчегә тотынып караган иде, бөгелеп кире җиргә куйды.

— Китаплар, — дип аңлатты, маңгаен ышкып Харис, һәм энесенә усал гына карап алды. — Йөри җүләрләнеп, рәхәтләнеп ял итәсе урынга!..

— Ә сезнең әйберләр кайда? — дип кызыксынды Харис, бераз атлагач. Ул ике чемоданны элдереп бөгелә-сыгыла атлый, кешеләрне тупас аралый иде.

— Безнең багаж күптән каютада инде, — дип аңлатты кыз.

— Аның абзасы врач-психиатр! Гипноз остасы! — дип аңлатты Алим.

Трапка атлаганда документ-фәлән дә тикшермәделәр, кәгазьләргә, гомумән, күз салмадылар, яшьрәк кенә бер матрос: "Ничәнче каютага?" — дип сорады да, кулындагы катыргага билге ясады. "Сиксән өченче."Ританың озын сыйракларына күз төшереп өлгерде дә, телен тегермәнгә әвереллдереп, җорлана ук башлады.

— Тәмәке, шырпы, сигара-сигарет ише куркыныч матдәләрне алып кермисезме, туташ? — диде. — Шартлау куркынычы булган суднога аяк басасыз!

— Безнең арада андый җүләр юк дип беләм. — Харис як-ягына каранды. — Юктыр, дип ышанам!

Керүчеләрнең кайберләре матросның уйнап әйткән сүзен чынга алдылар, ахрысы, кемдер ике кулын, әйбере-ние белән өскә күтәрде, берәүләр чалбар кесәләренә шап-шоп суккалап, үзләренең "буш кул" белән керүләрен аңлаттылар. Кемдер трап янына ук килеп җитеп, сигаретын сүндерде дә, озата килүчеләргә ыргытты:

— Истәлегем! Сувенир! Үлә-нитә калсам, "Тәмәке музее"на куярсыз.

— Шундый музей да бармыни?

— Без тартуны ташлагач, сез тартуны ташлагач, кем тартыр, тәмәке музейларда гына калачак!

— Ишек катына Христофор Колумбның сынын бастырып куячаклар. Европага тәмәкене алып кайткан кеше ул!..

— Россиядә Петр Беренче законлаштыра аны...

— "Ташлагач?" Әле аңа кадәр...

— Швециядә ил белән ташларга җыеналар, ди.

Алимны тагын бер нәрсә гаҗәпләндерде: пассажирлар арасында хатын-кызлар шактый иде. Шулай күпме алар арасында тәмәкечеләр? Әллә путевка җайга килеп, ихтыяри-мәҗбүри генә утырганнармы? Арада урта яшьләрдәге, күрер күзгә ягымлы хатыннар да байтак иде. Сәяхәт күңелле булачак!.. Аспирант булып, күзләренә төтен җибәреп йөрер көннәр киләчәк әле!

Өстә, капитан күперчеге янындагы төркем дә утырышу ыгы-зыгысын тамаша итеп тора. Башка вакытта команда пассажирларга болай игътибар итеп тормый иде. Капитан үзе, ярдәмчеләре, боцман, беренче матрос, үз күргәннәреннән нәтиҗә чыгарып та куялар.

— Бәлтерәеп беткән картлар да бар! Үлгәнче рәхәтләнеп тартасы инде!

— Кайчан котылсаң да соң түгел!

Капитан җыелганнарга соңгы кисәтүне ясауны тиеш тапты:

— Эш болайрак, иптәшләр. Безнең бу рейсның катлаулы һәм

эксперименталь төстә икәнен барыбыз да хәтердә тотыйк. Пассажирлар арасында тартмагыз, тәмәке турында сүз кузгатмагыз. Үтенеп сорасалар да, тәмәке табышмагыз. Безгә җаваплы һәм почетлы бурыч йөкләнә. Тәмәке тарту... — Капитан боцманның каралып беткән челеменә күз төшереп алды. — Бары тик хөрмәтле Ефим Ефимовичка гына рөхсәт ителә. Анда да яшертен рәвештә, кеше күзеннән башка урында.

Моны ишеткәч, шактый олы яшьтәге боцманның авызы ерылды.

— Профсоюзларның өлкә советы да, медиклар да безгә үтенеч хаты белән мөрәҗәгать иттеләр, — дип өстәде капитан. — Әгәр тәҗрибәләре уңышлы чыкса, алар ил күләмендә Чакыру белән чыгачаклар.

Капитан ярдәмчеләреннән берәү, кискен фикерле, яшел тавышлы берәү сүзсез генә тамак кырып алды.

Капитан көлемсерәде.

— Мин әйтеп тә бетермәдем, хөрмәтле Антон Михайловичның карышасы килә!

— Гафу итегез! Нигә команданы шулай җәзаларга? Кемнедер көчләп тәмәке ташлаталармы? Оешкан төстә?.. Менә мин... Беркөн йокыдан уяндым да үз-үземә: "Бүгеннән тартуны ташлыйм", — дидем. Беркемгә әйтмәдем, профсоюз да белми калды. Бер атна узгач: "Кәефем яхшы бу арада!" — дигән идем, хатыным: "Син тәмәкеңне ташладың ич!" — дип тора... Бу төркем тәмәкене ташлар дип ышанасызмы? Сафсата!

Капитанга карышмасалар да, матрослар арасыннан ярдәмчене хуплаганрак авазлар ишетелеп калды.

— Без дә интегикме?

— Ни пычагыма!

— Пассажирларга кушылып шул агудан сез дә котыла алсагыз, бер дә зыян булмас! — диде капитан ачык итеп. —Безнең бурыч авыруларга ярдәм итү. Мин аларны "авырулар" дип аңлы рәвештә атыйм.

Алардан ерак та түгел икенче бер төркем пассажирларны күз белән каршы ала, күз белән берәмтекләп каюталарга озата тора. Арада кара күзлек кигән, яше шактый булса да, һаман төз буйлы, елгыр хәрәкәтле берәү аерылып тора. Көмеш йөгергән куе, кара чәчләре әле һаман ялтырап, аның ак маңгаен бизәп төшеп тора. Ул ике кулы белән өстәлгә таянган да, бу хәрәкәттә, ыгы-зыгыда гаме юк кеше сыман, ниндидер бер көйгә ишетелер-ишетелмәс кенә сызгыра. Ританың абыйсы, гипнотизер Яков Борисович Цудечкис иде бу кеше. Менә ул трапка якынлашып килгәнРитаны, аның очраклы юлдашлары Харис белән Алимны күрде, чак кына алгарак тартылып, юлчыларның авыр чемоданнарына күз салып өлгерде. Ритага кул болгады. Абыйсы да, Алим да бу кешенең үткер карашын абайлап алганнар икән, Ританың да җавап ишарәсеннән аның кем икәнен аңладылар. "Карап-карарбыз! — дип ачуланып уйлады Харис. — Син җинәрсеңме бу халыкны, әллә безнең сигаретлар егып салырмы?"

Харис баядан бирле бары тик врачлар турында гына уйлап баш вата иде, хәзер кызыксынуы хәттин ашып, Ритадан сорамыйча, ачыкламыйча түзә алмады.

— Врач шулмы инде? Гипноз да ясыймы?

— Оста врач, диләр.

Теплоход та үзенең аклыгы белән, чисталыгы белән больницаны хәтерләтә иде. Шау-гөр килеп траптан менгән пассажирлар монда килеп керүгә үк юашланып, тынып калдылар. Каюталарын эзләүчеләр дә номерларын пышылдап кына әйтәләр, ачкычларны иплән кенә боралар, сүзсез генә урнашалар... Рита Алимга: "Пока!" диде дә, баскычтан өске катка менеп китте.

Сиксән өченче каюта. Алдан Алим керде. Керде дә елмайды. Харис бик төпченеп ишек-тәрәзәне, киштәләрне бер кат күздән кичереп чыкты.

— Син һөҗүмгә чыгарга җыенган полководец төсле... Һәммәсен күздән уздырасың, — диде Алим.

Харисның бу сүзгә кәефе килде, көлгән булды.

— Һөҗүмгә үк чыкмасак та, эшләр житәрлек булыр.
— Күрдеңме? — дип сорады Алим.
— Кемне?
— Кемне булсын,Ританы әйтәм. Чибәрме?
Харис елмаюдан туктап, шунда ук җикеренә башларга да күп сорамый! Тотынды егетне пешекләргә.
— Син юньсездә һаман кыз кайгысы икән! Менә син аңа ышанып эшкә ябышып кара! Дөньясын челпәрәмә китереп бетерәчәк. Әллә чак кына акыл кердеме дисәм, башында һаман диңгез җиле икән! Син әнә теге өстәге төркемне күрдеңме? Безгә челәеп карап калган врачны?!
— Тынычрак бул әле, — диде егет сабыр гына.
— Син эшкә тотындың, эшкә! Шуны онытма.
— Атлаган саен шуны искә төшереп торырдай булсаң...
— Кыз кирәк икән аңа, йолкышка...
Чемоданнарның икесен өске киштәгә сыйдырдылар, берсенә урын табылмады, анысын аяк очына идәнгә шудырдылар. Эш бетеп тә китте. Кара-каршы килеп утырдылар.
— Безгә әнә шул кыз ярдәм итәчәк тә инде.
— Кыз?
— Шуның ярдәмендә кешеләрне өйрәнәчәкмен дә! Ә болай... Кем мин? Алар кемнәр? Ничек сорашасың да, кемнән барып белешәсең?!
"Төтене туры йөриме әллә бу егетнең?" дип уйлады Харис гаҗәпләнеп, тик бу куанычын энесенә белдермәде. Күрше каюталардан сөйләшкән тавышлар ишетелде, тоның кына, аңлашылмаслык кына булса да ишетелде.
— Акырма, — диде ул, иреннәренә юан бармагын аркылы куеп. — Моннан соң тарту турындагы сүзләреңне оныт. Йөкне "товар" дип кенә ата. Анда да, сак бул!
Ул арада теплоход кузгалды.
Саубуллашу, яулык болгаулар, сыек кына күз яшьләре. Кемдер чәчәк бәйләме ыргытты, чәчәкләр палубага килеп тә җитә алмадылар, таралып яшькелт дулкыннарга уралып кайдадыр күздән югалдылар... Теплоходның бөтен гәүдәсе акрын гына дерелди-калтырый башлады, һәм күңелләрне монсулатып саубуллашу гудогы яңгырады...

Абыйсы ничаклы усалланса да, Алим бары тик кыз турында гына уйлый иде. Моңарчы да кызлар белән танышканы, бакча ышыгында качып кына үбешкәне дә бар иде Алимнын. Тик ул чакта Алим бөтенләй башка кеше иде, мөнәсәбәтләре дә бүтәнчә иде. Бүген ул кызга үзен "студент" дип таныттты. "Аспирант" дияргә көче житмәде. Аспирант аның карашынча, күк кешесе, аның буе җитә алмаслык бөек зат иде... Әле студент дигәч тә, аның йөрәге күкрәгенә сыймый башлап шашып-шашып тибеп алды... Ул да студентка. Алар тигезләр. Алар бердәйләр. Шуның өчен кыз да аңа якты күз, ышаныч һәм күңел уртаклыгы белән карады. Бер мизгелдә аларның күкрәкләре бер-берсенә тиеп торды. Алим бу минутның озын, бик озак булуын, мәңге бетмәвен теләгән иде. Үзләрен һәр яктан китереп кыскан халык ташкынына ул эченнән генә рәхмәт укыды. Үлчәп-санап карасаң, аларның арасы бик ерак, күк белән җир арасы кадәр иде. Кызга болай якын килер өчен Алимга биек тауларга менеп сыналырга, упкыннарга төшеп исән чыгарга кирәк иде. Ташкын аларны бергә кушты, ул бөтен күкрәге белән кызның йөрәк тибешен дә ишеткән кебек булды. Күңеленең иң тирән төпкелендә Алим бу сәяхәттән курка иде. Хәвефле эшкә алынуы да куркыта, юлдашының албасты, карун Харис абыйсы булуы да шурләтә... Һәм аның җанын аңлаган кебек кыз да "куркам!" диде. Алар икесе дә куркалар! Бу бит көтелмәгән, кадерле уртаклык. Һәр икесенең курку сәбәпләре бөтенләй капма-каршы булса да, Алим кызда үзенә теләктәш иптәш күрде, җаннары якынлыгын тойды... Аның бер секунд та монда утырасы килми иде, тизрәк-тизрәк

каюта кысасыннан чыгарга да Ританы күреп, аның янында булырга кирәк.

Товарны урнаштыру, аны саклау турында ул бөртек тә уйламады. Бу эш ничектер үз чиратында, шау-шусыз гына узып китәр кебек тоелды. Хәзер бер генә кыен як калды: егет кызның үзен студент дип белүен, читтән торып укуына ышануын тели иде. Әгәр ул аның кара күңелле сәүдәгәр икәнен белеп алса?.. Сату-алуны тулысы белән абзасына тапшырырга туры килмәгәе әле! Әйдә, сатсын да куансын, акча күрәсен дә — сөенсен... Идеяне Алим бирде, бурычтан котылырлык кына сумманы абзасыннан ничек тә каерачак ул! Аннары тотсыннар Алимның койрыгын! Йә гаражга эшкә керер, йә заводка кайтыр. Эшкә урнашкач, ныгыгач Ритага ул барын да сөйләп бирә алыр. "Теплоходта шаярттым гына, юлда кем дөресен сөйли!" дияр...

"Җүләр мин!" дип уйлады ул бераздан. "Бәлки аның сөйгән егете бардыр? Бәлки ул кияүдәдер?" Шунда ук бу уйларны качырып икенчеләре килеп житте. "Ире булса, озатмый калмас иде... Ничек тә бер сүз белән булса да телгә алыр иде! Юктыр!"

Пассажирларга Рита янынннан торып карагач, юлдашлары ошап та китте Алимга. Кызыл сакал да җитез генә атлап менеп килә. Иван Семенович егетләре гаскәри сафтагы кебек шәп-шәп атлыйлар, күкрәкләр дә киерелеп киткән. Тол ир генә баягы кебек үк боек һәм карашы түбәндә иде...

Алим тиз-тиз генә өс-башын алыштырды да чыгып бара. Өстендә без беренче күргәндәге спорт костюмы, аякларда кроссовкалар. Яланбаш. Чибәр егет, зифа егет...

— Кая атыласың?

— Чыгам әле! Монда кунаклап утырырга мин карт әтәч түгел!

Чыгып та китте.

Харис чемоданнарны тотып-тотып карады, санады. Уфылдап килеп утырды. Ярым караңгы каютада аның чырае каралганнан карала бара иде...

Бер дә ышанычлы адәмнәр күрмәде әле ул пассажирлар арасында! Һәммәсе дә җиңел сөякле, уенчак булып күренделәр аның күзенә! Ул юлга чыгучыларны башкачарак күз алдына китергән иде... менә, иртәләрен сыра кибетен сагалаучы өтегрәк киемле, сытык шешенке чырайлы, җимерелгән күз кабаклы кешеләр кереп тулыр... Алар һәммәсе дә мәет күмәргә баргандагы төсле кырыс һәм күңелсез булырлар... Ә болар?!. Тәмәкене уйнап-көлеп кенә тартканнар да, җиңел генә ташлап, онытып та бетергәннәр, диярсең. Көлә-көлә менәләр бит! Шаяралар, шук сүзләр ычкына! Олы эшкә алынган бертуган энесе дә кызлар турында уйлый ала! Мондый эшкә алынгансың икән, күңелеңдә шул гына булырга тиеш. Шул турыда гына кайгырт! Инде кыз белән аралашырга телисең икән, чамала, эшеңә файда китерә аламы ул, юкмы?.. Тукта, әгәр чыннан да кыз аша юлдашлар белән җинелрәк танышып китсә? Кемнең кем икәнен ачыкласа?..

Ул каютадан чыкканда Алим палубада басып тора иде.

Палубаның аргы башыннан кара күзлеген уйнатып врач килеп чыкты. Алим янына килеп җиткәч күзлеген салды, берара тыелып торды. Алар янына барып җитәрәк Харис тиз-тиз ямьшәйгән фуражкасын күтәреп куйды, елмаерга тырышты, бишкә бөгелеп врачка сәлам бирде. Врач исә җиңел генә баш кагып аның сәламен алды.

— Күрденме? — диде Харис энесе янына килеп җитеп. —Тартма, ди икән, тартмыйсың инде! Җендер бу! Күзләренә карасаң... Имәнәсең!

— Гайрәт сизелә аңарда!

— Ә син аннан да көчле бул!

— Абый, син һаман шул турыда! — диде Алим сызланып.

Харис тавышын түбәнәйтеп, Алимга табарак иелде.

— Врач — миңа! Үтәли күрәм мин ул явдне! Әллә кем булса да

танавы серен сөйләп тора. Салырга ярата! Монда эчемлек бардыр бит?

— Белмим.

— Йөгереп кенә буфетка разведкага барып кил.

— Ашыкма инде!

— Әллә монда ел йөрергә чыктыңмы? Беренче көне узып та бара. Кызны сиңа тапшырам. Ни пычагыма ул хор?! Үз янында тот син аны! Ә бусын үзем башкарам...

Буфетта ниләр барын белешү бер дә кыен булмады, Алимга баягы жор матрос очрады.

— Тамак кычыта да башладымы? — диде матрос, муеның ышкып.

— Юк ла, абый белән мин. Ул салгалый... Алдан ук белеп куйсам, аны тыярга яхшырак булмасмы!

— Ә-ә, — дип сузды матрос. — Аракы юк. Коньякның бик кыйбатлысы гына. Банкирлар эчә торганы. Шампан бар, коры-сары, сухое дигәндәй... Алары да аз, бик аз! Эчкән кеше тартуны ташлый аламы?. Әкият!

— Шуңа кайгырып йөрим дә!

Алим белән матрос дус булып аерылыштылар. Абыйсы турында шулай ихлас кайгыртып йөргән кешене кем ошатмас?!

Абыйсы янына кайтышлый ул кызны күрде. Күрде дә абыйсының боерыгын онытты. Тик кыз ялгыз түгел иде. Алар биш-алты йөнтәс егет белән өскә менеп баралар иде. Алим да, бераз арткарак калып, аларга иярде, якынрак барырга кыймады. Егетләр музыкантлар булып чыкты. “Нигә боларны ияртергә иде инде? Ярамаган тагын тәмәкечеләргә магнитофон лентасы!” Бер күрүдә яратмады Алим музыкантларны. Затлылар, чибәрләр, биек буйлылар, кызны урап алганнар да авызына керердәй булып сөйләшәләр. Кыз да шат, көлә! Музыкантлар да теплоходка алданрак кереп кунаклаганнар иде, ахрысы, ярда да, кергәндә дә күзгә чалынмаганнар иде. Бер дә ошамады ул компания егеткә! Кыз янында “студент” дип төтен җибәрергә була, ялганынны тоттырмассың да, ә бу аждаһалар янында... Ярты сүздән Алимны ашап бетерәчәкләр болар! Авыл мәктәбендә узган сигез класс белән әллә кая бара алмассың!

Әле бая гына күңеле күтәренке иде егетнең! Ул үзен пассажирлар арасында бердәнбер егет дип санаган иде, сәяхәте Рита белән булганда гел сөенечләрдән генә торыр дип ышанган иде... Ә хәзер... күңелсез һәм төссез булачак аның юлы! Егерме дүрт көн буена абыйсы колагындагы черки булып безләячәк...

Кыз да аны әллә кайчан күреп алды, елмаеп ике-өч тапкыр башын да какты, тик егетләр яныннан китәргә ашыкмады. Инде китәм дигәндә генә ул Алим янына йөгереп килде.

— Алим, — диде ул. — Рәхмәт. Син мине эзләп чыктыңмы?

— Чыккан идем дә...

— Соң?

— Сез эшкә керешкән димме?..

— Киңәшәбез. Ни эшләргә кирәклеген берәү дә белми. Дөрес, монда штаб та бар. Алар да киңәшеп утыралар бугай.

— Штаб та бармыни монда? — диде егет, сөмсере коелып.

— Бар, бар!

— Музыкантларның башлыгы кайсысы?

— Әнә теге сакаллы егетне күрәсеңме? Кстати, ул безнең коллега. Студент! Психологиядән диплом яза. Эш практикасын да монда уза. Шактый күңелле халык җыела әле монда! Мин сезне таныштырырмын. Борчылма, егетләр яхшы күренә.

— Минем абзый...

— Абзаң да әйбәт кеше күренә. Тик кырысрак димме?

— Катлаулы кеше, авыр холыклы. Аралашканны, танышканны өнәп бетерми.

— Аңладым. Күзенә бик күренеп йөрмә диергә теләдегезме?

— Алай түгел дә!

— Абзаңны да җиңәрбез. Көч бездә. Бердәмлек һәм хәрәкәт! Менә безнең девиз. Йә, әйт әле, тәмәкече, тартасың киләме?..

— Тартуны искә төшермә инде, Рита.

— Дөрес! Башта бөтен-бөтен җиргә плакатлар, кисәтүләр, тәмәкенең зарары турында фактлар эләргә ниятләгән булганнар. Ә хәзер берәр нәрсә күрәсеңме? Юк! Без барыбыз да ял итүчеләр, һәм ялны күңелле итү безгә йөкләнгән. Мин сезгә —яшьләргә таянам.

— Бүген үк җырлата башлыйсызмы халыкны?

— Бүгенгә биетәбез генә! Абыеңны танцыга алып чык!

— Серне ачтым да көлкегә калдым.

— Абзыйлар белән җиңел түгел. Минем янда кем барлыгын беләсәң иде син?

Алимның кызыксынуы соң чиктән ашты! Алар "сез" урынына "син" дип сөйләшүгә күчтеләр. Җитмәсә, абыйсы турында нидер әйтергә дә җыена!

— Гәрчә без бер каютада түгел, ул үзе, аерым булачак. Әмма ул җиде кат җир астыннан да мине күреп, күзәтеп торачак. Көнче! Көнчелеге аркасында аны хатыннары ташлап китте... Башка якларын белмим, мәгәр көнче!

Яков Борисович алар янынннан үтеп китте, кара пыялалар астыннан тирән чокырларга поскан олы күзләре шомлы булып күренеп калдылар.

— Кичкә танцага киләсез. Ә хәзергә, хөрмәтле яшь иптәш, көндезге ашка рәхим итегез!

Егет баядан бирле үзен бимазалап торган сорауны бирде:

— Рита, — диде ул, — эчке тәртип кагыйдәләре каты булырмы? Штабта нинди сүзләр йөри?

— Абыегыз өчен борчыласызмы?

— Борчылмый ярамый!

— Югары градуслы эчемлекләр куллану каттый тыела.

— Берәрсе тәмәке суыра башласа? Кем дә булса тартырга алып кергәндер бит?

— Бу мәсьәлә дә бик катгый куелачак. Команда кисәтелгән. Тартучы үзенә зыянны салучы гына түгел, барлык аңлы гражданнарны котыртучы, коткы таратучы булып саналачак. Әгәр берәр кеше явыз ният белән тартырга алып керсә, аңа шактый күләмдә штраф салыначак, эш урынына хәбәр ителәчәк.

— Алай-й...

— Сезгә ул куркыныч янамый ләбаса!

— Нигә?

— Сез тартмыйсыз, Алим.

— Юк, тартам.

— Күрәм, беләм. Сез абыегызны бәладән йолып алырга гына җыенасыз. Шулаймы?..

"Шулай", дисә, беренче көнне үк Рита аның бар серен диярлек алып бетрәчәк. "Алай түгел", дисә, алдаганы бик тиз беленәчәк...

— Әйе, тартмыйм мин, — диде Алим шыпырт кына.

— Мин моны башта ук сизендем. Сезгә хөрмәтем шуңа артты! Әйбәт кешеләр, ахрысы, сез.

Алим җавап бирергә өлгермәде, аны Яков Борисович чакырып алды.

— Нигә син шундый җилкуар янында чуаласың? — диде ул.

— Ярамыймы?

— Син аның чемоданнарын күрдеңме?

— Күрдем. Күтәреп тә карадым.

— Нәрсә бар аларда?

— Китаплар дип беләм.

— Синең балалыгың, гадилегең мине шатландыра. Әмма ерак туганың

буларак, искәртеп узам: көннәрдән бер көнне шушы егет палуба уртасына чыгып "алтын балдакларыгызны, акчаларыгызны чыгарып бирегез, чемоданнарда динамит, без корабны шартлатабыз!" дип акырса, мин гаҗәпләнмәс идем.

— Юлбасарлармы алар? — Рита рәхәтләнеп көлде. — Син аның абзасын ошатмадыңмы?

— Кисәттем, искәрттем. Калганы синнән... Абзасы гына түгел, икесе дә... Бел, юлдашларыбыз арасында ин куркыныччлы кешеләр — шулар.

"Менә кызык!" дип уйлады Рита. "Мин бер күрүдә Алимга тартылдым, ул да шулай шикелле... Ә Яков Борисович бер күрүдә аларны яратмый башлады. Хәтта дошман күрә! Бу хисләр кешедә шулай тиз уяна алалар микәнни?"

Һәм ул бу сүзләрне куен дәфтәренә теркәп куйды. "Беренче педагогик күзәтү!"

"Беренче класска урнашкан пассажирлар беренче нәүбәттә ашый, кырык минут узгач, алардан соң, икенче класс пассажирлары ресторанга рәхим итсеннәр!" — Радиодан шундый белдерү ясалды.

Ресторан чак кына кысанрак кебек тоелса да, зәвык белән бизәлгән иде. Стеналарында көзгеләр, рәсемнәр, акварельләр. Официантлар да елгыр гына йөриләр. Шулай да көндезге аш Хариска бер дә ошамады. Бәйләнер урын тапмады ул монда! Була бит шундый кешеләр, аларны авыз тутырып кеше дисәң дә ярамас, үтләре һәрвакыт сытык булыр. Теләсә нәрсәгә бәйләнергә торалар алар! Алар бәйләнә дип башкаларның эче поша, нервылары кузгала, ә аларга шул гына кирәк тә! Кеше интеккәннән, кеше борчылганнан тәм табучылар үзләре тып-тыныч кына калалар. Әгәр кемгәдер, нәрсәгәдер бәйләнеп, үчегеп алмасалар, җаннары тыныч түгел, бертуктаусыз быжлыйлар, сыкрыйлар, зарланалар... Өстәлдәге приборлар ошамады Хариска. Ниһаять, бәйләнер нәрсә тапты. Имеш, ярамаган идеме монда бөгелеп-сыгылып торган алюминий кашык-чәнечкеләр, бизәкле тутыкмас корычтан куйганнар! "Моның белән кеше чәнчергә була!" — диде ул Алимга, кулында чәнечкене уйнатып...

Савылып кереп утырдылар. Һәркем инде танышы-белеше, каютадашы белән урын алырга тырышты. Кызыл сакал да бу "смена"да икән, бригада ихтыярына буйсынып "сәяхәт"кә чыккан "квартет" та Иван Семенович Велягурский җитәкчелегендә бер өстәлне биләгән, йомыкый кеше өч хатын-кыз белән туры килгән. Бер ул башын түбән иеп утыра, башкалар бер-берсенә беренче тәэсирләрен тапшырырга ашыгалар, каюталарның уңайлылыгы турында сүзләр йөри, сөенәләр, шатланалар, гомуми хәрәкәт, диңгез һавасы, команданың пөхтәлеге аларның сүз чишмәсен кузгатып җибәргән иде.

Коры-сарыны, салатны әйләндереп кенә салдылар. Кашыклар эшкә тотынды — аш килде. Озакламый тәлинкә кырган тавышлар өстенлек алды. Чәнечкеләр-пычаклар да ярышка чыккан мушкетерларның кылычы кебек ялтырап кына алды — итле бәрәңгене дә ялт иттерделәр. Компотны икешәр стакан, өстәмә сорый-сорый эчтеләр.

Бер Харис ашамады.

— Нигә ашамыйсың? — диде Алим ипи катысы белән тәлинкә төбен кыра-кыра.

— Күрмисеңмени? Тыгыналар!

— Син безне ашаудан калыр дип көткән идеңме әллә?

— Минем нәрсә көткәнне Ходай үзе дә белми!..

Шау-гөр килеп палубага таралалар. Өстә һаман ике төркем. Капитан, аның ярдәмчеләре, боцман бер яктан кешеләрне күзәтсә, Яков Борисович, профсоюз вәкиле, штаб начальнигы Вера Павловна, Рита, музыкантлар комарланып-кызыксынып, ыгы-зыгыдан мәгънә эзлиләр.

Вера Павловна Яков Борисовичны тынычландырырга тырышып:

— Идеяне мин бирдем, мин башладым! Нәтиҗәсенең гүзәл булырына

да ышанам! Өлкә советында күтәреп кенә алдылар. Нидән шикләнәсез?

— Тамагы туйгач нишләр бу халык?

— Халыкны бер генә минутка да үз кулыбыздан ычкындырмаска! Һәр көн яңа идеяләр белән баетып аның рухына, вакытына, җанына хуҗа булырга кирәк! Безнең төп бурыч шул. Иптәшләр, сынатмагыз!

Вера Павловна "ишеттегезме?!" дигән сыман һәркемнең алдына чыгып, күзенә карап, кулына кагылып, сүзләрен кат-кат өләшеп чыкты.

Харис юри кешеләр ишетерлек итеп:

— Ашаганнан соң мин шәп итеп тартып җибәрә торган идем! Кырын ятып! Әй, суырасың күкрәкләрне тутырып! — дип куйды.

Алим аның кабыргасына төртте. Башкалар ишетмәмешкә салыштылар, йомыкый кеше алар янынннан читкәрәк китте. Алим аны беләгеннән тотып алды:

— Гафу итегез, бая исемегезне сорамыйча калдым.

— Покуль минем фамилиям, Гавриил Николаевич!

— Гавриил Николаевич, шахмат уйныйсызмы?

— Уйнаштырам. Бүгенгә диңгезгә карап кына барырмын дигән идем.

Әбәдкә ялгыз атлаганнар да табын тирәсендә танышып-берләшеп өлгергәннәр иде инде. Ул ара да булмады өстә оркестр уйнап җибәрде. Яшьрәкләр тупырдашып, бер-берсен җилтерәтеп тә алдылар. Артык ачык якалы күлмәк кигән бер ханым: "Ашаганымны коясыз! — дип чәрелдәде. — Ирем ябыкканны яратмый!"

Шахмат такталары килеп чыкты, икешәре уйнаса, унысы тамашага басты. Домино сөякләре шакылдады. Кемнәрдер камыш урындыкларны, шезлонгларны кояшка тартып чыгарып, ярым чишенгән хәлдә сузылышып яттылар. Кемдер гырлый ук башлады. Иван Семенович командасы шактый ишәйде, ул Василий Теркин кебек кап уртага чыгып баскан да мәзәкләр сиптерә. Ярты сүзе ишетелүгә җыелганнар гөрләшеп көлеп җибәрәләр.

— Әрмән радиосыннан сорыйлар: Кисловодскида ялда булып та иренә тугры калган хатыннарны өйләренә озатыр өчен ничә вагон кирәк булыр икән? Радио болай дип җавап биргән: бирегез ул җүләргә велосипед!

Җыелганнар ярылып көләләр, оркестр тавышы бер мәлгә ишетелми тора. Палубаның иң аргы бормаларыннан кешеләр алар янына ашыга, килүчеләр дә юлда ук көлә-көлә шаркылдый башлыйлар.

Теплоход җай белән генә бара, диңгез җиле хатын-кызларның чәчен тарата, алар үзләренә бер команда төзеп, күлмәкләр, кремнар турында кызып-кызып гәпләшәләр.

Бер Яков Борисович кына кырыс.

— Ни ошамый сезгә? Яков Борисович? — дип инәлә сөенечтән бите алланган Вера Павловна.

— Мин бу кешеләрнең иртәгесен күз алдына китерә алмыйм. Шул гына.

— Бер атнадан алар туганлашып бетәчәк! — дип ышандырырга тырыша Вера Павловна. — Күрерсез!

Рита да аны яклый:

— Һичшиксез шулай булачак. Ничек ышанмаска мөмкин?..

Аның кайнарлыгы, һәр яхшы сүзгә ышанырга торуы Вера Павловнага шулкадәр ошый, ул аның яңагыннан сыйпый: пәп итеп үбеп тә ала...

Харис бер урында да туктала алмый. Ул йокысы туймаган ачулы аю кебек лап-лоп атлап әле аска төшә, әле өскә менә, җыелганнар янында колагын торгызып, тыңланып тора. Тик үзе көткән сүзне, үзе сагынган ымнарны ишетми... Ул моңа ышанмый, ышана алмый, аның саен ачуы кабара, кабарган ачуын түгәр, багышлар кешесе юк, һәммәсе үзе белән, аның җанында, аның күңелендә... Шартлар иде, һәммәсен шартлатыр иде, анысы да аның кулыннан килми!

Оркестр җиңел көйләрне сыздыра, кешеләр шул көй уңаена очып

диярлек йөриләр, тәннәрне рәхәтләндереп, күңелләрне киңәйтеп диңгез җиле исә. Кинәт барысы да тукталып калалар, башлар бер якка борыла, борыннар киерелә, халыкның сәер тукталышын карап музыкантлар да тукталып калалар. Вера Павловна егылып төшәрдәй булып аска карый. Һәммәсе дә иснәнәләр.

— Кемдер тарта!

— Тәмәке исе!

Монысын шыпырт-шыпырт кына сөйләшәләр.

Тынлыкта капитанның тавышы яңгырады.

— Боцман, хәзер үк палубадан югалыгыз!

Ефим Ефимович та тамак туйдырып чыккан икән! Дөнья мазаларын онытып дәү, кара саплы челеменә ярты уч тәмәке тутырып кабызып җибәргән икән. Боцман приказ бирергә дә, үтәргә дә ярата торган җан иде, бер сүздән эреп юкка чыкты... Оркестрга тын торырга боерып, Вера Павловна халыкка эндәште.

— Кадерле юлдашлар! Бер уй, бер теләк безне берләштерде. Шуның өчен бүгеннән без барыбыз да тату бер гаилә булып яшәргә тиеш. Бурычыбыз уртак — без сәламәтлегебезне кайгыртып эш урыннарыбызга ныгып кайтырга тиеш. Икеләнүләргә баш бирмәскә, күңел ачарга, ял итәргә чакырабыз! Һәммәсе сезнең карамакта! Монда бөтенесе дә сезнең ял өчен әзерләнгән! Теплоходта менә дигән китапханә бар. Укыгыз, актарыныгыз! Шахмат, шашка, домино — һәммәсе җитәрлек. Бассейн эшли, иптәшләр! Файдаланып калыгыз! Бүгеннән хор түгәрәгенә язылу башлана. Ашыгыгыз! Үзләреннән шикләнгән, икеләнгән иптәшләрне койрыктагы салонда врач Яков Борисович көтә. Тәҗрибәле, ышанычлы врач...

Аңа кушылып Рита да бер-ике сүз өстәде:

— Хорга йөрергә теләгән иптәшләр борындагы салонга җыела алалар!

— Нигә безгә хор? — дип сорады Иван Семенович.

— Хор ул, иптәшләр, коллектив! Тавышлары булган, кайчандыр җырлаган иптәшләр бу чакыруны рәхәтләнеп кабул итәрләр дип ышанам!

— Безнең үз хорыбыз да бик шәп! Йә әле, Иван Семенович.

Велягурский матур гына җырлый икән, ул "Синий платочек"ны башлап җибәрде, аның янындагы иптәшләре, күптән гадәтләнгән кебек җырны дәррәү күтәреп алдылар. Кызыл сакал да аларга килеп кушылды, этеп-төртеп йомыкый Покульны да уртага чыгардылар:

— Качма, качма!..

Оркестрантлар җырчыларга ияреп, аларны куәтләп җибәрделәр. Ирләр тавышына хатын-кызлар кушылды, Рита югарыдан торып куллары белән һава бутап, аларга җитәкчелек итә башлады...

Җырны биюләр алыштырды, күмәкләп тә, ялгыз да биеделәр. Авыз җырып хуплау сүзләре әйтә-әйтә кул чабып, биючеләрне дәртләндереп тордылар.

Кеше юк җирдә аулакта алар кара-каршы очраштылар. Яков Борисович Харисны сагалап килә иде, ул Яков Борисовичны күзәтә иде.

— Сез нигә җырламыйсыз? — диде Яков Борисович.

— Сезнең дә төшеп биегәнегез күренми.

— Кәефегез начармы?

— Нигә? Әйбәт әлегә.

— Чыраегыз караңгы.

— Сез дә кояштай балкып тормыйсыз...

Алар бер-берсенә шикләнеп карап, үз юлларына киттеләр.

— Болай булырга тиеш түгел бу! — дип мыгырданды Яков Борисович үз алдына.

— Болай булырга тиеш түгел бу! — дип сыкранды Харис абзый үз алдына.

Рита өстән дирижировать итә, Вера Павловна ялгызакларны җырга кушылырга чакырып, өндәп йөри.

— Кушылыгыз, кушылыгыз!..

Яков Борисович авыр адымнар белән аның янына килеп баса. Вера Павловна куанычын яшерә алмыйча аңа иелеп кычкыра:

— Мин бирдем идеяне! Мин уйлап таптым!

Капитан белән беренче ярдәмче дә очрашалар. Капитан сүзсез генә аңа бәйрәм итүче халыкны күрсәтә, ярдәмче дәшми, иңбашларын уйнатып каютасына кереп китә...

Харис каютасына кереп, тәрәзә каршысында озак кына басып торды. Бөркү һавадан котылырга теләп, тәрәзәне ачты. Аннан җыр, музыка тавышы ургылып кереп, аның сытылган чыраен тагын да ямьсезләде... Тәрәзәне ябып, ишекне ачып карады. Аннан да шат тавышлар, өзек-өзек көлгән тавышлар килеп керде. Харис нишләргә белмичә, кая барып сугылырга җай тапмыйча чигәләрен ике кулы белән кысып урындыкка утырды.

— Тьфу! — диде ул. — Тартучылар юктыр монда! Кыланып кына, ялганлап кына чыкканнар алар бу сәфәргә! Давыл чыгып бер селкетеп алсын иде биючеләрне! Салкын җил исеп җырчыларның тамагы карлыксын иде! Иң гаҗәбе, аның үзенең дә тәмәке тартасы килми иде. Ул сикереп торып чемоданнарны барлап, санап чыкты, гасабиланып тагын ишеккә таба барды... Көтмәгәндә Алим кайтып керде.

— Абый!

— Бар, йөгер!

— Кая йөгерим?

— Белмисең мени?

— Кая? Әйт!

— Койрыкка! Тикшер: ярдәмгә мохтаҗ тартучылар врач янына килгәнме, юкмы? Алим карышуның файдасыз икәнен бер секундта аңлады. Ул йөгереп диярлек салонга барып керде, тәрәзәләре төрле яктан ачылган, юка батист пәрдәләре җилфер-җилфер килеп торган салонда чалбар балакларын тезенә кадәр сызганган, кара күзлеген салып өстәлгә куйган Яков Борисович әлсерәп берүзе утыра иде. Ул да Алимның мышнап килеп керүен сәер итте, тиз-тиз генә чалбар балакларын сыдырып:

— Килдеңме? — дип сорады.

— Халык кайда? — дип сорады сорауга Алим.

— Берәү дә юк.

Салонга кулларын чәбәкләп Вера Павловна килеп кергәч, Алим тиз генә чыгып таю ягын карады.

— Яков Борисович, — диде Вера Павловна. — Феномен!

— Расчет бирегез, миңа монда эш юк, — диде кырыс кына Яков Борисович.

— Хәзер үк Хезмәт сараена радиограмма бирәм! Коллективизмның безнең халыкка шулай тирән үтеп керүен күрү — минем өчен бәхет. Мин бит, Яков Борисович, гомеремдә дә гаилә, үз тормышым турында кайгыртмадым. Вакытым булмады минем аңа. Кешеләр өчен яшәдем! Халык өчен тырыштым! Бүген шуның гүзәл нәтиҗәләрен күрәм!

— Мондый житди нәтиҗәләр чыгарырга ашыкмыйсызмы, Вера Павловна?

— Ышанмас кеше сез! Күргәне бере миңа рәхмәт укый!.. Шундый күңелле! Мин шундый бәхетле!

Алим шахмат уйнап утырган ике карт янына барып житте.

— Бу ходны ясар алдыннан элек бер төтәтеп җибәрә торган идем, — диде берсе. — Ә бу ходтан соң мин шах куя торган идем!

— Ә бу ход белән без шахтан оста гына котыла торган идек.

— Ә без тагын...

— Теләсәң кая чык, тәмәке турында искә төшермә!

Тәмәке тарту хакында ул ишеткән бердәнбер сүзләр шушы булды. Тик ул бу турыда Хариска әйтеп тә тормады.

— Юк, — диде ул. — Врачка — гипнозга беркем дә килмәгән. Берәү дә юк.

— Яхшылап карадыңмы?

— Янында басып тордым.

— Берәр җирдә тарталармы? Сөйләшәләрме ичмасам?

— Тартмыйлар. Сөйләшкәнне дә ишетмәдем.

Ул Алимга бер кап сигарет сузды.

— Алайса, бар, син тарт!

— Минем тартканым юк. Тартасым да килми.

— Төтен исе тарат! Борыннарын кытыкла! Котырт!

— Абый, — диде Алим. — Көтик әле.

— Көтеп торып, товарны кочаклап калыргамы? Тәмәкесезлеккә күнегеп бетсеннәрме? Аларга рәхәт! Эксперимент дип уч тутырып акча алырга! Газеталарда шауларлар! Ә без нәрсә?.. Безгә үлгән йомран башымы?!

Алимның чыгып йөрисе, Рита янында буласы килә иде, тик абзасы мондый хәлдә чакта аны ташлап чыгып китәргә дә уңайсыз. Куркыныч та! Тиктомалдан әллә нинди җүләрлек эшләп ташлар! Тәмәкесен кабызып халык арасына чыгар...

Чишенеп яттылар. Абыйсы түшәмгә караган да кемнедер һаман сүгә, күренмәгән дошманнарына йодрык йомарлый иде.

— Белә идем бит! Ир-ат, тамагы ачса, гел ашау турында гына сөйләшә. Тамагы туйгач, сүз җебе төрләнә! Ул аракы, тәмәке турында гәп сүтәргә керешә. Ә салып алгач, рәхәтләнеп бер суыргач, хатын-кызлар турында сүз кузгата! Дөньяда ир-ат, ашау, эчү һәм кулы аша уздырган хатын-кызлар белән генә мактана ала. Шулай яши.

— Бәлки алай яшәмәүчеләр дә бардыр? — диде Алим йокы аралаш.

— Шулай яшиләр! Шулай яшәячәкләр дә, менә күрерсең. — Ышанычың шулай зур икән, нигә кабаланасың соң алайса?

— Әллә монда ир-ат юкмы?! Беткәнме дөньяда ир заты?!

Алар йокыга талды. Палубада соңгы аяк тавышлары янгырады. Музыкантлар арганнар, Алар тып-тын гына озаклап чәй эчәләр. Өстәл башында утырган Яков Борисович серле генә елмая... Нидер белә ул, нидер көтә! Беренче көннең алдавыч кына булып чыгуы бик ихтимал дип саный ул... Өч йөздән артык кешенең нәкъ бер, бердәй ныклы характерда булуы мөмкин түгеллеген ул врач буларак чамалый. Тик көндездән кичкә кадәр ару-талуны белмичә уйнаган, гомуми күтәренкелек шаукымына бирелгән музыкантларга ул шик-шөбһәләрен ачарга ашыкмый. Ялгышуы да ихтимал, әгәр ялгышмый икән, иртәгә алар өчен тагын да күбрәк, тагын да авыррак булачак. Вера Павловнаны да рәнҗетәсе килми аның! Әйдә, юансын бер, күңел күтәрелешенең ни икәнен аның серле рәхәтен тулаем татып, шатланып калсын. Иртәгәге көн аңа да яңа сынаулар алып килмәсмени?! Харис урынында борсаланып шактый яткач, калкынып тыңлап карады. Алим тигез генә мышнап, бөгәрләнеп йоклый иде. Ул караңгыда күлмәк-чалбарын эзләп табып киенде дә коридорга чыкты. Утларны киметкәннәр, ярым караңгы коридор буш һәм тып-тын иде. Ул борын яфракларын киереп иснәнә-иснәнә каюта ишек төпләрендә туктала-туктала шактый йөрде. Палубага чыкты. Сулы чиләк тоткан шук матрос аңа нидер әйтергә теләде дә, рейсның "спец" икәнен хәтерләп:

— Йоклап булмыймы, папаша? — дип эндәшеп куйды.

Йоклап булмый! Алай гынамы сиңа, яшәп булмый, иркен сулыш алып булмый. Чөнки син өметләнеп көткән көн бар ният-хыялларыңны җимереп ташлый!

Палубада алар Яков Борисович белән тагын йөзгә-йөз очраштылар. Бер-берсен күрмәмешкә салыштылар. Аралары бик тиз ерагайды...

Яков Борисович Ританы юксынып чыккан иде. Менә кемне күрәсе килә иде аның хәзерге минутта!

Дөресен әйткәндә, врач-психиатрның яшь кызга карата шәхси

планнары да бар иде. Бер-бер артлы ике хатыны ташлап киткәч, Яков Борисович ялгыз гына яшәп ята иде. Мондый сәяхәтләргә түгел кинога да сирәк йөри башлаган иде инде ул. Күбрәк вакытын өйдә ялгызы уздыра, килгән-киткәннәргә дә әллә ни ачык чырай күрсәтми, кемгәдер барып йөрергә үзе дә өнәмиерәк иде. Ашарга ресторанга йөри, иртәкичләрен каты-котыга да канәгать, куе кофе белән каймак табыннан өзелмәсен!.. Кофега күз рәхәте өчен коньяк та тамызгаласаң...

Рита югары мәктәпкә керергә дип өлкәнең иң читендәге бәләкәй генә каладан килде. Кардәшлек бик чамалы иде. Яков Борисович,Ританың әти-әнисен онытып бетереп барса да, кызны каршыларга, юатырга һәм ярдәм вәгъдә итәргә туры килде. Конкурсның "усал" һәм "мәрхәмәтсез" буласын ишетеп, кыз атаклы гипнотизер абыйсына бик нык өметләнеп килгән иде. Яков Борисович күптәннән беркемгә бернинди ярдәм күрсәтми, кирәк дип тә санамый, һәркем үз язмышын үзе белгәнчә корырга тиеш дип исәпли иде. Югары мәктәпкә керергә ярсып килгән яшь кызга аның ярдәме шуннан гыйбарәт булды, беренче август иртәсендә ул Ританы ияртеп институт ишеге төбенә кадәр килде һәм тыз да быз йөргән яшьләргә күрсәтеп болай диде:

— Менә болар һәммәсе дә синең чордашларың. Барыгыз да бер хокукта! Калганын син үзең башкарып чыгарга тырыш.

Әйтте дә китеп барды. Рита укырга керде, тулай торакка урнашты һәм абыйсы янына барып йөрүдән шып туктады. Абыйсының битарафлыгына рәнҗегән иде аның сизгер җаны.

Быел яз алар очраклы гына очраштылар. Яков Борисович хәйран калды: килгән чактагы кыз юк, аның урынына үсеп, пешеп житешкән чибәр туташ басып тора иде. Ул шунда гына кызның әйбәт кенә укып китүен, тагын бер елдан институт бетереп "хор дирижеры" исемен алып чыгачагын белде. Кыз үз язмышыннан канәгать иде, көлеп, балкып тора иде, һәм аның озын, таза балтырлары, зур, коңгырт күзләре Яков Борисовичның күзеннән читтә калмады...

Бер туры килсә килә бит ул! Нәкъ шул атна азагында ул кибеттә Вера Павловна белән дә очрашты.

Күптәнге танышлар иде алар. Вера Павловна яшь чагында яхшы гына җырлый иде, филармониядә дә эшләп йөрде, ике-өч тапкыр кияүгә дә чыкты, заманында яшь, талантлы перспективалы врач Яков Борисовичны ауларга да чамалады, тик нигәдер юллары аерылды.

Очраштылар, Яков Борисович аны-моны уйлап та өлгермәде, елгыр хатын аңа мең сүз, йөз тәкъдим әйтергә өлгерде. Иң ашыгычы: ул аны махсус рейска эшкә чакырды!

— Хуҗаларыгыз белән сөйләшерләр, сезгә һәрьяктан файдалы булыр. Ә безгә... — Бу урында Вера Павловна керфекләрен аска төшерде. — Сезнең кебек атаклы белгечнең рейста катнашуы безнең эшнең дәрәҗәсен генә күтәрәчәк!

Яков Борисович үзе дә көтмәгәндә, ризалыгын бирде, тик бер шарт куйды:

— Рейска минем сеңлемне дә аласыз! — диде.

Ританың кайда һәм кем булырга укуын белгәч, Вера Павловна тагын да ныграк сөенде: "Бер атуда ике куянны алды түгелме?"

Вера Павловна әле картаеп өлгермәгән, картаерга бер дә теләмәгән хатын иде. Яков Борисовичның тормыш хәлен ул бик яхшы белә иде, аның ялгызлыгын да, соңгы елларда хатын-кызлар белән сирәк аралашуыннан да хәбәрдар иде. Яков Борисович аның чакыруында яшертен бер ымны башта ук ишетсә дә, күз уйнатуларны, ишарәләрне, керфек тибрәнүләрен — үтеп киткән болытның соңгы күкрәве дип кенә кабул итте. Ул сәяхәткә чыгып китү белән үк Вера Павловнадан җинел котылачак! Ишле халык белән, гомумән, вакыты булмаячак аның... Булган вакытын ул Ритага, өметле һәм чибәр кызга багышлаячак... Ул бу сәяхәттән өйләнеп үк булмаса да, кызның йөрәген яулап кайтырга тиеш иде.

Ваемсызрак һәм үтә саф күңелле Рита, әлбәттә, болар турында уйлап та карамады. Яков Борисовичның әле артык карт түгеллеген белсә дә, аны ир-атка да санамый иде...

Яков Борисович бер ноктада ялгышты, ул пассажирларны күпчелектә олы яшьтәгеләр, һич югында, кырык-илледәгеләр булыр дип өметләнгән иде. Мондый кешеләр арасында әле ул да ир арсланы булып күренә алмасмыни?! Алимны ул бер күрүдә яратмады. Егетнең кызга, кызның егеткә бер караудa тартылуларын тәҗрибәле бүре Яков Борисович яшьләрнең үзләреннән алда белеп алды. Димәк, бу икенең йөрәкләре әле мәхәббәт газабына тоткынлыкка төшмәгән, алар үз эшләрен эзлиләр, күңелләре татлы хыяллар белән тулы...

Яков Борисовичның күзәнәкләрен мәкерле планнар биләде...

Икенче көнне, сәяхәтнен беренче иртәсен һәммәсе төрле уйлар, төрле өметләр белән каршылады. Иң элек, әлбәттә, Вера Павловна уянып чыкты. Киенгән, ясанган — яшьлек таңының иң гүзәл иртәсен каршылыймыни? Вак-вак кына шаян дулкыннар йөгерешкән диңгезгә, офыкта шәйләнгән тауларга, коры җиргә тиз-тиз генә күз йөгертеп алды да үз алдына куанып көлеп җибәрде. Шушы көлү сигнал булдымы әллә? Анда да, монда да тәрәзә пәрдәләре күтәрелде, хәерле иртә теләүләр, уенчак тавышлар, жор сүзләр бөтен яктан сибелә башлады. Вера Павловна палубада күренгән берәүне дә буш калдырмады дияргә ярый, һәркемгә барып сәлам бирде, хәл-әхвәлен сорашты, "Әйбәт йокладыгыз бит? Шулай булырга тиеш тә!" — дип әйтеп өлгерергә ашыкты. "Кичкә кырын тагын бер радиограмма озатырбыз! Ял искиткеч күңелле башланды!" — диде ул Иван Семенович Велягурскийга. Алар җыйнаулашып, киерелеп кыймылдашып диңгез өстен күзәтәләр иде.

Кабызмаган челемен суырып боцман узып китте.

Капитан рубкасында сытык чырайлы ярдәмче күренде. Ул палубадагы җанлылыкта, хәрәкәттә, сөенечле тавышларда аз гына ялган, ясалмалык булырга тиеш дип санап, кешеләрнең һәммәсенә дә шикле күз белән карап тора иде.

"Квартет" Кызыл сакалны да ияртқән бүген.

— Исай Маркович булам мин, Кривин. Сәяхәтнең болай күңелле буласын белгән булсам, хатынны да ияртә идем. Искиткеч минем Дора Михайловнам, гүзәл күңелле хатын! Кызлар да шәп минем! Андый кызлар беркемдә дә юк!

Тыңласалар да көләләр, тыңламасалар да көләләр егетләр.

— Йомыкый кайда?

— Покульмы? Нюрасын сагынып качкандыр әле! Әнә генә ич ярлар.

— Гавриил Николаевич ычкынган!

Шаулап-гөрләп аның каютасына барып керсәләр, Покуль майкачан, кыска чалбар кигән килеш, тирли-тирли хат язып утыра. Дүрт битне язган инде, вак-вак хәрефләр белән бишенче битне сырлый.

— Истәлекләрме?

— Түгел лә... — Гавриил Николаевичның бөтен бите, колаклары, муены җете кызыл төскә керә. — Хат бу, Нюрага. Мин аңа көн дә язарга вәгъдә биргән идем.

— Ничек җибәрәсең аларны?

— Акчарлак канатына тагыпмы?

— Юк ла, кайткач үзем тапшырам. Егерме дүрт көнгә егерме дүрт хат булырга тиеш.

— Ә син көннең нинди матур икәнен күрдеңме?

— Кая әле... — Покуль кәгазьләргә ымлап, муенын кашый. Аны башкача тыңлап тормыйлар, Иван Велягурский бер яктан тотып алуга, Кызыл сакал, "квартет"ның башка членнары Покульны күтәреп алалар да туп-туры бассейнга алып баралар! Кичә кызыгып карап кына йөргәннәр иде, бүген инде бассейнга да чират житте! Иң элек Исай Маркович

төшеп китә, чума, рәхәтләнеп су чәчрәтә башлый, өстән ямьле ыржаеп карап торган юлдашларына кычкыра.

— Менә кайда ул оҗмах! Әйтегез, моннан чыкмыйбыз, ашарга да монда китерсеннәр!

Иптәшләре көчләп диярлек Велягурскийны бассейнга ташлыйлар. Чират башкаларга да җитә. Бераздан бассейнда урын калмый. Басып кына торалар. Шау-гөр, тавыш, күңеллелек.

Өскә зур тартма кадәр аккордеонын тотып, музыкантларның берсе чыгып утыра. Шул хәтле бизәлгән аккордеон, аның ялтыравыклы калайларыннан чагылып төшкән нур, шаян песи баласы кебек, әле бер якка әле икенче якка йөгереп уйный.

Физкультурник та баядан бирле әзер икән. Аккордеон тавышына ияреп команда авазы яңгырады. Төрлесе төрле урынга баскан кешеләр иртәнге күнегүләрне ясый башладылар. Гәүдәләр җиңел, авызлар ерык, күпләр команда тавышын көтеп тә тормыйлар, музыка аккордларын узалар, тән хәрәкәт сорый, җан ашыга-кабалана, һәркемнең үз күңеле үзенә хуҗа, нинди кызык бар — бөтенесен эшлиләр. Яталар, сикерәләр, котыралар, кул чабалар, бер-берсенә бокс ясап төрткәлиләр. Тик хәрәкәтләрнең һәммәсендә нәзакәтлелек, тәртип, күзгә килешеп торган матурлык бар. Болармы соң кичә төтен болыты булып портны каплаган кешеләр?! Моны күзәтеп торган ярдәмченең салма савыты салынганнан салына бара... Кичә шахмат уйнаган картлар да монда. Аларны иң уртага алып мәзәк ясыйлар, хихылдыйлар, дәртләндерәләр, теге-яки бу күнегүне ничек ясарга икәнлеген күрсәтәләр...

Бассейнда тавыш, чыр-чу...

Палубаларда йөзәрләгән кеше. Шау-шуга Яков Борисович та уянып чыга. Ул күзләренә ышанмый, күз төпләрен уа, күзлеге төшеп китеп, чак кына ватылмый. Вера Павловна аның янына килеп баса.

— Мин уйлап таптым ич бу тамашаны, Яков Борисович! — дип пышылдый аның иреннәре. Ул шушы җөмләдән башка сүзне белми дә бугай инде, сүзләрнең бүтәннәре хәтердән чыккан, чөнки күз алдында дәвам иткән тамаша дөньяны онытттырып, аны бәхетле иткән. Ах, Яков Борисович та мәрхәмәтлерәк булып аңа елмаеп караса! Ах, шушы өч атнада гына Яков Борисович аныкы булып торсачы! Башка бер нәрсә дә кирәкми бәхеткә зарыккан дәртле хатынга! Моннан соң ничек яшәсә дә аңа барыбер, ул шулкадәр бәхетле, шулкадәр канәгать! Яков Борисович "сикер!" дисә, берсүзсез дингез кочагына ташланыр иде...

Тик Яков Борисович мәрхәмәтле карашын башка якка юнәлткән шул, анда, икесе бер почмакта Алим белән Рита гимнастика ясыйлар. егет елгыр җанвар кебек әллә ниләр эшли, Ритага кабатларга куша, кыз егылып китмәсен өчен аның биленнән кысып ала...

Авызына зур челем капкан Ефим Ефимович янында Харис басып тора. Кырынмаган, юынмаган, сөлгесе иңбашында. Ул кырын күзе белән генә челемгә карап ала да башка якка карый. Анда караса, файдалы сәүдәсенә кылыч янаган Яков Борисович, монда күзе төшсә, Алим белән Рита. Ритасы да аяк чалачак! Әнә, тоташ чылбыр булып бассейннан менеп киләләр. Күз ял итәр урын да калмаган Хариска! Ул койрыкка уза да түше белән култыксага ятып, бөдрәләнеп-бөдрәләнеп артка аккан яшькелт-зәңгәр дулкыннарга карап тора. Шаян матрос тагын чиләк тотып уза.

— Кәеф юкмы әллә, папаша?!

Спецрейс булмаса, бу бабайга бер-ике сүз әйтер иде матрос, — ярамый... Уза, югала, нихәтле халык арасында Харис берүзе, кара уйлары, күңелен ташлап дөньяга чыга алмаган мазалары, эшкә ашмаган хыяллары белән торып кала... Чабып каютасына кайта да ачуланып чемоданнарны тартып төшерә, типкәли, чыгарып ыргытырга уйлап, ишеккә таба сөйрәп китерә...

Аккордеон тавышы тына, Велягурский киң, көр тавыш белән җыр

башлап җибәрә, яраткан җыры "Зәңгәр яулык", аны бүтәннәр дә ярата, гимнастика тәмам, кешеләр беразга гына үз өннәрендә югалып торалар да, палубаны тагын аяк тавышлары күмеп китә...

Пассажирлар ташкын булып ресторанга агылалар. Пычак-чәнечкеләр кичәгегә караганда да җәһәтрәк уйнап тора, тәлинкәләр чыңлый, авызлар җитди эштә, тавык ботларын күз ачып йомганчы кимерәләр, тавык канатларын авыз гармуны итеп суыра-суыра ашыйлар, ялыйлар, яланалар. Ипигә калын итеп ягылган горчица да шуа, ипигә тоз сибеп тә ашыйлар, ипи телемнәре язгы кар көрте сыман тиз-тиз эри.

Аш бүлүче кара тиргә баткан, ун минут саен, билендәге ак сөлгесе белән маңгаен сөртә. Зур-зур кәстрүлләр бушап калган. Официантлар:

— Кемгә өстәргә кирәк? — дип әйтеп тә өлгермәделәр, бөтен яктан куллар күтәрелде.

— Миңа!

— Миңа да!

— Тәмле булды!..

Салонда Яков Борисович белән Вера Павловна утыралар. Алар янына өлкән повар килеп баскан.

— Үтерәләр болар, үземне тотып ашыйлар болай булса!

— Норманы азрак арттырырга кирәк булыр, — диде Яков Борисович. Повар башын чайкап, гаҗәпләнеп чыгып китте... Вера Павловнаның күзләре, нурга манчылган йөзе генә сөйли: "Ул уйлап тапкан бу хикмәтне! Акча чыгымнарын профсоздан ул каерып алган!"

* * *

Икенче көн гел хәрәкәттә, гел җанлылык белән узды. Танышулар, сөйләшүләр, бассейнда коенулар... Пассажирлар шушы кыска ара эчендә туганлашып та беттеләр.

Икенче кич. Палубада танцалар бара. Бөтен кеше бии! Пары бар да сикерә, ялгызлар да шунда уртада әйләнә, Иван Велягурский бармак шартлатып такмак та әйтеп җибәрә, иптәшләре аның тирәсендәрәк булырга тырышалар. Кыска аяклы Кривин бии, Покуль да курка-поса гына аякларын тыпырдатып ала, хәтта шахматчы картлар да монда. Алар аю биегәнен тамаша кылган кебек, авызларын ачып, шап-шоп кул чабып торалар.

Икенче кич. Яков Борисович салонда клиентларын көтеп утыра. Тиз-тиз атлап Вера Павловна килеп керә. (Ул башкача атлый да алмый, хәзер аяклары аны җирдән түгел, күктән генә йөртә!)

— Яков Борисович!.. Сез аңлата аласызмы моны? — Врач иңнәрен генә җыерды.

— Юк, сез сүз белән әйтегез! Аңлатыгыз миңа.

— Акыл ирешми! Тәмәке ташлауның авыры тәүге көннәре дип раслый фән!

— Ә мин аның шулай булырына башта ук ышандым. Кешеләрне беләм икән! Хезмәт сараенда ничә еллар дәвамында эшләү миңа шулкадәр ярдәм иткән! — Вера Павловна креслога чумып, сирәк керфекле күзләрен, тоныкплафоннарга терәде. — Ә менә сез... кешеләрне белмисез! Белә дә алмыйсыз! Үзегез врач-психиатр, гипнотизер! Кешеләрне белмисез сез.

Бу сүзләрне әйтә алуы белән дә Вера Павловна искиткеч бәхетле иде.

— Белми дисез алайса?

— Аңламыйсыз, аңламыйсыз! Аңласагыз...

Плафоннарның тоныкк үләгәләре Вера Павловнаның зур ачылган күзләрендә чагылды. Ул бәхеттән чытырдатып күзләрен йомды, ябык бармаклары сизелер-сизелмәс кенә калтырандылар.

— Аңласам нишләр идем?

— Кочаклап бер үбәр идегез ичмасам! Шундый кич... Шундый кич! Гарәп әкиятләрендә дә мондый кичләр булмагандыр...

Яков Борисовичның чыраеннан кара күләгә йөгереп узды. Вера Павловнаны аңлый иде ул, аның җаны нәрсәгә сусаганын да бик шәп белә иде! Шунысы, күкрәкләре мимылдаган хатын бу тәҗрибәле буйдакның азгын җаны кемгә тартылганын әлегә белми иде... Белер белүен, белгәч тузыныр, каргар. Тик нишли ала ул? Ританы куып чыгара алмый, алар өч атнадан артык шушы бер мәйданда, бергә яшәргә, яратсалар-яратмасалар да көн дә аралашырга тиеш.

Әллә бу шашкан хатын үбәргә үрелә инде. Чыннан да... Вера Павловна күзләрен йомган килеш авызын очлайтып Яков Борисовичка якыная башлады.

— Нишлисез? Килеп керсәләр?

— Беркем дә кермәячәк, ышаныгыз! Беркем дә сезнең ярдәмгә мохтаҗ түгел! Иптәшлек, арадашлык, бердәмлек һәммәсен җиңеп чыкты. Алар тәмәкене оныттылар да инде...

Яков Борисовичны коткарып ишек шакыдылар. Ул Вера Павловнаның кочагыннан ычкынып:

— Керегез! — дип кычкырды.

Ишектән Харис килеп керде. Бер ялгызы. Аңа яратмыйча караса да, Яков Борисович керүчегә эченнән генә рәхмәт укыды.

— Профессор, — диде Харис юри хырылдап.

— Тыңлыйм, — диде Яков Борисович.

— Ярдәмегез кирәк.

— Кемгә?!

— Миңа!

— Моның булуы мөмкин түгел! — дип ашыгып сүзгә катнашты Вера Павловна.

— Сез чыгып торыгыз әле, Вера Павловна, — диде врач, кара хатынны озатырга ашыгып. — Иптәшнең җитди сүзе бар булса кирәк.

Вера Павловнага бу көтелмәгән визит бер дә ошамады. Врачның үзен чыгарып җибәрүен дә бер дә килештермәде ул, алай да карышмады, башын иеп чыгып китте. Палубадагы җанлы шау-шу аны үзенә суырып алды, йотты, оныттырды. Ул очып диярлек капитан рубкасы янына менеп басты, кичке җил аның чәчләрен туздырды, ул кулларын колашалап авыз янына китерде һәм иң сөенечле сүзләрен җилгә тапшырды.

— Мин уйлап таптым моны! Шулай буласын алдан мин белдем!

Салонда Яков Борисович Харисны карый.

— Телегезне күрсәтегез. Ярый. Кан басымыгыз нормаль, йөрәк тибешегез әйбәт. Нинди зарыгыз бар!

— Үлеп тартасым килә!

Яков Борисович елмаюын учына яшерде.

— Зинһар, кычкырмагыз. Башкаларга кире тәэсир ясар.

— Башкаларда эшем юк. Әгәр коткармыйсыз икән, чыгам да: "Кемдә тартырга бар!" — дип кычкырам.

— Командада сезнең киреләкне генә җиңәрлек көч табылыр дип беләм. Алар иң элек миннән фикер сораячак. Ә мин сезнең тартасыгыз килми дип раслыйм!

— Ничек?

Яков Борисович Харисны җитәкләп алып чыкты, танца өермәсендә бөтерелгән пассажирларны күрсәтте.

— Кемгә ышанырга тиеш мин? Күпчелеккәме, азчылыккамы? Анда арада сездән күп өлкәннәр, сездән алда тарта башлаганнар күп. Нигә алар керми? Нигә зарланмый? Чөнки сезнең тәмәкәне күрәсегез дә килми.

— Килә! Кычкырам!

— Көтеп торыгыз. Мин сезнең энегезне алып киләм. Сез аны шулай дип таныштырасыз шикелле?

— Миңа энекәш законмы? Минем тартасым килә!

Ул арада биючеләр арасыннан бер төркем аерылып чыгып, врач ягына килә башлады. Яков Борисовичның коты ботына китте, әгәр болары да шушы кеше сүзен кабатлап тартырга таләп итә башласалар.

Иң алдан Иван Велягурский атлый. Аңа Покуль, Кривин, "квартет"ның башка членнары ияргән. Харисны күргәч тә, Велягурский кычкырып җибәрде.

— Менә ул!

— Ә без аны эзлибез.

— Монда нишлисең син, туганкай? — Бусын йомыкый Покуль әйтте.

— Шулай моңаеп торалармы? — Бусын — Кривин.

— Әйдә, хәзер үк уртага кер! Бие, шатлан! Без сине кичәдән бирле күзәтәбез, балтасы суга төшкән кеше кебек йөрисең. Болай ярамый. Рөхсәт юк! Син гомуми атмосфераны бозма инде, туганкай. — Бу озын сүзне Велягурский тезеп чыкты.

— Ни хәлләр, егетләр? — дип сорады батыраеп Яков Борисович.

— Шәп! — диде йомыкый Покуль.

— Белгән булсам! Хатынны да алып чыга идем. Хатын минем... Гаҗәп! Кызлар да шәп!

— Тартасы килмиме соң? — дип сорады тагын да батыраеп врач.

— Оныттык без аны! Моңарчы җүләр булганбыз. Ташлауның шулай җиңел икәнен белгән булсам... — Бусын Покуль әйтте дә каядыр ашыга башлады. Аны шунда ук эләктереп алдылар.

— Кая?

— Нюрага хат язасы бар!

— Хат нәрсә ул? Иртәгә без үзебезнең бригадага телеграмма сугабыз. Текстын да әзерләп куйдык.

— Ничек? — дип кызыксынды врач.

— "Тәмәкене ташладык, рәхәт чигә башладык!" Шәп бит ә?

Велягурскийга ияреп бөтен җыелганнар көлде, хәтта Харисның да йөзе үзгәрде, ай-ваена карамыйча аны да ияртеп алып киттеләр. Биюләр кызды, халык шашып-шашып, онытылып бии, сөенә, шатлана иде.

Югарыдан карап торган Яков Борисович кына моңсу, ул: "Моның булуы мөмкин түгел! Юк, мөмкин түгел", дип кабатлый...

Аулакта Рита белән Алим үбешәләр. Ашыкканнар дип үпкәләп булмый аларга. Бөтен кеше хәрәкәттә, бөтен җирдә җанлылык, яңарыш, тик торган бер генә кеше дә юк...

— Тарих факультетында укыйсың алайса?

— Тарих...

— Нинди белгечлекне сайладың?

— Борынгы кулъязмалар белән шөгыльләнәм. Бик кызык фән ул...

— Инде икенче көн узып китте, әле синең китапларыңа тотынганың юк...

— Моңа мин гаепleме?

— Мин гаепле алайса? — Кыз юри генә читкә киткән булды.

— Өлгерермен... Әле көннәребез бар!

— Абыең белән дә була алмыйсың.

— Мина син бар.

— Ә, беләсеңме, Алим!.. Түгәрәккә язылырга бирәү дә килмәде. Бик нык теләп, бик нык көтеп утырдым. Хор оештыра алмам, ахрысы...

Алим кул изәп күрсәтте:

— Әнә ич, нинди матур җырлыйлар.

— Мин оештырмадым шул аны.

— Син оештырдың, Рита. Кичә син башлап җибәрдең. Синең кодрәтеңә буйсынып башланып китте бу күмәк җыр.

Кыз галәттән тыш нык сөенде, егетне кочаклап ук алды.

— Син чынлап сөйлисеңме?

— Чынлап булмыйча!

— Син һәр чакта да бары тик дөреслекне генә әйтәсеңме?

— Шигең бармы, Рита?

— Минем түгел, абыйның.

Алимның тәне буйлап ниндидер ут чабып узды.

— Ә аның нинди шиге бар?

— Чемоданнарыгыз артык зур, ди. Аннары, сез бертуганнар түгел. Бер яктан да охшамагансыз, төсегез-битегез дә үзгә, ди...

— Тормыш шартлары кешенең характерын билгели. Ә характер йөзгә, кыяфәткә чыга. Мин абый кебек яшәргә теләмим! Яшәмәм дә!..

Тагын бер көн уза...

Тагын бер көн!

Оркестрантлар карышусыз уйныйлар. Уйнамаган бер көй дә калмагандыр! Иртән гимнастика!.. Иртән палубаны юарга чыккан матросларга эш калмады хәзер. Рита белән Алим, шук күңелле квартет, йомыкый Покуль, Кызыл сакал Кривин, яланаяк килеш, чалбар балакларын тезгә кадәр сызганып, бер-берсенә су чәчрәтә-чәчрәтә юалар, ышкыйлар, чистарталар. Кемдер сулы палуба буйлап шуып китә, шугалактагы кебек итеп фигуралар ясап маташа, аны күтәреп торгызалар, мактап күккә чөяләр, тотып алалар. Һәр сүз — көлке, һәр хәрәкәт — уен, күренгән һәрбер кешегә эндәшәләр, аны уртага, хәрәкәтнең үзәгенә тартып кертәләр... Бер кырыйда зур белдерү "Шахмат ярышлары". Шунда ук уенчыларның ничәшәр очко җыйганын күрсәткән диаграмма. Ярышлар белән безгә таныш картлар житәкчелек итә. Шахмат сәгатьләре дә туктап тормый, аларның кнопкалары өстендә бармаклар уйный... Анда да монда да "шах!", "гәрде!", "мат", дигән сүзләр яңгырый...

Берәү музыкантларның трубасын авызына китереп карый, аннан кот очарлык ямьсез авазлар өреп чыгара. Бусы да кызык! Аны гаепләмиләр, "була, була тагын азрак тырышсын..." дип, аны куәтлиләр...

Буш челемен суырып боцман узып китә.

Капитан белән ярдәмчесе сүзсез генә бәхәсләшәләр...

Ресторанда җанлылык тагын да көчәя төшкән.

Повар капитан янына керә.

— Бөтенесе өстәмә сорыйлар. Төшке ашка ике казан солы боткасы пешергән идек, ялт иттерделәр...

— Шулпаны икешәр тәлинкә бирәбез...

— Ипи пешереп өлгертә алмыйбыз!

— Нишләргә?

— Буфетка запас консерваларны чыгарыгыз. Портка керү унике көннән соң гына каралган. Шуңа кадәр түзәргә туры киләчәк!..

Матрослар складтан тартма-тартма ризык ташыйлар... Прәннек, печеньелар, балык консервалары. Буфетчының кулы-кулга йокмый, үлчәү табалары туктаусыз биеп тора, пассажирлар үлчәү табасыннан төшкәнне генә көтеп торалар, юлда ук шытырдатып прәннек кимерергә тотыналар, консерваларны кашык белән каерып алып, авыз тутырып ашыйлар...

Зур-зур кәстрүлләрдә буларын сикертеп аш кайный. Кәтлитләр кыза. Аш бүлүченең хәле беткән, ул аз гына хәл алырга теләп стенага таянып та өлгерми, официанткалар буш тәлинкәләрне китереп тезәләр.

— Өстәмә бармы?

— Сорыйлар!

— Ни булган аларга? Күпме йөзеп мондый тамашаны күргән юк иде.

Капитан аптырап, Яков Борисович янына барды.

— Нишләргә?

— Бирән чире булмагандыр? Анысы шулай. Тәмәке тартуны ташлагач, аппетитлары ачылган. Рәтләнер. Борчылмагыз...

Матрослар складның иң караңгы почмакларыннан ризык тутырган тартмаларны сөйрәп чыгаралар. Аш бүлүченең чүмече Мәскәүнең иң җанлы урамнарындагы регулировщик таягы кебек ялт та йолт ялтырап

кына тора. Тәлинкәләр тезелеп бара, кашык-чәнечкеләр уйнаклап кына тора... авызлар рәхәтләнеп чапылдый.

Өстә бер ялгызы Вера Павловна басып тора. Дингез тын әле,ерактагы ярларда сирәк-мирәк кенә утлар жемелдәп ала. Ачык тәрәзәләрдән кичке аш өстәле янындагыларнын сүзләре янгырап чыга. Сыраны да тост әйтә-әйтә эчәләр!

"Әгәр берәр кеше үткәндәге ялгышлар турында сүз кузгатса — аны бассейнга ыргытабыз!" "Әгәр берәр кеше безне үткәндәге эшләребезгә кире кайтырга өнди башласа — аяк-кулларын сындырабыз!"

"Инде берәрсе безне икеләндерергә маташса — эссе табада куырабыз!"

Өченче тост янгырагач, Харис түзмәде, йонлач йодрыгы белән өстәлгә китереп орды. Тәлинкәләр ямьсез шалтырап биештеләр, биештеләр дә тындылар. Теплоход бөтен гәүдәсе белән жинел генә дерелдәп гүли, кешеләр тирбәлеп, оеп, куанычларында онытылып баралар да баралар...

Харис кичләрен хәзер чыгып йөрмәскә тырыша. Кайта да ята. Ята да уфылдый. Сонгы көннәрдә бөтенләй сөйләшкәне дә юк, Алимга да эндәшми, башкаларны да күрмәмешкә салына. Яков Борисовичка да күзен акайтып кына карый... Һәм иң гажәбе —тәмәке тартасы килми!..

Бүген шулай да түзмәде, Алимны көтеп алды, керә-керешенә сорау бирде:

— Ни хәлләр анда?

— Чыгып карамасаң да ишетәсендер. Бәйрәм!

— Сиңа да бәйрәмме?

— Миңа да!

— Син бәйрәмне бозарга тиеш. Кем мине бу юлга котырттьі? Кем килеп коткы салып китте? Кемнең миңа бурычы бар? Юлга тоткан акчаларның барысын да сиңа язам. Тауарга тотылган чыгымнарның барысын да син түлисе, чөнки башлаучы син!

Абыйсының шаярмаганын аңлый егет, бик күп сызыкларда аның хаклы икәнен дә таный, тик әлеге көндәлек тормышны, ваемсыз бәйрәмнәр шулкадәр бөтереп алып кереп киткән ки аны, ул гомергә шулай яшәр төсле, бу көннәрнең озынга, бик озакка сузылуын тели ул. Абыйсына мең төрле жавап әзерләп карый: "Көне-төне эшләрмен, Төньяк төзелешләренең берәрсенә китәрмен, Арктикага язылырмын, анда кулы тик тормаганнар аена алты йөзне куа икән!" — дип әйтергә жыена... әйтми, чөнки аның абыйсы алдында авторитеты калмаган. Пассажирлар арасында ул ни әйтсә дә ышаналар, "төпле егет" дип, һәр сүзенә колак салалар. Алим да һәр очракта төпле фикер әйтә ала, каушамый, буталмый, бар халык белән үзен иркен ирекле тота ала. Абыйсы белән икәүдән-икәү генә калдыларммы, авыз эче кибә, теле көрмәкләнә, сүзләренең энәсе-жебе югала. Ничек котылырга бу бәладән? Ничек арынырга бу халәттән?!

— Бозасың! Мин әйткәч, бу тантананы бутыйсың!

— Ничек?

— Чыгасың да: "Түзә алмыйм" — дип, тәмәке тартасың...

Алимның күз алдыннан берәм-берәм юлдашлары уза...

Менә Покуль... Иелеп, елмаеп, өметләнеп Нюрага хат яза...

Исай Маркович кызларын мактап рәхәтләнеп көлә...

Иван Семенович Велягурский юлдашларының күңелен күрер өчен әллә ниләр эшләргә әзер тора...

Хәзер Алим чыгып аларны хак юлдан яздырырга тырышырга тиешме? Акча өчен, мал өчен?!.

— Ишетмәдеңмени? Ботыннан тотып диңгезгә атабыз, диделәр. Баш-аягын капчыкка тутырабыз, диделәр.

— Ә син тоттырма! Исеңне генә калдыр, үзең күренмә!..

Хәзер Алимның йокысы кача...

Хәзер аның күзләре түшәмдә...

Тагын ялгышлык ясадымы ул гомер юлында?!

Яков Борисович Ритага зарлана.

— Эш юк миңа, Ритуля... Эч поша!

Рита аңа кул болгый да каютасына кереп бикләнә. Төннәрен командадан кала теплоходта бер генә кеше йокламый. Ул кеше — Яков Борисович. Ул медицина китаплары караштыра, үзенең иске язмаларын актара һәм бер җөмләне кабатлый: — Моның булуы мөмкин түгел! Тәмәке болай җиңел ычкындыра торган чир түгел. Ин көчле агу! Иң астыртын наркотикларның берсе!.. Тавык төшенә тары керә. Вера Павловна төшендә дә шул ук бер сүзне сөйли: "Мин уйлап чыгардым моны! Шулай икәненә кешеләрне мин ышандырдым!"

Алим аркасы белән борылып ятса да, абыйсының кыштыр-мыштыр чемодан ачканын ишетте. Сикереп торды.

— Кагылма, абый!

— Кагылсам? Товар синеке түгел, минем акчага алынган.

— Хәзер Вера Павловнаны уятып алып киләм!

— Яныйсыңмы миңа?!

— Бурычлы булып калмам. Үләргә җыенмыйм. Бише белән кайтарырмын. Зинһар, мине көлкегә генә калдырма!

Харис чемоданны ачты, башта бер кирпеч тартып чыгарды, аннары икенчене...

— Китаплар ди бит... Студент!

Нидер хәтерләп Харис киштәдәге чемоданнарны да тартып төшерә, аларның һәр икесеннән дә икешәр кирпеч чыгарып идәнгә тезеп утырта.

— Берәрсе күрсә, абый?

— Теләсәң нишләт! Куркасың икән, чыгар да ыргыт!

Алим кирпечләрнең алтысын да аслы-өсле тезеп күтәрде дә тезе белән ишекне ачты, башын тыгып карады һәм яшен суккан кебек артка сикерде. Коридорның аргы башында, теге дөньядан чыккан өрәк сыман Яков Борисович басып тора һәм бик тырышып тыңлана иде.

Егет кабаланып кирпечләрне берәм-берәм карават астына эшерде дә сузылып ятты...

Диңгез өсте сизелерлек шадраланган, дулкыннарның чап та чоп теплоход бортына килеп бәрелгәннәре дә ишетелеп тора. Ләкин көндәлек режим әле бозылмаган. Вера Павловна төркемнән-төркемгә чабып йөри. "Хәлегез ничек, күгәрченкәйләрем! Исән-сау тордыгызмы?" Иван Семенович аңа баш бармагын күрсәтә, бүтәннәр дә аңа ияреп Велягурскийның бәясенә кушылалар, төрле яктан хуплау, мактау сүзләре яңгырый. Оркестр күңелле көйләр, маршлар сыздыра. Халыкның чак кына салмаграк маташканын беренче булып Рита күрде, сизде:

— Егетләр, чак кына акрынрак! — дип кычкырды.

Егетләр музыканың темпын киметтеләр, гимнастика ясаучылар барыбер ритмга ияр алмыйлар иде...

Иртәнге аштан соң Вера Павловна каютасына делегация килеп керде. Алдан Велягурский, Покуль да монда, Исай Маркович ишек төбендә кала.

— Хөрмәтле Вера Павловна?!

— Тынлыйм. Бер-бер зарыгыз бармы әллә?

— Юк, һәммәсе менә дигән. Шулкадәр акыллы уйланылган! Үзебез дә шаккатабыз: күңелләребез көр, берни турында уйламыйбыз, берни өчен борчылмыйбыз. Тик бер җитди үтенечебез бар.

Вера Павловна телсез калды, ул күзләрен шарландырып депутатларга текәлде.

— Тартыргамы? — дип сорады ул шыпырт кына.

Керүчеләр шаркылдап көлеп җибәрделәр.

— Аны онытттык без! Кирәкми! Зинһар, искә төшермәгез.

Вера Павловна айдай балкып, сикергәли башлады. — Утырыгыз

әле, иптәшләр. Нигә басып торасыз. Урын тарлыкка карамагыз! Анын каравы күнел кин... Йә-йә, тынлыйм. Уф...

— Сәгать дүрттә әндри әбәтендә коры-сары чәй бирәләр. Чәйне бик тәмле пешерәләр. Яратып эчәбез!

— Шунда бирәр кайнар ризык та пешереп булмасмы икән? Безнеңчә, моны искә алырга кирәк!

Вера Павловна каушады.

— Иптәшләр, иптәшләр! Без болай да... Команда алдында уңайсыз. Кок болай да көн аралаш капитан янына зарланып керә.

"Депутатлар" бер-берсенә уңайсызланып карашып алдылар. Иван Семенович бу карашның мәгънәсен аңлатып бирде:

— Безнеңчә, моны искә алырга кирәк! Һәрберебезнең организмы үзгәреш кичерә!

Вера Павловна юату сүзләренә оста иде, һәркемнең аркасын иркәләп какты да, Исай Марковичка: "Ничек, кызларга радиограмма җибәрәсезме?" — дияргә дә өлгерде һәм туп-туры капитан янына кереп китте. "Депутатлар" аны көтеп калдылар. Ул ерактан ук кул болгап кычкыра башлады:

— Булды! Хәл иттек! Тап-таза матрослар трюмнан кәбестә мичкәләре тәгәрәтеп меңгерәләр, сәфәрчеләр арасыннан ирекләләр зур-зур пычаклар белән эре тәнкәле балык чистарталар. Бәрәңге кабыклары өзелмәс чылбыр булып түгәрәкләнеп олы колашаларга төшеп тора. Дәү-дәү кәстрүлләрдә су кайный. Кухня ду килә!..

Кич. Салоннарның берсендә Яков Борисович клиентларны көтә. Икенче салонда җитди кыяфәт белән Рита утыра.

Алимның кергәнен күрсә дә, Рита аңа борылып, күтәрелеп карамады.

— Ни булды сиңа, Рита?!

— Күрмисеңмени? Атна узды, беркем хор түгәрәгенә язылмый. Беркем мине тыңламый! Беркем мине санламый! Беркемгә дә минем кирәгем юк!..

— Беркем мине санламый иде! Беркем мине тыңламый иде! Беркемгә дә кирәгем юк иде минем! Хәзер барысы да үзгәрде.

— Ни сөйлисең, Алим?

— Гафу ит, үзем белән үзем сөйләшәм икән. Син миңа кирәк. Терелт мине, яз хорга! Бүгеннән, шушы минуттан башлап мин синең тугры укучың. Өйрәт җырларга?!

— Бер кешедән хор булмый.

— Рита... — Алимның күзләре нидер әйтергә теләп елтырадылар.

— Тс-с...

Шактый ук сытылып Яков Борисович килеп керде. Аңа Вера Павловна ияргән иде.

— Минә күрегез! — диде врач, ярсып. — Монда да беркем юк.

— Нигә булмасын? — Рита кыюланып Алимга төртеп күрсәтте.

— Моның белән ни әйтергә телисең, Яков Борисович?

— Ялганлыйлар алар безне! Төннәрен бикләнеп каюталарында пыскытып яталар. Мин ышанмыйм аларга! Мондый хәлнең булуы мөмкин түгел!

— Мөмкин! Мөмкин! — Вера Павловнаның бөтен кыяфәтенә җиңү тантанасы чыга.

— Әлбәттә, яшертен тикшерү яхшы нәрсә түгел... Алай да, инде сез беркемгә дә ышанмагач, әйдәгез, шаһитлар алдында, әйләнеп керик. Карыйк. Тыңлыйк.

— Исәнәник! — диде мыскыллап Рита.

Алдан тәҗрибәле сунарчы кебек Яков Борисович бара. Аның артыннан җитди, җиңүчән кыяфәт белән кыптыр-кыптыр Вера Павловна теркелди. Көлеп җибәрелмәсен өчен учлары белән авыз-борыннарын каплаган Рита белән Алим алардан ике-өч адым калыбрак, янәшә баралар,

терсәкләре белән тӛрткәләшәләр. Аларга кызык, тамаша! Яков Борисовичка кайгы! Кӛчсез булып калды ул шушы халык алдында, аларны аңламады...

Юк! Бер җирдә дә тәмәке тӛпчеге юк! Әһә! Менә берәү! Яков Борисович иелеп алды да, күзенә якынрак китереп карады. Бӛтереп ташлаган кәгазь кисәге генә икән!.. Ӛске каттан аска тӛшteләр. Монда да тынлык. Ишекләрдән бӛркелеп тӛтен чыгып тормый. Алай да коерыкка җитәрәк Яков Борисовичның куш йодрык сыярлык борын тишекләре киерелеп, киңәеп китте. Ул сул кулын күтәреп, башкаларга сак булырга боерды. "Ӛстенә барып чыгыйк!" Хәзер башкалар да сизде, татлы тәмәке исе килә иде. Тарталар! Качып тартып яталар!.. Алар йӛгереп диярлек коерыкка килеп чыктылар. Анда бортка терсәге белән таянып, боцман челемен тарта икән. Врачның аяк тавышын ишетеп, ул нигәдер сискәнеп китте, борылып карагач, сүрән генә елмайды.

— Ах, бу сезмени? — диде ул.

— Бу сез икән, — диде врач та.

— Тормышмыни бу?! — Боцман челемен шакы-шокы кага башлады. Кем аркасында газап чигәбез? Кӛне буе челемгә тотынырга куркып йӛрим. Тәмәке юлдаш бит ул, юаныч! Бигрәк тә юл йӛргәндә...

— Зинһар, моны башкаларга әйтмәгез! — дип ялынды Вера Павловна.

— Тартасың килми икән, ташла. Ӛендә ташла! Менә бит нинди заманга чыктык: тәмәке ташлатуны да дәүләт эше дәрәҗәсенә күтәрәбез! Тәмәкечеләрнең күңелен күреп, махсус рейслар оеша!

— Дәүләт күләмендәге эш дип, сез дӛрес әйтәсез!

Вера Павловна тагын нинди акыллы фикерләр әйтер иде, анысы билгесез калды, Яков Борисович боцманны култыклап алды.

— Пассажирлар арасында кагыйдә бозучылар күренми шикелле?

— Шуңа гаҗәпләнәм дә! — Боцман челеменә ярты уч тәмәке тутырып, кабызып җибәрде. — Тартканымны беләләр. Күрәләр дә! Беркем килеп сорап карамый! Мин тугыз тапкыр ташлап, тугызында да дүрт-биш кӛннән тарта башладым.

— Хәлләр бар монда! — дип сузды Яков Борисович.

— Мин тәкъдим иттем бу сәяхәтне! — дип, сӛенеп ачыклады Вера Павловна.

Рита белән Алим шыпан-шыпан гына моннан ычкынганнар иде инде. Алар күләгәгә кереп, тын гына үбешәләр...

Тагын таң ярылды. Тагын кӛн туды. Теплоходта гадәти кӛн башланды. Тик күк йӛзендә беренче мәртәбә болыт куерды, диңгез ӛсте каралды. Тып-тып килеп тӛшкән җирендә тӛртке-тӛртке юеш эзләр калдырып, яңгыр сибәләп узды. Кайдадыр, бик еракта, юаш кына, сузылып кына күк күкрәде. Болытлар тиз таралды. Яңгыр ашыгып узды. Оркестрант-лар инструментларын күтәреп чыкканда кӛн аязган иде инде.

Яңгыргамы, җилгәме, халык бүген әлләни күп түгел иде. Алай да җыелганнар бераздан җанландылар, сүз күбәйде, гимнастика ясый башлады-лар. Рита күзе белән һәммә кешене капшап чыкса да, арадан Алимны тапмады. Алим юк... Иван Велягурский җитәкләгән "квартет" та чыкмаган. Кызыл сакал Кривин да күренми, Покуль да арада юк иде...

"Квартет" гимнастикага чыгарга әзерләнгән иде инде. Бүген алар һәммәсе дә озаграк мыштырдадылар, электробритвалары сузылыбрак выжылдады. Инде палубага күтәреләбез дигәндә генә арадан берәү:

— Егетләр, ә Гавриил Николаевич кичен күренмәде! — дип әйтеп салды. Юрау китте:

— Чирләгәндер бәлки!

— Салкын тидермәдеме? Бассейнда озак чупылдаган иде.

— Керәбезме?

— Керәбез.

Гимнастикага чыкмаска сәбәп табылуына сӛенгән сыман, алар

парлашып, ләкин артык ашыкмыйча Покуль каютасына барып керделәр. Ул койкасыннан тормаган да иде әле. Юынмаган, кырынмаган, кичтән салып ташлаган кием-салымнары теләсә кайда аунап ята, бер туфлясы ишек катына ук килеп житкән. Чибәр генә, авызын сөйкемле ерып төшкән хатын-кыз фотосы өстендә теш щеткасы... Яңаклары эчкә суыры-лып кергән, ябыккан, ямьсезләнгән Покуль юлдашлары кергәч торып утырды, тезләрен кочаклап, томанлы күзләре белән еракка, күз күрмәгән якларга карады.

Иван Семенович тавышына көрлек өстәргә тырышып:

— Син нишләп болай әле? — дип сорады.

— Үзегез генә чыгыгыз инде, егетләр.

— Бергә сәфәр чыктык. Сүз биреештек. Кул кысыштык. Атна буе туганнарча яшәдек. Хәзер аерылышабызмы?

— Мин, мәсәлән, аеры яшәүне күз алдыма да китермим! —диде "квартет" егетләренең берсе.

— Сезнең рәхәт, — дип ыңгырашты Покуль.

— Ә синең?

— Әгәр чынлап торып яратса... Әгәр тормышын миңа бәйләргә уйласа... Аз гына мәрхәмәте, шәфкате булса... шундый авыр шарт куяр идемени?!

— Кемне әйтәсең, Гавриил Николаевич?

— Билгеле инде... Нюраны!

Һәр сүзгә уңайлы дәвам таба торган жор, кыю Велягурский да сүзсез-өнсез калды. Ачык ишек катында күренгән кызыл сакал Кривин да эндәшмәде. Ничек керәсе иткән әле Исай Маркович?.. Әллә аның да кәжәсе килеп, кәефе кырылганмы?!

— Чынлап яратса, болай интектермәс иде. Тотар иде дә чыгар иде! Мондый катылык, мондый кешелексезлек. Мондый авыр сынау!..

"Тәмәке ташлатып жәзалау... Oho-ho!" — дип бөтәннәр гөрләгәндә, Велягурский сорауны туп-туры куйды:

— Тартасы киләме?

— Үләм!

— Чыда, дус кеше. Түз! Узар! — дип аны юатырга тырышса да, Иван Семеновичның тавышында да элеккеге ышаныч, элеккеге ныклык юк иде. — Менә мин... — дип тагын бер кат жепнең очын үз кулына алырга маташса да, бу юлы иптәшләре аны бүлдерде:

— Сөйләмә инде, Ваня!

— Бетәбез инде!

— Ашыйм-ашыйм, мантымыйм, эч суырылып керде.

— Төшемдә гел жен-пәриләр, убырлар күрәм!

— Бар иде рәхәт көннәр! Кайткач ашап-эчеп алыр идең дә, үз караватыңа сузылып ятып, рәхәтләнеп берне көйрәтер идең...

— Үзебез теләп ожмахтан качканбыз!

— Ни өчен бригада өчен газап чигәбез!

"Квартет" сөйләгәндә Исай Марковичның да сүз арасына кереп, үз фикерен кыстырасы килгәне күренеп тора иде, ул кукәй салырга ашыгып чират көтеп торган тавык кебек, әллә ничә мәртәбә муенын сузып "ых-ых!" дип әйтеп алды, әмма "квартет" члennарының түземе беткән икән, алар бер-берсенә өстәп, ташка кызуны сала гына тордылар.

— Тарта идек, планны үти идек. Нәрсәгә ул безгә бригада даны? Рәхәтләнеп тартырлык булмагач эшмени ул?!

Ниһаять, Исай Марковичка да чират житте. Ул йодырыкларын һавада уйнатып алды:

— Хатынның үзен иртәсе калган. Күрер иде ул минем нинди газаплар кичергәнне. Хатын шәп минем! Искиткеч. Сиңа Нюра белән безнең кебек яшәргә язсын!..

Алар сөйләгән арада Гавриил Николаевич урыныннан торды, киенде, чырае минутлап түгел, секундлап яктыра барды, ниһаять, ул биеп жибәрде.

— Егетләр, сез мине терелттегез ләбаса! Бер мин генә җебегән, ихтыярсыз адәм дип көн туды исә үземне чыбыркылыйм. Кичә Нюрага хат та язмадым хәтта! "Тәмәке ташлатыр өчен җибәрмәгән, сынар өчен олактырган бу мине!" дим. Моңарчы сезгә әйтергә кыймый идем...

— Егетләр, — диде Кривин шыпырт кына. — Тартырга алып кердегезме соң?

— Юк, — диде Иван Семенович.

— Миндә дә юк!

— Баш җитмәгән.

— Шыр тиленәр без, — дип йомгак ясады Покуль. — Шунда тутырып кына керәсе калган да бит!

Үкенешеп, тел шартлатып, аңгыраеп шактый утырдылар болар.

Иң беренче булып Велягурский акылга килде.

— Иптәшләр, диде ул. — Юкка без болай... Кирегә сукалый башладык. Гавриил Николаевичка ярдәм итәсе урынга, без аны котыртабыз булып чыга түгелме? Без аңа ярдәм итәргә, тартуны онытырырга тиеш.

Борыннар ныграк салынды, чырайлар җимерелде!

— Алай да... — диде Исай Маркович кычкырып ук. — Ихлас яратса, шундый иләмсез шарт куяр идеме?

— Кемне алдыйбыз без?! — дип тузынды "квартет"тагы яшь әтәч. — Күрәм, барыбызның да үлеп тартасы килә. Нигә бер-беребезгә ялганлап маташабыз? Ичмасам, дөресен әйтик.

— Ярамый алай, — диде Иван Семенович. — Гавриил Николаевич ташларга тиеш. Нюраны яратамы? Ярата. Өйләнү өчен бер генә, нәни генә тоткарлык калган. Без аңа булышырга тиеш. Ирләрчә. Үзебез корбаннар биреп булса да... Коллективны таркатмыйк, берни дә булмаган кебек, көлә-көлә юлдашларыбыз янына чыгыйк, көлә-көлә иске гадәтләргә каршы көрәш алып барыйк! Мин Покульне кызганам.

Аны аңладылар, карышмадылар.

— Нишлибез соң?

— Бүгеннән һәрберебез берәр стакан көнбагыш паегы ала башлый!

— Ур-ра! — диде мыскыллап көлеп Исай Маркович.

— Ур-ра! — диештеләр башкалар да.

Тынлап карыйлар, музыка күптән тынган. Тыңлап карыйлар, тавышлар ишетелми.

— Егетләр! Без иртәнге ашка соңармыйк тагын!

Бик ашыгасылары килә, ашыкмыйлар. Бер-берсен узып барасылары килә, аяклары атламый. Барысы да кызганып, зур бер теләктәшлек белән Гавриил Николаевичка карыйлар... Язмыш нинди зур сынаулар җибәргән янәсе!..

Иртәнге ашка җыелган пассажирлар аларның буш урыннарын шунда ук күреп алды. Көтеп торганнар диярсең, һәммәсе шул турыда гына сүз куертты.

— Качканнардыр әле!

— Шуңа гел бергә йөргәннәр икән!

— Кая качсыннар. Бик качар иден дә...

Кашыклар бүген авырайган, чәнечкеләр ялкауланган, авызлар салынган — шапылдап тормый. Пассажирлар түшләре белән өстәлгә ятып, йөзләрен яшереп, ризык тирәсендә чемченәләр, ипи телемнәре Хеопс пирамидасы кебек өелеп тик утыра. Чәй эчүче юк.

Тегеләр балкырга тырышып, җорланып, түш киереп килеп кергәч, кашыкларга аз гына җан керде, пычак-чәнечке тавышлары да яңгырады, куллар ипи телемнәренә сузылды... Өстәлләр тирәли Вера Павловна йөреп чыкты. Тукталып тормады, кыстамады, сүз катмады. Буш урын каршындагы тәлинкәләрдә шактый гына ризык калган иде. Аш бүлүче озын чүмечен селкеп боегып басып тора. Официантлар:

— Кемгә өстәмә? Кемнен ашыйсы килә? — дип сорап карасалар да, берәүдән дә тавыш-тын ишетелмәде.

Кок капитан янына керде.

— Әллә әндри әбәтен пешермәскә инде? Кичә дә байтак ризык калды, — диде.

— Врач белән киңәшегез, — диде капитан.

— Нәрсә киңәшәсең аның белән? Берни дә аңламый. “Болай булырга тиеш түгел”, — дип кабатлаудан ары эше юк.

— Ә Вера Павловна?

— Анысы да... “Шулай булырга тиеш!” — дип сайрый...

Капитан да борчулы...

Дингез өсте караңгыланганнан-караңгылана бара. Дулкыннар чайканып-чайканып теплоходны төрле яктан кыйныйлар. Моторлар тавышы бөтенләй ишетелми дә диярлек. Халык каюталарда. Палубалар буш. Палубалар кешесез...

Салоннар да буш. Яков Борисович ялгызы.

Вера Павловна килеп керде дә сүзсез генә креслога кереп чумды. Теле белән:

— Мин бик бәхетле бит, Яков Борисович! — дисә дә, чырае төксе иде аның бүген.

Яков Борисович жанланып, кызыксынып күтәрелеп карады.

— Тик сез минем бәхетемне уртаклашырга жыенмыйсыз.

— Ничек була ул “уртаклашу”?

— Ничә еллар сезне яратып йөрим!..

— Миннән дә шуны көтәсезме?

— Алдагыз ичмасам! Бүген алданасым килә! Беркем дөресен сөйләмәсен иде! Була икән, шундый чак та житә икән...

— Сез бүген әллә ничегрәк...

— Чынын әйткәндә, Яков Борисович, мин куркам.

— Кеше һәрвакыт нидәндер курка!

— Сез бүген берни дә ишетмәдегезме?

Яков Борисович житдиләнде, сагайды.

— Юк.

— Мин бит авыл кызы. Театр училищесына керергә дип шәһәргә килдем дә... Барыбер авыл кызы булып калдым! Бабам бар иде минем, умартачы. Бар дип, хәзер дә исән. Кортлар гөжләвен ярата идем... Тыныч, кояшлы көннәрдә шундый матур аларның күмәк тавышлары! Очалар, куаналар, бал ташыйлар... Берзаман умарта тирәсендә шомлы, хәвефле тавыш өстенлек ала! Димәк, кортларга аерылырга вакыт житте дигән сүз. Бүген көне буе теплоходта шундый шомлы гөжләү ишетәм... Сез игътибар итмәдегезме?

— Минем бабай итек тегүче булган, итекче!

— Куркам мин, Яков Борисович. “Берни дә юк!” дип алдагыз ичмасам... Без бит алдауларга, юатуларга шундый күнеккән... Гомер буе алдаганнар, алданганбыз...

Сүзне аяк тавышлары бүлдерде. Дәү корсагын, иләмсез зур ак калфагын чайкалдырып, кок килеп керде.

— Күпме ризыкны дингезгә түгәбез. Монда хайваннар фермасы юк. Куян да асрамыйбыз. Үзләре “давай” да “давай!” дип якага ябыштылар, ә хәзер кабып та карамыйлар! Калдыралар. Махсус рейс, авыр пассажирлар дип команда өлешенә кереп, ризык нормасын арттырдык. Аңламыйм. Ни булды? Соңгы көннәрдә ни үзгәрде?! Һава дисәң, шул ук... Аш әзерлисе килми...

— Күрәм, — дип ачы көлемсерәде Яков Борисович. — Тәмәкече юлдашларымнан бигрәк, командага ярдәм кирәк икән миннән! Аларда ышаныч кимеп бара.

Кок барында иреннәрен кысып утырган Вера Павловна сикереп торды:

— Минә күрдегезме? Ишеттегезме?!

— Ишеттем. Сагаеп, көтеп тә торам. Ләкин нишләргә, нинди чарага керешергә кирәклеген аңлап бетермим.

Гасабиланып, бер-берсен күрмәскә тырышып, шактый дөмегеп утырдылыр. Сискәндереп ишек ачылды, аннан "квартет", Покуль һәм кызыл сакал Исай Маркович килеп керделәр.

Салонда киеренкелек урнашты. Киеренкелекне арттырып каяндыр Рита килеп керде, ишек катына җыелганнарны аралап уртага узды, Яков Борисович янында чит кешеләр барлыгына игътибар да итеп тормастан:

— Абый, алар мине тыңламыйлар! — дип җылап та җибәрде.

— Сиңа да мин кирәк булдыммы? — дип юатты аны врач. — Кем тыңламый?

— Бөтенесе дә! Оркестр уйный, мин көйне, җырчыларны эзгә кертергә тырышам, алар юри бозалар. Берсе "Подмосковние вечера"ны суза, икенчесе әллә кая "Вдоль по Петерской"га кереп китә!

— Балакай! Оешкан хорың юк әлегә?!

— Монда эшлисе эшләр бар, — дип кыстырды Вера Павловна.

— Дусларым, — диде йомшак кына Яков Борисович. Рита кергәннән бирле аның үзгәрүе Вера Павловнаның очлы күзеннән ычкына алмады. — Әле эшнең башы гына. Минемчә, безне алда зур сынаулар көтә. Иптәшләр килгән, көттермик. Сез минем янгамы?

— Сезнең янга, доктор.

Вера Павловна күз яшьләрен сөртеп утырганРитаны алып чыгып китте. Кыз:

— Алим, Алим! — дия-дия чыкты.

— Нинди акыллы кыз! Егет тә табып өлгергән! — дип кычкырып калды Вера Павловна. Аның шунда ук Яков Борисович янына борылып керәсе килде, чак кына түзеп, тыелып калды. Эчтә кызып-кызып нидер сөйләшәләр иде.

Иван Семенович салон тәрәзәләрен ябып чыкты.

— Нигә мондый саклык чаралары кирәк? — дип көлде врач.

— Тиздән аңларсыз, — диде Кривин.

— Егетләр, бәлки кирәкмидер? — дип үтенеп сорады йомыкый Покуль.

— Кирәк! — диештеләр "квартет" членнары.

— Үзеңә генә уңайсыз дисең — без дә килдек! Бик теләсәң, синең белән алда да бергә булырбыз!

— Тәмәкеме? — дип сорады врач.

— Үзе! — диде Велягурский. — Тәмәке генә бер хәер иде, гыйшык та бар!

— Анысын әйтмә, — дип ялынды юаш Покуль.

— Барын да белсен! — диде катгый Иван Семенович. — Монда, Гавриил Николаевич, яшерен эш юк. Минә шул. Сиңа тәмәкене ташларга кирәк.

— Котыл син аннан! — диде Исай Семенович.

— Яратып йөргән хатынына "ташлыйм!" дип вәгъдә биргән.Хатын шунсыз "сиңа чыкмыйм" дигән. Ә ул... Гел шул турыда гына уйлый. Көн саен бер әр дәфтәр хат яза. Ничә булды инде хатын?

— Тугыз...

— Уйлаган саен тәмәке тартасы килә.

— Сезнең? Сезнең дә тартасы киләме соң?

"Квартет" членнары бер-берсенә караштылар. Гадәттәгечә алар исеменнән Велягурский сөйләде.

— Әлегә түзәрлек. Ну, иптәшлек йөзеннән, Гавриил Николаевичны ялгыз гына калдырасы килми, без дә тәҗрибә куяннарына әйләнергә риза! Гипноз кирәк безгә, гипноз!

Бер минутка тын калдылар, бу арадагы эшсезлектән, чуалчык уйлардан ихтыяры ифрат йомшаган врач аякларын сузып, кулларын көч

белән тез кумәченә батырып, әчтән генә тантана итә иде. Тәмәкечеләр тын тартырга да базмыйча аның хөкемен көтеп тордылар. Хәзер өмет шушы кешедә, аның кодрәтендә иде.

Алим бик озак Ританы тынычландыра алмады.

— Үзең шуны теләдең. Хыялың хор оештыру иде! Менә, җай чыкты, иртәгәдән эшкә тотын. Хорга катнашучыларның исемлеген төзе. Син оештырган хор менә дигән булачак.

— Юатма син мине!

— Алайса эшкә керешәбез. Әйдә, белдеру язып эләбез!

— Әйдә!

Озак та үтмәде алар зур итеп язылган белдеруне чыгарып та элделәр. "Хор җырларга теләүчеләр иртәнге аштан соң туп-туры салонга килсеннәр", диелгән иде анда.

Егет белән кыз аерыла алмыйлар.

— Килмәсләр, беркем дә килмәс.

— Беренче булып мин киләм, мин язылам, Рита.

— Төп эшеңә зыян килмәсме?

— Укугамы? Өлгерәм!

— Шул кадәр китаплар алып кереп... гел минем янда син, Алим.

— Китаплар төягәндә юлымда син очрарсың дип уйламаган идем.

— Теге кешеләр абый янына гипноз үтенеп килгәнме?

— Мөгаен... Гавриил Николаевич гыйшык чиренә түзә алмый башлаган дип тә колагыма чалынды.

— Гыйшык чиргә әйләнә микәнни?

— Миңа да синең абыеңа ялынып барырга калмаса!..

— Сиңа да шул чир йоктымы?

— Иң авыр формасы! Узмый торганы йокты!

Икесе дә тирә-якларында нидер үзгәргәнен сизәләр: шахмат такталары ятим калган, бассейнда су чупырдамый, домино сөякләре тыныч кына ялтырашып яталар, кешеләр каюталарда. Кешеләр сөйләшмиләр. Әле ачыктан-ачык зарланучы да, шыңшучы да юк.

Ниһаять, дөньяга Харис яралып чыкты. Ул ике кулы белән дә күкрәгән шытыр-шытыр уа-уа Алим белән Рита яныннан ике тапкыр узды инде, дәшмәде. Күз-кашларын гына уйнатып, сикертеп алды.

Алим Ританы озатып кайтканда Харис чалкан ятып ишетелер-ишетелмәс кенә җырлый иде.

Диңгезләрне кичтем, давылларны үттем,
Сәяхәттән җаным туймады.
Өметләнәм әле,
Ышанам әле,
Кочагыма алам дөньяны!..

Алим дәшми. Алим көтә. Харис абый җырлый башлаган икән — инде бу соңгы чик! Нидер тамырдан үзгәргән дигән сүз.

— Кирпечләрне чыгарып ыргытасыңмы, юкмы?

— Җитешермен, вакыт бар.

— Да-а, вакыт бар. Вакыт безгә ярдәмгә тора. Вакыт тегәрмәче безнең файдага зыр-зыр әйләнә. Тик мин сине өлешсез калдырырга булдым.

— Ничек?

— Ничек икәнен алда күрерсең. Беләсеңме, врач ни дип үгетли тегеләрне?! Хәлләрен җиңеләйтмәкче буламы! Белдем, ышандым, берсе дә тартуны ташлый алмаячак! Тәмәкеләре юк икәнен дә ишеттем... Әгәр синең җаның бар икән, кешеләрне аз гына кызганасың икән, "миндә бер пачка калган иде!" дип бүген үк, кеше аягы тынгач, Гавриил Покульга илтеп бирәсең.

— Ә Нюра?

— Нинди Нюра?

— Анын кәләше! Ул бит аңа ташлыйм дип сүз биргән.

— Анысы синең маза түгел.

— Врач бер яктан аларга ярдәм итәргә тели, ә без аңа аяк чалып, иблис сыман Покульне котыртырга тиешме?

— Кем сөйли бу сүзне? Җәбраил фәрештәме? Әллә Газраилме?! Кем уйлап чыгарды? Кем мине юлдан яздырды? Кем котыртты?!.

— Нигә үзең башкармыйсың ул эшне? Мин сиңа нигә кирәк?

Харис туры сорауга туры җавап бирде.

— Куркам мин. Теге чакта әләккәннән бирле гел куркам. Әгәр курыкмасам, сиңа ялынып торыр идемме? Тота идем дә сата башлый идем. Куркам. Мин тикшердем, берәүдә дә тартырга юк. Берәүдә дә! "Үләм!" дип байтак кешегә сүз салып карадым. "Коткарыгыз!" дип күпләрдән ялындым. Үзләре минем хәлдә. Тәмәке исеме чыгуга ук ап-ак булып агарыналар. Алган булганнар, теге атна башында суга ыргытып бетергәннәр. "Суга ыргытабыз", имеш... "Тереләй туныйбыз", имеш. Хәзер бик үкенәләр, юк... Теплоход бер портка да кермәячәк. Керә күрмәсен!..

Харис аны-моны күрерлек хәлдә түгел иде, ары-бире атлаган арада тагын кирпечләргә килеп абынды.

— Чыгарып ыргыт шушы нәрсәләреңне! — дип акырды ул.

— Кеше йөреп тора. Иртән, таңнан ук уянырмын да чыгарып ташлармын. Котылырсың.

Ике караватта ике гәүдә ята. Ике гәүдә генә түгел — ике уй, капма-каршы фикерләр, хыяллар. Акча турында уйламый хәзерге мизгелдә Алим, уйлый алмый, кадалып китсен акчасы! Ул монда үзен кеше итеп сизде, кеше булуның тәмен татыды. Авылда авыру ана. Ятимлек. Аннары абыйсының тозагына килеп капты. Котылу юлын ансат хәл иткән икән ул. Ансат уйлаган. Теплоходка тәмәке төяп керә дә акча көрәп чыга, имеш! Әле күңеленнән ничә тапкыр янады бит! "Кешеләр җүләр", имеш. Ул аларның җүләрлегенә бары тик әшәкелек белән генә җавап кайтара!.. Кешеләр төрле икән... Нечкә күңелле, юкка да күз яше сытылырга әзер Гавриил Покуль!.. Рәхәтләнеп, дөнья тутырып көлеп җибәрә торган Иван Велягурский... Кызларын һәм хатынын үлеп ярата торган Кызыл сакал — Исай Маркович...

Алар юл чатында. Җиде юл чатында да түгел хәтта, ике юл чатында. Пар нарат арасында гына! Заман аларга тәмәке дигән чир йоктырган. Хәзер Алим шул чирнең ялчысы булып, шул әйбәт кешеләр арасында сигарет сатып йөрергә тиеш. Моңарчы аны, студент, әйбәт егет, тыңлаучан дип белгән Покуль белән Велягурский ни уйлар? Исай Маркович нинди күз белән карар? Шахматчы картлар? Рита... Рита... Ах, Рита! Вера Павловна ни әйтер? Ә Яков Борисович тантана итәчәк! Яратмады ул Алимны, бер сәбәпсез баштан ук дошман күрде. Хәзер Рита алдында мактаначак: "Әйттемме мин сиңа... хәтерлисеңме... пассажирлар арасында иң куркынычы әнә шул ике кеше... рас килдеме?"

Әрсез кеше ул Яков Борисович! Җиңә алырмы ул Покульнын гыйшык чирен? Тартуны юксынып тилмерә башлаганнарның хәлен чак-чак кына булса да җиңеләйтерме?

Ритага да хәзер эш артачак! Башланачак хәзер монда хәлләр!

Әллә абзасы күрмәгәндә генә чемоданнарны чыгарып тондырыргамы? Котыласың да эш бетте! Юк, ярамый. Әрсез алабай тавыш-гауга кубарачак! Башка әмәлен табарга кирәк. Тавышсыз-тынсыз гына котылу җаен эзләргә кирәк. Иң элек күз көеге кирпечләрдән котылырга! Кирпечләрдән котылырга, кирпечләрдән... котылырга... ырга... га.

Ул йоклап китте.

Ул тирән йокыда.

Ләкин соңгы көннәрдәге сизгерлек аны сикертеп уятты. Харис

чалкан яткан да гырлый. Гырласын әйдә! Алимнең нишләгәнен күрми калсын. Ул торды. Ипләп кенә киенде, ишекне ачып куйды. Бергә алып чыгаргамы, әллә берәм-берәм тондырыргамы? Ул ике кулына да өчәр кирпеч тотып палубага чыкты. Әле бөтен кеше йокыда. Теплоход дрейфта, ахрысы, барганы да сизелми. Салкынча икән, жил.Дулкыннар кабарып-кабарып йөгерешәләр. Бигрәк әйбәт, кирпеч төшеп су чупылдаганы ишетелмәс!..

Бортка килеп життем дигәндә генә артында аяк тавышлары ишетеп, ул ялт кына борылды...

— Тс-с, — диде Исай Маркович.

— Тс-с, — дип куәтләде аны Алим, нигә пышылдаганын да аңламыйча.

Исай Маркович кирпечләрне күрсә дә, төпченеп тормады, китеп барды. Ул палубада йөргәндә диңгезгә кирпеч ыргытып булмый инде. Ни уйламаслар...

Алим каютага борылып керде, утырып азрак көтеп торды, кирпечләрен кочаклап кире чыкса... күзе шар булды!

Иван Семенович Велягурский Гавриил Покульне житәкләгән, алар тып-тып каядыр ашыгалар иде.

— Кемнән качасыз болай? — Алим сорамыйча түзә алмады, иртәнге йөгерешчеләрнең кыяфәте мәзәк тә, серле дә иде. Киемнәре дә өсләрендә алак-шалак кына элэгеп тора, кабаланып киенеп чыкканнар, як-якларына каранала... Жавап урынына сорау бирделәр егеткә:

— Нишләп күтәреп йөрисең боларны?!

— Мин... алар миңа гантель урынына! — Һәм Алим кулы саен өчәр кирпеч тотып чүгәли, тора башлады, булдыра алган кадәр кыйланды. Артына борылып караса — жилләр искән, Покуль да юк, Велягурский да. Инде тәвәккәлләп кирпечләрне диңгезгә тондырам дигәндә генә "квартет"ның калган өч вәкиле дә уянып, йокылы күзләрен йодрыклары белән уа-уа, кыптырдап килеп життеләр. Алим аларны күргәч, "гантель"ләре белән күнегүләр ясый башлады. Кирпечләрнең кызыл комы битенә коелды. Чая егет аның тирәсендә әйләнгәли башлады.

— Яшь чактан ук кирпеч күтәреп гадәтләнгән. Юлга да алып чыккан идем, — дип мыгырдады Алим.

— Ә-ә...

Алим тагын чүгәли-күтәрелә башлады. Хәзер кирпечләрне ыргытырга ярамый да инде! Ничә кеше күрде? Нишлисең, авыр сулап кирпечләрне каютага алып кереп, берәм-берәм караватастына яшерергә туры килде. Алай да бая очраганнарның сәер, мәзәк кыяфәте, берәм-берәм дә, күмәкләп тә каядыр яшертен ашыгулары Алимга тынгылык бирмәде. Бөтенесе бер якка — коерыкка таба тәпилиләр иде.

Ул да чак кына тынланып торды — абыйсы сизеп калмасын тагын! Хәзер арттан куып житәр дә... кем белә, бәлки анда берәр сер ачылыр?!

Барып житсә... Исай Маркович, Покуль, Велягурский житәкчелегендәге дус "квартет" чүгәләп чиратка басканнар да, дөньяларын онытканнар. Алар Алимнең сак кына атлап килгәнен ишетмәделәр дә. Берсе авызын сузып исни дә, янга тайпыла, аның урынына икенчесе килеп урнаша. Алим сузылып аска карады һәм чак кына кычкырып жибәрмәде. Аста куш йодрык хәтле трубкасын чожылдата-чожылдата боцман тәмәке тарта, рәхәтләнеп дәү-дәү төтен алкаларын жибәрә, жилсез як, алкалар уйнаклый-уйнаклый өскә менәләр, ә болар... Болар шуннан чыккан тәмәке төтенен йотлыгып-йотлыгып сулыйлар икән... Белдеме икән боцман аларның өстәге кыланмышларын? Белгәндер, белмәсә төтен йомгакларын колак мендәре дәүмәлегендә чыгармас иде. Ә болай гамендә дә юк, таянган, күзе диңгездә (карап туймаган икән!) пуфылдата гына!..

Алим артка чигенә башлады, аяк очларына басып, жирнең тарту көчен каһәрли-каһәрли чигенде... Шул чак шапылдап арты белән барып төште. Тигез жирдә абынды!

Тәмәкечеләр аңа борылып карадылар, һәммәсенең күзләрендә шашу-шашыну иде. Уен түгел бит! Әле кайчан гына бертавыштан: "Кем дә кем безнең хәтергә төшерә! Яки шушы килешүне боза — тотып диңгезгә ыргытабыз!" — дип кычкырганнар иде. Арада иң нык кычкыручылар шулар иде...

— Кил, — диде бер чакта да югалып калмый торган Велягурский, — кил, кинән. Сине чиратсыз уздырабыз.

Һәм Алим коты чыгып кире чаба башлады. Астан боцманның тамак кырганы ишетелде...

Тагын бер таң яралды. Тагын яңа көн килде. Диңгез өсте ямьсез! Дулкыннар алай галәмәт зур булмаса да, буразналар белән ермакланган кара күкнең күләгәсе су өстенә егылып төшкән. Кап-кара бүген диңгез суы, котсыз, җиле дә нәзек, әллә кай төшләргә үтеп керә... Оркестр шул ук, физкультурник тиргә батып тырыша:

— Иптәшләр, иптәшләр! Менә болай. Раз-два, ра-аз-два-а...

Гимнастика ясаучыларның саны сыек, анда бер кеше, монда ике, алары да язын уянып җитмәгән бөҗәкләр төсле алынкы-салынкы кыймылдыйлар... Бер Харис уртадагы зур мәйданны алып тора.

— Менә карагыз! — ди ул мускулларын киереп күрсәтә. —кая югалдыгыз, әй, кешеләр!.. Менә мине карагыз!..

Музыка кинәт бию көенә алышына һәм Харис шашып бии.

Нигә бии, кем кушкан аңа, кем үтенгән? Беркем белми. Нинди сөенече бар аның? Моңарчы иртәнге йокысын бүлдергәнне яратмаучы байбакны кем җилтерәтеп алып чыккан — бусын үзе дә белми.

Вера Павловна. Җылый-җылый күзләре шешенеп беткән Вера Павловна йөгереп килеп Харисны кочаклый, бокста җиңгән чимпионны котлаган сыман уң кулын һавага күтәреп башкаларга күрсәтә.

— Күрегез, карагыз! Үрнәк алыгыз! Ирлек ныклыгы сакланган иптәшләр бар арада. Менә кемнәргә иярергә кирәк! Бөтен өлкә шаулый. Үзәк газеталарда информацияләр! Мәскәүдән махсус шалтыратканнар. Шауладык, гөрләдек, әгәр тәҗрибә барып чыкмаса, ил алдында көлкегә калабыз!..

Бар икән, тәмәке алып кереп бүгенгә кадәр яшереп саклаган кеше дә бар икән. Ай-һайлап җыйнаулашып аны тотып китерәләр. Юаш кына, мокыт кына бер бәндә, тартыпмы тартып ята икән тегендә! Алып килүчеләр әллә аңа ачуланалар, әллә язмышларына, иллә мәгәр тавышлары кумәк һәм куәтле чыга.

— Безне юлдан яздыручы шушы кеше!

— Күрегез әнә!

— Штраф салырга кирәк!

— Бөтенебезнең чыгымнарын ул түләсен!

Вера Павловна башта ни әйтергә белмичә җәлләп тә, ачуланып та мокыт кешегә карап тора.

— Сез ялгышып кына тарттыгыз бит, иеме? — дип сорый.

— Ялгышып кына. Түзәр әмәлем калмады, — ди кеше басынкы гына итеп.

— Иптәшләр! Ул үз гаебен таныды! Яңадан тартмаячак! Шулай бит?

— Бетте. Яңадан суырып та карамыйм, — ди мокыт кеше.

— Барыбер болай калдырырга ярамый!

Чәчрәп Рита килеп чыга...

— Бүгеннән гипнозга йөри башлыйсың.

Кирәк бит, нәкъ шул чагында Яков Борисович килеп чыга. Ул терсәкләрен күтәреп үзен кочаклаган, кара күзлеген салган, кыяфәтенә олысымаклык, вәкарь кергән.

— Әйе, килсен. Бүген иртәнге аштан соң гомуми сеанс...

Иртәнге аш. Рита кайчан өлгергән диген, көзгеләр арасында баягы тәмәкеченең карикатурасы...

Кашыклар чирләгән — чак кыймылдыйлар, чәнечкеләр җан биргән — йоп-йомшак кәтлит гәүдәсенә дә кадалып керә алмыйлар, компотлар тилергән — чишмә булып иякләрдән агалар...

Гипноз сеансы бара. Салонга сыймаганнар урындыкларын, креслоларын ачык тәрәзәләргә, ишеккә якынрак тартып китергәннәр. Яков Борисович уртада, мәһабәт кыя сыман басып тора. Аның тавышы хәтәр чыга, башкалар күзләрен йомып, таралып кына тыңлыйлар.

... Тяги к курению у меня нет.
Я себя чувствую нормально.
Настроение у меня хорошее.
Явлений дискомфорта у меня нет.
С каждым днем я себя чувствую все лучше и лучше.
Тяги к курению у меня нет.
Я здоров, я совершенно здоров...

Вера Павловна бу тамашаны читтән генә карап тора. Ул иңбашларын бөрештереп, куырылып кечерәеп калган...

— Ничек матур башланган иде бит сәяхәт! Хәзер Хезмәт Сараенда ни диярләр? Ни әйтер Иван Иваныч?! Ни әйтер София Ивановна?!

Кок тагын капитан янында.

— Унсигез кеше иртәнге ашка килмәгән.

— Сәбәп?

— Сәбәпләре билгесез.

— Авырмыйлармы?

— Фельдшер йөреп чыккан, күрер күзгә һәммәсе сау-сәламәт...

Матрос теш арасыннан сукрана-сукрана кәбестәле мичкәләрне трюмга кире тәгәрәтә, буфетчы хатын янынннан бер-берсен тыгызлап өелгән тартмаларны кире ташыйлар. Кокның ярдәмчеләре зур бер кәстрүл ботканы диңгезгә түгәләр. Давыл булып ияреп килгән диңгез ачәрвахлары — акчарлаклар боткага, ипи телемнәренә ябырылалар.

Кокның юан ярдәмчесе маңгай тирен сөртә.

— Санслужба белеп калса... Штрафның катысы эләгәчәк.

— Май кап! — дия анын иптәше.

Икенче салонда Рита. Аңа да чират баскан. Хорга язылу бара. Беренче булып Алим язылган да, хәзер Ритага булыша. Кулында каләм, алдында кәгазь. Колга кебек озын, юка гына кеше кереп баса.

— Рәхим итегез. Җырларга телисезме?

— Мәктәп хорында җырлап диплом алган кеше.

— Нинди тавыш белән җырлый идегез?

— Мәктәпнең атаклы бас-баритоны идем.

Рита рояль клавишасына баса.

— Йөгез, югары "до"ны алып карагыз әле. Башладык. Бер, ике...

— Хәзер, хәзер.

Колга кульяулыгына йөткереп торды-торды да... Рояльдән ургылып көчле тавыш яңгырады, ә колганың бугазыннан ата каз ыславы сыман неп-нечкә тавыш сызылып чыкты.

— Ничә ел тартасыз инде?

— Унике яшьтән бирле суырам.

— Бер читтәрәк утырып торыгыз.

— Тагын бер кат тыңлап карагыз, зинһар!

Алим, чиратны күрсәтеп, аны куа:

— Теркәп куйдым мин сезне. Күрмисезмени?!

— Туташ. Мин котылырга телим... Үземнән генә чыкмый, булдыра алмыйм. Характерым йомшак. Бас- баритон идем бит! Мәктәптә йөгерешче идем.

— Утырып торыгыз.

Икенче булып сыра мичкәсе кебек юан килә.

— Ябыгыр өчен көне-төне тәмәке ашадым... Көненә өчәр пачка тарта идем. Юк, барыбер тазарам. “Сынап кара!” дип, шушы сәфәрне тәкъдим иттеләр.

— Нинди тавыш белән җырлыйсыз?

— Тенор идем заманында! “Куда, куда вы удалились”ны Козловскийдан ким җибәрми идем.

— Кайда?

— Үзебезнең трест концертларында. Парикмахер мин! Трест управляющие мине Мәскәүгә кадәр алып барып йөри иде!.. Н. шәһәрендә эшлим. Юлыгыз төшсә миңа керегез. Принцесса ясыйм! Иң ямьсез кызлар да миндә булганнан соң ике атнадан кияүгә чыгалар.

— Йәгез, “ре” нотасын алыгыз әле...

“Ре” урынына аның күгәргән бугазыннан тимергә-тимер ышкылган авазлар гына килеп чыкты.

— Ничә ел тартасыз?

— Бер-ике йөк ашадым инде! Тәмәке киоскалары минем аркада премия ала. Хатын әйтә “бер “Волга” ике “Жигули” ны төтен итеп очырдың инде”, ди.

— Алай да, ничә ел?

— Егерме өченче елымны суырам.

— Утырып торыгыз.

Чиратта хатын. Йөзе сап-сары. Бармаклары, тырнаклары сап-сары. Кашы коелып беткән, керфекләре сынык-сынык. Йөзенә сагыш сарган.

— Ничә ел тартасыз?

— Унике яшьтән. Күрше егете өйрәтте. Тамара, ди, дөньяда аннан да тәмле нәрсә юк, ди. Бала ясады һәм тәмәке тартырга өйрәтте. Баласы калды, гадәте калды — үзе үлде. Муены астына килгере! Котылу юк җәфадан!

— Нинди тавыш белән җырлыйсыз?

— Нинди тавыш белән кушасыз?.. Секретарь-машинистка мин. Өйгә дә эш алам.

— Ничек алай: “Нинди тавыш белән?”

— Директор ничек куша инде! Кош булып сайрарга кушса, сайрыйсың. Карга булып каркылда дисә дә әмәлең юк. Ялгыз башың белән малай үстерү ансат түгел.

— Барыгыз, утырып торыгыз.

— Ничә ел тартасыз?..

— Утыз икенче елым. Биш яшьтән тарта башладым.

Сакал-мыеклары шырпы-шырпы булып чекрәеп торган бу гыжлау кешегә карап Алим имәнеп китте. Шушымы аның клиентлары?! Шулармы?!

Менә язылу тәмам. Исемлек шактый озын. Кешеләре яхшук кызыклы. Кемнәр генә юк икән арада! Нинди язмышлар аларны монда китермәгән!

Ритамы бу? Үземе? Тавышы моңарчы гел чынлап, чыңгырдап тора иде. Йөзе дә ничек үзгәргән, картайган, йолкынган...

— Иптәшләр, сез бүгеннән хорга йөри башлыйсыз. Йөрү мәҗбүри түгел, әмма үз файдагыз өчен даими катнашырга чакырам. Йәгез, башладык. Иң элек басынкы тавыш белән генә, барыбыз да белгән бик гади җыр “Чижик, пыжык”ны үтеп карыйк. Сез, монда басыгыз, сез, бу якка! Икегез бер рәткә. Булды.

Ританың куллары атылган кошның канатлары кебек авыр гына хәрәкәтләнеп алдылар, егерме-утызар ел тәмәке төшмәгән авызлар ачылдылар, ачык авызлардан куркыныч тавышлар өермәсе килеп чыкты. Теплоход култыксасына таянган боцман чак кына егылып төшмәде, матрослар куркышып ары-бире чаба башладылар.

— Ут чыкканмы әллә?

— Юк ла! Жырлыйлар.

— Жылыйлар, диген?! Йә, Ходай, бу газапларыбыз кайчан бетәр икән?!

— Акылдан язмасаң, азагын да күрерсең.

Чәчен йолкыр иде Рита, унга-сулга карамыйча йөз чакрым чабар иде, бу ыңгырашуларны тагын бер кат ишетмәс өчен ун ел гомерен бирер иде. Әле ярый, янында Алим бар. Әле ярый, ул күз карашы белән аңа көч биреп тора, тынычлыкка өнди.

— Менә күрәсезме, иптәшләр, сезнең тавышлар шактый үзгәргән. Сәбәбен үзегез аңлыйсыз, шуның өчен тагын бер тапкыр тырышып карыйк. Әйдәгез, "По долинам и взгорьям"ны үтәбез!

Кул күккә күтәрелә, авызлар ачыла, ачык авыздан сөремле-төтенле, никотинлы өзекләр ыткылып килеп чыга. Матрослар колакларын тотып, төрлесе төрле якка юнәлә. Акчарлаклар чиный-чиный чәчеләләр. Бу тавыштан куркып диңгез өстенә ишелергә торган болыт буразналары тагын да куера сыман...

Вера Павловна Иван Семеновичны үз каютасына алып кергән. Термостан чәй агызып сыйлый, алдына әчтерхан чикләвеге, кәнфитләр, прәннекләр куя. Өмет белән аның күзләренә карый.

— Менә сез, Иван Семенович, алдынгы класс вәкиле. Эшче. Сезнең турыда миңа бик күп яхшы сүзләр ишеттерделәр. Сезне коллектив көтә! Җиңү белән кайтырсыз дип ышана.

Тапкыр Велягурский, чая кеше, бүген сүз әйтми, күзен җирдә йөртеп бары тик бер сүзне генә мыгырдый:

— Шулай, шулай...

— Әйтегез әле, каян башланды? Кемнән?

— Кемнән дип...

— Зинһар, яшермәгез.

— Мәхәббәт колы — тәмәке колы инде ул! — дип әйтеп салды тәкате корыган Велягурский.

— Покульмы? Шундый әдәпле, итагатьле кеше! Көтмәгән идем. Мин бит, мин бит, кадерле Ванюша, мәхәббәт фәненең профессоры! Үз тормышымны кормасам кормадым, күпме кешене таныштырдым, кавыштырдым. Әгәр башта ук әйткән булсагыз, бу хатаны әллә кайчан төзәтә идек... Коткара идек! Булыша идек!..

Кичке аш вакытында теплоход радиосы аша түбәндәге сүзләр яңгырады:

— Безнең пассажирлар арасында хезмәт батыры, дуслыкның, мәхәббәтнең кадерен ифрат тирән аңлаучы бер иптәш бар. Гавриил Николаевич Покуль. Покуль иптәш Федор Иванович Шаляпин җырлавын ярата. Покуль иптәш хөрмәтенә бөек җырчы Шаляпин җырлый...

Аш тәлинкәләре өстенә иелгән бөек кешеләрнең баш очыннан таныш арияләр яңгырап уза.

Вера Павловна белән Рита сөйләшеп торалар:

— Алдан күрүчәнлек бер чакта да зыян итми. Әле ярый Шаляпин язмаларын алган идем...

Озакламый кок арба тәгәрәтеп, рәтләр буйлап узып бара. Арбасында бүрегеннән дә зуррак, төрле чәчәкләр белән бизәлгән торт.

— Кадерле Гавриил Николаевич! Сезнең туган көнегез, әлбәттә, килеп җитмәгән. Ул күңелле көн декабрьдә генә. Декабрьдә теплоходта очрашу мөмкинлеге юк, бүгеннән сезне котлап куярга булдык. Бөтен коллектив исеменнән шушы кечкенә генә бүләгебезне кабул итегез!

Бүләк, дөрестән дә, кечкенә! Тота алмый Покуль, куллары калтырый. Велягурский Алимны этеп чыгара.

— Йәле, кирпеч-гантельләр күтәреп ныгыган беләк, булыш! —

Алим тортны җитез генә уйнатып эләктереп ала. "Кирпеч гантель" дигән сүз Вера Павловнаның колагына кереп калган!

— Йәгез әле, йәгез. Сөйләгез әле халык уеннарын?! Иртәгә кирпеч гантель күтәрү буенча ярышлар игълан ителә...

Харис ризык тулган авызын ачып карап тора, йодырыклары йомарланган, яшен атып торган күз карашлары Алимны телемнәргә телгәләп ташлыйлар...

Кич.

Вера Павловна белән Яков Борисович каютада сөйләшеп утыралар.

— Яков Борисович, сезнең кодрәтегез җитәр дип уйлыйм!

— Җитә — билгеле бер чиккә кадәр! Кичә утыз кеше иртән булды, көндезге-кичке сеансларда иллешәр кеше. Әгәр иртәгә туксан, йөз кеше килә башласа! Көненә өч мәртәбә! Меңәрләгән кешене үз ихтыярыма буйсындырырга мин Александр Македонский түгел лә!

— Нишләргә соң?

— Нигә ашыгырга? Нигә каударланырга? Хәзер һәммәсе үз эзенә керде. Шулай булырга тиеш иде! Бер атнага сузылган энтузиазм чоры узды. Хәзер бер атна депрессия чоры булачак. Аннары һәммәсе тигезләнәчәк.

— Атна буе ничек түздерәбез?

— Кулда булган барлык ысулларны, бар әмәлләрне эшкә җигәргә кала.

Вера Павловна ишек тоткасына ябышып, аптырап басып тора.

Яков Борисович көлеп җибәрде: — Нигә мәхәббәт турында сөйләмисең, Вера Павловна?!

— Бичараларны ничек коткарырга дип баш ватам. Ватык башта мәхәббәткә урын юк!

— Нигә эшнең авыр, катлаулы буласын алданрак уйламадыгыз.

— Миңа һәммәсе дә ансат, җиңел генә узар кебек тоелган иде. Ничек матур башланган иде бит. Нинди гүзәл иде!

— Безнең илдә һәр башлангыч гүзәл була. Азагы гына...

Иртән Алим тагын таң яралуга уянды. Уянды да тизрәк чыгып китү ягын карады. Кичәге урында, нәкъ кичәгечә хәл кабатлана иде. Боцман кинәнеп-кинәнеп төтен алкаларын очырта, башкалар чүгәләп, тезләнеп, чиратка басып төтен алкаларын авызлары белән тоталар иде...

Төркемнән Иван Семенович Велягурский белән яшь кеше аерылып башка якка киттеләр. Алим алар артыннан иярде. Икесе дә корабльнең шлюпкасы янына килеп җиттеләр.

— Күрәсеңме? — дип ымлады яшь кешегә Велягурский.

— Күрәм дә!..

— Төнлә төшерәбез дә ычкынабыз. Без алтау. Алмаш-тилмәш ишәрбез!

— Куркыныч!

— Нәрсәсе куркыныч?

— Тотсалар? Гавриил Николаевич үзен харап итеп ташламасын дип, аны коткарырга гына теләгән идек, диярбез.

— Хәйләкәр син, Иван Семенович.

— Хәйлә ул — дипломатия. Хәйләсез дөнья файдасыз!..

Алим тәмам аптырап калды. Корабльдән шлюпка урлап качмакчы буламы бу башсызлар? Димәк эшләре харап. Чикнең актыгына барып җиткәннәр. Тәвәккәлләсәң, хәзер сигаретларны сөйрәп чыгарырга иң җайлы вакыт. Пешеп өлгергәннәр болар! Әллә?..

Алим үз уйларыннан үзе куркып китте, ялт итеп як-ягына каранды. Мәкерле уйлар соңгы мизгелләрдә аның башына еш килеп куналар, ул аларны куып җибәреп котыла тора иде. Тик аяусыз чынбарлыктан ансат кына котылмак юк иде.

Менә сәяхәт тәмамланыр. Рита белән чыркылдашып күктән җиргә төшәрләр... Кая барыр егет?! Муеннан бурычка батып, абзасы белән дошманлашып кем ишеген барып кагар?! Әҗәт муенчагы һәр адымда кысып тотачак. Шәһәрдән качыйм дисәң дә, буш кесәңне җилфердәтеп кая бара аласың?Ританы да ташлап китәсе килми егетнең, күнеленә минут саен ныграк керә бара! Әллә... Абзасы ни әйтер! Хәер, Алимнын үз язмышы үз кулында!

Иртәнге аш вакытында радио башта озак кына кыштырдады, аннан Вера Павловнаның калтыранган тавышы ишетелде.

"Иптәшләр! Бүген Гавриил Николаевич исеменә радиограмма алынды. Рөхсәт итегез, укып чыгарга". "Кадерле Гавриил Николаевич! Сезнең файдалы сәяхәтегезнең ифрат уңышлы һәм нәтиҗәле дәвам итүе турында газеталардан укып, радиодан ишетеп торам. Мин синең белән, синең ихтыяр көчеңнең ныклыгы белән горурланам. Шулай дәвам итегез! Нюра".

Гавриил Николаевич ашавын ташлап, врач янына йөгерде.

— Зинһар коткарыгыз! Яхшылык белән кеше үтереп була диләр иде, ышанмадым. Мөмкин икән!

Тәҗрибәле Яков Борисович аңа ни кирәген бер карауда аңлап алды. Покульнең күзләре акайган, куллары дер-дер калтырый, яңакларына күкле-яшелле төс йөгергән.

— Бераз көтегез, кадерлем. Башкалар да җыелсын.

— Йоклатыгыз да ярга чыкканчы уятмагыз мине!

— Утырыгыз, тынычланыгыз!

— Су йоттырам дип агу эчертәләр. Инде аз гына онытылам дисәң. Тагын Нюраны искә төшерделәр.

— Вера Павловнаны кисәтермен!

— Эх, яратмый Нюра мине! Яратса **мондый** газапларга дучар итәр идеме? Тереләй утка ташлады. Җәһәннәм тагарагына куып кертте.

Покуль абына-сөртенә палубага чыкты, мәгънәсез, битараф караш белән еракка, мираж кебек кенә шәйләнгән яр ягына карап тора башлады.

Харис беренче корбанын билгеләгән иде. Ул пассажирлар арасындагы хәлнең һәммәсен белеп, мыегына чолгый тора иде. Беренче корбаны Покуль булачак!

Өченче көн Харис !"Һәр кабына өч сум сорыйм!" дип өзеп уйлаган иде. Кичә "бишәр сумга" менгерде. Бүген, иртәнге аш тирәсендәге шәүләкүләгәләрне күргәч, "сигез сумнан да арзанга бирмим!" дип ныгытып куйды. Беренче булып Покуль алачак. Аның артыннан бүтәннәр!

Харисның бәхет сәгате сукты, тик йоклап калмаска иде, бар товарны тизрәк урнаштырырга кирәк!

Берән-сәрән дә, төйнәлеп тә гипноз сеансына агылдылар. Харис санап торды: өч йөз егерме кешедән йөздән артыгы тәмәке богавыннан котылырга ашкынып, Яков Борисовичтан ашыгыч ярдәм көтә иде. Аларның сүзсез-карышусыз, селлин-селлин атлап килүләрен күреп, врачның күләсе дә килеп куя! Алар төнге өрәкләр сыман аллы-артлы атлыйлар, башлар иелгән, танысалар да, бер-берсенә сәлам биреп тормыйлар, кайда туктасалар, шунда утыралар, идәнгә чүгәлиләр, тавышлар карлыккан, ара-тирә корык-корык ютәлләүчеләр дә бар.

Сеанс башланды...

Яков Борисовичның куллары һаваны телеп әле өскә менеп китә, әле нәни баланы сыйпагандай иплән кенә хәрәкәтләнә башлый. Тавышы үзгәрә, ул тук, иркә мәче сыман мыраулый, үз катындагыларны тынычланырга чакыра, өнди, кыстый, сабыр булырга куша... Күзләр бер-бер артлы йомылалар, чырайларга тоныч кына саран нур инә. Җыелган халык догага оеган кебек тып-тын кала... Шундый чакларда Яков Борисович биек кыяга менеп кунган дәү бөркет кебек. Вера Павловна аның шундый чакларын тәрәзә аша күзәтергә ярата.

Йокыга талган йөз кешене калдырып Яков Борисович аның янына чыга.

Иң кырыйда яткан Покуль сыңар күзен ача, Вера Павловнаны абайлап, икенче күзе дә ачыла, ул тезләнә, торып баса.

— Гайрәтең, сихерең мул, доктор! — дип сыена аңа Вера Павловна. — Шулай да... мин уйлап таптым бу могҗизаны! Минем даным илдән-илгә китәчәк, менә күрерсең!

Кырыйда чүмәшкән Покульнең сул күзе ачылды... Карашы авыр иде кияү егетенең, йодрыклары кысылган, очлы ияге күкрәгенә кадалырдай булып дер-дер килә иде.

Икенче күзе ачылганда Покуль сикереп торып һәм бугазын ертып акырып җибәрде:

— Менә ул — болгаткыч таяк! Телевизорда маймылланып, радио аша дөнья сасытып безне җәһәннәмгә илтеп тыккан хатын шушы!

Салон җанланды, берәм-берәм барысы да калкындылар һәм нәфрәт тулы күзләрен чекерәйтеп, профсоюз әһеленә карап тора башладылар. Покуль дөнья бетереп һаман кычкыра иде. Коты чыккан Вера Павловна врачның беләгенә чытырдап ябышты. Яков Борисович үзе дә шыр җибәргән иде. Ләгънәт, каһәрләү сүзләре әлегә Вера Павловна өстенә ябырыла иде.

— Шул котыртты безне! Шул үгетләде.

— Шул уйлап чыгарды!

— Врач ярдәм итәр, диде.

— Кайда ул ярдәм?!

Кешеләр калкынган саен Яков Борисовичның да куркуы арта барды. Вера Павловнаның коты чыгып, аның артына качты, ике куллап аның муенына асылынды. Алар шулай парлашып, тулганып, артка чигенеп карадылар да ярсыган, кызган, шашкан халык ташкыны уртасында калдылар.

— Иптәшләр, кадерле иптәшләр! — дип инәлде Вера Павловна.

— Сез йокламый идегезме? — дип сорады Яков Борисович.

— Нинди йокы ди?

— Йокы тәмәкене җиңә диме, тиле!

— Кичә дә юри яттык.

— Өченче көн дә!

— Синең такылдавыңның беркемгә файдасы юк

— Тәмәке көчлерәк!

— Без сиңа ышанмыйбыз.

— Менә ул гаепле кеше!

Вера Павловнага бармак белән төртеп күрсәтәләр, аның борыны төбендә йодрык яшеннәре уйный.

— Шул коткы таратты!

— Ул уйлап чыгарды!

— Теләмим мин тәмәкене ташларга!

— Рәхәтләнеп, кинәнеп суырасым килә!

— Ярга чыгарыгыз безне! Яки тартырга табыгыз!

Иң нык бугаз киергәне Харис иде бугай.

Ул йөгереп чемоданнарны сөйрәп чыгарырга бик теләде. Вера Павловна белән врачның камалыштан ничек котылуларын да күрәсе килде. Тарткалап, өзгәләп ташласыннар иде шуларны! Җиңелеп, изелеп аста калсыннар иде!

Хәзер чемоданнарның, товарның язмышы хәл ителәчәк. Йә баеп кала Харис, йә янып көлгә әверелә...

Вера Павловна актык көчен җыеп сайрый:

— Иптәшләр, иптәшләр! Бүгенге көндә безнең рейс турында бөтен ил белә! Башка өлкәләрдән, профсоюз оешмаларыннан вәкилләр килә. Без намусыбыз бәрабәренә ахырга кадәр сынатмаска тиеш. Бөтен шәһәр җәмәгатьчелеге безне каршы алачак! Түземле булыгыз!

Тарткалаш, талаш ни белән бетәр иде...

— Кирәкми безгә күнегүләр!

— Без тартырга телибез!

— Яшәсен тәмәке!

— Яшәсен сигаралар!...

Теплоход гудогы яңгырады.

Кемдер:

— Каршыбызга теплоход килә! — дип кычкырды.

Каршыга өч палубалы теплоход йөзә. Аның бөтен җире балкыган. Музыка уйный. Чибәр-чибәр киенгән ирләр, хатын-кызлар, егет-кызлар төз басып, зифа гәүдәләрен күрсәтеп мактанып палубаларны тутырып йөриләр. Бөтенесенең авызында тәмәке. Капитан да тарта, штурвалдагы вахтенныйның авызында да тәмәке...

Бичаралар боларның бөтенесен дә күрмәделәр, әлбәттә, күрә дә алмадылар, әмма җил алар ягыннан иде, тәмәкенең хуш исе борыннарны рәхәт итеп ярып килеп керде, ярсыган күңелләрне тагын да ныграк уйнатты, кузгатты! Бөтен халык — ир-аты, хатын-кызлары теплоход ягына, бортка ташландылар.

— Коткарыгыз!

— Үләбез!

— Бер генә суырырга!

— Төпчекләрегезне ташламагыз!

Бар халыкның бер якка кинәт ябырылуыннан теплоход аз-маз гына янтая башлады. Капитан күперчегенә чабып чыккан боцман кулына рупор алып:

— Урыннарыгызга марш, каһәр суккан вәгъдәсез тәмәкечеләр! — дип акырды.

Аяк асларының чак авышуын иң элек хатын-кызлар сизде, алар кулларын югары күтәреп:

— Батабыз!

— Бетәбез!

— Коткарыгыз! — дип чинашып икенче якка ташландылар. Алар артыннан ирләр иярде, аңгырайган сарык көтүе кебек бу якка чабып чыгып бөялгәннәр иде, аллакайгынам, теплоход бу якка янтайды...

Вера Павловна оркестрларны өреп чыгарды, этеп-төрткәләп Ританы алга бастырды.

— Уйнагыз! Кая сезнең хорыгыз? Кайда диплом эшегез?! Кайда сезнең көчегез!

Каяндыр Алим килеп чыкты, ул Ританы җитәкләп алып, көчле тавышы белән җыр башлап җибәрде, күз яшьләренә буылып аңа Рита кушылды, тагын бер-ике тавыш кыяр-кыймасрак көй суза башладылар.

Бу вакытта Харис кесәләренә ике кап сигарет салып Покульны эзли иде. Анда бара, монда тыгыла, юк кына Покуль! Кешеләрдән сорашып карый.

— Гавриил Николаевич күренмәдеме?

— Юк!

— Бая, теплоход узганда суга сикермәгәндер бит?

— Белмибез.

Теплоход җай белән генә бара, кешеләр акрынлап урыннарына урнашалар, домино сөякләре ялкау гына шакылдый, пешкалар авыр аякларын сөйрәп, сугыш кырында һаман корольләрне саклыйлар, атлар аксаган — сикереп алалар да сөрлегеп тукталалар. Бер җирдә шау-шу, ыгы-зыгы юк, көлмиләр дә, йөзләр мумия булып каткан, теплоход авыр чирдән әлерәк кенә котылган зәгыйфьләрне төяп бара кебек. Һәммәсенең күңелендә әле генә булып узган хәл. Ярым тиле хәлдә, кул сузып, илереп акырулары күз алдында. Кешеләр бер-берсенә карарга да оялалар...

Ниһаять, берән-сәрән палубага чыга башлыйлар, икешәр-өчәр булып тупланалар, күзләр күтәрелә, йөзләргә тере елмаю чыга. Кемдер көлеп җибәрә. Кешеләр бер-берсенә төртеп күрсәтә-күрсәтә дөнья яңгыратып шаркылдыйлар...

— Минем исемдә дә юк иде...
— Мин дә!
— Ничек нярел киткәнемне абайламадым...
— Вәт мәзәк ясадык!
— Суга бата яздык бит?!
— Һаман шул каһәр суккан тәмәке өчен.
— Булса ни дә булмаса ни минем өчен.
— Мин ташлыйм.
— Тартмыйм.
— Түзәм.
— Чыдыйм.
— Әй, чабалар бер заман!
— Мин дә чабам! Котырып китсәң китәсең икән.
Харис кесәсендәге сигаретларын кысып тотып кычкырып җибәрде:
— Кайда ул Покуль?

Алим мәсьәләне шунда ук аңлап алды: Харис абыйсы тәвәккәлләгән. Хәзер ул бернәрсәдән дә куркып тормаячак, хәзер ул кешеләрнең өлгереп җиткәнлеген күрде. Шашкан халыкның үзәгендә булды! Хәзер ул иң беренче итеп Гавриил Николаевичны кабып йотачак. Ничек коткарып калырга аны?! Ничек саклап, аралап алырга ерткыч тырнагыннан?! Чабар иде, аны Рита җибәрми.

— Тагын аз гына минем янда тор әле!..
— Нигә?
— Син мине коткарып калдың.
— Ә син халыкны...

Яков Борисович үзенә урын таба алмыйча йөри дә йөри. Ниһаять, аның күзе Рита белән Алимга төште. Ул ныклы бер карарга килеп, кызны чакырып алды.

— Рита!
— Нәрсә, абый?
— Нигә син һаман аның янында?
— Ул минем янда бит, нишлим?
— Куып җибәр... Рита... син минеке булырга тиеш.
— Юк, Яков Борисович!
— Ах, алаймы?..

Юаныч эзләгән докторның йөрәгендә яна җәрәхәт сызыла...

Сәяхәтче теплоходның җайсыз яклары, торган саен теңкәгә ныграк тия башлады. Моңарчы төнкаты ябып-ачтырып торган утлардан Алим гына зарлана иде, хәзер хәлләр үзгәрде. Докторның да күздән югаласы килә, Вера Павловнаның да уе шундыйрак, тәмәкечеләр төркеме шаулапыргылып аңа ташланганнан соң беркемне күрәсе, беркемгә күренәсе килми иде профсоюз лидерының. Телдән-телгә күчеп йөргән, күңелләргә дәрт өстәп торган "тәмәкене ташладык..." гыйбарәсе дә кабыгын үзгәртте, "тәмәкене ташлый алмадык... җәфа чигә башладык!" дип сукрана хәзер Вера Павловна...

Юк, теплоходта күздән югалып торырлык караңгы почмак юк! Каһәр суккан аяклар аны беренче каттан икенчесенә, теплоход борынынынан койрыкка сөйрәп йөртә, ә дәртле яшь хатынга сыенырга ышык урын юк!

Күзенә ак-кара күренми Вера Павловнаның, югары палубада, япъяктыда чак кына абынып егылмады, култыксага тотынып калды. Карлыккан усал тавыш аның зиһенен кисте: "Күзең чыкканмы әллә?!" Шушы авыр сүзләр бичара хатынның язмышын ачыклады: көндезге, баягы гауга вакытында нинди генә сүзләр ишеттермәделәр аңа, ниләр генә әйтеп карамадылар. Хатынның хәле үтә мөшкел иде. Ул кая барып бәрелергә белмичә койрыкка йөгерде. Моңарчы сизмәгән икән — җил чыккан, итәкне чайкалдырып, куеннарга кереп йөри торган төнге җил. Йә Ходай, кайсы игелексезе койрыкны яктыртучы плафоннарны сүндереп бетергән, монда ярымкараңгы икән. Эңгер-меңгердә берәүнең шәүләсе шәйләнде.

Бәндә Вера Павловнаны күрмәде шикелле, ул ике кулы белән култыксага ябышкан да үзалдына нидер мыгырдый иде. Тынлый торгач, сүзләре дә аңлашыла башлады:

— Берлинда булдым! Лондонга чакырып алдылар! Җәһәннәмдәге Австралиягә барып кайттым. Рангун фестивалендә бер үземә алтын медаль тапшырдылар! Йөрмәгән жирем калмады! Минем ихтыярыма бөгелмәгән әдәми затлар юк иде. Алла идем мин!

Вера Павловна докторны җәлләде, хатын-кызларча жебеп, жепшеп энже яшьләрен коя-коя жылады. Каты бәгырьле кеше буларак, жылаудан кинәт туктады, ирлек ныклыгын югалткан Яков Борисовичтан үч алырга мөмкин икәнлеген абайлап, зәһәр агулы тавыш белән:

— Ә монда... жилбәзәк бер кызны да бөгә алмадыгыз! — дип пышылдады. Яков Борисович һич көтмәгәнчә сабыр гына аңлатып бирде:

—Ританың әтисе яһүд булса да, әнисе татар ич аның! Чи мөселман! Намаз укыганын үземнең күргәнем бар. Монда кереп татар малаен очратты да монарчы йоклаган күзәнәкләре жанланды да куйды кызыйның... Ярга чыгыйк әле карап карарбыз!!

Беравыкка икесе дә тын калдылар, күңелсез уйлары бер юнәлештә куалаштылар. Менә сәфәр тәмамланып, ярым кыргыйга әйләнгән буынсыз тәмәкечеләрне төяп ярга чыгарлар... Аларны ур-ра кычкырып житәкче даирә вәкилләре, журналистлар, телевидение кешеләре каршылар... Ә анда... тантананы матәм алыштырыр. Кая керер тишегеңне таба алмассың. Димәк, соңга калганчы теплоходны ташлап качарга кирәк. Ак матчага эленгән ак шлюпка кемнедер көтә түгелме? Яр әлләни ерак түгел...

— Яков Борисович! — дип инәлде Вера Павловна, — мин монда кала алмыйм! Жаен табып мине ярга чыгарыгыз!

— Әфсен укыпмы? — Докторның каны качкан юка иреннәре мыскыллы бөршәйделәр.

— Команданы сатып ал! Акчасын бирермен! Ялын, сихерлә, юмала, хәйләлә! Мине чирле диген! Үлә, диген!

Ул сыңар кулы белән докторның иңенә асылынып йөзләрчә төче сүзләр табып аны юмаларга, үз ихтыярына буйсындырырга тырышты. Алар көймә эленгән урынга барып чыкканнарын сизми дә калдылар. Көймә тирәсендә нидер эшләп кайтканнан кешеләр дә аяк тавышларын ишетеп каушадылар, бер-берсенә карашып ымлашып качарга омтылдылар, профсоюз әһеле үзенең кем булуын исенә төшереп зәһәр, әче тавыш белән кычкырып жибәрде: "Нишлисез сез, явызлар?" Велягурский иптәшләренә тик торырга ишарәләп алгарак чыкты, бераз аңгыра сарык кебек мәэлдәп торгач, тотлыга-тотлыга аңлатып бирде:

— Покульне кызганыгыз! Тартмаса үлә инде... Әллә инде көймәне төшереп ярга чыгарырга булышабызмы дибез... Жил юк, диңгез тыныч. Яр ерак түгел... Ә дигәнче әйләнеп киләбез...

Велягурскийның сүзе бетмәгән икән әле, ул нидер сизенгән сыман:

— Ә сез нигә йокламадыгыз? — дип сорады.

— Безме? — диде каушап Вера Павловна. — Без күзәтеп йөрибез. Халык нигәдер борчыла.

— Нигә икәне билгеле, газап чигә халык, — дип бердәм мөгердәделәр качарга жыенганнар.

Анда да, монда да кешеләр күренде. Көймәнең суга төшкәнен генә көтеп, посып торучылар кыюланып яктыга чыктылар. Доктор белән Вера Павловнаны урап алдылар.

— Иптәшләр, иптәшләр!

Профсоюз башлыгының тасма теле корып аңкавына ябышты, ияк асты калтырап бии башлады. Төрле яктан ризасызлык тавышлары яңгырады:

— Безнең дә ярга чыгасы килә!

— Кайтабыз!

— Юкка акча туздыру гына булды бу.

Ниһаять, тавышлар иң аулак почмакта берсе кочагына икенчесе сыеп беткән Алим белән Ритага да барып иреште. Тик тавышлар аларны мәхәббәт исереклегеннән айныта алмады, үкчәләре белән палуба идәнен төя-төя дөнья шаулатып Харис үтеп киткәч кенә, алар күктән җиргә төштеләр.

Харис исә Велягурский командасының качарга җыенуын кичтән үк чамалап, тегеләрнең һәр алымын бөркет күзе белән күзәтеп тора иде. Алим белән Рита да тавышлар килгән якка юнәлделәр.

Көн яктыра башлады. Иртәнге җил вак-вак дулкыннар белән теплоход кабыргаларын ялады. Көн ачылган саен тавыш-гауга көчәйде. Боцман команданы уятып: "Бу җүләрләр берәм-берәм суга сикермәсеннәр тагын! Бәладән баш-аяк!" дип кисәтте.

Бүтәннәрнең күзе күрмәскә әйләнгән, алар Харисның томырылып чабып китүен абайламадылар да. Рита гына Алимның терсәгенә төртте:

— Абзаң кая чапты? — дип сорады. Алим бурлаттай кызарып кызны үз каршысына бастырды:

— Рита, мин студент түгел! — дип кычкырды.

— Беләм.

— Ишлексез бер җилкуар мин!

— Чамалыйм!

— Һәм... Мин сине өзелеп яратам!

Иреннәр иреннәргә сузыла, әмма җил-давыл кебек килеп бәрелгән кешеләр агымы яшьләрне ияртеп алып китә.

Ул арада яңгыраган карлыккан тавыш соңгы йокычыларны да уята:

— Монда сигарет саталар! Сигарет! Кабы унбиш сум! — Аяк тавышлары. Чабалар, ашыгалар, йөгерәләр. Палубада аяк тавышлары бу көннәрдә күп тапкырлар янгырады, ләкин мондый көчле, тоташ һәм дәһшәтле ишетелгәне юк иде әле. Өстән дә, астан да каюталардан кешеләр чабып чыга, ярым шәрә хатыннар ыргыла, ирләр бер-берсен таптардай булып, вулкан аткандагы кебек шашып, шашынып яшь тайлар кебек ыргылалар. Вера Павловна да йөгерә. Аның артыннан вак-тәяк адымнар белән, үзенең врач икәнен бер чакта да онытa алмый торган доктор теркелди.

— Абзый! — Алимның мондый тавышы да бар икән!

— Якын килмә!

Өч чемоданны да сөйрәп чыгарган да Харис берсен ачып җибәргән.

— Шушындый әйбәт кешеләрне газаплыйлар! Интектерәләр! Нигә терелэй утка тыгарга аларны? Кичә бата яздыкмы? Яздык! Мин коткарам аларны! Мин! Явызлык бар җирдә яхшылык та булырга тиеш! Тапканнар эш — тәмәке ташлаталар, имеш. Теләгәннәр ташлар. Теләмәгәннәр — тартсын! Нигә кеше ирекен буарга? Подходи! Налетай! Әҗәл даруы ук булмаса да, бүгенгә ярап тора. Күңелләргә шифа, тәнгә сихәт... Һәр кабы унбиш сумнан!..

Алим сизде — Ританың, Вера Павловнаның, Яков Борисовичның гына түгел, иптәшләренең дә карашы аңа кадалды. Керфекләр мең ук булып аңа атылдылар, күз нурлары ялкын-очкын булып аны яндырдылар. Кергән чакта бу буаз чемоданнарга бөтенесе дә игътибар иткән икән! Ул бит үзен **студент** дип таныттты. Китаплар алып керәм, диде ул. Хәзер ни әйтерләр алар? Ни булачак? Халыкның ярсыганын күрде ул, бүген генә очрашты. Әгәр баягы кебек ярсып, кабарынып аңа ташлансалар?! Ритага да барысын да аңлатып бетермәде ичмасам... Әгәр Рита аңлаудан баш тартса? "Моннан соң күземә күренмә!" дисә?.. Әле сәяхәтнең ничә көне бар. Ул дәвам итәчәк. Сынаулар бетмәгән. Тәҗрибә дәвам итә! Инде җайга салына башлап, үз уңаена тәгәрәгән тәгәрмәчкә ул таяк тыгучы буламы?!

— Ә менә кадерле Гавриил Николаевичка бер кап сигаретны бүләк

итәм. Иң татлысын. Иң хуш ислесен! — һәм абзый сигарет кабын ин олы бүләк итеп, ике куллап тотып Покульга сонды. — Ул ике яктан газап чигә. Тәмәкедән дә мәхрүм итәләр аны. Мәхәббәт газабы да бар! Тарт, Гавриил дус! Яхшылыкның кадерен бел. Кем диген идең әле син бая? "Бер кап сигарет бирүче булса, мин аны фәрештәм, аллам, дип әйтер идем", диденме? Кабатла шул сүзләренне! Белсеннәр минем кем икәнне! Кабы унбиш сум гына, иптәшләр. Килегез, ни карап калдыгыз?!

Вера Павловнаның күзе Покульда. Покульнең күзе сигарет кабында. Менә ул бер адым атлады, ике, өч, Харис янына барып житте.

— Рәхмәт. Кирәкми.

— Ничек кирәкми?

— Тартуны ташлаганмын икән мин!

Чират Вера Павловнага барып житте. Ул атылып чыгып кызарынган Покульне ике кулы белән битләреннән тотып чут-чут үбә башлады.

— Без тартуны ташлаганбыз икән, — диде Велягурский.

— Мин дә... Минем хатын... — Кривин як-ягына каранды да кулын селкеде.

— Кирәкми! Үзең тарт! Нәрсәгә ул зәһәр агу безгә?!

— Егетләр! Бу бит чын сигаретлар! Егетләр!..

Алим ике-өч сикерүдә чемоданнар янына барып житте, ачыгын эләктереп алды да борт аркылы диңгезгә ыргытты. Төрле төстәге сигарет каплары кояш нурларында жемелди-жемелди диңгезгә сибелделәр. Беренчесе артыннан икенчесе очты, өченчесе...

— Нишлисең син?!

Өч чемодан бер-берсенә тагылган кебек, һич аерылырга теләмичә теплоходтан ерак та китмичә йөзеп әйләнәләр иде. Бераздан алар түгәрәк ясап бер урында чайпала башладылар.

Алим жинел сулап, Рита янына килеп басты.

— Чемоданнарым, чемоданнарым! Бата! — һәм Харис күп уйлап та тормастан чемоданнар артыннан диңгезгә сикерде. Шунда ук югарыдан команда яңгырады:

— Человек за бортом!

Алим тиз-тиз чишенә башлады, чая матрос аны этәреп бер-бер артлы ике "коткару бoжрасы"н ыргытты. Харис бoжраларга тотынмады, аның күлмәге артыннан кабарды, ул читкә тайпыла башлаган чемоданнарга карап, тырышып-тырышып йөзә иде.

— Спускать шлюпку, — дигән команда яңгырады.

Абзый янына тагын бер бoжра килеп төште.

— Ябыш, ябыш, котылырсың, — дип кычкырдылар аңа югарыдан. Абзый бoжраларны читкә тибәреп һаман йөзде, чемоданнарга якынлашты. Чыгыр тавышы яңгырады, шлюпка суга якыная башлады. Ул арада Харис чемоданнарга барып житте, өчесен бергә тартып китерде һәм үзе өскә менеп утырды.

— Батмый, — диде кемдер кинәт урнашкан тынлыкны бозып.

— Батмый, ә?!

Әле генә шомланып карап торган кешеләр көлә, шук сүзләр әйтә башладылар. Рита өскә менеп, кулын болгап жибәрде. Каяндыр оркестрантлар пәйда булды, алар уйнап жибәрде. Алим жыр башлады. Жыр беренче көннәрдәге кебек тоташ һәм куе чылбыр булып яңгырады.

— Мин уйлап чыгардым бит моны! — дип пышылдады күз яшьләрен сөртеп Вера Павловна.

— Болай булырга тиеш түгел! — диде кырысланып Яков Борисович.

Покуль иелеп Хариска бер пачка сигарет ыргытты.

— Ал! Миннән бүләк! — дип кычкырды.!

— Батмый! — диделәр кешеләр әллә сокланып, әллә нәфрәтләнеп.

— Явызлыктан тиз генә котылырмын димә. Утта янмый, суда батмый ул! — диде Велягурский көрсенеп. — Явызлыкны батырырга иде дә!.. — диде кемдер.

Тавышка Вера Павловна да, Яков Борисович та борылып карадылар. Тик бу сүзләрне кем әйткәнен белерлек түгел иде. Әллә Алим, әллә Рита, әллә башка берәү... Авазларның барысын да җыр тавышы күмеп китте, өч чемодан өстенә җайлап менеп утырган Харис янына шлюпка якынлашты. Ул шлюпкага тоттырмас өчен сынар кулы белән тырышып-тырышып ишә иде, күзләре тоныкк кына шәйләгән ерак ярларга төбәлгән иде аның...

*18 март 1983 — 30 май 1984 ел.*
*Переделкино.*

АВТОРНЫҢ ЙОМГАКЛАУ СҮЗЕ

*И-и, булган инде заманалар! Кемнендер кибәк очыруларына, саксыз биргән вәгъдәләренә ышанып, Татарстанда кино сәнгате тудырырга маташып йөрдек бит! Мин дә худсовет әгъзасы, җыелабыз, сценарийлар укыйбыз, ярсып бәхәсләшәбез. Киносценарийларга конкурс уздырган булдык, шунда мин үземнең генә түгел, башка бик күпләрнең кинодраматургиягә омтылуларын яки алданырга ратуларын аңладым. Әллә никадәр кульязма килде. Житез һәм өлгер әдип Гариф Ахунов белән өч-дүрт ел дәвамында икешәр чытыр арба кинокульязма укыдык. Вакытны кызганмыйча, мин дә киноповесть маташтырган булдым, фәкыйрегезгә нәкъ татарстанча, күзгә кырып салырлык кына премия дә бирделәр. Киноповестьны Мәскәүдә мәшһүр драматург Валерий Тур аркамны төя-төя мактады: "Талантлы кеше син, Аяз!" Мактагач: "Ләкин..." Озакламый мин дә бу "Ләкин"нең ни икәнен аңладым.*

*Татар киносының планнарын, бүгенгесен һәм киләчәген бинһая дәү бер сценарий йотты. Сценарийны мин дүрт куллап хуплап каршыладым (мактаулы рецензиям кайдадыр саклана булыр). Байтак еллар үткәч, мин үземнең киноповестем белән укучыларны таныштырырга булдым.*

*27 март 1998 ел.*
*Зәй шәһәре.*


## Киләсе санда — яңа исемнәр

Әдәбиятта кайчак шундый сөер хәлләр була: көтмәгәндә-уйламаганда дигәндәй, теге яки бу вакытлы матбугат битләрендә фикер үткенлеге, сурәтләүдәге гайре табигыйлеге белән сискәндереп җибәрә торган язма күренә. Һәм табигый ки, беренче чиратта андый әсәрләрнең авторын эзли башлыйсың. Баксаң, ул яисә бөтенләй таныш булмаган исем, яисә инде моңарчы да күренгәләп килгән, әмма моңа кадәр иҗатында ничектер ачылып җитмәгән автор булып чыга. "Казан утлары" журналының 11 санында укучылар әнә шундый ике яңа автор белән танышырлар. Аларның берсе — **яшь язучы Мансур Шаһимәрдәнов** үзенең шактый үткен каләме белән язылган хикәяләре аша әдәбият сөючеләргә таныш инде. Бу юлы ул журналда зур күләмле беренче әсәре — "Татлы агу" дигән романы белән катнаша. Роман бүгенге чор вакыйгаларын беркемне дә кабатламыйча үзенчә тасвирлавы, кеше язмышларында, аларның гаҗәеп катлаулы үрелеш-чорналышларында җәмгыять тудырган вәзгыятьнең сәбәпләрен күрсәтә белүе белән игътибарны җәлеп итә.

Икенче исем дә укучыларга азмы-күпме таныш булса да, әдәбиятта әле ул яңа. Сугыштан соңгы елларда авыл малайларының үзләре ач-ялангач булган килеш тә яшьтәшләренә, авылдашларына карата кылган миһербанлыкларын үтә җылы буяуларда сурәтләгән "Балыкчы малайлар" исемле хикәянең авторы — **Әлмәттә яшәүче журналист Әсгать Салах.**

*Болардан тыш журналның 11 санында Сез танылган язучы* ***Фоат Садриның*** *"Яшьләй сөйгән ярлар" дигән пьесасы,* ***С. Гәрәева, Р. Низами, Р. Зәйдулла, Ф. Тарханова*** *шигырьләре, әдәби тәнкыйть һәм мәдәниятебезнең төрле проблемаларын яктырткан күпсанлы язмалар белән таныша алырсыз.*

# ШИГЪРИЯТ



## Айдар Хәлим

ИСХАКЫЙ КАУРЫЕ

### Сабак турында баллада

Игеннәр агарып килә...
Сабак хәвефле уйда:
Урылмый, башаклы килеш
Каласы килә буйда.

Бөртеген "гөпкорсак итеп"
Туендырасы килә,
Таңның сары угызында
Коендырасы килә.

Чайкалып йоклый басулар,
Дулкыннар йөгерәләр.
Бөртекләр дә, сабыйлардай,
Йокыда өлгерәләр.

Сабак-Ана — башагына
Бишек җырлары җырлый.
"Күр мин дә йоклыйм!" — дигәндәй
Ясалма итеп гырлый...

Бөртек хакына — ураза,
Аягөсте ач тора:
Намаздан төшми, тамырга
Көн-төн "авыз ачтыра"...

Дерт итә — урак теш йомран
Тишектән сызгырса да;
Ураклы кош-корт очышта
Ярышлар уздырса да;

Дерт итә — ураклы Кояш
Кызганмый кыздырса да;

Ураклы яшен сыздырып,
Җил-давыл туздырса да...

...Беләлми сабак: тере җан
Яшәеш чиратында
Урактан урылмый калмый
Мәхәббәт сиратында.

Чөйми-черетми, басуга
Урак кергәнгә күрә
Сабак үзе бөртек аша
Үлемсезлеккә керә.

Ул күрми — Галәм күрә.

## Автобуста

Үземнән алдагы рәттә
Яшь ана, чиста гүзәл,
Сабыен уйнатып килә, —
Мин, гашыйк, көчкә түзәм.

Ул аны чут-чут үпкәндә
Җилләре миңа тия.
Кырык корама юрганда
Мин ятмыйм икән нигә?

Нигә хет бер уенчыгын
Ул миңа бирми икән?
Нигә ул мине яңадан
Биләүгә төрми икән?

... Эндәшми күзәтәм аны.
Утыргыч арасыннан
Кушучлап мәхәббәт җыям
Күзенең карасыннан...

* * *

*Фәүзия Бәйрәмовага*

Урам аша — ике эмигрант,
Туган җирдә, Татарстанда,
Урам аша —
Гүя чит илләрдән
Хәлең беләм коштан, дустан да...

Кызыл чүпрәкле бау — безнең чик бу.
Аучы халкы, тотып колгалар,
Һәр куакның эчен савып, имеш,
Безне түгел — бүре сугалар...

Урамнарга ялгыз чыкма, дисең.
Үзең белән ал бер сак, дисең.
Саксыз йөрим: белəм, доган белəн
Күбебезне, сеңлем, саклыйсың.

Бер камышның ике буынындай,
Бер туй, бер буй, бер үк уйдан без —
Җиргə сəлəт булып туган өчен
Алдан һəлак булып куйган без...

Аягүрə килеш чери кеше.
Кояшы да əллə нишлəде:
Синнəн ялкын алып янды күктə —
Кеше арасына төшмəде...

Синең тəрəзəңə карап яшим —
Анда лəйсəн ява яшенлəп.
Яшен күзен ачтым: шунда мəллə
Безнең татар серен яшергəн?

Яшен күзе күзəтү астында
Яше белəн тозлы кан ялый:
Үзəгендə яшь кенə Абыстай
Энҗе энə белəн җан ямый...

...Урам аша — ике эмигрант,
Туган җирдə, Татарстанда,
Буран аша —
Гүя чит иллəрдəн
Хəлең белəм коштан, дустан да...

## Күлəгəсез урман

Ат күзлəре белəн түшəлгəн юл —
Без тормышка синнəн башландык.
Ат яшьлəре юган бу юл бүген
Ташсыз кабер сыман ташландык.

Аһ, Кралов! *
Балачак урманым!
Синнəн өзеп алган балтырган
Минем моңны ак чарларда чарлап,
Зəңгəр чарлак**ларга чаптырган!...

Аһ, Кралов!
Кара урман! Көндез
Печəн чабып, төндə ат чабып,
Палищщик***тан урлап, синнəн генə
Шарт аудара идек матчалык.

---

* "Королев дачасы" дигəннəн алынган. Алпавыт исеме.
** Офыклар ачылða торган биек урын.
*** "Полесник"тан алынган. Урман каравылчысы. *(Автор искəрмəлəре.)*

Менә бүген куйныңда ауныйм дип
Кайткан идем — сине танымыйм!
Урманнардан шәрә колга калган,
Ниләр генә булды, җаныем?!

Яфракларың кая? Сайрар кошың?
Синме безнең җиләк келәте?
Корыган,
корыган имән
кочып җылыйм —
Урманнарда имән үләте!..
Агачларны колониаль сөю
Шундый дәһшәт белән, тәүбәсез
Көйдергән ки —
Мәңге тере урман
Үлгән — күләгәсез, шәүләсез!

Буш кәүсәләр бозык кавем сыман
"Туй чапмыйлар, бала тапмыйлар".
Очкычлардан агу сибеп, урман
Шәүләсенә кадәр саттылар!..

Исәр кәүсәләрдән исәрләнеп,
Саташам, аһ, үземә кул салам! —
Кайтар, мәлгунь, кара урманымның
Кара шәүләләрен булса да!..

Бер шәүләсез яшәү мөмкин түгел.
Яшьне дә шәүләсез сөртмиләр.
Урман белән тәмуг керәп барам —
Шәүләсез анда да кермиләр...

Ходайга ялварган әсирләрдәй,
Буш ботактан күкне кайтарып,
Ат күзедәй шартлап чыгып, урман
Ава —
Куя галәм чайкалып.

... Чираттагы имән гөрселдәгәч
Киселде иң актыккы өметләр.
Бер пычкысыз урманнар аудара
Тамыр кырмыскасы-термитлар...

## Исхакый каурые

Миңа — дүрт. Туң тәрәзәдә
Зеңгелди бозлы күзләр.
Аркама суынган мичтән
Дәүләти җылы эзләп,
Утырам — сабый — сәкедә.
Ач карын карын көри.
Янымда минем тирәләп
Фәрештә очып йөри...

— Калдырма ялгыз! — дим Аңа. —
Бу өйдән китә күрмә!
Син булсаң — җылы һәм рәхәт,
Син китсәң — салкын төрмә!..

— Китмим! — ди индә Фәрештәм. —
Бисмилла, сабый, сөен:
Исхакый үзе сиңа дип
Җибәрде каурыен...

## Кипарис кайткан иленә...

*Салих Баттал истәлегенә*

Кипарис кайткан иленә —
Шашкан Ил Анасыдай,
"Тереме? Үлеме?" дигән
Ике ут арасында
Таулардан тауларга чаба...
Үзәнлек, далаларын
Барлап, берәмтекләп йөри
Югалткан балаларын.

Ташларның йөрәген тыңлый,
Сындырып, чуерташның
Күзәнәгеннән черегән
Үзәген алып ташлый.

Һәр нәрсәне капшый, сыйпый,
Ярата, яраттыра —
Ул белә, бүген бу хаят
Яңадан яратыла.

Үрелеп, Галәмне исни,
Җиде күздән кичерә —
Сусаган Айга, Кояшка
Учыннан яшь эчерә.

Алтынсыз калган Йолдызны
"Алтыным!" диеп сөя.
Бисмилласында җан өреп,
"Үс!" диеп күккә чөя.

Чәйнәп карый, үләннәрнең
Исән кыягын иеп.
"Яшелдә нәселгә яшел
Калдырганнармы?" — диеп.

Китәргә тиеш кораблар
Ник җилкән күтәрмиләр?
Диңгезгә кирәргә итә —
Ярга да үткәрмиләр.

Кипарис кайткан иленә —
Илле ел арасында

Күз караларын табалмый
Күзенең карасында.

Арып, туктый да далада
Җиләнен салып ташлый.
Кулына инә ала да
Нәрсәдер казый башлый...

— Ни эзлисең, Кипарис? — дим.
— Мин әле кое казыйм, —
Ди Кипарис. — Шул коедан
"Әлифба" эзләп карыйм...

Читтә Ач Саңаклы Җәллад
Самосад төреп тора.
"Әлифбаң минем кесәмдә", —
Дип мыек борып тора...

## Казанда — тыныч, Кабанда — давыл.

Куркак булдым — ихтыярсыз калдым,
Кадерләдем — калдым кадерсез.

Күренми шәһәр, күренми авыл.
Казанда — тыныч, Кабанда — давыл.

Үзгәртергә мине әзерсез дә,
Яшәтерсез микән җәберсез?

Күренми шәһәр, күренми авыл.
Казанда — тыныч, Кабанда — давыл.

Башларың әйләнсә көймәдә,
Адашасың икән күлдә дә.

Күренми шәһәр, күренми авыл.
Казанда — тыныч, Кабанда — давыл.

# Чәчмә әсәрләр

## Фәйзи Галиев



# ӘТНӘ — КҮҢЕЛЕМ БИШЕГЕ

ИСТӘЛЕКЛӘР

### Әтнә белән танышу

*Мин үзем Әтнә районының Түбән Шашы авылында туып үстем. Гомеремнең 49 елы берничә авылны берләштергән "Искра" колхозында рәис булып эшләп узды. Шул зур колхозны тәшкил иткән Күнгәр, Түбән Шашы, Югары Шашы, Күшәр, Мөндеш, Ташчишмә, Мокшы авылларының эшчән кешеләре турында өч китап яздым. Авылдашларымның меңнән бер өлешен булса да кәгазьгә төшерүем белән горурланам. Аларның эшләрен, көнкүрешләрен, хәзерге матур тормышыбызга җиңел генә ирешелмәгәнлекне яшь буын кешеләренә аңлатырга тырыштым. Бу китапларны язган вакытта ук районыбыз колхозларының тормышы, район җитәкчеләре хезмәте белән бәйләнеше хакындагы язмаларымны дәвам итү теләге туган иде. Менә хәзер, эштән китеп, пенсиягә чыккач, шул уемны тормышка ашыру мөмкинлеге туды. Элекке язганнарымны барлап, илебездә һәм районыбызда барган хәлләрне күзәтүдән чыгып, фикерләремне халыкка җиткерергә уйладым. Баштан ук искәртеп куям : елларда, исем-фамилияләрдә төгәллек булмаска да мөмкин, чөнки вакыйгалар күп елларны эченә ала.*

Хәзерге вакытта районыбызның үзәге булган Әтнә авылы исемен беренче мәртәбә миңа бала вакытта ук ишетергә туры килде. Күрше малайлары белән урамда уйнап йөргәндә, авылыбызның югары очына таба кешеләр чабыша башлады. Күршеләребез Кашшаф абый, Нәгыймәбикә, Мәһирә апайлар артыннан минем әни дә йөгерде. Мин дә аларга иярдем. Барган уңайга мин әниемнән нишләп барлык кешенең шул якка йөгерүләрен сорадым. Әни Әтнәнең януын хәбәр итте. Без, малайлар, бодай басуында, биегрәк урынга басып, Әтнә ягын күзәтә башладык. Тик бригадир Мәгъсүм абый безне аннан куып чыгарды. Мин әни янына барып, Әтнәнең кайда булуын сорадым. Әни Әтнә ягына бармагын төртеп күрсәтте. Миңа, яшь малайга, Әтнә өстендә күренгән ут бик куркыныч булып тоелды. Әле дә хәтеремдә,

---

Фәйзи ГАЛИЕВ — *Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы. "Икмәк язмышы", "Авылым гадәтләре" китапларының авторы. Әтнә районы Түбән Шашы авылында яши.*

җәйнең шундый эссе көнендә авылның берничә урыныннан ялкын күтәрелде. Карап торучылар утның төрле урамнарда килеп чыгуын әйтеп, кызу-кызу сөйләштеләр, бәхәсләштеләр. Кешеләрнең күбесе атлар белән дә, җәяүләп тә туганнарына, танышбелешләренә ярдәм итәргә ашыкты.

Төрле урамнардан чыккан янгын бер заман бергә тоташып, зур һәм куркыныч ут өермәсе хасил итте. Безнең авыл кешеләре, Әтнә халкын кызганып, кайда торырлар инде, ничек яшәрләр, авыллары белән янып бетәләр ич, дип борчылышып сөйләштеләр. Ут бер караганда югары күтәрелә, икенче караганда түбән төшә, дулкын булып тирбәлеп тора, әле сикерә, әле тына иде. Кичкә таба ул зәңгәрләнде, Әтнә булган җирдән кара төтен чыга башлады.

Шулай итеп, беренче мәртәбә мин Әтнә сүзен ул авылга килгән зур фаҗига белән бергә бәйләп ишеттем. Бу янгында 500 дән артык йорт янган. Аның сәбәбен берәүләр: байлар, йорт-каралтыларын тартып алуны теләмичә, үзләре ут төрткән, диделәр. Ут саксызлыктан чыккан, диючеләр дә булды.

Бер мең йортлы Әтнә авылы өстенә килгән бу гарасат авыл халкына бик кыйммәткә төшә. Халыкның бер өлеше авылларында калып, бик зур авырлык белән яңа нигез кора. Чит җирләрдә тормыш кора алуларына ышанганнары күчеп китәргә мәҗбүр булалар. Боларның байтагы азмы-күпме гыйлем иясе һәм таза тормышлы кешеләр булган. Чит җирләргә китеп урнашканнарның балалары зур укымышлы булып үсеп җитеп, кайчандыр бабалары, әтиләре яшәгән җирләрдә күренекле башлыклар.

Авыллар тарихында сирәк була торган мондый фаҗиганы кичергән Әтнә үз әйләнәсендәге авылларны берләштергән район үзәге булып китә. Район үзәге булу, әлбәттә, күп үзгәрешләр китереп чыгарды.

Район булганчы бу төбәктә яшәгән авыллар Казан губернасына караган ике өязгә бүленгәннәр. Ашыт суының уң ягындагы авыллардан иске Өҗем, Яңа Өҗем, Кызыл Утар, Кызыл Яр, Яңа Шашы, Ключи Сап, Малмыж, Чембулат, Иске Җогып, Күнгәр, Югары Шашы, Түбән Шашы, Дусым, Җилгелде, Күәм, Казак Үртәме, Каенсар, Әйшияз, Түбән Көек, Югары Көек, Иске Шимбер, Яңа Шимбер, Күлле Киме, Ары, Бактачы, Яңа Бәрәскә, Мәзекәү, Атамыш авыллары, шулай ук Яңа Кенәр авылы янындагы берничә авыл Чар өязе (Царево-Кокшаевский) дип йөртелгән хәзерге Йошкар-Ола шәһәрендә урнашкан өяз үзәгенә буйсынганнар.

Ашыт суының сул ягындагы авыллардан Кышкар, Наянгуш, Симетбаш, Иске Кишет, Яңа Кишет, Бәхтияр, Олы Мәңгәр, Иске Мәңгәр, Яңа Мәңгәр, Күшәр, Олы Әтнә, Кече Әтнә, Шәкәнәч, Норма, Югары Сәрдә, Байчыга, Иске Җөлби, Яңа Җөлби, Кушлавыч, Мәрҗән, Комыргужа, Төрекләр, Ябынчы, Кабакса, Соңгыр, Югары Бәрәскә, Түбән Бәрәскә, Олы Өшкәтә, Кече Өшкәтә, Олы Бәрәзә авыллары Казан өязенә кергәннәр. Шулар өстенә әлеге авыллардан күчеп киткән кешеләр кечкенә авылларга берләшеп, Маяк, Үрнәк, Яңа Җогып, Күчкән Күәм, Крестьян Үртәме барлыкка килгән һәм алар да Чар өязенә караган. Ә Нариман, Кызыл Байрак авыллары Казан өязенә кергән. Бу авыллар Олы Мәңгәр, Иске Ашыт, Ташчишмә авылларыннан аерылып чыккан булганнар. Бу өязләргә кергән авылларның халыкларына өяз белән элемтәгә керү юл ераклыгы аркасында бик уңайсыз булган. Чар өязенә кергән безнең авыл картлары сөйләвенә караганда, солдатка чакырылган егетләр Чарга җәяү барганнар, җәяү кайтканнар. Барып кайту өчен ике кием чабата кирәк булган. Әтнәдә район төзелгәннән соң, халык өчен уңайлык, аның авылларга якын булуында күренә.

Икенче мәртәбә Әтнә авылын миңа тугыз яшемдә күрергә туры килде. Әти Күнгәрдә авыл Советы рәисе булып эшләгәндә, мине үзе белән Әтнәгә алып барды. Җәй көне иде, болын аша бардык. Ике ара биш чакрым. Базар көн иде. Әтнәдә һәр шимбә көнне зур базар була. Башта әти райбашкармага кереп чыкты. Ул Бәрәскәгә чыга торган урамның иң соңгы йорты булып, ике катлы бина иде. Райбашкармадан чыккач, каршы яктагы ике катлы йортны әти: менә бу мәктәп була инде, дип аңлатты. Аннан бераз төшкәч, яңа оешып килә торган МТС урнашканлыгын әйтте. Шуннан күпергә таба

бара башлагач, Гатаулла бай йортына кердек. Анда да нинди дер район оешмасы урнашкан иде. Аннан чыккач, базар аркылы өске урамга менеп киттек. Күпергә кадәрге урамда атлы олауларда печән, күмер, юкә, утын, бүрәнә-такта ише нәрсәләр, икенче кырыйда пешкән ризыклар: клиндер, перәннек, вак бәлеш саталар. Шундагы бер йортның түбән ягында кечкенә генә кибет бар иде. Без барганда, анда зур чират булып, мин бик гаҗәпләндем. Әтидән: “Бу нинди кибет, анда нәрсә саталар?” — дип сорадым. Аның аракы кибете икәнен, кабак дип аталуын аңлатты әти. Кибет әйләнәсендәге җанлылыкны бераз күзәтеп тордык. Аннан кешеләр чирекле (өч литрлы), бер литрлы, ярты литрлы, чирек литрлы (чити), чирек литрлының яртысы (әчмухә) шешәләр күтәреп чыгалар иде.

Югарырак менгән саен, базарга килгән халык күбәя барды. Мин гомеремдә беренче мәртәбә шундый күп сатучыларны, сатып алучыларны Әтнә базарында күрдем.

## Авыллар

Революциягә кадәр, районнар булып исемләнгәнче, өязләр эчендә волостьларга бүленеп идарә ителгән. Ул волостьларда җитәкчелек аз кешеләр кулында булган. Мәсәлән, Югары Шашы авылында урнашкан Кышлау волосте канторында бер башлык, бер писер, бер конторны карап торучы — барысы өч кеше эшләгән. Ә ул волостька 18 авыл кергән. Һәр авылда җитәкчелек итүне һәм тәртип саклауны авыл халкы сайлап куйган староста белән мулла алып барган. Соңга таба, волостьлар белән идарә итү өчен кантон дигән оешма барлыкка килә. Бу чорда волостьлар эреләнә. Мин яшәгән авыл Күлле Киме волосте, Арча кантонына карый иде. Бу исемләү озакка бармый, авыллар белән идарә итү өчен районнар төзелә башлый. Беренче мәртәбә Әтнә районы төзелә. Аның биләмәләренә шактый гына авыллар керә.

Әтнә районы булып озак кына яшәгәннән соң, Кенәр ягындагы авыллар Әтнәдән аерылып чыгып, яңа район төзиләр. Район үзәге булып Яңа кенәр билгеләнә. Районның исеме Кызыл юл дип йөртелә башлый. Әтнә районыннан бүленеп чыккан авыллар белән бергә, Балтач районыннан да шактый авылларны бүлеп алып, Кызыл Юл районына кушалар. Әтнә һәм Кызыл Юл районына кергән авыллар ике район булып бүленсәләр дә, бик тату яшәделәр. Чөнки аларның күбесе Чар өязендә бергә яшәгән авыллар иде.

Район белән җитәкчелек идарәсе итеп район советы һәм аның башкарма комитеты оештырыла. ВКП(б)ның район комитеты һәм аның бүлекләре төзелә. Район белән җитәкчелек итү оешмалары Әтнә авылындагы байлар йортларына урнашып торганнан соң, зур район вакытында ук югарыда искә алынган базар мәйданы уртасында идарә оешмаларын урнаштыру өчен бер бина салына. Бу — хәзерге хакимият урнашкан бина. Аны төзү өчен авыллардагы таш мәчетләрне сүтеп, шуның кирпечләреннән файдалану күздә тотыла. Кайбер мәчетләрне сүтү җиңел булып, дөрестән дә кирпечләрен ташыганнар. Кайберләрен, бик тырышсалар да, сүтә алмаганнар. Шуларның берсе — Югары Бәрәскә авылы мәчете. Аның әйләнәсендәге баганаларын, мәчет бинасының бераз алдын, бераз өстен генә ала алганнар. Кирпечләрне тоташтыручы измәне кубарабыз дип кирпечләрне вата башлагач, ташлап китәргә мәҗбүр булганнар. Нинди генә авырлыкларга карамастан, ул бинаны төзеп бетереп, район оешмалары шунда урнашкан.

Әтнә белән өченче мәртәбә танышуым, әтине Күнгәр авыл советы рәислегеннән Әтнә район башкарма комитеты сәркәтибе итеп күчергәннән соң булды. 1935-1938 елларда әти шунда эшләгәндә миңа аның янына гел барып йөрергә туры килә иде. Ул вакытта миңа 10-13 яшьләр булгандыр. Район белән җитәкчелек итү аппаратында хәл ителә торган мәсьәләләр белән кызыксыну миндә шул вакыттан ук уянды. Хәзерге хакимият башлыгы утырган бүлмәдә ул вакытта райбашкарма рәисе иде. Алгы бүлмәдә сәркәтибе

— минем әти эшләде. Аның бүлмәсенә еш кына башкарма комитетында эшләүче хезмәткәрләр кереп-чыгып, киңәшеп, сөйләшеп утыралар иде. Район советы башкарма комитеты рәисе вазыйфасын Саттаров Гайнетдин башкарды. Тумышы буенча Мөндеш авылыннан. Әтнәгә кайтып эшли башлаганчы Казанның дары заводында профсоюз житәкчесе булган. Кешеләрне оештыруда сәләтлелек күрсәткәнен искә алып, өлкә комитеты бу иптәшне райбашкарма комитеты рәислегенә тәкъдим итә. Төз гәүдәле, тулы бәдәнле, саргылт чәчле. Сәркәтибе булып эшләүче минем әтигә ихтирамы зур иде. Әти мәдрәсә белеме белән дә зур эш башкарды — урыс телен, мари телен, татар телен яхшы белә һәм грамоталы итеп яза иде.

Дәһшәтле 1937-38 елларда район житәкчеләренең күпчелегенә "халык дошманы" дигән исем тагылып, төрмәләргә ябылды, атып үтерелде. Кайберләре төрмәдәге начар шартлардан, шул исәптән башкарма рәисе Саттаров Гайнетдин дә төрмәдә үлә. Гаиләсе кимсетүләргә чыдый алмыйча, башка урынга күчеп китә. Ләкин анда да хатынына һәм өч баласына яшәргә мөмкинлек бирмәгәннәр. Балалары балалар йортларына китеп, төрле якка таралышып беткән. 1937-38 еллар фажигасе районнардан авылларга да күчә. Башта бу афәт муллалар өстенә төшә. Мин яшәгән Түбән Шашы авылы мулласы Зарифны төнлә алып киттеләр һәм ул шул китүдән кайта алмады. Гаиләсен йортыннан куып чыгарып, мәктәп ачтылар. Хатыны Кафия апа биш баласы белән мунчада яшәде. Авыл халкы аларга ярдәм итеп торды. Соңыннан, кимсетүләргә чыдый алмагач алар Үзбәкстанга —туганнары янына күчеп киттеләр. Мондый хәлләр авыл саен булды. Кайберәүләргә кулак исеме тагылып, авылдан сөрелделәр. Малларын, йорт-жирләрен конфискацияләп, "торги ясап" сатулар оештырылды. Хәзерге вакытта кайберәүләр авылдан читкә китүчеләрне акча көрәп алырга киттеләр, дип бәяли. Фактта алар төрле мыскыллауларга, мәсхәрәләүләргә түзә алмыйча чыгып киттеләр. Әле дә хәтеремдә, безнең авылның мәчете каршында атларга төяп, бер хәлле гаиләнең йорт әйберләрен сатарга алып чыкканнар иде. Сатуны оештыручы авыл Советы вәкиле Вәли абый әйберләрне күрсәтә дә бәясен әйтә, сатып алучыларның соравына, таләпләренә карап, әйбернең бәясен арттыра, кимета. Мин карап торганда алучылар булмады, чөнки әйберләрнең хужасы читтә елап тора иде.

Авыл халкының читкә китүе бердән мин әйткән сәбәпләр аркасында булса, икенчесе — кирәгеннән артык зур түләүләр халыкның теңкәсенә тиюдә иде. Алар зур күләмдә ит, сөт, йомырка, йон, һәртөрле акча салымнары түләргә мәжбүр ителделәр. Салымнарны соңга калып түләгәндә яки түли алмаган очракта малларын мәжбүри алып чыгып китү очраклары да булды. Әле дә күз алдымда, безнең авылдагы Фәйзиев Фәтхерахман абыйның, ит заданиесен түләмәгәне өчен, район хәзерләүләр конторы вәкиле килеп, ояда утырган казын алып чыгып китте. Мескеннең 12 йомыркасы ояда калган, каз колхоз идарәсе янында нишләргә белми, кагынып кычкыра. Үзе бер кая да китә алмый, чөнки аны вәкил әржә кырыена бәйләп куйган иде. Кешеләр вәкилнең казны калдыруын үтенәләр, ә тегесенең бирәсе килми, ит заданиесен баштарак түләсен иде, ди. Шулай итеп вәкил казны кычкырта-кычкырта арбасына салып урам буенча алып китте. Ә каз хужасы Гыйльмижиһан апай йомыркаларны башка кешеләргә биреп, бәбиләр чыгартып йөрде. Авылыбызда анасыз бәбкәләр, шул чорның фажигасен белдереп, боегып йөрделәр. Һәр төрле заемнар, салымнарның арта баруы кешеләрнең ризасызлыгын арттырды. Ул заем дигән афәт озак еллар буе дәвам итте. Иң элек, районнан авыл саен заем планы житкерелде. Аны һәр хужалыкка бүлеп чыктылар. Ул планны үтәтү өчен, кешеләрнең ризалыкларын белдереп кул куюлары кирәк иде. Авыл активыннан өч-дүрт кешелек комиссия йорт саен кереп йөрде. Комиссия кул куйдыра алмаса, ул кешеләрне авыл Советына чакырып куркыттылар. Район вәкиле белән берлектә кул куярга мәжбүр итәләр иде. Безнең авылга район вәкиле булып Садриев Әхмәт исемле галәмәт усал кеше килгән иде. Миңа аның Зарипов Усман абый белән сөйләшүен тынлап торырга туры килде. Усман абый үзенә заем планының артык зур булуын, аны түли

алмаячагын әйтүе булды, вәкил ярсып китеп: “Мин синнән түли алмавынны сорамыйм, кул куясынмы, юкмы!” — дип жикеренде. Шул арада авыл Советы рәисе бу кешенең умарталары да булуын исәпкә алып план җиткерелүен әйтте. Вәкилнең шул сүзне ишетүе булды: “Бу әле чебенгә дә баймыни?” — дип катырак кычкыра башлады. Шул арада вәкил авыл Советы рәисенә әйләнеп карады да: “Умартасы да булгач, ник аңа планны аз җиткердегез? Планны арттырып языгыз!” —дип әмер бирде. Шул арада арттырып язып, Усман абыйның шул планга кул куюын таләп итә башладылар. Мескен Усман абый болай да кыска буйлы кеше, бу хәлдән соң тагы да кечерәеп калган кебек күренде. Үзе мичкә терәлеп утырган, тирләгән, төсе киткән, курыкканы күренеп тора. Тәки кул куярга мәҗбүр булды.

Авыл җиреннән кешеләр китүнең тагын бер сәбәбе —мәҗбүри рәвештә яшүсмерләрне ФЗӨ мәктәпләренә җыйнау иде. Ул чорда шәһәрләрдә зур төзелешләр башланды. Мәсәлән, Казанда авиация заводына, моторлар төзү, ясалма каучук, ясалма күн, кинопленка заводына эшчеләр җыю барды. Шуның өстенә Донбасс, Кузбасс шахталарына бик күп яшьләрне көчләп җибәрделәр. Качып кайтсалар, хөкем чыгарып, колонияләргә озаталар иде. Кайберләренең ата-аналарыннан ФЗӨда баласы өчен тотылган чыгымнарны да түләттеләр. Безнең авылның Габдрахманов Сәлимне ФЗӨдан качып кайтканы өчен төрмәгә утырттылар. Илне индустрияләштерү өчен авыл хуҗалыгын таркату башланды. Бу сәясәт һәрвакыт радио, матбугат аша мактылып торды.

Авылдан кешеләрнең күпләп китүнең тагын бер сәбәбе — хезмәткә түләүнең түбән булуы иде. Бу эш колхозлар төзелә башлау белән, 1930 еллардан ук башланды. Эшкә чыккан өчен хезмәт көне язып барып, ел азагында колхозларның аны түли алмавы кешеләрне бөлгенлеккә төшерде. Ә авылдан китүчеләр эшкә иң сәләтле, булдыклы кешеләр иде. Әле санап киткән сәбәпләр өстенә көнкүреш кирәк-яракларының булмавы, булганын сатып алу өчен акчаның җитмәве дә авылдан китәргә мәҗбүр итте халыкны.

Кешеләрнең авылдан китүенең тагын бер сәбәбе — революция булганнан соң бер төркем хәллерәк кешеләр төрмәгә утыртудан куркып чит илләргә чыгып тайганнар. Шундыйлардан безнең авылдан да берничә кеше киткән. Хәлиулла исемле кеше, туганнарын, балаларын ияртеп, Кытайның уйгурлар яшәгән Колҗа шәһәренә китеп барган, соңгы елларда Кытайда культура революциясе башлангач, исән калганнары Казакъстанга кайтып яши башладылар. Безнең күршедәге Иске Өҗем авылыннан шул ук Кытайга китеп, аннан Төркиягә килеп, соңыннан Германиядә укып кайтып, Төркиядә зур галим булган Арат Рәхмәти исемле кешене дә беләм мин. Шулай ук Мәнгәр авылыннан үзен Мәнгәрле дип йөрткән кеше дә Төркиягә киткән. Малае әле дә исән, зур автобуслар чыгара торган кампаниянең хуҗасы булып эшли.

Бу төбәктә яшәүче кешеләрнең элек-электән читкә чыгып акча эшләү гадәтләре дә булган. Әүвәле алар иген эшләре беткәч кенә чыкканнар, тормышлары авырая башлаган соңгы елларда шунда бөтенләй күчеп яши башлаганнар. Безнең авыл, күрше авыл кешеләре Брянск өлкәсенең Дятьково шәһәрендәге пыяла заводында эшләп, шунда төпләнеп калганнар. Комыргужа ягы кешеләре шахталарга киткән. Бәрәскә, Күнгәр кешеләре Әстерхан байларына барып ялланган. Шул исәптән минем әти дә шунда эшләп чыныгу алган. Тормыш авырлыгын җиңеләйтү өчен төрле вак сатучылык, кустарчылык эшләре белән шөгыльләнгәннәр. Ашыт суының уң ягында урнашкан авылларның күпчелеге, марилар белән аралашып, мари урманы байлыкларыннан файдаланганнар. Агач, җиләк-җимеш, юкә, мүк һ. б. әйберләр алып кайтканнар. Мәсәлән, юкә алып кайтып, аннан чабата-башмак ясап сатканнар. Әле соңгы елларда да Әйшияз, Кече Әтнә кешеләре чабата ясап Әтнә базарында сатып көн иттеләр. Байчыга кешеләре тире эшкәртү, Кече Әтнәләр киез итек басу, Шимбер, Күәм, Бәрәзә кешеләре чыпта сугу белән шөгыльләнеп, кайбер авылларда оекбаш-бияләй, шәл бәйләп көн иттеләр.

Авыллардагы оста иген игүчеләр — авыл байлары —игенчелектә үрнәк булып торганнар. Кайсылары халык өчен кирәкле товарларны табып, алып

кайтып сату эшен оештырганнар. Шундыйлардан Олы Әтнәдә Гатаулла бай, Бәрәскәдә Гали бай, Олы Мәңгәрдә Гатаулла, Яңа Шашыда Хәйрулла, Мамышта Мәҗит байлар булган. Аларны сөрү авылда игенчелеккә, товар житештерүгә шактый тискәре йогынты ясаган. Болар бит нигездә авыл халкына бик ярдәмчел булганнар. Үз чиратында алар уңышлы сәүдәдән соң файдаларының бер өлешен күрше авыл кешеләренә дә өләшкәннәр. Безнең тирә авыл кешеләре Мәҗит бай кайткан икән, закят өләшә башлаган, дип, шунда бара торган булганнар.

* * *

Татар халкы урнашкан урыннарның табигате гаҗәп матур. Пароходлар йөри ала торган дүрт зур елга — Идел, Чулман, Нократ һәм Агыйдел Татарстанга гүзәллек биреп тора. Аларга кушылган Зөя, Зәй, Чирмешән, Ык, Минзәлә шикелле елгалар янында алардан кечерәк Мишә, Ашыт, Гөбнә, Казансу, Актай, Чишмә һ. б. күп кенә инешләр республикага матурлык өсти. Кечерәк елгалар буена районыбыз авыллары урнашкан. Татар авылларының чишмәләре күп булу — ул үзе генә дә зур байлык. Безнең Әтнә, Арча, элекке Кызыл Юл районнары урнашкан урында җир астында зур гына су бассейны бар, шуннан чыккан вак чишмәләр елгаларны туендырып тора. Бассейнның үзәге булган Тукай-Кырлай басуыннан биш-алты чакрым ераклыктагы урыннардан сигез вак елга башланып китә. Ашытбаш янынннан Ашыт, Шурабаштан Шура, Шушмабаштан Шушма, Иябаштан Ия, Бирәзәбаштан Бирәзә, Симетбаштан Симет, Субаш Атыдан Аты, Орнашбаштан Орнаш инешләре башлана. Бу елгаларның үзәннәре әйләнәсендәге болыннар терлек асрау өчен печән үстерү чыганаклары булып торганнар. Алай гына түгел, елгалар буена су тегермәннәре тезелеп киткән. Ул тегермәннәрнең буаларын шул тирә авыл кешеләре төзегән һәм төзеклеген карап торганнар. Буалар белән суны күтәртеп, болыннарда печән уңышын мул итеп үстерү мөмкинлеге туган. Нәтиҗәдә, күпләп хайван асрый алганнар. Тегермән буаларында балык күп була иде. Буа арты чоңгылларында бигрәк тә. Зур-зур бәртәчләр, корбан балыклары канатларын селкетеп, көн яктысында ял итеп яталар. Сулыклар тирәсендә яшәүче авыл кешеләре аерата яз көннәрендә күпләп балык тоталар иде. Әле дә хәтеремдә: 10 килолы чуртан балыгын эләктереп, Югары Шашы кешесе Сафагәрәй абый бау белән аны иң башына салып менгәндә балыгы тез астына кадәр төшеп тора иде. Авыл саен җил тегермәне дә бар иде. Безнең район биләмәсендә Әтнә янында ике тегермән булып, берсе — Юанаяк тегермәненең аз гына җилдә дә әйләнеп торганын хәтерлим. Бәрәскә авылы янында хәтта 4 тегермән эшли, Күнгәр, Түбән Шашы кебек кечерәк авыллар янында да берәр тегермән бар иде. Безнең район авылларының тегермәнсезләре булмагандыр. Электр кергәнче җил һәм су көченнән файдалану киң таралган булган. Су тегермәннәренең берничә ташта ашлыкны иләп, ак он итеп тарту, гади он тарту, ярма ярдыру, хәтта йон тетүгә көйләнгәннәре дә булган. Су һәм җил тегермәннәренең урынын дөрес билгеләү әһәмиятле булган. Елга суының агу тизлеген, күплеген, елга борылышларын исәпкә алырга туры килгән. Җил тегермәне урынын үр өстенә, җилнең юнәлешен өйрәнеп билгеләгәннәр. Бу эшләрне тәҗрибәле осталар башкарган. Алар бик кадерле һөнәр ияләре булганнар. Соңгы вакытта, электр көченнән файдалана башлагач, табигый көчләрдән файдалануга игътибар бетте. Барлык эш электрга корылгач, су һәм җил тегермәннәренең кирәге калмады. Болыннарның матурлыгы, уңышлары кимеде. Балыкларның да затлылары бетте. Сулар саекты. Елгаларда ташбаш, чабак балыклары гына үрчи ала хәзер. Безнең буын кешеләре табигатьнең матурлыгын киметүдә гаепле булып калдылар. Шуның өстенә елның теләсә нинди вакытында күпләп көтү йөртү аркасында табигый болыннарның сыйфаты начарланды. Шушы эшне төзәтү йөзеннән, галимнәрнең киңәшләренә нигезләнеп, болыннарны яхшырту өчен, аларны сукалап, культуралы үләннәр дә чәчеп

карадылар, әмма ул да тиешле нәтиҗә бирмәде. Элегрәк авылыбыз кешеләре җир-суларны бик кадерләп, саклап тора торган иде шул. Чишмәләрне чистартып тордылар, болыннарга мал-туарны да печән чабып алгач кына чыгаралар иде. Ә ана кадәр көтү кара басуга чыгарылды.

Җирне эшкәртүдә зәпкә сөрү кулланыла иде. Хәзер җирләрне әйләндереп сукалау аркасында туфракның уңдырышлы өлеше җәйге яңгырлар, язгы ташу сулары белән бик каты юылуга дучар була. Шул сәбәпле инешләр саекты, чишмәләр күмелде. Грунт суы өскә якынаю аркасында аерым урыннарда сазлыклар барлыкка килә башлады. Туфракның юылуына юл куймау ул — туфрак өчен кыйммәтле гумус өлешен саклау дигән сүз. Туфракны болгатмауны күздә тотып, элегрәк басуларны өч өлешкә генә бүлеп файдаланганнар. Беренчесе — чиста пар, икенчесе — арыш басуы, өченчесе — сабан культуралары. Бу басуда бодай, солы, борчак, ясмык, карабодай, арпа, тары кебек культуралар игелгән. Басуда сызма культуралар да, бәрәңге дә игелмәгән. Колхозлашуга кадәр бәрәңге үстерү безнең якларда киң таралмаган. Әле мин бала вакытта да вак кына әмерхан (ягъни америкән) дигән бәрәңге игелә иде. Безнең якларга бит бәрәңге Америкадан китерелгән. Ә иген җирләрен эшкәртүгә килгәндә, төп корал итеп сабаннар, ягъни кусила дип аталган кораллардан файдаланганнар. Аның тәртәләре агачтан, тәренен тимердән, ә тырмалары агач рамнарга имән тешләр куеп ясала иде. Колхозлашу алдыннан читт илдә ясалган бер атлы, ике атлы металл сабаннар кайта башлады. Мин бер төрлесенә "Берлин" дип язылганын хәтерлим. Тырмаларның тешләрен металлдан ясап куя башладылар. Игеннәрне фәкать кул урагы белән генә уралар, урак өсте житкәч, авыл халкы өмәләр ясап, бер-берләренә ярдәмнәр оештыра иде. Кул көче белән урган ашлыкны көлтәләргә бәйләп, 50-60 көлтәдән чүмәлә куйганнар. Чүмәләләрдә ашлык кипкәч, зур кибәннәргә куеп саклаганнар. Сугу эшен халык үз ишек алларында, хәллерәк кешеләр әвеннәрдә чабагачлар белән башкарган. Дымлырак булган елларда шешле әвен дигән киптерү җайланмалары төзеп, көлтәләрне шунда киптерә торганнар иде. Ул әвеннәрнең астына чокыр казып, шунда ут ягып, өстенә аерым җайланмалар белән ут тимәслек итеп, көлтәләрне тезеп куялар. Бу көз яки кыш айларында сукканда шулай эшләнә. Ә җәй көне кояшта киптереп сугалар. Суккан ашлыкны көрәк белән аз-азлап җилгә җилпеп җилгәрәләр иде. Ашлык көрәктән җирдәге җәймәгә төшә, ә җиңелрәк чүп-чарлар (кибәкләре) җилгә оча. Ашлыкны сугуның чабагачлардан башка икенче төрле ысулы да бар: агачтан ясалган станнардагы бүрәнәгә көлтәне суккалап, ашлыгын коялар, ә көлтәдә, көлтә бауларында калган бөртекләрне тәпәчләр белән суккалап төшерәләр иде. Безнең районга кергән авыл халкы гасырлар буена иген игү эшен югарыда саналган тәртиптә башкарып килгән. Ашлыкны су һәм җил тегермәннәрендә тарттыру турында әйттем инде. Халыкта шулай ук кул тегермәннәре дә бар иде.

## Базарлар

Авыл кешесе артык игеннәрен, терлек азыклары булган ит, сөт, май, йомырка кебек әйберләрне, кустарчылык юлы белән житештергән нәрсәләрне базарда сата иде. Безнең Әтнә районы биләмәләрендә Әтнә базарыннан тыш Бәрәзә, Күлле Киме, Иске Ашыт авылларында да базарлар булган. Шулар арасында иң күренекле, зурысы, әлбәттә, Әтнә базары. Шундый ук зур базар Мари иленең татарлар яши торган Бәрәңге авылында да булган. Бу базарларга йөрүчеләр бер-берсе белән әйберләрнең кыйбат яки арзан булуларын белешеп, хәбәрдар булып торганнар. Сәүдәгәрләр шул юл белән үзләренә төшем тапкан. Мәсәлән, безнең авылның Сибгат дигән кеше Бәрәңге, Әтнә базарларыннан арзанрак хакка хайван сатып алып, Казан каласына сыер ите әзерләп саткан. Хайваннарны үз аяклары белән Казан янындагы Сухая река дигән авылдагы бер сәүдәгәргә илтә торган булганнар. Бу сәүдәгәр Казан шәһәре базарларында ит саткан. Сатып

алу һәм базарлар турында сүз барганда, Әтнә базарына тагын кайтам. Соңгы елларда аның урыны күчте. Элекке базар урынына Советлар йорты, түбәндәрәк тагын берничә кибет салынгач, янгын сүндерү йорты да барлыкка килгәч, базар урынын хәзерге клуб урынында ясадылар. Ул рәшәткә белән әйләндерелде, базар эчендә берничә рәт булып, кибетләр өчен тактадан урыннар әзерләнде. Сатучылар базарга акча түләп кертелделәр. Җыйналган акчага базар җитәкчеләре билгеләнде, базарны тәртиптә тоттылар. Кергәч тә уң якта чабата, сул якта икмәк сату урыны, уртада кибетләр, югары башта хайван сату урыннары иде. Еллар узу белән, район үзәге Әтнәдә яшь гаиләләр өчен йорт урыннары, клуб, балалар бакчалары кирәк булганлыктан, базарны хәзерге МСУ урынына — авыл читенә күчерделәр. Монда исә базарга озак яшәргә туры килмәде. Дөньяда район, колхозларны берләштерү чире килеп чыккач, гомер-гомергә халыкның артыгын сатып, кирәген алып яшәргә өйрәнгән матур гадәтләре белән исәпләшмичә, базар бетерелде. Ләкин халык үз гадәтләрен һич югалтмады, көз җиткәч, артык хайваннарын сату өчен, кайберләре алу өчен Әтнәдә кыргый базар оештыра торган булдылар. Базар Әтнәнең төрле җирендә алып барылды. Хәтта мәктәп алды мәйданында да базар оештырдылар. Анда хайван тизәкләре, чебеннәр, сасы исләр барлыкка килде. Балалар йөри торган урынның чисталыгы бозылды.

Кыргый базарларның хуҗалары юк. Хайваннарның каян, ни өчен китерелүе, сәламәтлеге турында авыл Советы, ветврач белешмәләре юк. Шуның аркасында Мари өлкәсе ягыннан һәм билгесез җирләрдән төрле хайваннар килә, безнең якларда булмаган төрле авырулар килеп чыга башлады. Хәзерге чорда ил сәясәтендә бөтен җиһан базар мөнәсәбәтләренә күчәргә дип шаугөр килә. Алып барган сәясәт чынбарлыкка туры килми. Безнең авыл халкын әнә шул мөнәсәбәтләр ата улны, ана кызны белми торган хәлгә куйды да инде. Хәзерге чорда базарлар район үзәгендә генә түгел, һәр авылда булу зарур. Гомумән, базарлар күп һәм төрле булырга тиеш. Алар авыл саен булса, сатучылар машина белән урам буйлап чабып йөрмәсләр, ә бер мәйданда гына сату итәрләр иде.

Соңгы вакытларда республикабызда, шул исәптән безнең Әтнә районы авылларында да, төрле-төрле йогышлы авырулар күренә. Мөгезле эре терлекләр туберкулез, ленкоз дигән чирләр белән авырый. Дуңгызларда чума, сарыкларда суалчан авырулары күбәюенә күзәтүчесез базарлар да булышлык итте. Безнең республиканың Мари республикасы белән янәшә булуы аркасында шул яктан сатып алынган хайваннарның билгесезлеге югарыда искә алынган авыруларның таралуына сәбәпче булып торалар.

## Авыллардагы халыкның әхлагы

Революциягә кадәр авыллардагы тәртипне халык тарафыннан сайлап куелган старосталар алып барган. Алар үз чиратында волость түрәләре белән элемтәдә торганнар. Волость түрәләренә югары дәрәҗәдәге өяз түрәләре тарафыннан зур ышаныч һәм хокуклар бирелгән. Крестьян хуҗалыкларында килеп чыккан аңлашылмаучылыкларны, тәртип бозучыларны авыл үзе, староста белән берлектә хәл иткән. Үзләре хәл итә алмаганнарын волость, өяз түрәләре белән хәл итә торган булганнар. Волость идарәләре йортында җинаятьчеләрне ябып куя торган бүлмә дә булган. Авылларда тәртип бозучыларны, зина кылучыларны халык җыенында хөкем иткәннәр. Гомумән, халык җыеннарының дәрәҗәсе зур булган. Авыл старосталары кайбер вакытларда кирәксез каты җәзалар да кулланган. Кайбер очракларда урлаган әйберләрен муеннарына асып каракларны урам әйләндергәннәр, законсыз бала табучы кызларның капкаларын дегеткә буяп киткәннәр. Бигрәк тә авылда олы кешеләргә хөрмәт зур булган. Теге яки бу кешенең гаепле эшен тикшергәндә өлкәннәр сүзе өстенлек иткән. Авылларда урлау, хулиганлык, эчкечелек кебек нәрсәләр сирәк булган.

Авылның тәртибен саклауда мулла-мәэзиннәр күркәм эш башкарган.

Авылларда гражданлык активларын муллалар алып барган: никахлашу, яна туган балаларны теркәү, исем кушу, үлүчеләрне җирләү кебек гамәлләрне һәм мөселман дине кануннарын төгәл үтәүне таләп иткәннәр. Хәзерге вакытта авыл Советы аппараты алып барган эшне элек бер мулла алып барган. Шул ук вакытта клуб, китапханә, мәктәп башкарган эшләрнең дә күбесен мулла, мәэзин башкарган. Кешеләрне соңгы юлга озату да шушы изге кешеләр тарафыннан башкарылган.

Әле соңгы көннәрдә, кешеләрнең пенсия документларын хәзерләгәндә, туган елларын ачыклау өчен муллар язып барган метрика кенәгәсеннән файдаланырга туры килде. Бу кенәгәләрнең төгәл, пөхтә, һәр сүзен ачык, аңлаешлы итеп тутыруларына гаҗәпләнерлек. Архив материалларын караганда бу эшне безнең авыл мулласы гына шулай алып бардымы икән дип уйлап, башка авыл муллалары язып барган кенәгәләрне дә ачып карадым. Барысында да шундый пөхтәлекне күреп гаҗәпләндем һәм аларга карата ихтирамым тагын да артты.

Бу төбәкләрдә яшәүче халыкларның мәдәниятлекләре хакында түбәндәге фикерләрне әйтергә мөмкин булыр иде. Урыс елъязмаларында революциягә кадәрге татар халкы бик надан итеп тасвирлана. Хәтта губерналар арасында укымышлылыкны урысча укый-яза белү белән генә бәһаләгәннәр. Фактта татар халкы үз телендәге гарәп хәрефләре белән укый һәм яза белү ягыннан урыс һәм башка милләт халыкларына караганда укымышлырак булган. Татар авылларында мәхәлләләр каршында авыл муллалары ир балаларны, абыстайлар кызларны хәтта үз йортларында да укырга-язарга өйрәткәннәр. Бу укымышлы затлар татар халкы өчен бәһаләп бетерә алмаслык изге эш эшләгәннәр. Авылларда халык күплегенә карап мәчетләр саны төрлечә булган. Мәсәлән, Бәрәскәдә 4 мәхәллә, Күнгәрдә 2, кечкенә авылларда берәр мәхәллә яшәгән. Әтнәдә 4 мәхәллә, Күәмдә 3 мәхәллә булып, ул мәхәллә кешеләрен муллалар тәртипкә чакыра торган булганнар.

Мәхәллә муллары исә мәдрәсәләрдә белем алган. Безнең якларда шундый мәдрәсә Кышкар авылында иде. Мәшһүр мәдрәсәләрдә 14 әр ел белем җыеп, галим кеше булып чыкканнар. Шундый атаклы мәдрәсәләр Балтач районының Түнтәр авылында, Әгерҗе районының Иж-Бубый авылында икәне мәгълүм. Әлеге мәдрәсәләрне бетереп чыгучылар берничә тел белгәннәр. Миңа Кышкар мәдрәсәсендә укып чыккан Кысна авылы кешесе Хисмәтуллин Хәй дигән кеше белән очрашырга туры килде. Ул Казан югары уку йортларында студентларга лекцияләр укый, мәктәп укучылары өчен дәреслекләр яза. Без бала вакытта шуның дәреслекләре белән укыдык. Ул шул мәдрәсәдә укыганда күп телләр өйрәнгән. Камил рәвештә татар, гарәп, фарсы, төрек телләрендә сөйләшә ала. Русчаны үзлегеннән өйрәнгән, мәдрәсәдән 5 тел белеп чыккан. Кышкар мәдрәсәсен бетереп чыгучылар Коръәнне татарчага әйләндереп бирә алганнар. Авылларда укытканда балаларны гаделлеккә, инсафлылыкка, шәфкатьлелеккә, әхлаклы булырга өйрәткәннәр.

Революциядән соң бу мөгаллимнәрне эшләреннән алып, мәчетләрнең манараларын кисеп, муллаларны куып тараттылар. Авылларда эчүчелек күбәйде, олыларга хөрмәт белән карамау артты, кешеләр бер-берсенә дорфалык кыла башлады. Бу гамәлләргә динле кешеләр, гади халык бик рәнҗеде. Мәсәлән, безнең авыл мәчетенең манарасын Галиәкбәр Габдрахманы кисеп төшергән иде. Манара гөрселдәп килеп төшкәч, бу мәхшәрне карарга килгән кешеләрнең күзләреннән ихтыярсыз күз яшьләре атылып чыкты. Ә Габдрахман абый манара кискән акчасына аракы алып, эчеп, исереп өендә яткан — ястыгында косыгына тыгылып үлде. Авыл халкы аны Алла каргаган дип бәһаләде. Шушы күңелсез хәлләрне кичергән авыл халкын гыйлемлеккә өйрәтү өчен укытучылар кирәк булды. Шул чорларда татар халкының гадәтләнгән гарәп хәрефләре белән укуын латин хәрефләренә күчерү башланды. Шул ук чорда наданлыкны бетерү курслары эшләде. Мәктәпләрдә, курсларда латин хәрефләрен өйрәтәләр иде. Авылларда ирләр өчен аерым, хатын-кызлар өчен аерым курслар ачылды. Аларның уку урыннары куылган байлар йортларында булды. Кайбер авылларда манарасы киселгән мәчетләрне мәктәп

итеп ачтылар, клуб итеп файдаландылар. Бу чорда укытучылар күп кирәк булганлыктан, авылдагы укый-яза белүче яшьләрне аерым курсларда укыттылар. Мисал өчен безнең Түбән Шашы авылы кешеләреннән 8 егет Күлле Кимедә укып, киләчәктә укуларын дәвам итеп, чын укытучы җитәкчеләр булып киттеләр. Халык күп яши торган зуррак авыллардан Олы Әтнә, Олы Мәңгәр, Күлле Кимедә урта мәктәпләр ачылды. 1939-40 елларда урта мәктәптә укыган өчен акча түләү кертелде. Бу кайбер гаиләләрдә балаларны укыта алмау борчуы тудырды, кайбер бала укудан туктап калды. Мин үзем Әтнә урта мәктәбен ярты ел укыгач, 75 сум акча түли алмыйча, ташлап кайтырга мәҗбүр булдым. Иртәгә акча алып килмәсәгез, укуга килмәгез, дигәч, авылга күңелсезләнеп кайтырга туры килде. 1937-38 еллар фаҗигасе авылның укымышлы кешеләре — укытучыларга нык кагылды. Ул вакытта мәктәптә укучылар күп иде. Мәсәлән, бер елны Күнгәр мәктәбендә 5 нче класслар дүртәү иде. Чөнки укучылар Күшәр, Югары Шашы, Түбән Шашы, Кышлау авылларыннан килеп укыдылар. Шуңа күрә авыл мәктәпләре укытучыларга мохтаҗ иде. Шулай булуга карамастан, укытучыларның кайберләренә "халык дошманы" исеме тагып, аларны бер-бер артлы кулга ала тордылар. Әле дә хәтеремдә: иртән мәктәпкә укырга килгәч, безнең мәктәп укучыларын иртәнге очрашуга мәктәп коридорына тезеп куйдылар. Мәктәп директоры булып эшләгән Рафиков Мәгъсүм абый "халык дошманы" булган икән, балаларны партия кушканча укытмаган, бик явыз кеше булган, дип сөйләделәр. Без, укучылар, бу хәлгә бик гаҗәпләндек. Аның явызлыгына шикләнеп карадык, чөнки бу кеше балаларга карата ихтирамлы, ягымлы иде. Директор-җитәкче булганы өчен дә ярата, ихтирам итә идек без аны. Классларыбызга таралгач та малайлар белән шыпырт кына директорга яман сүзләр әйткән укытучыга ихтирамыбыз кимүе турында сөйләштек. Берничә көн үтү белән төнлә Кадыйров Сабир абыйны алып киткәннәр. Яңадан безне җыйнап, шул ук начар сүзләр белән ул укытучыны да яманладылар. Бераздан мәктәбебезнең завучы Касыймов абыйны да төнлә кулга алганнар... Калган укытучылар, кайчан безгә дә шул хәл килеп җитәр, дип, куркып яшәделәр. Авылдагы кешеләр бер-берләреннән куркып, сөйләшмичә, сөйләшкәндә дә ярамаган сүз чыкмагае дип, бер-береннән шикләнделәр. Бу чорда авылларда халык арасында тикшерү оешмалары билгеләгән яшерен шымчылар барлыгы беленде. Мәгълүматлырак кешеләр арасында чүпләрлекләре калмагач, гади кешеләргә дә кул суза башладылар. Мисал өчен Күнгәр авылында яшәүче Нәбиулла дигән кеше басудан авылга ат белән көлтә алып кайта. Әвендә салам селкүче хатын-кызлар Нәбиулла абыйдан: "Кәгъбә ишеге ачылды, күрдеңме?" — дип сораганнар. Ул "күрдем", — дигән. "Син нинди теләкләр теләдең?" — Ә ул, күп уйлап тормаган: "Колхоз таралса ярар иде, дип теләдем", — дигән. Нәбиулла абый шаян кеше. Уены-чыны белән болай әйтүенә иртәнгесен үкенгәндер дә инде, әмма соң була. Шул ук төнне бу кешене дә алып киткәннәр. Күрәсең, әвендә эшләүчеләр арасында шымчылар булган. Шул китүдән ул кеше авылга әйләнеп кайта алмады. Бу язманы укучылар арасында "Кәгъбә ишеге ачылу" дигәнне аңламаучылар булуы мөмкин. Мөселман халкының язмаларында кәгъбә ишеге ачылганда, ягъни һавада, ниндидер якты балкыш барлыкка килгәндә, нәрсә теләсәң, шул теләк үтәлә дигән гадәт бар. Безнең авыл кешеләре шундый балкыш вакытында теләк тели торган булганнар.

## Колхозлашуга юл тоту

Колхозлашуга кадәр җирне һәр хуҗалыкка җан башыннан бүлеп биргәннәр. Җир ир балалар хисабына гына бирелгән. Кыз балалы кешеләргә бик унайсыз булган. Безнең Түбән Шашы авылында дүрт кыз балалы Гатауллага, мәсәлән, тормыш итү бик авырга туры килгән. Кешеләр, бу гаделсезлеккә риза булмыйча үтенечләрен губерна җитәкчеләренә яза килгәннәр. Аларның таләбендә җирне, кешенең җенесенә карамыйча,

барлык кешеләргә тигез бирү каралган. Зур ризасызлыклардан соң гына жирне тигез бүлүгә ирешкәннәр. Жирләрне тәртипкә кертәбез, дип, авылларга жир үлчәүчеләр килгән. Хәзерге Әтнә районына кергән кайбер авыл кешеләре элек-электән Мари ягында урман чистартып, агач төпләп үзләре өчен жир мәйданнары әзерләгәннәр. Революциядән соң жирләрне шулай бүлеп, аерым хужалык булып, тыныч кына эшләп, көн итеп ятканда Россиянең кайбер якларында, берничә крестьян хужалыгы жирләрен берләштереп бергә эшли башлаганнар. Бу берләшеп эшләүне русча ТОЗ (товарищеское общество земли) дип атаганнар. Шулар үрнәгендә 1929-30 елларда колхозлар күренә башлый. Гомер буе, адәм баласы аңлы рәвештә яши башлаганнан бирле, жир байлыкларыннан һәм үзләре тапкан хәзинәләрдән үзләре файдаланып яшәргә өйрәнгән кешеләр, жирдән мәхрүм итүне бик авыр кичерде. Үзенең аты, иген кораллары белән жир эшкәртеп, гаиләсен изге иген эшенә юнәлткән игенче, өйрәнелгән гадәтләрен бозып, жирен дә атын да, орлыкларын да, иген коралларын да, амбарларын да колхозга бирергә тиеш булды. Игенче борчыла, төннәр буе йокламый чыга, бер-берсе янына килеп, моның киләчәге ничек булыр икән, дип сөйләшә иде. Халык арасында йөргән төрле уйдырма сүзләр крестьян халкын борчуга сала. Киләчәктә колхозга кергән кешеләр бер юрган астында йокласы икән, хатыннар да күмәк була икән, дигән шөбһәле сүз таратучылар күбәйгән. Безнең район биләмәләрендә колхозлар нигездә 30 нчы елда төзелә башлаган. Башта колхозлашу мәжбүр итү юлы белән барган. Әлбәттә, кешеләр арасында ризасызлык туган. Шушы хәлләрдән соң “Правда” гәзитендә Сталинның “Уңышлардан баш әйләнү” дигән мәкаләсе чыга. Мәкаләнең төп асылы — колхозлашу ирекле рәвештә булырга тиеш дигәнне аңлата. Төзелә башлаган колхозлар тарала, күмәк хужалыкта яшәргә теләүчеләрнең гаризалары нигезендә генә колхозлар төзелә. Мин биш яшьлек малай гына булсам да, бу вакыйгаларны ачык хәтерлим. Авылларда иң элек атларны жыеп алдылар. Аларны зуррак каралты-куралы кешеләрнең лапасларына урнаштырдылар. Иген кораллары, чәчүлек орлыклар башта крестьян хужалыкларында сакланды. Яз житеп, жәйгә чыгу белән иген игү эше күмәк рәвештә башланды. Беренче эш итеп, күмәк игелгән икмәкләрне саклау өчен, хужалык келәтләрен күчереп, берләштереп, аерым урында салдылар. Атлар, сыерлар өчен абзарлар сала башладылар. Ул тораклар әзер булгач, хужалыклардан бозаулар жыеп, шунда яптылар, фермалар оештырылды. Абзарларны төзү өчен безнең якларда беренче мәртәбә саман кирпече сугу башланды. Аның өчен авыл читендә чокыр казыла, ана кызыл балчык, салам, су салып, шуны аяклар белән дә, атлар белән дә таптап, измә хәзерлиләр дә, шул измәне формаларга салып, кирпеч хәленә китерәләр һәм кояшта киптерәләр.

Колхозлар белән идарә итү өчен житәкчеләр сайлана. Алар колхоз рәисләре дип аталдылар. Колхозларның оештыру эшләрен авыл халкы сайлап куйган авыл Советы житәкчеләре башкара. Ә колхоз житәкчеләрен колхозчыларның гомуми жыелышында сайлыйлар. Колхоз рәисе итеп авылның дәрәжәле, абруйлы, иген эшен яхшы белә торган алдынгы карашлы кешеләре сайлана. Ул чорларда житәкче булу бик жиңел булмый. Аерата тазарак тормышлы, хайваннары, жирләре күп булган кешеләрнең колхозга алыначак малларын кызганып, йортларына ут төртеп яндыру очраклары да булды. Хәтта житәкчеләрне үтерүгә хәтле барып життеләр. Мисал өчен, безнең районның Яңа Мәңгәр колхозы рәисен үтереп, бәдрәфкә ташлаганнар. Язучы Гариф Ахуновның Арча районында колхоз рәисе булып эшләүче әтисен дә кулаклар яллаган бандит үтерә.

Колхозларга төрле-төрле авыл хужалыгы машиналары кайта башлый. Авыл халкын гажәпләндергәне — беренче тракторлар, ашлык уру лабогрейкалары, үзе ташлап ура торган ургычлар, чәчү машиналары, ат көче белән хәрәкәткә китерелә торган сугу машиналары, орлыкларны чистарту машиналары да кайта башлады. Элек кул көче белән генә эшләнә торган чәчү, уру, суктыру, жилгәрү эшләрендә ат көче куллану мөмкинлеге табылды. Моңа кадәр ашлык суктыру аерата авыр эш санала иде. Әле дә хәтеремдә,

безнең авылга килеп, йорттан-йортка йөреп, кул көче белән әйләндереп ашлык суга торган молотилка машинасы белән бертуган Әтнә кешеләре ашлык суктырып йөрделәр. Ашлык суктыручы дүрт егетнең өлкәне Сафа атлы иде. Ул кеше соңрак авыл саен кино күрсәтеп йөрде. Шушы кешеләрне азаплаган техникаларны алыштырып, колхозларга ике атлы, дүрт атлы, аннан алты атлы сугу машиналары кайтты.

Колхозлашу уңышлы гына барса да, колхозга кермәгән гаиләләр 1940 елга кадәр аерым хуҗалык булып яшәүләрен дәвам иттеләр. Аларга начар гына басулардан чәчүлек җирләр бүлеп бирелде, төрле-төрле салымнар салып нык җәберләделәр. Кайберләрен, колхоз төзелешенә карата начар фикердә дип хөкемгә дә тарттылар. Мондый гаиләләрнең аерым әгъзалары, төп гаиләдән аерылып, колхозга керү очраклары да булган. Колхозлар төзелеп, тулы канлы хуҗалык булып яшәү өчен, идарә итү кануннарын табарга кирәк иде. Төрле колхозда төрлечә идарә итү, идарә итүне төрлечә аңлау нәтиҗәсендә районда, илдә нindидер гомуми, төгәл бер тәртип урнаштыру кирәк булды. Шул мәсьәләне хәл итү өчен бөтенсоюз колхозчылар съездын оештыру теләге туа. Бу съездга колхозлардан дәрәҗәле, алдынгы колхозчыларны делегат итеп сайлыйлар. Әлеге съездда безнең районнан да делегатлар катнашты. Съездда авыл хуҗалыгы артеленең үрнәк уставы кабул ителә. Анда колхоз тормышына кагылган күп кенә мәсьәләләр законлаштырыла. Бу устав нигезендә җирләр мәңгелеккә файдалану өчен колхозларга тапшырыла. Җирне колхозларга тапшыру актлар белән рәсмиләштерелә, ул актлар колхозчыларның гомуми җыелышында дәүләт исеменнән тантаналы рәвештә тапшырыла. Уставта, колхозлар белән идарә итүнең иң югары органы — колхозчыларның гомуми җыелышы, дип билгеләнә. Җыелышлар арасында хуҗалык белән идарә итү өчен аның идарәсе сайлана. Уставта гомуми җыелышның, идарәнең, аның рәисенең, ревизия комиссиясенең, баш хисапчының бурычлары һәм хокуклары ачыклана, колхозчыларның идарә белән элемтәләре нинди булырга тиешлеге әйтелә. Хәтта колхозчы хуҗалыкларында күпме җир, ничә мөгезле эре терлек, ничә сарык, ничә кош-корт, ничә баш умарта асрау да языла.

Устав кабул ителгән чорда аның таләпләренең төгәл үтәлүенә зур игътибар бирелде. Район оешмалары, хәтта хокук саклау органнары да уставның төгәл үтәлүен тикшереп тордылар. Соңга табарак, сугыш алды елларында, авыл хуҗалыгы артеле уставы таләпләренә игътибар кимеде. Төп сәбәбе — колхоз эшләренә тыкшыну хокукы бирә торган Мәскәү карарлары иде. Хәтта шуңа барып җиттеләр — ВКП(б) Үзәк Комитетының бер пленумында җирләрне фәкать 22 сантиметр тирәнлектә генә сукаларга дигән карар кабул ителде. Районнан колхозларга вәкилләр килеп, кесәләренә сантиметрлы линейкалар тыгып, сөрелгән җирләрнең тирәнлеген үлчәп йөри торган булдылар. Бу исә үз нәүбәтендә колхоз җитәкчеләренең үз җирләренә мөнәсәбәте йомшаруга китерде. Нинди генә үзгәрешләр, яңалыклар булмасын, колхозчыларга түләүне оештыру иң җаваплы, иң четерекле эш булып торды һәм тора. Көнлек нормалар колхозда башкарыла торган эшләрнең катлаулыгына, авырлыгына, яки ат көченең зурлыгына карап билгеләнде. Шул эшләрнең бер нормасын үтәгәндә күпме хезмәт көне язылырга тиешлеге ачыкланды. Мәсәлән, ике атлы сабан белән көнлек сөрү нормасы гектар ярым итеп билгеләнде. Шуны үтәүчегә бер ярым хезмәт көне языла. 1 кешенең бер көнлек печән чабу нормасы, печәнлек җиренә карап, утыз-кырык сотый билгеләнә иде. Кул белән урак уру унбиш-егерме сотый. Шуңа бер ярым хезмәт көне язылды. Кул тырмасы белән печән кабарту кырык сотый... Шундый ук тәртиптә терлекчелек һәм төзелеш эшләрендә дә нормалар билгеләнде. Бу нормаларга түләү гомуми җыелышта расланды. Нормалар бик киеренке. Мәсәлән, ике ат белән гектар ярым җирне сөрү өчен 33 чакрым үтәргә кирәк. Шушы башкарылган эшләргә тотылган (язылган) хезмәт көненә түләү аз, бик аз иде. Түләү колхозда җитештерелгән авыл хуҗалыгы азыкларын бүлүгә нигезләнә. Беренче чиратта, хезмәт көненә карап икмәк бүленә. Ләкин икмәк бирү күләме дәүләткә тапшыру планын үтәп бетергәннән һәм орлыкка, фуражга аерып куйганнан соң гына билгеләнә иде. Шулай ук

колхозда игелгән яшелчә һәм бәрәңге, салам, печәннәр дә шул тәртиптә бүленә. Бүленү күләмнәре колхозларның гомуми җыелышларында тикшерелгәннән соң гына гамәлгә ашырыла. Елына карап, икмәкне бер хезмәт көненә бер килодан ун килога кадәр биргән колхозлар бар иде. Районыбызда иң югары уңыш алган ел 1937 ел санала. Шул елның архивлары белән танышып утырганда иң югары уңыш Сонгыр колхозында булганлыгын белдем. Хезмәт хакын колхозлар җитештергән продукция күләменнән чыгып түләүне мин иң дөрес юл дип исәплим. Яхшы эшләгән икән, күп алсын, начаррак эшләүчеләр аз алсыннар, бу тәртип бүтәннәрне дә яхшы эшләргә мәҗбүр итәр. Хәзерге көндәге тигезләү методы — ялкауларны күбәйтүгә сәбәпче бит ул. Бу очракта үз колхозыбыздагы бер хәлне мисалга китерергә уйлыйм. Шулай, колхозчылар җыелышы барганда, тракторчы Сибәгатов Рәфкать сүз алды да: "Ничек инде мин сукалаган җирдән сигез сум гына алам? Ә бит бу җирдән безнең колхоз 28 центнер уңыш алды! Күрше колхозда таныш тракторчы да шул эшне башкарган өчен минем кадәр хезмәт хакы алды. Гәрчә алар бер гектардан нибары 17 центнер гына уңыш алсалар да. Бу гаделсезлекне ничек аңларга?" — диде.

Сәбәбе гади — колхозларның барысына да үрнәк нормалар бирелгән, уңышның күләме күрсәтелмәгән. Кешеләргә югары оешмалар тарафыннан билгеләнгән "хезмәтенә күрә түләү" кануннары бозылды. "Кем эшләми, шул ашамый" дигән канатлы сүзләр көчен югалта башлады. Шушындый гаделсезлекләр кешеләрдә битарафлык китереп чыгарды. Хезмәт хакы дәүләт хисабына барыбер түләнә дигән фикер кешеләрдә иген игү эшенә салкын караш тудырды, икмәкнең кадере кимеде.

Бу урында колхозлар төзелә башлаган чорда кешеләрнең икмәк кадерен белеп, аны саклау хакындагы фикерләренә тукталып узасым килә. Кул белән урак уручы хатын-кызлар уракка кермәгән башакларны авызларына җыептешләп барып, көлтәгә кыстырып куя торганнар иде. Чүмәләне көлтәләр җилләп торырлык итеп куюлары хәтеремдә. Кибән куясы урыннарны чистарталар, кибән куеп бетергәч, чәчелгән бөртекләрне себереп, капчыкка тутыралар һәм колхоз келәтенә тапшыралар иде. Көлтә ташыганда, өй паласларын алып килеп, арбаларына җәяләр, шуның өстенә көлтәләрне өя торганнар иде. Балалар үстергәндә дә ата-аналар икмәккә карата бик зур ихтирам тәрбияләделәр. Әнинең мин бала вакытта икмәкне кадерләү турында сөйләгән бер кыйссасы күңелдә калган. Элекке заманда бер хатын, мәчесе сәкегә менеп, икмәккә үрелгәч, кулында булган ипи кисәге белән мәчегә сугып, аны сәкедән куып төшерә. Соңыннан шул хатынның ипине мыскыл итеп мәчене куган кулы корый. Икмәк валчыкларын идәнгә чәчәргә — төшерергә ярамавын да әйтеп, кисәтеп тора иде әни. Гомумән, безнең татар авылларында икмәккә изге итеп карау яшәде. Соңгы вакытларда үсеп утырган уҗымнар өстеннән машина белән куян куу, өлгергән игеннәрне таптату, урылган учмалар өстеннән йөрү, шәһәр балаларының урамнарда, яшьләрнең тулай торакларда икмәк кисәкләрен теләсә кая ташлауларын, күргәч: "Кешеләр, нишләдек без?" — дип кычкырасы килә.

## МТСлар чоры

Колхозлашып, җир мәйданнары киңәйгәч, әлеге мәйданнарда эшләү өчен көчле, зур машиналар булдыру зарурлыгы туды. Ил буйлап колхозларга иген игүдә ярдәм итәргә дип, МТСлар төзелә башлады. Шул исәптән безнең Әтнә районында да (Әтнәнең үзендә) МТС формалашты.

МТС иң элек зуррак колхозлардан Олы Әтнә, Олы Мәңгәр, Күшәр, Кишет, Күәм, Бәрәзә, Бәрәскә шикелле авылларга хезмәт күрсәтте. Аларның төп машиналары — "СТЗ" маркалы көпчәкле тракторлардан гыйбарәт булып, тракторчыларга утырып йөрү урыны бик унайсыз иде. Кабинасыз булганлыктан, кояш нурлары, җил үтү аркасында тракторчылар чирлиләр иде. Ягулыгы — керосин. Атна саен подшипникларын ныгытырга кирәк. Аны тракторчылар

подшипник тарту дип атап йөрттеләр. Ул эшне башкару өчен тракторчы трактор астына кереп чалкан ятарга мәҗбүр. Күз күнгәрендә, кышкы салкыннарда аны башкару бик газаплы эш. Ул вакытта чыккан комбайннар "коммунар" исемле иде. Аларны шул СТЗ тракторлары тартып йөреп эшләтте. Комбайнның үз моторы сугу, орлык чистарту агрегатларын гына эшләтә алды. Сугылган салам комбайн артына тагып куелган сәке шикелле тактадагы мәйданчыкка төшерелә. Комбайнчының ярдәмчесе салам җыелган мәйданчыкны бау белән тартып саламны чүлмәкләндереп төшерә, комбайн артыннан басулар вак салам өемнәре белән тула иде. Берзаман, игеннәрне суктыру өчен МТСларга зур сугу машиналары кайта башлады. Безнең район колхозларына "МКА-1100" маркалы сугу машиналары хезмәт күрсәтте. Бу машиналар басу урталарына урнаштырыла, басудагы көлтәләрне атлар, таяклар ярдәмендә шул мәйданга ташып суктыралар.

МТСлар төзелеп, колхозларга хезмәт күрсәтелә башлагач, аларның эше өчен түләү мәсьәләсе дә килеп басты. Шулай итеп, колхозларга бирелгән басуларда ике төрле хуҗа барлыкка килде. Беренчесе — кооперативлар милкенә хуҗа булган колхозлар, икенчесе — дәүләт милкенә нигезләнгән МТСлар. Дәүләт бер вакытта да үз мәнфәгатьләрен икенче чиратка куймады. МТСлар хезмәте өчен натуралата түләү тәртибе кертелде. Игеннәр өлгергәч, дәүләт исеме белән МТСлар тарафыннан төзелгән комиссия колхозларга барып, бер гектардан чыгачак уңышны билгели. Югарыдан җибәрелгән таблица нигезендә дәүләткә күпме ашлык тапшырылырга тиешлеген саный. Санау гадәттә дөрес булмый. Чөнки үсеп утырганда билгеләнгән уңыш (биологик уңыш) фактта азрак чыга. Бер гектардан чыгачак уңышны билгеләгәндә, югарыдан килгән комиссия колхоз җитәкчеләренең фикерләренә игътибар итми. Аннан икенче ягы — игенне үстерү өчен МТСлар җир эшкәртү белән генә шөгыльләнделәр. Игеннәр үсү өчен әле ул гына җитми бит — аларны тәрбияләү, яхшы сортлы орлыкларны сатып алу, ашламалар кертү — бар да колхоз көче белән башкарыла лабаса! Шулай итеп, зур тырышлык белән иген үстергән колхозлар дәүләткә икмәкне колхоз көче бәрабәренә күп тапшыра торган булып чыга иде.

## Сәүдә хезмәте

Революциягә кадәр, районнар төзелеп колхозлашканчы, кешеләрне кирәк-ярак белән сәүдәгәрләр һәм байлар кибете тәэмин итеп торган. Сәүдәгәрләр авыл кешеләреннән артык игеннәрне, терлекчелек продуктларын сатып алып яки җыйнап, башка җирләргә илтеп сатканнар. Шуның белән беррәттән, дәүләт исеме белән, казнага дип, икмәк сатып ала торган булганнар. Авыл саен зур келәтләр булган, аларны дәүләт келәтләре дип атаганнар. Ашлыкны шунда җыеп, чит илләргә дә озатканнар. Шуның бер мисалы — Идел, Чулман, Агыйдел буенда урнашкан авыллардан җыйналган икмәкне купец Астахиев Албания, Франциягә озатып торган. Чаллыда, Чистайда әле соңгы елларга кадәр Астахиев фамилиясе язылган йортлар саклана иде.

Кайбер байлар кызыл мал дип аталган ситсы, кәшимер, постау, сатин, йон кебек тукымалар белән сату иткәннәр. Керосин, буяу, тимердән ясалган савыт-саба, фарфор савыт-саба, агачтан, пыяладан ясалган савыт-саба белән дә сату иткәннәр. Зуррак эш йөртүче байлар Урал, Чиләбе, Оренбург, Казахстан шикелле урыннарга барып, моннан алып киткән товарларны сатып, аннан башка төр товарлар төяп кайтканнар. Әтнә авылыннан Гатаулла бай хакында соңгы елларга кадәр хөрмәт белән сөйлиләр. Үзенең әллә ни зур гыйлеме дә булмаган, ләкин башы бик яхшы эшләгән. Ул сәүдә итеп чит җирләрдән кайтканда, мал төягән атлар теземенең бер башы Әтнәдә, икенче башы Әтнәдән ике чакрымдагы Шәкәнәч авылында булган. Ана шулкадәр байлыгын, затлы йортларын калдырып, авылдан чыгып чит җирләргә китүе бер дә җинел булмагандыр.

Революциядән соң авыл кешеләренә хезмәт итеп килгән байлар кибете ябыла. Халык кирәк- яракны алу өчен интегә башлый. Тәэмин итү оешмасы кирәклеге көн тәртибенә килеп баса. Шушы чорда районнарда райпотребсоюз дип аталган сәүдә оешмалары барлыкка килә. Аларны оештыру түбәннән башлана. Ин элек кооператив кибетләре барлыкка килә. Ул оешмага керү өчен кешеләр пай акчасы түләргә тиеш булалар. Шушы пай членнары җыелып, авыл сәүдәсе — сельпо төзү өчен вәкилләр сайлыйлар. Шул вәкилләр җыелышында сәүдә оешмасының рәисен, хисапчысын сайлап куялар.

Ул елларда райсоюзлар каршында җир белән эшләүче оешмалар да оештырылды. Аларны коопхозлар дип атадылар. Алар игенчелек белән беррәттән хайван асраучылык белән дә шөгыльләнделәр. Шундыйларның берсе Күшәр авылы җирендә, хәзерге РТС каршындагы урында оештырылган. Аның үзенең җитәкчесе булган, анда яшелчә үстергәннәр, дуңгыз асраганнар. Ләкин алар озак яши алмаган — бөлгәннәр. Чөнки иген игү һәм хайван асрау сату-алу эше генә түгел, ул күп шартларга бәйле, аны белеп эшләргә кирәк.

## Кешеләргә башка төр хезмәтләр күрсәтү

Район төзелгәннән соң хезмәт күрсәтүнең башка төрләре буенча да яңалыклар кертелде. Мәсәлән, кием тегү. Элек киемне аерым кешеләр үз йортларында тегә, яки кием тегү осталары өйдән-өйгә йөреп туннар, бишмәтләр әмәлли иделәр. Ул осталар Арча ягыннан булып, Әзәк дигән авылдан киләләр, кечкенә арбаларга, чаналарга тегү машиналарын салып йөриләр иде. Безнең Түбән Шашыда да Миңлебай атлы кеше, Күшәр авылында Абдуллаҗан атлы кеше йөрде. Абдуллаҗан Күшәрдә торып ук калды.

Киез итек басу, йон тетү, самовар, савыт-саба ямау осталары да бар иде.

Әтнәдә район төзелгәннән соң халыкка хезмәт күрсәтү буенча төрле артельләр эшли башлады. Беренче булып хәзерге авыл Советы урнашкан урында кием тегү эше белән шөгыльләнүче "Крупская" исемендәге артель төзелде. Ул артельгә күрше авылларда тегүчелек белән шөгыльләнгән осталар килеп урнашты. Әле дә хәтеремдә, Васыйл атлы кеше район буенча оста тегүче булып танылды. Ул артельдә җылы туннар, драп пальтолар, кәзәки-чалбарлар, күлмәкләр, баш киемнәре тектеләр. Шулай ук Әтнәдә хәзерге мәчет урынында "Дулкын" артеле төзелде. Ул агач эшкәртү, чыпта сугу, капчык тегү, оекбаш, бияләй бәйләү белән шөгыльләнде. Шәһәрдән заказ алып та эшләделәр, артель кыш айларында, иген эше беткәннән соң, авылдагы кешеләргә шушы эшләрне өйләренә биреп тә эшләтә иде. Әтнәдә тагын "Чаткы" артеле булып, ул инвалидлар артеле дип аталды. Монда тегү һәм бәйләү эшләре хутка китте.

Районда шулай ук ризык әзерләүче комбинат оештырылды. Ул хәзерге мәктәп-интернат урынындагы йортта иде. Комбинат җиләк-җимештән вареньелар кайнатты, прәннек-печенье пешерде, аларны район кибетләрендә сатуны оештырды.

Революциягә кадәр безнең район авылларында культура хезмәте өчен махсус биналар булмаган. Муллалар, мөгаллимнәрнең үз йортларында гына шәхси китапханәләре булган. Телефон, радио кебек нәрсәләр бөтенләй юк. Революциядән соң, аерым кешеләр, үзләре радиоалгычлар сатып алып, шуны тыңлый башлагач, авыл халкы моңа бик гаҗәпләнә. Безнең авыл халкы радио тавышын беренче мәртәбә Югары Шашы авылында мөгаллим булып эшләүче Кәрим йортында ишеткән.

Революциядән соң халыкны агарту эше белән укытучылар шөгыльләнде. Алар тырышлыгы белән авылларда үзешчән сәнгать түгәрәкләре оешты, спектакльләр, концертлар кую башланды. Аларга авыл кешеләре дә бик теләп кушылды. Ул спектакльләр авылдан сөрелгән байлар, муллалар йортында куела иде. Аларны авыл халкы бик яратып карады. Шундыйларның берсе, ихтирамга лаеклы булганы, Әтнәдә оешкан үзешчән-сәнгать түгәрәге.

Коллектив соңгы елларга кадәр яшәп, эшен дәвам иттерде. Үзешчән театрны Баязитов Котдус абый, Галимә апай, Хәбибуллина Разия, Баязитова Әминә һ. б. шундый сәнгать сөючеләр оештырып җибәрде. Соңга таба коллектив Әтнә Халык театры дәрәҗәсенә күтәрелде. Районыбызның даньш республика сәхнәләрендә, хәтта Мәскәүгә барып та яклауга ирештеләр. Әтнә районы яшәүдән туктаган вакытта да, сәнгатькә җаны-тәне белән бирелгән кешеләр аркасында, Әтнә Халык театры сакланып калды. Коллективны таратмауда аның җитәкчесе Мәрдәнов Гомәрнең хезмәте зур булды. Алар авылларга төрле һава шартларында — атлар белән дә, җәяүләп тә бардылар, спектакльләр, концертлар куйдылар, очрашулар оештырдылар. Озак еллар колхоз рәисе булып эшләгәнлектән, миңа колхозның төрле эш кампанияләре вакытында бу коллективка мөрәҗәгать итәргә туры килә иде. Алардан беркайчан тискәре җавап алмадым. Нинди вакыт булуга карамастан клубларда, больнинарда, кырларда, фермаларда, хәтта бәрәңге базлары янында да концертлар куйдылар, кешеләргә җан җылысы өләшеп йөрделәр.

Революциядән соң авылларда кешеләрнең укый-яза белүләре арткан саен китапханәләр ачу ихтыяҗы туа. Әлеге дә баягы авылдан куылган байлар йортларында ачтылар китапханәләрне. Ул чорда латин хәрефләре белән язылган китаплар кайта башлады. Авылда радио булмаганлыктан, гәзит-журналлар килмәгәнлектән, кешеләр китапны күп укыйлар иде.

## Районда җитәкчелекне оештыру

Халыкка хезмәт күрсәтү һәм күмәк хуҗалык булып яши башлау җитәкчелек өчен бер үзәк таләп итә. Әлеге язмаларда ул үзәк турында бераз төшенчә бирелсә дә, аның оешу тәртипләрен ачыклап китәргә уйлыйм. Бу эшләрнең башында, әлбәттә, коммунистлар һәм комсомоллар тора. Район оешканга кадәр үк кантоннар каршында кантон коммунистлар оешмасы — кантком барлыкка килә. Алар бер төбәктәге авылларның коммунистлары һәм комсомоллары белән җитәкчелек итә башлыйлар.

Аннары райкомнар төзелә. Аларның оешу нигезе түбәндәгечә: авыллардан вәкил булып килгән делегатлар конференция үткәрәләр, анда пленум әгъзалары сайлана, пленум исә райком секретарьларын сайлый. Шул ук пленумда райкомның бүлекләре һәм аларның җитәкчеләре дә билгеләнә.

Партия сәясәтен авылларда үткәрү өчен комсомол оешмалары төзелде. Әлеге яшь көчләр колхозлар төзелү чорында, бигрәк тә партия оешмалары булмаган авылларда, бик зур активлык күрсәттеләр. Авылның хәллерәк кешеләрен ачыклап, "кулак" исеме тагып, аларны авылдан сөрү кебек эшләр дә алар намусында. Авыллардагы кешеләрне байлар, урта хәлләләр, ярлыларга бүлүне дә комсомоллар башлады.

Юкка мени авылларда сугышка кадәр:

"Комсомоллар эштән кайта,
Иңбашында көрәге,
Алтмыш буржуйны куркыта
Бер комсомол йөрәге",

— дип җырлап йөриләр иде. Колхозга керүчеләрнең милекләрен барлап, колхозга бирелергә тиешләрен, үзләрендә кала торганнарын ачыкладылар. Ул вакытта колхозларның озак яшәвенә ышанып бетмәүчеләр байтак иде. Янадан аерым хуҗалык булып яшәүне өмет итүчеләр дә булды. Берләшергә тиешле мал-мөлкәтен, ат дирбияләрен яшереп куючылар да табылды. Шул вакытта комсомолларны шымчылар итеп файдаландылар. Шулай ук алар көче белән авылларда концертлар, спектакльләр куелды. Төрле өмәләр, спорт уеннары, ярышлар үткәрделәр.

Сонрак, зур төзелешләр башлану белән, районыбыз комсомоллары шунда китәләр. Шул исәптән, ерак көнчыгышта Амур елгасы буенда шәһәр төзелешендә катнашалар. Ул шәһәрне "Комсомольск на Амуре" дип атыйлар.

## 1930-40 елларда Әтнә районы

Беренче оешкан вакытыннан ук Әтнә районы республика күләмендә алдынгы районнарның берсе булды. Кем белә, бәлки моңа колхозлашуның безнең районда чагыштырмача тыныч узуы да сәбәпче булгандыр. Республиканың кайбер районнарында колхозлашу чоры зур тавышлар белән, ыгы-зыгы белән үтте бит. Күп вакыйгаларны эченә алган колхозлашу чорын үткәргәннән соң, халык колхоз тормышына ияләнә башлады. Гомумән, авылларда социализм идеяләрен халыклаштыру, ягъни искене җимереп яңача яшәүгә күчү каты законнар чыгарып, халыкны куркытып яшәү белән атаклы иде. Шул чорларда вак урлаучылыкка карата 7 август карары дигән дәһшәтле бер карар кабул ителде. Аз гына әйбер урлаган өчен дә бишәр-унар елга төрмәгә утыртулар башланды.

Колхозлашудан индустрияләштерүгә күчтеләр. Ул елларда республикабыз шәһәрләрендә халыкның 30 проценты гына яши иде. Шәһәрдәге төзелешләрдә — юллар салу булсын, биналарны җылыту өчен утын, торф әзерләү булсын — авыл халкы күп файдаланылды. Мисал өчен әйтим, сугыш алды елларында республикада Әгерҗедән Бөгелмәгә кадәр тимер юл салу планы төзелеп, ул эшкә авылдан күп кеше тартылды. Колхозларга әлеге төзелешкә ничә ат, ничә кеше җибәрү планы житкерелде, аны үтәү мәҗбүри иде. Безнең Түбән Шашыдан гына да ("Чулпан" колхозы) 8 атлы, 18 җәяүле кеше җибәрелде. Аларга анда балчык ташу өчен махсус арбалар ясатылды, ул бер күчәрле, әрҗәсыман итеп ясалган савыттан гыйбарәт. Арбага ныгытылган әрҗәне элмәгеннән ычкындыру белән андагы балчык тиз генә агып төшә торган итеп җайланган. Ул арбаны безнең якта гөлдер арбасы дип атап йөрттеләр. Анда баручылар белән житәкчелек итү өчен бер бригадир, бер пешекче билгеләнде. Төзелеш мәйданы белән колхоз арасында ризыклар ташып йөрү өчен бер атлы кеше дә җибәрелде. Яшәр өчен брезент палаткалар әзерләнде. Анда кешеләрне тантаналы рәвештә озаттык. Авылның урта бер мәйданында гөлдер арбаларына җиккән атлар белән чибәр-чибәр егетләрнең арбаларда тезелешеп торулары әле дә хәтеремдә. Авылның иң яхшы атлары, эшчән егетләре, кызлары шунда тупланган иде. Җәяүле эшләрдә эшләргә тиешле балчык төяүче кызлар көрәкләр белән коралландылар. Колхоз рәисе Сәлим абый үзенә күрә озату сүзләре әйтеп, нотык сөйләде, кузгалырга рөхсәт бирде. Алар урамнан тезелешеп чыгып киттеләр. Әти-әниләре, туган-тумачалары, яхшы теләкләр теләп озатып калды.

Ул елларда илне индустрияләштерү авыл халкы хисабына башкарылды. Завод-фабрикалар төзелә башлады, әмма авыл хуҗалыгында эшче куллар шактый кимеде.

## Бөек Ватан сугышы чорында Әтнә районы

Җәйнең матур бер көнендә мин үзебезнең гаилә йомышлары белән Әтнә базарына барган идем. Сугыш башланганын шунда ишеттем. Әкрен генә базарга якынаеп килгәндә Әтнә авылының райбашкарма ягыннан кызу-кызу атлап бер кеше килүен күрдем. Ул бераз каушаган, агарган, туктап тын алганнан соң базар алдына җыелган кешеләргә: "Җәмәгать, герман безгә сугыш башлаган бит!" — дип кычкырып җибәрде. Шул тавышны ишетүгә сату-алу эше белән мәш килгән кешеләр, шөгыльләрен ташлап, бу кешегә төбәлделәр. Шуннан соң базар халкы әйберләрен күтәреп, авылларына тарала башлады. Берничә минут элек кенә гөжләп торган базар мәйданы бушап калды. Мин дә, йомышымны үти алмыйча, авылга кайтып киттем. Ул елларда базарга бару-кайту җәяү була иде. Җиңел машиналар бөтенләй юк, атлар иген эшеннән бушамый. Безнең авыл кешеләре Әтнә урамын чыккач, бер-берләре белән сөйләшмичә бераз тын гына кайттылар. Үз авылыбызга таба борылып, болын сукмагына кергәч, Сабир абый сүз башлады: "Ярар

инде, егетләр, бер дә сөйләшмичә кайтып булмас, без кайтышка кайберләребезне сугышка чакырып хәбәрләр дә килгәндер...” — диде ул.

Чыннан да шулай булып чыкты. Авылыбызның бер төркем кешесенә сугыш башлануның өченче көнендә үк чакырулар килә башлады. Шулар арасында Сабир абыйга да бар иде.

Районыбызның тыныч тормышы өзелде. Һәр гаиләгә: бүген берсенә, иртәгә икенчесенә хәбәрләр — чакырулар килеп торды. Әле аерым хуҗалык булып яшәүдән күмәк хуҗалыкка чын-чынлап күнегеп тә җитмәгән халык өстенә яңа бер гарасат ябырылды — Бөек Ватан сугышы башланды. Һәр кемне үзенең киләчәге, балаларының, туганнарының язмышы борчыды. Һәркем сугыш турында гына уйлады.

Кайберәүләр: “Сугыш тиз бетәр, безнең ил бик көчле, бездә танклар да, самолетлар да бик күп”, — дип сөйләделәр. Бер абый исә: “Белмим шул... Ай-һай, тиз генә бетәр микән? — дип, фин сугышын исенә төшерде. — Өч миллион халкы булган Финляндия сугыш вакытында безнең илнең күпме кешесен кырды, сугышы да шактый озакка сузылды”. Шул сүзләрдән соң Халхин-гол һәм Хәсән күле буендагы сугышлар искә төшә иде. Гражданнар сугышы да искә алынмый калмады. Үзбәкстандагы басмачылар белән булган сугышның да 1918 елдан 1924 елга кадәр сузылганын әйтеп үттеләр.

Гатаулла бай йортына урнашкан хәрби комиссариантның эш тәртибе үзгәрде. Аңа атлар, яңа кешеләр тупланды. Әле дә хәтеремдә, Әтнә мәктәбе директоры Садыйков Сабир, хәрби комиссариатка булышлык йөзеннән, сугышка китүчеләрне аерым командаларга бүлеп, исемлекләрен төзеп, кешеләрне озату белән шөгыльләнеп йөрде. Командаларны туплаган чакта хәрбиләрне алмаштырып куйдылармыни! Элек авыл Советы, колхоз җитәкчеләре белән ягымлы гына сөйләшәләр иде, сугыш башлану белән бу кешеләр җитдиләнү генә түгел, кырысланып ук киттеләр. Хәрби комиссариат бер көнгә өчәр-дүртәр команда туплап, Казанга, Арчага, Коркачыкка җибәреп торды. Медицина тикшерүе бик ашыгыч үткәрелә, бер көнгә бик күп кеше озатырга туры килгәнлектән, аларны табиблар тикшереп өлгерә алмыйлар иде. Ул елларда табиблар хастаханәләрдә яткан авыруларны дәвалау белән бергә, хәрби комиссариат таләпләрен дә үтәп бардылар. Сугыш башланган елны авылда солдатка китүчеләр күп булу сәбәпле, хәрби комиссариат югарыдан бирелгән планны вакытында төгәл үтәп бара алды. Соңга табарак, авылларда ир-ат кимегәч, бу эш катлауланды. Ул чорда мин колхозда комсомол оешмасы секретаре булып эшли идем. Авыл Советы кушуы буенча үзебезнең авыл кешеләрен Әтнәгә хәрби комиссариатка озатып йөрдем. Кешеләрнең сагышлы-хәсрәтле йөзләрен күрү күңелгә авыр тәэсир итте. Китүчеләр үзләрен озата килүче әти-әниләре, туганнары белән төркем-төркем булып сөйләшеп торалар. Яшьрәк парлар, Әтнә урамының аулаграк урыннарына китеп, сабуллашалар, бер-берләрен кочаклап, сулкылдап елашалар иде. Андагы сагыш, китүче олаулар артыннан аерыла алмыйча елашып, Әтнәне чыкканчы чабышып барулар... Ул аерылышу хәлен язып, әйтеп кенә аңлату мөмкин түгел. Аның авырлыгын күреп кенә аңлап була. Андагы хәлләрне күрү күңелемә шулкадәр сенеп калган: соңыннан авылыбызда колхоз рәисе булып эшләгәндә дә авыл халкына каты бәрелә алмадым, сүзем белән һәркайсының күңелен рәнҗетүдән курыктым. Сугышта газиз ирләрен яки улларын югалткан хатын-кызларга, аналарга, ятим үскән балаларга кулымнан килгәнчә ярдәм итәргә тырыштым.

Безнең Әтнә районыннан киткән күп кенә солдатлар мари ягындагы үзебезнең Суслонгер, Сурук, Шелангер хәрби лагерьларында газап чиктеләр. Яманаты чыккан Суслонгер лагере күп кешеләрне ачтан интектерде. Анда булучылар өйләренә шундагы начарлыкны әйтеп хат язганнан соң, хатыннары капчык белән сохари һәм башка төрле ризыклар күтәреп, 100 чакрым араны җәяүләп узарга мәҗбүр булдылар. Бу хәлләрне миңа үзебезнең авыл кешесе Харис абый да сөйләгән иде. Аның белән очрашу көтелмәгәндә булды. 1941 елның көзендә, колхоз рәисе әмерен тыңлап Буа ягына окоп казучыларны озатырга туры килде. Тәтешкә барырга дип пароход көткәндә, икенче пароходка утыртырга бер төркем солдат алып килделәр. Алар арасында безнең авылның

Харис абыйны күреп алдым. "Харис абый!" — дип кычкырып җибәрүем булды, ул минем янга йөгереп килде. Аларны пароход белән каядыр озатырга дип Суслонгер лагерыннан алып килгәннәр икән. Ул үзе дә кая барасыларын белми, әйтмәгәннәр. Гомумән, сугыш вакытында күпчелек хәлне сер итеп саклау гадәткә кергән иде. Шунда Харис абый Суслонгер лагерындагы хәлләрне бәйнә-бәйнә сөйләп аңлатты. Җәй көне июль аенда ук аларны урман эченә илтеп ташлаганнар. Элек агач кистергәннәр, иңбашларына күтәреп ташытканнар, взвод өчен землянкалар казытканнар. "Нарат бүрәнәләрне күтәреп бару авыр булды, кайберәүләребезнең иңбашлары җәрәхәтләнеп бетте, күбебезнең билләре авырта башлады, җәфаландык, — диде. Лагерьдагы ашауның начарлыгыннан зарланды. — Гадәттә гел кәбестә шулпасы, икмәкне бик аз бирделәр, кешеләр бик ачыкты, ябыктылар", —диде. Харис абыйга карап кешеләрнең ябыгуына ышанырга була иде. Бәләкәй генә буйлы кеше иде, тагын да кечерәеп калган. Ул үзе җор, шаян кеше. Минем белән сөйләшкәндә күңелендә шатлык, җорлык юк иде инде. Аларны Сталинград ягына сугышка җибәрүләре булган икән. Шул китүдән Харис абый кайтмады, озак та үтми үлгән дигән хәбәре дә килде.

Соңыннан, Суслонгер лагерында солдатларның азапланулары хакында югарыдагы җитәкчеләргә дә барып ирешә. Мари лагерьларын тикшерү өчен зур бер комиссия җибәрелә. Анда дошманлык эше белән шөгыльләнүчеләр булган, командирларын хөкем иткәннәр икән дип ишеттек. Соңыннан солдатлар китеп беткәч, ул лагерьларга туган җирләреннән сөрелгән Кырым татарларын китереп тутыралар. Көньяк халыклары да анда зур авырлык кичерә.

Ир-атны сугышка алу белән беррәттән атларны да алу башланды. Һәр колхозга комиссия җибәрелде. Комиссия иң яхшы атларны тамгалап чыкты. Колхоз атларының паспортлары да була торган иде. Анда атның исеме, төсе, буе, биеклек үлчәүләре, яше языла, һәр төрле дәвалау вакытлары күрсәтелеп, тамга салына. Паспортларга комиссия "Хәрби хезмәткә яраклы" дигән нәтиҗәне дә язып куйды. Атларны җыйнап, аларга дирбияләр, арбалар, хәтта кучәр майлау өчен май савытларына кадәр бирделәр. Атлар белән бергә май савытлары да армиягә китте. Ат көче белән артиллерия коралларын, ризыклар ташыдылар. Махсус атлы гаскәрләр өчен дә атларны бездән алдылар. Авыл кешесенең күрәчәге моның белән генә бетмәде. Сугышка яраксызлар (авыру атлар һәм хатын-кызлар) окоп казу эшенә җибәрелә башлады. Һәр колхозга аерым план җиткерелде. Анда күпме кеше һәм ат катнашырга тиешлеге генә күрсәтелмичә, ничә километр окоп казырга кирәклеге дә әйтелә иде. Окопларны казу урыны итеп безнең район өчен Буа районы биләмәләре билгеләнде. Бу эш кышын башланып, язга кадәр дәвам итте. Монда, нигездә, авыллардан тупланган кызлар бригадасы эшләде. Аларга тимер лом, бәлҗә, кирәкләрне колхозлар әзерләп җибәрә иде. Туң балчыкны казу бик авыр булды. Ул елны ноябрь аеннан башлап декабрь, гыйнвар, февраль айларында 50 шәр градус салкыннар торды. Менә шунда фаҗигаләр башланды инде. Оек-чабата, телогрейка гына киеп эшләүче кызларның кайсыларының аяк-куллары өшеп, хастаханәләрдә дәваланып, кире кайта башладылар. Салкын тидереп үлүчеләр дә булды. Кыш урталарында авылларга мәетләр кайтты.

Сугыш афәте урып-җыюның сузылуына сәбәпче булды. Сугу эшләрен кыш буе алып барырга туры килде. Игеннәрнең күп өлеше чәчелеп, югалуга дучар ителде. Сугып алган ашлык кышкы салкыннарда сакланса да, язын көннәр җылыта башлагач, кар белән буталганлыктан, орлыклар юешләнеп бозыла башладылар. Ашлыкны киптерү бик авыр эшкә әйләнде. Аны хуҗалыкларга тараттылар. Ягулыклары булмаганлыктан орлыкны идәннәргә, мич башларына, сәкеләргә, өстәлләргә таратып киптереп карадылар. Ләкин кояшта киптерә алу мөмкинлеге булганчы күпчелек орлык череп яраксызга чыкты. Колхоз келәтләренә ярым-яртысы гына әйләнеп кайтты.

1941 елның көзе авыл кешеләрен бер дә уйланылмаган вакыйга белән очраштырды. Көзгә таба авылларга сугыш ягы шәһәрләреннән эвакуация

белән бик күп кеше кайтып төште. Алар күтәрә алган киемнәрен күтәреп, тимер юл буенча Казан, Арча станцаларына килделәр. Колхоз житәкчеләре аларны атларга утыртып үз колхозларына алып кайтты. "Кунаклар" белән житәкчелек итү өчен районда штаб оештырылды. Райбашкарма рәисенең урынбасары дәрәжәсендә бер кешене штаб начальнигы итеп куйдылар. Алар авылларга таралган бу кешеләрнең көнкүреш хәлләрен тикшереп тордылар. Аларны икмәк карточкалары белән тәэмин иттеләр. Икмәк һәм башка азыкларны район үзәгеннән алып кайталар иде. Баштарак аралашу читен булды — алар татарча, безнең авыл хатын-кызлары һәм балалар урысча белмиләр. Бу аралашу читенлеге тора-бара кимеде, килүчеләр үзләре дә бик кирәкле сүзләрне өйрәнә-белә башладылар. Безгә күчеп килүчеләрнең күпчелеге Мәскәү шәһәреннән иде. Бер группа кешеләр Латвиядан латыш балалары белән килде. Алары Олы Мәңгәр авылына урнашты, мәктәп бинасында интернат-мәктәп оештырдылар. Бу балалар үсеп житкәннән соң да Олы Мәңгәр авылы кешеләре белән элемтәләрен өзмәде, хатлар языштылар, соңгы елларда Мәңгәргә кайтып, үзләре белгән истәлекле җирләрне карап, Мәңгәр зиратына күмелгән туганнарының каберләрен күреп киттеләр. Күчеп килүчеләрнең кайберләре туган җирләренә кайту мөмкинлеге тугач та, безнең республикада торып калды. Безнең Түбән Шашы авылында Мәскәүдән кайтып торган Дондуков фамилияле кеше Казанга китеп төпләнде. Аның балалары безнең авылны туган авыллары дип йөрделәр.

Сугыш дәвам итте, ятимнәр саны артты. Сугыштан үлү хәбәрләре килгән ирләрнең хатыннары тормыш авырлыгыннан үлеп китеп, балалары ятим калу очраклары да булды. Ул балаларны саклап калу өчен районыбызда ике урында балалар йорты ачылды. Берсе Олы Мәнгәр авылында, икенчесе Күлле Кимедә. Анда безнең район балаларын гына түгел, башка районныкыларын да китерделәр.

Сугыш чорында авыл халкы өстенә яңадан бер зур авырлык төште — сугыш булган урыннардан Татарстан җиренә күп кенә заводлар күчеп килде. Ул заводларны эшләтеп җибәрү өчен биналар төзү кирәк иде. Шәһәрдә эшче көчләре җитмәде. Авыллардан үсмер кызлар һәм малайларны ФЗӨларда укытып, шул заводларда эшләргә әзерләделәр. Колхоз рәисләренә аларны җыеп озату йөкләтелде. Шуның өстенә заводларны төзү өчен атлы эшчеләр җибәрү планы да җиткерелә иде.

Авылга план өстенә план килеп кенә торды. Безнең район колхозларына Казан шәһәре өчен Мари урманнарыннан утын әзерләү планы да бирелде. Бу урманда агач кисүчеләрнең эш шартлары авыр булды. Анда барып эшләү мәҗбүри иде. Урманнарда авырып үлүчеләр дә булды. Безнең Түбән Шашы авылыннан Сабир абый Мөхәммәтҗанов та Мари урманында агач кисеп кайтканда иптәшләреннән артта калган, кайтасы җире ерак, арыган, ял итеп алырга уйлаган. Үзе генә калгач адашкан һәм туңып үлгән. Эзләп тапканда тәнен бүреләр җәрәхәтләп бетергән була инде аның. Ул солдат яшеннән чыккан олы кеше иде. Авылга алып кайтып күмү халыкта коточкыч кызгану тойгылары уятты.

... Сугышның беренче кышы бик салкын булды. Сугышта катнашучыларның туңып, суык тиеп, өшеп җәфаланулары хакында матбугатта яза башладылар. Шул уңайдан район күләмендә сугышчыларга җылы киемнәр җыю кампаниясе башланды. Район халкы зур оешканлык күрсәтте. Комсомолның район комитеты бу эшкә аеруча игътибар итте. Авылларда эшләүче житәкчеләр, комсомоллар, йорттан йортка кереп, солдатларга җылы киемнәр: йоннан бәйләгән оекбаш, бияләй, киез итекләр, сырмалар, хәтта иләмәгән тиреләр, авыл кызлары чиккән кулъяулыклар, матур итеп тегелгән тәмәке янчыклары җыйдылар. Җыйналган әйберне район штабына илтеп, шунда аларны вак ящикларга тутырдылар, кызлар исеменнән хатлар язып җибәрделәр. Әле дә хәтеремдә, Әтнә колхозының мастерское каршындагы бер келәттә шул әйберләрне без, авыллардан килгән комсомол секретарьлары, посылкалар итеп әзерләдек. Бу изге эш берничә мәртәбә кабатланды. Шундый ук юл белән районыбыз авыллары кешеләреннән танк колонналары төзү өчен акча

жыйдык. Самолет эскадриясе төзү өчен дә акча жыйнау булды. Бу эшне комсомоллар, авыл активистлары, колхоз, авыл Советы житәкчеләре башкарды.

Районыбыз авыллары, сугыш авырлыгын жиңеләйтү өчен, бер нәрсә белән дә исәпләшмәде. "Барысы да фронт өчен!" дигән чакыруга кушылып эшләде. Авылдан кешеләрнең завод-фабрикаларга эшкә китүе сәбәпле, колхозда эшләр йомшарды. Колхоз житәкчеләре солдатка алыну аркасында хужалыклар житәкчесез калды. Колхоз рәисләре булып сугышка яраксыз картлар, хатын-кызлар, гомумән очраклы кешеләр сайлана башлады. Жирләр елдан-елга сөрелми, чәчелми калды. Иген игелмәгән жирләрдә әрем, алабуталар урман кебек булып үсеп китте. Икенче, өченче елларда агачлар үсә башлады. Аерата каен агачы куе булып үсте. Буй урманнардан басуларга агач орлыклары тарала иде. Бу жирләрдә әрләннәр, тычканнар, ерткыч жанварлар күбәйде. Бүреләр, төлкеләр, куяннар ишәйде. Сунарчылык булмау аркасында аларга үрчү мөмкинлеге туды. Бүреләр авылларга килеп, салам түбәле лапасларның түбәләрен тишеп, сарыкларга һөжүм иттеләр. Төлкеләр көпә-көндез каз, үрдәк, тавык-чебешләргә ташландылар. Иген игә торган басуларның мәйданы кимегәч, ашлык житештерү дә кимеде. Жыеп алынган икмәкнең күпчелеге фронтка озатылды. Колхозларда кала торган өлешенә аерым нормалар куелды. Әйтик, жыйнап алынган уңышның 13 проценты орлыкка, 15 проценты эчке кирәкләргә калдырыла иде. Аның эченә фуражга кую да, хезмәткә түләү дә керә. Уңыш түбән булган елларда бер гектардан 6-7 центнер гына уңыш алына, ә 13 процент кына орлыкка калган өлеше чәчү мәйданын елдан ел кимәтә иде. Районнан килгән бу нормаларны югары оешмалар бик төгәллек белән күзәтеп тордылар. Әлеге нормаларның сакланып житә алмавы аркасында, ялгышлык өчен, кайбер колхоз житәкчеләре хөкем ителеп төрмәләргә ябылды. Еллар узган саен авыл кешесенең көнкүреше начарлана барды. Авылларга кием тегү өчен кирәкле тукымалар кайтмый, кайтса да акча булмау сәбәпле кешеләр аны ала алмыйлар иде. Өс-баш киемнәре туздЫ, начарланды. Берничә кат ямау салган киемне киеп йөрүчеләр күбәйде. Кешеләрнең ямаулы киемнәр киеп, ачлы-туклы йөрүләре аркасында кыяфәтләре күңелсез төс алды. Авыл кешеләрен аеруча борчыган нәрсә — кыш көннәрендә өйләрен ягып жылыта алмау булды. Кешеләр, шул хәлдән чыгу өчен, өйләреннән мунчаларга, кечерәк өйләргә күчеп яши башладылар. Хәтта берничә гаилә берләшеп, өйдәш торучылар да булды. Ягулыкка чәчелми калган жирләрдәге әрем файдаланылды. Аны кем ничек булдыра ала, шулай алып кайта: берәүләр күтәреп, кемнәрдер кул арбасы, бәләкәй чана белән ташыды. Авылларда кечкенә арба, чана ясаучы осталар барлыкка килде. Арба-чаналарга исемнәре дә табылды. Аны "уфалла арбасы" дип, "Уфалла чанасы" дип атадылар. Урман якынрак булган авылларда коры агачны, ботак-чатакны шулар белән ташыдылар. Авылдан 30 чакрым ераклыктагы урманнан кечкенә чана белән Сәләхова Әминә апайның ботак төяп кайтуы әле дә күз алдымда.

Авыл халкының сугыш еллары һәм әле сугыштан соңгы елларда да төп азыгы булып бәрәңге саналды. Бәрәңгене пешергәндә, йорт яхшы жылытылмаганлыктан, бәрәңге суыннан чыккан пар белән өйнең түшәм-стеналары юешләнеп, тамчылар тама. Кышын суыктан саклану өчен, тышкы яктан тәрәзәләр салам көлтәләре белән капланып бетә, тышкы яктан өйнең нигезләренә дә салам түшәлә иде. Кешеләрнең көн күрүе өчен шартлар начар булса да, колхоз эшенә катнашу мәжбүри булды. 300 көн эшкә чыгу турында югары оешмалар карар кабул итте. Шул көннәр үтәлмәсә, судка биреп, хөкем итү тәртибе кертелде. Нормасын үтәмәгән кешеләрне еракка жибәреп, мәжбүри урман кисү, жир казу кебек авыр эшләр эшләттеләр.

## Сугыш чорында район оешмалары

Район оешмаларының эшен оештыруда сугыш чоры законнары кулланылды. Район күләмендә үткәрелә торган жыелышлар кимеде, аларны фәкать эш сәгатеннән соң гына үткәрү тәртибе урнашты.

Райком, райбашкарма җитәкчеләренең эш сәгатьләре озайтылды. Районның Совет йорты дип аталган бинада ут төнге 12 гә хәтле сүнми иде. Район җитәкчеләре күпчелек вакытларын авылларда, халык арасында үткәрергә тырыштылар. Авылларга бару өчен, фәкать атлар гына хезмәт итте. Райком, райбашкарманың өчәр аты бар иде. Районның җир һәм финанс бүлекләре дә шул күләмдә ат тотты. Милиция идарәсенең атлары башка оешмаларныкыннан аерылып торды. Яллары матур итеп кыркылган, өсләре чистартылган була иде. Җәй өчен тарантаслар, кыш өчен терәкле чаналар гаҗәп матур ясалган. Алар элекке байлардан талап алынган ат дирбияларыннан файдаландылар. Тарантаслар тал чыбыгыннан пөхтә итеп үрелгән, терәлеп утыру урыннарына келәмнәр ябылган була иде. Шундый яхшы атлар белән район түрәләре авылларга еш килеп торды. Милициядән авыл халкы бик шикләнә, куркып яши иде. Менә шул сугыш елларыннан башлап, электән дә зур хокукларга ия булган дәүләт сакчылары, соңга таба үзләрен бик иркен тота башладылар. Революциядән соң бу оешмалар кулыннан бик күп кеше үтте. Алар башта революция дошманнарын, аннан троицкичыларны, милләтчеләр, кулакларны, социализм дошманнарын, кулак тегерменәнә су коючыларны "халык дошманы" дигән исем тагып, кырып бетерделәр. 1937 елларда республиканың иң зур җитәкчеләре булган ВКП(б) өлкә комитетының беренче секретаре Липон, совнарком рәисе Абрамов хөкем ителде. Район башлыкларыннан райком секретарьлары, райбашкарма җитәкчеләре шушы оешма кешеләре тарафыннан кулга алынып, хөкем ителеп, төрмәләргә ябылды, күпчелеге җәзалап үтерелде. Бу вакыйгаларны күреп торган яңа җитәкчеләр әлеге хөкем чыгару оешмалары белән исәпләшми булдыра алмадылар. Сугыш вакыты законнарына таянып, милиция органнары авылларда яшертен вәкилләр билгеләде, халыкны куркуда тотты. Шымчылар арасында төрле кешеләр булу, кайбер очракларда үзләренең дошманы дип исәпләнгән кешеләрне күзәтеп, алар өстеннән гайбәт житкерү белән шөгыльләнүчеләр дә табылды. Бу хәл сугышның соңгы елларына кадәр дәвам итте. Безнең Әтнә районында үзенең кырыслыгы белән Садриев дигән прокурор район тарихына кереп калды.

Берзаман сугыш кырларыннан безнең армиянең җиңүгә ирешә башлавы хакында хәбәрләр килде. Авыл халкының күнеле күтәрелә башлады. Район оешмаларының җитәкчеләре дә холыкларын үзгәртә төштеләр.

Шул елларда безнең Әтнә районына өлкә комитеты тарафыннан тәкъдим ителеп, яңа райком секретаре килде. Ул элек Ютазы районында башкарма комитет рәисе булып эшләгән Шакиров Сабир исемле кеше иде. Районыбызда халык тарафыннан сайланып куелган райком, райбашкарманың дәрәҗәсен үз югарылыгына күтәрү шушы иптәш килгәч башланды. Бу иптәш райкомның дәрәҗәсен күтәрү буенча күп эшләде, әкренләп, әмма эзлекле рәвештә тәртип урнаштырды. Гомумән, партия райкомы район белән идарә итүне тулысы белән үз кулына алды. Аңа ул эш ансат бирелмәгәндер. Ул тәртипсезлекләргә каршы кискен көрәш ачты.

Бу урында шул чор өчен гаҗәп булган бер вакыйганы искә төшереп үтәм. Ул чорда Олы Мәңгәрдә ("Электросталь" колхозы) Галиәхмәтов Габдрахман дигән кеше колхоз рәисе булып эшләде. Бер вакытны ул колхоз рәисләре җыелган җирдә райком бюросы членнары белән булган бер хәлне сөйләде. "...Мин югында, колхозны тикшерергә прокурор Садриев килгән. Колхоз хисапчысы белән әңгәмә корып, исәп-хисап кәгазьләрен карап утырган. Кыш көне басуда катлаулы машина белән ашлык суктыручыларга кайнар аш пешерү өчен дип бирелгән ат ите кызыксындыра моны. Көннәр үткәч, яңадан килеп, колхоз эшләренең башка төрләре белән дә кызыксына. Ашлык сукканда әрәм-шәрәм ителгәннәрне тикшереп йөри, авыл халкы белән әңгәмә кора, минем тискәре якларны сөйләүчеләрдән мәгълүмат җыя. Бу хәлләрне миңа хисапчым җиткерде. Әлбәттә, борчылдым, нәрсә булыр икән дип көтеп йөрдем. Көннәрдән бер көнне райком бюросына чакыру килде. Хуҗалык эшләренең торышы хакында исәп бирергә тиеш булдым. Яңа килгән райком секретаре белән әле аралашканым юк, ниндиерәк кеше икән дип борчылып

кына килдем. Ишекне ачып, беренче секретарь бүлмәсенә килеп кергәч озын өстәлнең ике ягында бюро әгъзалары, түр өстәл артында Шакиров утырганын күрдем. Озын өстәлнең ишек ягына килеп бастым. Бюро әгъзалары мин кергәнне күрми калган кеше кебек, түбән карап утыруларын белделәр. Шуннан әкрен генә, үзенә хас салмак тавыш белән Шакиров "Электросталь" колхозында хуҗалык эшләренең торышы, ашлык сугуының барышы турында җавап тотуны сорады. Мин колхоз эше турында, бигрәк тә ашлык сугу турында күп сөйләдем. Ул вакытта әле ике атналык сугу эше бар иде. Мөмкинлекләребезне, ашлыкны киптерү читенлекләрен әйттем, ягулык булмаудан зарландым. Сүзне бетерүем булды, секретарь бюро членнарына мөрәҗәгать итте. Ул тикшерүчедә һәм бюро членнарында нинди фикер уянуын сорады. Шул вакыт беренче булып прокурор Садриев сүз алды. Ул 10-15 минут сөйләде. Минем барлык эшләрем начар булган, сугуны ике смена оештыра алмаганмын, ашлык бөртекләре саламда, кибәктә күп калган, зур югалтуларга юл куелган, рәис үз эшенә салкын караган... Колхозда суелган ат итен ашлык сугучыларга гына бирергә тиеш булса да, аны чит кешеләргә тараткан... һ. б. Һ. б... Ул иттән авыр хәлле күп балалы солдат хатыннарына да бераз өлеш чыгарган идем, ул да ярамый, янәсе. Аның артыннан милиция начальнигы Сафин сөйләде. Ул да мине мактамады. Аның артыннан КГБ начальнигы Хөснетдинов сөйләде. Анысы миннән бөтенләй халык дошманы ясап бетерде. Аның сөйләве буенча мин Гитлер яклы кеше булып калдым! Кинәт мине курку алды. Тезләрем калтырый, йөрәгем чыгардай булып тибә башлады. Егылып китмәсәм ярар иде, дип уйлап бетермәдем, секретарь миңа: "Ни әйтерең бар?" — дип сорау бирде. Шуны ишетү белән сискәнеп киттем, күңелемнән: "Миңа бу бюродан кайту насыйп түгел, ябып куялар икән..." — дип уйладым. Шулчак... күңелемә юанычлы бер уй килде. Бюро членнарының күбесе безнең колхоздан ит, май, бал шикелле әйберләр алып китәләр иде бит! Урынымнан сикереп тордым. Бүлмәгә кергәч тә сул як стенада өс-баш киемнәре эленеп торуы күземә чалынган иде. Шул элгечләр янына йөгереп бардым да, кемнеке булгандыр, бер бүрекне алып, прокурор Садриев каршына килеп бастым: "Сез безнең колхоздан алып киткән балга акча түләмәгән идегез, салыгыз акчагызны бүреккә!" — дип бәйләнә башладым. Ул кинәт уңайсызланып калды, шул арада райком секретарена борылдым да кызу-кызу сөйләп киттем: "Иптәш Шакиров, монда утыручылардан сез генә чиста, боларның өчесенең дә куллары колхоз маена, балына буялган, болар һәрвакыт колхозга соранып киләләр иде, берсе дә акчасын түләмәде! Соңгы килүендә прокурорга ит бирә алмадык, беткән иде. Менә шуның өчен алар миннән үч алалар", — дидем. Аннары Хөснетдиновка, Сафинга таба борылдым, бүрегемне сузып, аларның нәрсә алганнарын әйтеп, акча сорый башладым. Шуннан секретарь бераз гаҗәпләнеп карап торды да: "Җитте!" — дип кычкырды. Миңа әйбәтләп кенә: "Син чыгып тор әле!" — дип дәште.

Мин бүлмәдән чыктым. Секретарь бүлмәсендә нәрсә булыр икән дип көтеп утырам. Үзем борчылам, артыгын җибәрдем бугай, дип үземне шелтәлим. Шул ук вакытта үзем райзода эшләгәндә оешмаларның төрле колхозлардан атлар өчен түләүсез фураж, печән һ. б. әйберләр алганнарын уйлыйм. Мин чыгып киткәннән соң эчке бүлмәдә бюро озак барды әле. Һәрхәлдә миңа бик озак булып тоелды. Бюро беткәч, бу иптәшләр янымнан җитди кыяфәт белән генә чыгып киттеләр. Дәшмәделәр дә, борылып та карамадылар. Алар чыгып беткәннән соң секретарь мине янадан үз бүлмәсенә чакырып кертте. Үзе генә иде. Бик җайлы сөйләште. Колхоз эшләрен кабаттан сорашты. Мин сөйләгәннәрнең дөресләнгән беләсе килде бугай. Сөйләгәннәремне язып бирүне үтенде. Бу вакыйгадан соң, милиция начальнигы Сафин мине үз янына чакырып, ничек болай килеп чыкты соң бу, дип, минем белән яхшы гына сөйләште, уфтанып утырды..."

Райком секретарена бу оешмаларның үз вазифаларыннан артыграк файдалану-лары, кешеләр белән тупас мөгамәләдә булулары хакында бик күп мәгълүмат кергән. Әлеге оешма кешеләре райком күзәтүенә алынды. Районыбызда эшләүчеләр алардан курку-калтыраудан арына башладылар.

## Сугыш чоры үзгәрешләре

Сугыш чоры электән яшәп килгән тәртипләргә үзгәрешләр кертүне таләп итте. Республика буенча җитәкчелекне кешеләргә якынайту максаты белән районнарны бүлгәли-ваклый башладылар. Балык Бистәсеннән Корноухово, Арча һәм Саба районнарыннан Чүриле аерылып чыкты. Алабугадан — Морд районы мөстәкыйль яши башлады. Районнар саны артты. Ул хәлләр үз нәүбәтендә, яшәп килгән зур авыллардагы колхозларны бүлеп, ваграк колхозлар ясауга юл ачты. Безнең Әтнә районында да колхозларны бүлү башланды. Шул исәптән Әтнә авылындагы Киров колхозын бүлеп, ике колхоз ясадылар. Авыл уртасыннан ага торган инеш суының ике ягы ике колхоз булды. Озак яши алмады бу колхозлар, янә бергә кушылдылар. Кушылуның сәбәбе — элек бергә эшләп өйрәнгән колхозчылар аерым яшәргә теләмәде. Бер-берләренең әйберләрен урлау гадәткә керә башлаган иде шул. Шулай булмый хәле дә юк. Чөнки бер ишегалдындагы ферманы икегә бүлеп булмый. Аларның гомере озын булмады, кушылырга мәҗбүр булдылар.

Бәрәзә авылындагы Куйбышев исемендәге зур колхоздан дүрт колхоз ясадылар. Бу авылда да, шул ук Әтнә авылындагыча, авыл уртасыннан агып чыга торган инешнең һәр ягында икешәр колхоз. Әтнә ягыннан килә торган юлның югары ягында Орджоникидзе, түбән ягында Чкалов, суның икенче ягында Андреев, Куйбышев исемендәге колхозлар барлыкка килде. Бу колхозларда да бер-берсен аңламыйча, әйберләрне дөрес бүлмичә, урлаулар башлангач, кушылырга мәҗбүр булдылар.

Колхозларны бүлү буенча өченче тәҗрибә Күәм авылында үткәрелде. Аны өчкә бүлделәр. Әтнә ягы өлешен Калинин, урта өлешен Карл Маркс, югары башын Молотов исемендәге колхоз иттеләр. Бу колхозлар да озак яши алмады, берләшергә мәҗбүр булдылар. Бәрәзә, Әтнә, Күәм авылларындагы колхозларны ваклау тәҗрибәсе шул авыл кешеләре тарафыннан яклау тапмады. Сугыш вакытында колхозларны авыр хәлдән чыгару өчен бер чара булмасмы икән дигән чираттагы бер көчәнеш кенә булып калды.

## Үземә кагылышлы берничә сүз

**1942** елның декабрь аенда Түбән Шашы авылындагы Чулпан колхозыннан комсомол оешмасы секретаре булып эшләгәндә, мине комсомолның Әтнә райкомына дәшеп алдылар. Миңа 17 яшь иде. Хәрби училищега укырга барырга дип димләргә чакырганнар икән. Сөйләшкәндә бу эш ачык калган кебек иде, шуннан озак та үтмәде, мине хәрби комиссариатка чакырдылар. Иң беренче сүз итеп хәрби комиссар: “Үз теләгегез белән хәрби училищега китәргә уйлавыгыз белән котлыйбыз”, — диде.

Аптырап калдым.

“Сезгә 1943 елның июль аенда 18 яшь тула икән, нәкъ шул вакытта сез үзегез барасы хәрби училищеда укып бетереп, лейтенант дәрәҗәсе алачаксыз”, — диделәр. Училищега хәзерләнеп торырга кушып, кайтарып җибәрделәр. Шулай итеп, мине Удмуртиянең Сарапул шәһәренә, сугыш булган җирдән күчеп килгән Смоленск пехота училищесына язып та куйдылар. Минем белән бергә районнан тагын берничә егет китте. Училищеда уку вакыты 6 ай иде. Тик училищены тәмамларга туры килмәде.

1943 елның җәендә Курск, Орел шәһәрләре тирәсендә барган сугышларда безнең ил солдатлары зур җиңүгә ирештеләр. Югалтулар да күп булды. Хәрәкәттәге армияне тулыландыру өчен, укуны өзеп, безне шунда җибәрделәр. Әлеге училищеның исемен йөрткән Смоленск тирәсендәге сугышларда катнашырга тиеш булдык. Смоленск шәһәренә барып житкәндә, Духовщина-Ярцево районы биләмәләрендә барган каты сугышларда снаряд кыйпылчыгы тиеп яраландым. Шундук кыр госпиталендә операция ясап, Калинин шәһәренә

озаттылар. 1944 елның 1 январенда армиягә яраксыз булып, инвалид хәлендә авылга кайттым. Армиягә киткәндә мине озатып калган авылым мәшәкатьләре тагын да үрчеп каршы алды. Алты ай үткән саен комиссия торгызып, инвалидлыгымны барлап-тикшереп тордылар. 1944 елның 19 июнендә, 18 яшемдә мине, инвалид егетне, авылдашларым үзебезнең Түбән Шашы авылы — "Чулпан" колхозына рәис итеп куйдылар. Әнә шул көннән башлап авылдашларым һәм районДашларым белән бергә, авырлыклар өчен көенеп, шатлыклар өчен сөенеп, 1993 елның 25 июленә кадәр эшләргә туры килде. Колхоз рәисе итеп сайлау өчен башта райкомга чакырдылар. Секретарь Шакиров Сабир абый белән шактый сөйләшеп утырырга туры килде. Яшьлегемне сәбәп итеп, ул эшне булдыра алмам дип тә әйтеп карадым, булмады, Сабир абый минем белән килешмәде. Колхозчылар да яшьрәк булуым сәбәпле кабул итмәсләр дип шикләнып йөрдем.


*Ф. Галиев. Армиядән яраланып кайткач. 1944 ел.*

Җыелыш ачык җирдә — мәктәп ишегалдында үтте. Районнан килгән вәкил — райзо мөдире Галиәхмәтов Габдрахман колхоз рәисе итеп минем фамилияне әйткәч, авылыбызның бер өлкән кешесе Җаббаров Габдрахман: "Ул малай бик яшь ич әле, тәҗрибәлерәк кешене — Мәңгәрнең Галиевне сайласак ничек булыр икән?" — дигән тәкъдим кертте. Вәкил, мине яшь дип әйткән кешеләрне гаепләп, минем кандидатураны яклап сөйләде. Авылда комсомол башлыгы, әйбәт хисапчы булып эшләүләремне әйтте. Шулай итеп, мин күпчелек тавыш белән колхоз рәисе булып сайландым. Җыелыштан авылдашларым төркем-төркем булып таралыштылар. Вәкилне дә озаттым. Аны озатканнан соң миңа бу тормыш әллә ничек, бик шомлы булып калды. Чыннан да, авылыбыз бу көннәрдә ыңгырашып-сыкрап торган кебек иде. Янымда басып торган элекке колхоз рәисе Котдусов Нуриаздан абый: "Энем, хәзер мин нишлим инде?" — дип миңа мөрәҗәгать итте. Аңа шундый авыр елларда колхоз рәисе булып эшләгәне өчен рәхмәт әйттем.

Өйгә кайтсам, әни ике энекәшне кочаклап елап утыра. Мине башта елый-елый орышты. "Ни башың белән шул зур җаваплылыкны өстенә алдың?" — диде. Аны бераз тынычландырып, көндезге ашны ашагач, янадан колхоз идарәсенә киттем. Хисапчы Җәләлиева Һәдия белән кенәгәләрне карап, колхоз милкен барлап чыктым. Ул кенәгәләрдә барларлык күп нәрсә юк иде. Колхоз келәтендә бер грамм икмәк, бәрәңге юк. Колхоз кассасында, банкта акча да калмаган. Кичке якта колхоз идарәсенә нәрәт алырга бригадирлар һәм тармак җитәкчеләре җыелды. Алар белән озаклап колхоздагы хәлләр турында сөйләшеп-аңлашып утырдык. Кешеләрнең тормыш хәлләрен авыл башыннан башлап берәмтекләп сораштым. Алар күп кешеләрнең эшкә чыга алмавына борчылдылар. Байтак кеше ачлыктан интегеп, шешенеп ята икән. Шушы хәлләрне белгәннән соң, иң беренче эшем итеп, шул кешеләрне барладым, исемлекләрен төзедем. Авыл буенча барлык йортларга кереп, авыруларны ачыклап чыктык. Алар 80 кеше булды. Мин шул исемлектәге кешеләр өчен икмәк табуны беренче бурычым итеп куйдым.

Район башкарма комитетына барып хәлне аңлаттым. Районда икмәк карточкалары белән эш итүче райбашкарманың җаваплы кешесе безнең авылның Җәләлетдинов Гыйлаҗ абыйдан ярдәм сорадым. Ул мине тыңлап, райсоюздан алу өчен ике капчык онга язу бирде. Шул онны арбага салып авылга кайтканда, мин бик куанган идем. Бу минем колхоз рәисе булып эшли башлавымның беренче көнендә ирешкән иң зур уңышым һәм сөенечем булды. Авыру кешеләрне мәктәп бинасына җыеп, алар өчен кайнар аш хәзерләп, шунда тукландырдык. Бөтенләй килә алмаучыларына ризыкны өйләренә илтеп бирдек. Шулай итеп, яңа иген өлгергәнче, авыр хәлдәге кешеләрнең гомерләрен саклап кала алдык. Шулай да ачлыктан шешенеп бер кыз балабыз үлде. Ул баланың ачлыктан интегеп, авызы карышып ризык ашый алмыйча ятуы озак вакытлар күз алдымнан китмәде.

Игеннәр өлгергәч, авыл балалары арыш басуына барып, арыш башагыннан арыш уып ашый торган булдылар. Шактый җирне таптап җәберләсәләр дә, аларның анда туклануына комачауламадым, күрмәмешкә салыштым. Бу чорда яшәгән хатын-кызлар балаларын исән-сау саклап калуда гаҗәп зур тырышлык куйдылар.

Язга чыккач, кешеләр узган ел иген игелгән җирләрдәге урып өлгерә алмыйча калган яки чәчелеп калган башакларны җыеп өйләренә алып кайта башладылар. Көньяк районнарда яз безгә караганда бер-ике атнага иртә килә торган иде. Менә шул районнарда мондый чәчелгән-кышлаган ашлыкларны ашап кешеләрнең үлү хәбәрләре ишетелде. Бездә дә шундый хәл бумасын өчен, колхоз җитәкчеләре халык арасында аңлату эшләре алып барды. Шулай итеп, бу сиптик ангенага юл куймыйча, кешеләрне үлемнән саклап калдык. Соңгы елларда колхоз рәисе булып эшләгән хәлдә кешеләрнең сугыш елларында эшләгән эшләрен бүгенге эшләре белән чагыштырып карый торган булдым. Ул чор кешеләренең эш сөючәнлеге, тырышлыгы, гаделлеге, бер-берләренә булган яхшы мөгамәләсе, дөнья байлыкларына комсыз булмаулары, игъмлылыклары сагынып сөйләрлек бит! Үземчә шундый бер нәтиҗә чыгардым: тормышта авырлыклар күреп, ачлыктан интегеп яшәгән кешеләр дөнья малының кадерен белә, табигать үзенең шундый кырыслыгы белән кешеләрне сынап, аларны акыллырак булырга, дөнья байлыгына сак карарга өйрәтә икән.

Миңа сугыш чорында һәм сугыштан соң илне торгызу кебек катлаулы вакытларда колхоз рәисе эшен дәвам итәргә туры килде. Беренче елларны тәҗрибәм булмаганлыктан, күп кешеләрнең киңәшләренә таяндым. Уңай тәҗрибәне өйрәнергә, кабул итәргә тырыштым. Тискәре эшләреннән алай эшләргә ярамаганлыгын аңладым. Район җитәкчеләренең теге яки бу эшне башкарырга дип каттый таләп белән язылган күрсәтмәләрен күңелемнән кичереп, безнең хуҗалыкка яраклы булганнарын алдым, тиешсезләрен төшереп калдырдым. Безнең Әтнә районында шул чорның алдынгы карашлы, тырыш, эшчән байтак җитәкчеләре белән бергә эшләргә туры килде. Шулар арасында беренче очрашкан кешеләр турында миндә зур истәлекләр калды. Шундыйларның берсе — Күәм авылында туып үскән, шул авылда һәм Әтнәдә колхоз рәисе булып эшләгән Шакиров Гали абый. Холкы әйбәт, үз-үзен тотышы тыйнак, кешеләр белән иренмичә, гади итеп сөйләшә белә, үзендә булган тәҗрибәсен яшьләрдән яшерми.

Ул чорларда районыбызның күренекле кешеләре исемлегендә Ишниязов Ибраһим абыйны әйтеп китәргә була. Холкы ягыннан Гали абыйга караганда бөтенләй башка иде ул. Тиз кабынучан, кул астында эшләүчеләрне дер селкетеп ташларга мөмкин. Кешеләрне кабул иткәндә гадел хөкем чыгарырга сәләтле. Үч тотмавы белән безне үзенә якынайта торган иде. Бу иптәш районыбыз өчен ике МТС төзеп бирде.

Районыбызның күренекле кешеләреннән тагын берсе —Бәрәскә авылы “Ленин” колхозында колхоз рәисе булып эшләүче Касыймова Рауза иде. Бу колхоз ул чорда республикабызда иң күренекле колхозларның берсе булып торды. Хәтта колхоз рәисе тормышыннан бер пьеса да язылды. Аның исеме “Миңлекамал” булып, спектакль Г. Камал театрында озак еллар сәхнәдән

төшмәде. Касыймова сугыш һәм аннан соңгы елларда ике тапкыр Татарстан Югары Советына депутат булып сайланды. Авыл хуҗалыгы фәне белән артык таныш булмаса да, авылдагы өлкән игенчеләр белән уртак тел табып, аларның эш тәҗрибәләреннән файдаланып, хуҗалык эшен оештыруда үзенен бик сәләтле җитәкче икәнен күрсәтте.

Районыбыз тормышында яңадан зур бер вакыйгага тап булырга туры килде. Сугыш беткәннән соң, колхозларны кадрлар белән тәэмин итү өчен, югары оешмаларның карары нигезендә, СССР буенча 30 мең кешене шәһәрләрдән колхозларга җибәрделәр. Безнең районга да колхоз рәисе булып берничә кеше килде. Әтнә МТСына директор, Күәм МТСына баш инженер итеп шәһәр кешеләрен җибәрделәр. Аларны Казанда кыска сроклы курсларда авыл хуҗалыгы эшләре белән таныштырганнар икән. Күбесе авыл хуҗалыгын бөтенләй белмәгәнлектән, үзләрен аклый алмады. Шундыйларның берничәсен искә төшереп китәм: Күлле Кимегә килгән бер иптәш — акыллы, йомшак күңелле колхоз рәисе булып эшләүче "утыз менче" кич эштән кайта икән. Фермадан бер колхозчының печән урлап, кечкенә чана белән тартып баруына очрый бу. Рәис бу кешенең азапланып тартып барганын күреп, чананы этешә башлый. Үзе урлаучыга киңәш итә: "Болай күп итеп төягәч, колхоздан ат сорап торып, зур чана белән алып кайту кирәк иде", — ди. Ахырдан моны печән урлаучы көлеп сөйләгән. Колхоз рәисе колхозчының ферма печәнен урлап кайтуын аңламаган.

Шундый хәлнең икенчесе. Ары авылы "Йолдыз" колхозына да рәис Казаннан килә. Ул, колхоз эшен алга җибәрәм дип, алдынгыларны бүләкләү өчен колхоз кассасыннан акча алган, документларын рәсмиләштермичә, кешеләргә өләшеп йөргән. Финанс ялгышлыклары бу иптәшкә кыйбатка төште.

Атамыш авылы исемен үзгәртеп, "Победа" дип аталган колхозга рәис булып Мусаев фамилияле кеше килде. Бу иптәш бик тынгысыз иде, колхозны тиз генә алдынгы итеп чыгару максаты белән каты кагыйдәләр кулланып карады. Ләкин эше алга китә алмады. Шуннан гайрәте чигеп, колхозны ташлап китәргә мәҗбүр булды.

Шундый ук тагын бер иптәш Соңгыр авылы, "Красный борец" колхозына килде. Анарчы ул шәһәрдә завод директоры булып эшләгән. Сәяси яктан белемле, ләкин авыл хуҗалыгы эшләрен бик начар белә. Сөйләү сәләте көчле, Ленин томнарыннан өзекләр китереп, матур әдәбият китабындагы мисалларга таянып бик матур, көчле чыгышлар ясый, бәйрәмнәрне авыл халкының эш вакыты белән исәпләшмичә, шәһәрдәге кебек бик зурлап үткәрә торган иде.



*1945 ел. Язгы чәчү вакыты.*

Шундый вакыйгаларның берсен Соңгыр авылында тракторлар бригадиры Насретдинов Гарифҗан сөйләгән иде. Ул Беренче Май бәйрәме көнне, язгы чәчүнең кызган вакытында, нинди дер бер киңәш кирәк булгач, колхоз рәисе белән сөйләшергә дип колхоз идарәсенә бара. Идарәдә каравыл торучы әйтә: "Шәһәрдән хатыны килгән, икенче көн инде аның монда күренгәне юк", —ди. Эш мөһим булганлыктан, Насретдинов рәиснең өенә китә. Барып керсә, өендә бәйрәм итеп ята ди теге. "Минем сәламемне алу белән, стаканга аракы салып, кыстарга тотынды. "Сабан өсте бит, көн яхшы вакытта чәчәргә кирәк, минем чәчүчеләр янына барасым бар, яхшы түгел", — дигәч, стаканны күтәргән килеш, каршыма килеп: "Бүген бәйрәм көн, бөтен дөнья бәйрәм итә, шулай булгач, ник без генә бәйрәм итмәскә тиеш, без генә синең белән икенче сортлы юкәдән тәрелгән кешеләр түгел ич, чәчәрбез, бүген булмаса иртәгә чәчәрбез, моны эчмичә, бер төрле сорауны да хәл итмибез", — диде. Миңа стаканны бушатып бирергә туры килде. Шуннан сөйләшеп, мәсьәләне хәл иттек —мин чыгып китә башладым. "Юл аягына эчмичә китмә", — дип, кабат туктатты. "Үзең белән эшләүче трактористларыңны минем исемнән Май бәйрәме белән котла", — диде. Миңа, гомерем буена, язның бер көне ел туйдыра, дип тәрбияләнгән кешегә рәиснең гамәле бик сәер тоелды.

Урыс авылы кешеләре дә, эшләрен читкә куеп, бәйрәм белән кирәгеннән артык мавыга торганнар иде. Бу "утыз меңчеләр" исәбеннән колхозларга килгән кешеләр авыл хуҗалыгына зур файда китерә алмады. Аларның күбесе үз теләкләре белән килмәгән, партия кушуына каршы килә алмыйча гына риза булган иде. Аларның Казанда фатирлары сакланды, колхозларда вакытлыча гына фатирда тордылар. Күпчелеге гаиләләрен дә алып килмәде.

## Сугыш беткән көн

Сугыш беткән көнне мин сабанчылар янында идем. Бу язның аяз, кояшлы, җылы бик матур бер көне иде. Сабанчылар атлар белән сука сукалыйлар, малайлар үгезләр белән җирне тырмалыйлар. Чәчүчеләр белән киңәшеп торганда, карасам, бер хатын-кыз бик кызулап, хәтта йөгергәләп үк килә. Күршебез Маһинур апа сугыш бетү хәбәрен ишетеп, миңа әйтергә йөгерә икән. Шул сүзне ишетү белән әллә ниткән бер җиңеллек тә, авырлык та тойдым. Сугыш эчендә булган кешеләрнең исән калганнары өчен сөендем, үлгәннәре өчен кайгырдым. Телефонга ашыктым. Ул вакытта авыл Советы Күнгәрдә иде. Мин авыл Советына кергәндә, Югары Шашының ("Марс" колхозы) рәисе Арсланов Әхәт абый да килеп җиткән иде. Телефоннан райком секретаре белән сөйләшеп, чыннан да сугышның беткәнлегенә ышанып, авылга кайтып киттем. Мин туп-туры чәчү орлыгы әзерләүчеләр янына — амбарга кайттым. Анда авылдан да кешеләр менгән, шактый кеше җыйналган иде. Алар "Сугыш бетте!" дигән хәбәрнең дөресме икәнен белү өчен мине көтеп торганнар. Райком секретаренең сугыш бетү хакында әйткәннәрен сөйләп сөендердем. Иң кызганычы шунда булды да инде. Ирләренең үле хәбәрен алган хатын-кызлар һәм солдатка киткәннән бирле хәбәре булмаган ирләрнең хатыннары, сугыш бетү хәбәрен ишеткәч, үксеп елый башладылар. "Исәннәр кайтыр, безнекеләр кайта алмыйлар ич инде, безнең балаларыбыз ятим калдылар бит инде", — дип, такмаклап, үкси-үкси еладылар. Ул хәл амбар янындагы барлык кешегә авыр тәэсир итте. Сугышка катнашы булмаган кешеләрнең дә сугыштан кайтмаган авылдашларын кызганып, күз яшьләре акты. Минем үз гомеремдә шул көндәге хәтле тетрәнү кичергәнем булмагандыр.

Сугыш беткән көннең иртәгесен колхоз һәм авыл Советы рәисләрен районга җыеп, җиңү көнен ничек билгеләргә, авылларда нинди эшләргә кирәклеген сөйләделәр. Сугышта ирләре үлгәннәргә аеруча игътибарлы булу, балаларына ярдәм оештыру, ашау-эчү белән ярдәм итү кирәклеген аңлатып, күрсәтмәләр бирделәр. Җыелышның икенче өлешендә язгы чәчүнең торышы турында фикер алышу булды. Арча элеваторыннан орлыклык арпаны алып

бетерү бурычы куелды. Әлеге арпа орлыгы Төрекмәнстан ягыннан килгән иде.

Җыелыш беткәннән соң колхоз рәисләре атларына утырып, колхозларына таралдылар.

Мин юл буе уйланып кайттым. Иң элек, ачлыктан интеккән кешеләрне ничек тә саклап калырга кирәк иде. Дамбадан болын юлына төшкәч, шушы болыннарда печән чабып, Ашыт суында коенып яшәгән авылдашларымның сугыштан кайта алмаучыларын берәмләп күз алдымнан уздырдым, сугышта күргәннәремне күңелемнән яңарттым...

Фронтның алгы сызыгына барып җитеп, оборонада торучы солдатларны алыштыру өчен, төне буе 30 чакрым араны җәяүләп узып, арып хәлдән тайган идек. Шул сәбәпле, үзебез сыярлык окоп казып бетерә алмадык. Шундый чокырыбыз булмау аркасында дошман снайперлары күбебезне атып үтерде. Бер пуля да ата алмыйча, беренче көнне үк күпләр һәлак булды. Мин тырыша-тырмаша окопны казып керә алдым, шул сәбәпле генә исән калдым. Эшелонга төялеп барган чакта ук дошман самолеты бомбага тотудан күпме кеше кырылды! Беренче көннән үк сугышка керүче иптәшләремнең күбесе вафат булды. Тора-бара янындагы үлүчеләргә, мәетләргә дә ияләнә башлыйсың икән. Ин авыры сугышка керүнең беренче көненнән үк бик якын дустым булган кешене күмә алмыйча калдырып китү булды. Дошманга каршы барганда ул миннән алдарак иде. Төрле урыннарга төшкән снарядлардан яраланып ауды, мин янына килеп җиткәндә, күзендә нуры бар иде әле, ул арада үлеп тә китте. Ярчык уң як кабыргаларын җәрәхәтләп, тәнен умырып ташлаган иде. Ачык җәрәхәттән үпкәсе күренеп, кан агып тора. Мин, акылымны җуяр дәрәҗәдә аптырап торганда отделение командиры килеп житте дә: “Нишләп торасың?” — дип мина төбәлде. “Моны күмеп булмасмы икән?” — дип сорадым. “Аларны арттан килүче махсус отряд җирли, әйдә, артта калма!”, — дип боерык бирде командир. Мин аның яныннан китешли: “Сау бул, дустым!” — дип гәүдәсенә караганда, бер дәү чебен җәрәхәтле үпкәгә килеп кунды. Ул чебен гомерем буе күңелемнән китми...

Шушы уңай белән күңелемә икенче уй килеп төште. Фронтның алгы сызыгына кергәндә, Белый дигән шәһәр аркылы үтәргә туры килгән иде. Ул тирәдән сугыш үткәнгә 20 көн дигәннәр иде. Андагы чебеннең күплегенә, сасылыкка исебез китте. Биш чакрым араны чебен болытын ярып барырга туры килде...

Уфада госпитальдә ятканда күргән вакыйгалар да искә төште. Бер бүлмәдә 14 кеше идек. Аяксыз-кулсыз, күзсез солдатлар белән дә очрашырга туры килде...

Авылга килеп керү белән авылдашларымның көндәлек хәлләре фронт хәлләрен оныттырды. Үз туган авылында җитәкче булып эшләүнең бер яктан уңайлылыгы бар. Барлык кешенең ата-анасын, әби-бабаларын, нәселен белеп торасың. Икенче яктан, туган-тумачаларын күп булу, мәктәптә укыган яшьлек дусларың белән бергә көн итү уңайсызлык тудыра. Өстәвенә, синең җиде буыңга кадәр булган туганнарыңны, холык-гадәтләреңне, ата-ананның кем икәнлеген белеп торалар. Аларның уңай яки тискәре яклары авыл халкы каршында көзгедәге кебек ачык күренә. Туган авылында колхоз рәисе булып эшләү бик җаваплы эш. Гомергә колхоз җитәкчесе булып тормассың бит! Әгәр дә авыл халкына урынсыз, хаксыз яманлык эшләсәң, алар күзенә ничек күренерсең! Әмма колхоз рәисләрен читтән эзләү белән мин бер дә килешмәдем. Аларның бик азы гына авыл халкы тарафыннан кабул ителә иде. Ул җитәкчеләрнең кайберләре үзләрен килеп акча эшләүче дип кенә хис иттеләр. Авырлык килү белән үз мәнфәгатьләрен кайгыртырга тотындылар. Китереп куйган колхоз рәисләре югары оешма кешеләренә яраклашырга тырышып эшләделәр. Мина, шул авыл кешесе булганлыктан, гел җаваплылык тоеп эшләргә туры килде. Эш дәверемдә балаларны саклап калуга аеруча игътибар иттем. Сугыштан соң 1947 елда гына хезмәт көненә икмәк бирә башладык. Аңа кадәр кешеләрнең туклану рационында төп урынны бәрәңге, акбаш, кузгалак, балдырган, кычыткан, алабута, ат кузгалагы алды. Шул

1947 елдан башлап көннән-көн авылларда тормышның җайга салынуы сизелде. Әле шуның өстенә сугыш үткән җирләрдәге халыкларга да ярдәм итәргә тиеш булып чыктык. Украинага, Белоруссиягә сыерлар төяп җибәрелде, икмәкләтә дә ярдәм ителде. Районга безне җыеп, кем күпме ярдәм итә ала, шуны ачыкладылар. Бу чорда колхозларның хәле бик начарланган иде инде. Аның йомшаруына сугыш афәте генә түгел, төрле-төрле бурычлар кую да сәбәп булды. Колхозларны йомшартуга юнәлдерелгән сәбәпнең икенчесе — сугышка кадәр үк шәһәрләрне үстерү, яшьләрне ФЗӨга алу, Донбасс, Кузбасс шахталарына җыйнау булды. Тормыш авырлыгына чыдый алмыйча, кешеләр үз теләкләре белән авылдан китә башладылар. Шуның өстенә авылларда армиядән кайткан кешеләргә, аерата әсирлектә булган кешеләргә ышанычсызлык күрсәтеп, аларны КГБ кешеләре еш чакыртып, борчып тордылар. Мондый хәлләр безнең колхозда да булды. Әсирлектә булып кайткан Хафиз абыйны ат караучы итеп куйган идек. Көннәрдән бер көнне районнан килгән КГБ кешеләре, ышанычсыз кешегә атлар карауны тапшыргансыз, дип мине тәнкыйтьләделәр. Хафиз абыйны эшеннән алырга туры килде. Менә шул сәбәпләр аркасында кешеләрнең авылдан китүе кампания төсен алды. Кайбер авыллар, кешеләр күп китү сәбәпле, бөтенләй бетте. Бу хәл бигрәк тә урыс авылларында тизләнеш алды. Татар авылларында кешеләр кимү сонга табарак башланды. Районыбызда иң элек Мәзекәү, аннан Байчыга, аннан Соңгыр, иң ахырдан Атамыш авыллары бетте. Атамыш зур, 200 хуҗалыклы авыл иде. Каралтылары нык, зур, атаклы механизаторлары бар иде. Соңгы елларда бу авылда туып үскән Очалов Владислав ил күләмендә зур дәрәҗәле генерал-полковник та булды әле.

Шулай итеп, татар авылларында да читкә китүләр көчәйде. Башта кечкенә авыллар таралды, чөнки сугыш вакытында аларга игътибар бетте, аларда кибет, клуб, китапханә, сәламәтлек саклау пунктлары булмады, хәтта су белән тәэмин итү дә начарланды.

Ил белән Хрущев житәкчелек иткәндә, агрошәһәрчекләр төзү планы булдырылып, бу авылларны үзәккә җыйнау мәслихәт дип табылды. Шул сәбәпләр аркасында Кабакса, Кече Өшкәтә, Кече Күәм, Крестьян Үртәме, Кызыл Байрак, Нәриман, Үрнәк, Яңа Җогып, Кызыл Маяк, Норма авыллары таралды. Аларның җирләре күрше авыл җирләренә кушылды, авыл урыннары сукалап ташланды. Зур тракторлар белән кабер өсләрен дә сукаладылар. Еллар үтү белән, чит җирләрдән, шул каберләрдә җирләнгән кешеләрнең туганнары, балалары кайтып, каберләрне эзләп йөрде... Каберлекне саклауга игътибарсыз булу бер җитәкчене дә бизәми. Бу авылларны бетерү кыргыйлык булса, зиярәтларны таптатуны вәхшилек дип әйтер идем. Әйләндереп алырга мөмкинлек булмаса да, аны сөрмәскә иде. Үлән үсеп, кыргый чәчәкләргә күмелеп утырса ни була?! Үз авылларыннан булган җитәкчеләр бу ямьсезлеккә бара алмаслар иде, чөнки аның үз кешеләре шунда җирләнгән бит! "Исәннәрнең кадерен, үлгәннәрнең каберен бел" диләр. Авыллар һәм каберләрнең кадерен белмәгән җитәкчеләр исән кешеләрнең дә кадерен белә алмый.

Авыл кешеләренә мәрхәмәтле булу район җитәкчеләренә дә бәйле. Аларны гел алмаштырып тордылар. Сугыш вакытында һәм аннан соңгы авыр елларда район халкы белән бергә эшләгән райком секретаре Шакиров Сабир абыйны да партия мәктәбенә укырга җибәрделәр. Сугыштан соңгы елларда республикабызда партия мәктәбе ачылды. Башта ул ике еллык иде, аннары тулы югары белем бирә торган мәктәпкә әйләнде. (Ул мәктәп Казандагы хәзерге 6 хастаханә бинасына урнашкан иде.) Шакиров урынына безнең районга партия өлкә комитеты Билалов Исмәгыйль дигән кешене тәкъдим итте. Мамадыш ягыннан иде ул. Ачык күңелле, тиз аралашучан, ягымлы. Ул эшли башлаган чорны авыл хуҗалыгында сугыш чоры яраларын төзәтү чоры дип атарга булыр иде. Шакиров эшләгәндә, районыбыз алдынгы районыбыз исәбенә керә башлады. Ә Билалов данныбызны тагын да үстерде. Районнарның алдынгылыгы ул вакытта дәүләткә ашлык тапшыру, игеннәрне чәчү, җыйнау эшләрен алдан бетерү белән генә бәяләнә иде. Дәүләткә

ашлык тапшыру буенча Әтнә районы күп еллар беренче булды. Кешеләр белән эш иткәндә, Билалов эшне ашыгып кына хәл итү ягында булмады. Бу очракта беренче секретарьның кешеләр белән мөгамәләсе хакында бер вакыйганы искә төшереп үтәм.

Мин, безнең авылда укытучы булып эшләүче Бәрәскә кызы Бикташирова Сарага өйләнергә булдым. Риза булышуның барлык кануннарын үтәп бетергәннән соң (яучылар аша), аны алып кайтырга Бәрәскә авылына бардым. Кызның әтисе, булачак бабай: "Без кызыбызны никах укытмыйча җибәрмибез", — диде. —"Никахсыз тормыш булмый ул", — дип кырт кисте. Бу эшне хәл итү өчен хәзерлек эшләрен дә җиренә җиткереп куйганнар иде. Мина, коммунист кешегә, никах укыту рөхсәт ителмәсә дә, риза булырга туры килде. "Үзен никахта катнашмассың, синен яктан якын кешең кирәк булачак", — диделәр. Минем ул эшкә ярардай беркемем дә юк иде. Шул вакыт "Трактор" колхозы рәисе Фәттиев Фәйзи абый искә төште. Тиз генә аның янына бардым да хәлемне аңлаттым. Ул бераз аптырап торгач, барырга ризалык бирде. Никахта кызның туганнары, күршеләре һәм Фәйзи абый да булды. Без кәләш белән никах авазы ишетелми торган икенче урында сөйләшеп утырдык.

Никах мәҗлесе бетте. Кешеләр өйдән чыгып киттеләр, Фәйзи абый, үзенә генә хас тизлек белән килеп, безне законлы никахыбыз белән котлады. Бераз безнең белән шаяртып сөйләшеп торгач, өенә кайтып китте. Кыз белән мин дә авылыбызга кайттык. Безне бик матур итеп озатып калдылар. Мин ул вакытта Казанда укый идем. Казанга китәргә туры килде. Бераз вакыттан соң авылга кайтсам, райкомга чакыралар. Барсам, райком коридорында Фәйзи абый йөренгәләп тора. Үзе куркынган, агарып киткән, кечерәеп калган. Ул болай да юка гәүдәле, тәбәнәк кеше иде. Фин сугышында катнашып, бер күзен югалтып кайтты. Шул күзен кыеклап марля белән бәйләп йөри, ачык калган исән күзе бик хәвефле ялтырый иде. Ул, ашыга-ашыга, безнең өстән язылган шикаятьне сөйләп бирде. Ике коммунист, берсе ата булып, икенчесе кияү булып никах укытып утыруыбызны язганнар иде.

Килүебезне секретарь кызга белдердек. Озак та үтмәде, эчке бүлмәдән ике кеше чыгып китте. Секретарь кызны беренче секретарь чакырып, кыңгырау шалтырады. Аннан соң без дә кердек. Секретарь безгә урын күрсәтте, утырдык. Чакыруның сәбәбен аңлатты. "Сезнең өстегездән шикаять бар", — дип шуны безгә укып күрсәтте. Хат бик шыксыз язылган. Кемнеңдер Фәттиев Фәйзидән үч аласы килүе сизелеп тора. Хатның эчтәлеге болай. "Болар икесе дә ялган коммунистлар. Партиябез кешеләрнең башын бутаучы, искелек калдыгы булган дингә каршы көрәш алып барганда ике коммунист дин йолалары буенча авыл кешеләрен җыеп никах укыттылар. Алар шундый сыйфатлары белән коммунистлар сафында торырга лаеклы түгел, партиядән чыгарылып, җитәкчелек эшеннән дә алынырга тиешләр...

Бу эш зурга китәр ахры, дип уйлап куйдым. Райком секретаре хатны укып бетергәч, өстәлгә салып куйды да безгә карады: "Йә, ничек булды бу?".

Бу эшнең сәбәпчесе мин икәнне әйтеп, ничек булган шулай сөйләп бирдем. Фәйзи абыйга сүз бирелгәч, ул минем сүзләрне раслады гына.

"Менә шундый чорда яшибез, нишлик соң инде, бар бит кешеләр, шундый изге эш белән яңа тормыш башлаган яшьләрнең канына тоз салырга яратучылар, — диде райком секретаре. —Үзегез дә саграк булмагансыз, — дип өстәде. — Ярар, бу хат, яңадан кабатлануны таләп итүче булмаса, шуның белән тукталып торыр"...

Ул Фәйзи абыйдан колхоз эшләре турында, минем укуларымның ничек баруы турында сорашты. Бу кешегә карата ихтирамым зур булды. Үзем эшләгән дәвердә мина кушкан барлык эшләрен җиренә җиткереп үтәргә тырыштым.

Бу иптәш эшләгән чорда районны электрлаштыруга омтылыш булды. Ул елларда кечкенә елгаларда булган тегермәннәрдән файдаланып

электростанцияләр төзү белән күп шөгыльләнделәр. Безнең районда да Җилгелде су тегермәненнән шул максатта файдаланырга уйладылар. Бу эш район Советында тикшерелеп карар кабул ителде. Колхозларга Җилгелде авылыннан Әтнәгә кадәр баганалар утыртып чыгуны йөкләделәр. Ул эшне кыш көне башкарырга туры килде. Баганалар да утыртылды, тегермәнгә куярга генераторлар да алып кайтылды, ләкин эш без уйлаганча ук барып чыкмады. Суның көче җитмәгәнлектән, электр энергиясе бик аз булды. Суның өзлексез бер тирәнлектә (көчлелектә) булуын тәэмин итү читен иде. Тегермән буаларының да ныклыгы җитәрлек түгел иде. Язгы, җәйге яңгырлар белән тегермән буаларының агып китү очраклары да булгалап торды.

Шул чорда район җитәкчеләре тарафыннан бик кирәкле булган төзелеш материалы — кирпеч сугу эше оештырылды. Әтнә районы өчен райбашкарма бинасын салганда ук кирпеч булмау үзен сиздерде. Шул чорлардан башлап районга җитәкче булып килгән иптәшләр бу эшне башлап карадылар. ләкин барып чыкмады. Аны Гыйззәтуллин Гариф абый гына нигездә яхшы оештыра алды.

Гариф абый тумышы белән Кышлау авылы кешесе иде. Холкы әйбәт. Башта ул райсоюз рәисе булып эшләде, аннан райбашкарма рәисе итеп күчерелде. Үзебезнең районда туып үскән кеше булганлыктан, кешеләрне бик яхшы белә. Кешеләр белән гади сөйләшүе аркасында колхоз, авыл Советы җитәкчеләре аны бик хөрмәт итәләр иде. Акыллы фикерләре белән безнең ише яшь җитәкчеләргә дә ярдәм итте. Шулай бер вакыт безнең колхозга килгәч, аның белән басуга сабан эшен эшләүчеләр янына бардык. Кайтканда урамнан безгә каршы бер исерек килә иде. Безне күргәч, бер капка артына кереп качты. Мин ул кеше өчен уңайсызландым. “Нишлисең инде, Гариф абый, бездә шундый кешеләр дә бар шул”, — дип куйдым. “Ул акыллы исерек, айныр ул, анадан туган исеректән сак бул, энем”, —диде Гариф абый. Ул бу сүзе белән, яшь чагыннан ук бәйләнчек кешеләрне күздә тоткан икән. Эш дәверемдә миңа шундый кешеләр белән шактый очрашырга туры килде. Бер төрлеләре җитәкче өстеннән гаеп кенә эзлиләр, азрак эшләп күбрәк алырга омтылалар, тәртипкә чакыра башласаң, төрле янау сүзләре әйтеп, башка кешеләрне котырталар иде. Шундый кешеләр белән очрашкан чакта Гариф абый әйткән сүзләрне искә төшерә торган булдым.

Райком, райбашкарма җитәкчеләре бер-берсен аңлап, бик тату эшләделәр. Бу татулык урыннардагы колхоз һәм авыл Советлары җитәкчеләренең бергә, тату яшәүләренә үрнәк булып торды.

Сугыштан соң басуларда иген игү эше тәртипкә керә башлагач, хуҗалыкларны бераз икмәк белән тәэмин иткәч, ашлыкны дәүләткә тапшыру планы да артты. Безнең район колхозлары икмәкне Арча, Коркачык элеваторларына тапшырырга тиеш иде. Колхоздагы аз-маз атлар белән генә бу эшне башкарып чыгу мөмкин булмаганлыктан ниндидер чаралар табу кирәк булды. Бу эшне тәртипкә салу йөзеннән колхозлардагы келәтләрдә дәүләт икмәген вакытлыча саклап тору чарасы күрелде. Аларга “глубинка келәтләре” дигән исем кушылды. Башта ул келәтләрне зур авылларда гына ачтылар, тора-бара, алар күбәйде, һәр авылга берне ача башладылар. Бу чара колхозларга бераз җиңеллек тудырды. Колхозда хуҗалык эшләрендә генә файдалана торган үгез, сыер җигеп, шулар ярдәмендә ташу мөмкинлеге ачылды. Башта бу хайваннар, аларның холкын белеп бетермәгәнлектән, көтелмәгән күңелсезлекләр чыгарып тордылар. Бервакыт шулай үзебезнең колхоздан сыерлар колоннасын — ашлык төягән олауларны Әтнәгә чыгарып җибәрдек. Әтнәгә барышлый йөкче малайларның игътибарсызлыкларыннан файдаланып, сыерлар берсе артыннан берсе Ашыт елгасына су эчәргә керә башлаганнар. Суга кергән сыерларның олауларындагы ашлыкны көчкә коткарып калдылар. Ярый әле суның тирәнлеге арба өстенә менеп җитәрлек булмаган. Көне буе ашлыкны капчыкларга тутырып, үлчәп, кирәкле кәгазьләрен хәзерләгәнче, сыерлар сусаган булган икән. Бу хәл безгә зур сабак булды, юлга аларны эчертеп чыгарырга һәм елга тирәсеннән үткәндә саграк булырга өйрәтте. Шул мал белән икмәк тапшыру планын үтәргә уңайлык туды.

Шул елларда Арчада автоколонна төзелде. Сугыш чорында Америка ярдәме белән безнең илебезгә бирелгән "Форд Студобекр" автомашиналарын шәһәргә, районнарга тараттылар. Хәзер инде ашлыкны Арчадагы автомашиналар берләшмәсе көче белән ташырга тотындык. Бу эшне урып-җыю эшләре беткәч, кыш айларында башкарырга туры килде. Ул машиналарны йөртү, юлларны кардан чистарту өчен, колхозларга йөкләмәләр бирелде. Ул елларны бер генә колхозда да бульдозер юк, гомумән, трактор белән кар көрәп була дигән төшенчә юк иде. Алар соңгы елларда гына күренә башладылар. Барлык кар көрәү көрәкләр белән башкарылды. Көрәп-чистартып кына бетерәсең, буран чыгып машиналар тагын юлда кала. Кайсы колхоз чистарта торган жирдә туктап кала, шул колхоз юлны кабат чистарта. Авылда көрәк тота ала торган хатын-кызлар кыш буе шул юлларда газап чикте. Бу эш колхозларга

## 1950-60 еллардагы үзгәрешләр

Сугыш афәтеннән котылганнан соң, колхозчыларның тырышып эшләүләренә карамастан, колхозларның хәле авыр килеш кала бирде. Авыл халкының көнкүреше бераз уңайланган кебек булса да, шәһәрдә яшәүчеләр белән чагыштырганда, әле бик түбән иде. Шуның аркасында кешеләрнең авылдан шәһәргә китүе һаман дәвам итте. Колхозның хужалык эшләрен башкарып бетереп булмый башлады. Боларның күбесенә кешеләр житмәү сәбәп булды. Ил буенча колхозларда халыкның аз булуын искә алып, МТСларга күп кенә техника кайтара башладылар. Элеккеге "СТЗ" һәм "Нати" тракторларына алмашка "ДТ-54" тракторлары кайтты. Коммунар комбайннарын "Сталинец-6" комбайннары алыштырды. Аларны исә үзйөрешле комбайннар алыштырды. Техниканың күп кайтуы авылларда кешеләрнең кимүен беразга тоткарлап торды. Комбайннар игенне лабогрейка белән уруны кысрыклап чыгарды. Колхозларга берсеннән-берсе зур, көчле техника кайту аларны файдалану өчен зуррак масштаблы басулар таләп итте. Ниһаять, 1950 елны безнең районда колхозларны эреләндерү башланды. Бу эш шул дәрәжәгә барып житте, безнең күрше Мари республикасының Шиншә колхозына 30 авыл кушылды. Киров өлкәсенең "Кызыл Октябрь" колхозына бөтен бер районның 100 дән артык авылы кушылган. Кызыл Юл районының "Северный" совхозына 17 авыл кушылды. Бу кампания, тора-бара, шундый аяныч төс алды, бөтен бер авылларның бетүенә, авыл халкы таралуга иң зур сәбәпләрнең берсе булды. Колхозларны эреләндерү чире еллар буе дәвам итте. Эреләндерү кампаниясе башланганчы районыбызда 50 дән артык колхоз булса, эреләндерүнең иң соңгы чорында 12 колхоз гына калды. Авылларны күпләп берләштерү буенча райком, райбашкармаларда планнар төзеп, кайсы авылны кайсына кушарга икәнлеген билгеләп чыктылар. Бу кампаниянең иң зур ялгышы авыл халкының фикеренә колак салмау иде. Күп авылларны халыкның үтенеп соравына карамастан, алар теләмәгән авыллар белән берләштерделәр.

Эреләндерелгән колхозлар белән житәкчелек итү өчен тәжрибәле, сәләтле житәкчеләр кирәк булды. Бу очракта шул ук кечкенә колхозларда житәкчелек иткән рәисләр зур колхозларга житәкче итеп сайланды. Аларның күбесе каушап калды. Ул елларда сайланган колхоз рәисләренең 70-80 проценты ике-өч тапкыр алыштырылды. Идарә итү сәләтләре житмәде. Шушы хәлләрне исәпкә алып, республика күләмендә ике-өч еллык, алты айлык курслар ачылды. Курсларның алты айлыкларына эшләп торган рәисләрне жибәрделәр. Ә өч еллыгына яшьләрдән сугыш ачысын татып кайтучыларны тупладылар. Аларга агроном дипломнары бирделәр. Әлеге кадрлар республика колхозларында озак еллар житәкчелек эшендә эшләде.

Төрле юллар белән колхозларны күтәрергә тырышып карасалар да, берсе дә уңай нәтиҗә бирмәде. Сталин үлгәннән соң, портфель бүлү сугышында жиңеп чыккан Никита Сергеевич Хрущев партия Үзәк Комитетының генераль секретаре булгач, югарыда саналган ялгышлыкларга үсәргә тагын да юл ачты. Хрущевның Курск өлкәсендәге туган авылы Калиновка бу

чараларны үткәрүдә үрнәк итеп күрсәтелде. Авылларга, колхозларга генераль планнар төзеттеләр, ул планнарда кайсыдыр авыллар киләчәктә өметле булып исәпләнделәр, кайсылары бетәргә тиеш ди, хөкем ителде. Бетәргә тиешле авылларда бер генә төзелеш тә бармады. Мәктәпләр ябылды, кешеләр үзләренең балаларын өметле дип исәпләгән күрше авылларга йөртеп укытырга мәҗбүр булдылар. Ул авылларда кибетләр дә ябылды. Ләкин мед. пункт, кибет, китапханәләр булмаганда да кешеләр, әле гел болай булмас, тәртип бер керер, дип өметләрен өзмәделәр. Берничә ел шулай азапланып, өмет чаткылары сүнгәч, перспективасыз дигән исем тагылган авыл кешеләре күпләп шәһәрләргә күчеп китте.

Авылларны туздыру мәхшәре өстенә икенче бер мәхшәр килеп чыкты. Республикада районнарны эреләндерү кампаниясе башланды. 1959 елда безнең Әтнә районын Кызыл Юл районы белән берләштерү хакында республика югары оешмаларының күрсәтмәсе килеп төште. Бу вакытта Әтнә райкомының беренче секретаре булып Ибраһимов Мөнәвир эшли иде. Тумышы белән ул Әгерҗе районының Тирсә авылыннан. Моңа кадәр Кайбыч райкомында икенче секретарь булып торган. Мөнәвир Гәрәй улы холкы ягыннан тыйнак, акыллы, үз алдына куйган бурычларны хәл итүгә бик җитди карап эш йөртте. Кадрлар белән аңлашып эшләде. Бер вакытта да, нинди очрак булуга карамастан, тавышын күтәрмәде, кешеләрне кимсетә торган тупас сүзләр әйтеп җикеренмәде. Килеп чыккан кимчелекләрне төзәтергә тиешле кешеләр белән килешеп, әйбәт киңәшләрен бирә торган булды. Кимчелекләрне төзәтергә вакыт бирде, шулай да аларны күздән ычкындырмады. Аннан соң гына ахыргы нәтиҗәгә килә торган иде. Менә шушы кешедән аерылу Әтнә районы коммунистларына җиңел булмады. Ул районнан киткәннән соң Арча райкомына беренче секретарь итеп сайланды.

Ике районны Кызыл Юл һәм Әтнәне берләштерү конференциясе Кенәр авылы культура йортында булды. Анда райкомның беренче секретаре итеп Кызыл Юл районында беренче секретарь булып эшләгән Сафиуллин Хәниф Фатыйх улы сайланды.

Әтнә районы белән Кызыл Юл районы берләшеп яши башлаган чорның үзенчәлекләренә туктапып узасым килә. Бер коллективка икенче коллектив килеп кушылганнан соң гадәттә аңлашылмаучылыклар килеп чыга. Партия конференциясендә мине дә президиум әгъзасы итеп сайлаганнар иде. Урыным "Северный" совхозы директоры Сафин Нәкыйп белән янәшә булып чыкты. Сафин конференциядә чыгыш ясаган кешеләрнең Кенәр ягыннан булганнарын аңлатып барды. Кайсы кайда эшли, нинди рәк кеше, янәсе. Әтнә ягыннан сөйләүчеләрне исә мин аңлаттым.

Әлеге конференциядә Иске Өҗем, Кышлау, Яңа Өҗемнәр берләшкән колхозның рәисе Кашшаповның чыгышы бик тәртипсез булды. Конференциягә барганда, элек Әтнә районында милиция начальнигы булып эшләгән Зәйнуллин дигән кеше боларның машиналарын туктата. Машинаның бортлары махсус кеше йөртү өчен көйләнмәгән, делегатлар машина әрҗәсендә басып барган булганнар. Зәйнуллин болай йөрергә ярамаганлыгын әйтеп боларга кисәтү ясаган. Шоферның правасын алып калып, иртәгә милиция идарәсенә аңлашырга чакырган. Колхоз рәисенә, күрәсең бу бер дә ошамаган. "Милиция начальнигы Әтнәдән килеп, беренче очрашуда ук безне куркытырга уйлады, без алай курка торган егетләр түгел", — диде ул. "Без Кенәр якларын кимсетергә юл куймабыз", — дип тә өстәде.

Берләшеп эшләү дәверендә райком секретаре Сафиуллин да, райбашкарма рәисе Минушев та район белән җитәкчелек иткәндә ике төрле фикер булуга юл куймадылар, гадел эшләделәр. Башта әйткәнемчә, берләшкән район җитәкчеләренең, (Кенәр ягыннан килгәннәрнең) Әтнәдә фатирлары булмады. Алар Кенәрдән килеп йөрделәр. Беренче эшләре Әтнә белән Кенәр арасындагы юлны тәртипкә китерү булды. Бу чорда Әтнәдә культура йорты да салынды. Бу өлкәдә Фатыйх Минушевның хезмәте аеруча зур булды. Аның тырышлыгы белән бер ел эчендә культура йорты төзелеп бетте. Иртән ул Әтнә урамына чыгып баса да, милиция кешесе белән бергәләп, машина

тота. Әтнә урамыннан үтүче машинаның нинди эш белән йөрүен исәпкә алмыйча, Кенәргә кирпеч алып кайтырга җибәрә. Шоферларның праваларын җыеп алып кала. Аларның үзләрен генә җибәрми, колонна ясап, шуның белән үзе идарә итә, яки берәр ярдәмчесенә кушып машиналарга тулы йөк төятә, төзелешкә кайтарып бушатканчы барлап-күзәтеп тора.

Шул ук елларда Әтнә урамына асфальт та җәелде. Фатыйх Әтнә районын яхшы белә иде. Институтта укыганда ук, Бәрәзә колхозына кайтып, практика узды, колхозда агроном вазыйфасын дә үтәде. Бу ике иптәш Әтнә районында җитәкче булып эшләгәндә ике ел рәттән корылык булды. Күрәсең, районның алга бару мөмкинлеге булмавын исәпкә алып булса кирәк, Сафиуллинны секретарьлыктан бушаттылар, республика авыл хуҗалыгы техникасы җитәкчесенең беренче ярдәмчесе итеп Казанга күчерделәр. Киткән вакытта: "Бу эштә минем бәхетем булмады инде, ичмаса, минем урынга килгән кешенең бәхете булсын", — дигән Сафиуллин.

Районнарны үзгәртү буенча бу чорда яңалыклар гел булып торды. Зурайтуберләштерү вакытында күп кенә районнар яшәүдән туктады. Безнең якта Кызыл Юл, Чепья, Чүриле, Дөбьяз районнары, аннары Корноухово, Юдино, Норлат, Подберезье, Кайбыч, Тархан, Тәмте, Буденный, Тельман, Ямаш, Юхмачы, Кузнечиха, Биләр, Шөгер, Тымытык, Матвеевка, Ворошилов, Калинин, Кызыл Йолдыз, Кызыл Армия, Яңа Чишмә, Ширәмәт, Морт, Красный Бор, Тәкәнеш, Столбище, Теләче һәм тагын мин белмәгән берничә район бетте. Шушы берләштерү аркасында район җитәкчеләре хезмәт кешесеннән тагын да ерагайды. Район җитәкчеләре урыннардагы чын хәлне белми башлады. Җитәкчелек итү мәгълүмат кәгазьләрендә булган саннар ярдәмендә генә алып барылды. Районнар зураячагы турында газетләрдә хәбәрләр күренеп торды. Шул чорда Мәскәүдә авыл хуҗалыгы министрлыгы икегә бүленде. Берсе колхозлар, икенчесе совхозлар белән идарә итә торган булды. Безнең республиканың да партия өлкә комитетында авыл хуҗалыгы буенча беренче секретарь булып Табеев, промышленность буенча Князев калды. Авыл хуҗалыгы министрлыгы бетерелде, аның эшен министрлар советы рәисенең беренче ярдәмчесе алып барды. Ә авыл хуҗалыгы министры булып эшләгән Биктимиров янартылып төзелгән зур Минзәлә районына авыл хуҗалыгы идарәсенә җитәкче итеп җибәрелде. Менә шушы чорда авыл хуҗалыгы белән җитәкчелек итүдә аңлашылмаучылык башланды. Республикада авыл хуҗалыгы министрлыгы беткәннән соң аның эшен башкару өчен алты урында авыл хуҗалыгы берләшмәләре барлыкка килде. Аларда җитәкчелек итү өчен республиканың иң сәләтле кешеләрен җибәрделәр. Тора-бара бу алты берәмлекне бүлгәләп, янә берничә авыл хуҗалыгы идарәсе ясадылар. Әле бу чорда районнар шул идарәләргә буйсынган хәлдә яшәүләрен дәвам иттеләр. Безнең район үзенең эшчәнлеге белән Арчада төзелгән зур идарәгә буйсына торган булып калды. Арчада бу идарәгә Балтач, Саба, Кукмара, Мамадыш һәм Биектау районнары да кергән иде. Кукмара, Саба, Мамадыш һәм Биектау икенче берләшмәләргә күчтеләр. Тора-бара, Балтач районы аерылып чыгып, мөстәкыйль район булып яши башлады. Безнең Арча авыл хуҗалыгы идарәсе башлыгы булып Шәрифуллин Лев Равилович дигән кеше эшләде. Зур идарәләрнең җитәкчелек эшенә кадрларны партия өлкә комитеты куя иде. Шушы зур идарәләргә ияләнә төшкәч аларны элеккечә, район идарәсе дип атадылар. Бу очракта Әтнә һәм Балтач районнарын яшәүдән туктатып, Арча районы дип кенә йөртә башладылар. Арча райкомының беренче секретаре итеп Закиров Мөхәммәт Закир улы сайланды. Шулай итеп, 1962 елда Әтнә район булып яшәүдән туктады. Бу чорда янадан-яна җитәкчеләр, колхоз рәисләре белән танышып-белешергә кирәк иде. Әтнә ягында яшәүче колхозларга һәркөнне төрле-төрле район җитәкчеләре килә башлады. Райком, райбашкарма, авыл хуҗалыгы бүлеге хезмәткәрләре: заготзерно, сельхозтехника, май заводы, суд, прокуратура, милиция, банк, саклык кассасы, автомобиль хуҗалыгы кешеләре килеп, колхозларны өйрәнделәр. Арча зур район булгач, аның оешмаларында хезмәткәрләре дә күбәйде. Килүчеләр, колхозларны өйрәнүгә караганда, үзләре өйрәнергә тырыштылар, игътибар таләп иттеләр.

Шулай беркөнне Арча районы авыл хуҗалыгы идарәсенең бер ревизоры безнең колхозга килеп, финанс хәлләрен тикшерде. Аны колхозның кунакханәсенә урнаштырдык. Бер тәүлектән соң колхоз идарәсенә керде дә: "Фәйзи Әхмәтович, сездә теш врачы юкмы?" — дип сорады бу. Мин: "Тешегез авыртамыни?" дидем. Ә ул: "Юк, тешнең кирәге калмады, кичә манный боткалары гына ашадым", — диде. Миңа бик уңайсыз булды. Ул көнне ничектер колхозда ит булмаган. Аңа ак икмәк, майлы боткалар гына ашаткан булганнар. Андый кешеләр белән шактый очрашырга туры килде. Аларның уенда ашау ризыгы гына түгел, күңел күтәрә торган ризыклар — эчемлекләр дә була иде. Безнең колхозда ул елларны андый эшләр бер дә практикада булмады шул. Бу түрәләр колхоз рәисләренең алдан планлаштырылган эшләренә комачаулыйлар иде. Ул чорда райком белән авыл хуҗалыгы идарәсе аңлаша алмыйча яшәделәр.

Районда күп төрле хакимиятләр булу, аңлашылмый торган тупаслык, бер-береңә ихтирамсыз караулар колхоз рәисләренең дә тәртибен үзгәртте. Аларны яңа тәртипләргә ияләшә алмауга китерде. Колхоз рәисләре үз эшләренә бикләнеп, гел үзләренчә генә эшләүгә күчтеләр. Районнарны зурайтып, район күләмендәге җитәкче постларга кешеләрне куеп, колхозларга ярдәм оештырмакчылар, авыл хуҗалыгын алга җибәрмәкчеләр иде. Ләкин ул тормышка ашмады, колхозларда үзгәреш булмады.

Арча ягы колхозларының тимер юл янында булулары исә кешеләргә шәһәргә китеп эшләү өчен мөмкинлек бирде. Шуның аркасында эшкә сәләтле кешеләрнең читкә китүләре аларда иртәрәк башланды. Менә шушы хәл колхозларның бераз йомшаруына китерде. Шушы шартларны исәпкә алып, районда хуҗалык эшләрен тәртипкә оештыру, хуҗалык эшләренең вакытында башкарылуы районның алга китүенә сәбәпче булды. Матур гына эшләп ятканда Балтач ягы авыллары Арча районыннан аерылды. Алар, Арчадан аерылып чыгу белән, зур оешканлык күрсәтеп, авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерүдә зур гына уңышларга ирештеләр. Тора-бара Балтач республика күләмендә әйдәп баручы районга әйләнде. Балтач районында булган үзгәрешләр элеккеге Әтнә районы колхозларында да аерылу хисе уятты. Ул фикернең уянуына нигезле сәбәпләр дә бар иде. Шуларның кайберләре. Авыллар район үзәгеннән ерак. Авыл халкы моңардан бик интекте. Ягулык өчен кирәк булган күмер, утын, төзелеш материалларын станцадан алып кайтырга машиналар җитмәү үзәккә үтте. Әтнә белән Арча арасында автобуслар йөртүне юньләп оештыра алмадылар. Кыш айларында, буранлы вакытларда автобуслар, машиналар атна буе йөри алмады. Шул сәбәпле район оешмаларына йомышы төшкән кешеләр Арчага бара алмыйлар иде. Элекке район үзәге — Әтнәдә —төзелеш бөтенләй туктатылды, халык ихтыяҗын тәэмин итү дә Арча ягы авылларына караганда түбән иде. Бу кешеләрдә борчу тудырды. Бер район булгач Әтнә авылы кешеләренең дә Арча бистәсендәге кебек яшиселәре килде. Арчада төзелеш яхшы гына алга китте. Арча тирәсендә яңа бистәләр күренә башлады. Колхоз җитәкчеләрен җыелышларга барып кайтып юлда көн уздырып йөрүләр дә борчый башлады. Кыш көннәрендә Арчага бару өчен Казан юлыннан Каменка станцасына кадәр барырга, шуннан борылып Арчага таба кире кайтырга туры килә, баруга ике сәгать, кайтуга ике сәгать вакыт уза иде. Менә шул сәбәпләр аркасында элекке Әтнә районына караган авылларның җитәкчеләрендә, әгәр без аерылып, мөстәкыйль район булсак, эш өчен уңайлырак булыр иде дигән фикер уянды. Балтач районы аерылып чыкканнан соң аерылу теләге тагын да көчәйде. Без элеккеге Әтнә районы колхозларының җитәкчеләре исеменнән партиянең Татарстан өлкә комитетына һәм Министрлар советына Әтнә районын мөстәкыйль район итүне сорап хат юлладык. Колхоз җитәкчеләре Әтнәдә яшәп килгән банк бинасында ул хатны язып, кул куйдык. Ләкин аңа төпле җавап ала алмадык. Мин Арча райкомының беренче секретаре Җиһаншиннан бу эшне яклавын үтендем. Ул да миңа яклаячагын әйтмәде. "Элеккеге Әтнә районы Кенәр белән бергә кушылып яшәгән чорда, бер район булып Арчага кушылдылар, әгәр дә шул зурлыкта Арчадан китсәләр, Арча бик фәкыйрь

булып калачак ич", — диде. Бу эш шуның белән тәмамланды. Шактый вакыт узгач Казанда партия өлкә комитетының зур бер җыелышы булды. Анда безнең район колхозларыннан да делегатлар катнашты. Шул җыелышта "Социалистик Татарстан" газете редакторы Хамматов Шәмси чыгыш ясады. Безнең бүлекнең соралап язган хатыбызны искә алды. Хатта Әтнә районының фәкать татар авылларыннан гына торачагы әйтелгән иде. "Татар халкының гореф-гадәтләрен саклауда республикабызда кечкенә генә бер нокта булыр иде", — дип язган идек. Хамматов шул сүзләрдән сәяси нәтиҗәләр чыгарып, милләтләрне бер-берсеннән аерып политик хата ясаганнар, бу хатыгыздан пантюркистлар исе килә, диде. Ул хатта Габдулла Тукай безнең Кушлавыч авылында туган дигән җире дә бар иде. Ул да ярамаган сүз булып чыкты. Тукай исеме белән сәүдә итәргә җыеналар, гомумән, ул хаттан милләтчелек исе килеп тора, диде. Андый карашларга безнең партия тиешле бәясен бирергә тиеш, дип сүзен бетерде. Безгә бер дә күңелле булмады. Шулай итеп, безнең мөстәкыйль яшәү теләгебез туктатылды. Балтачларның, аерым район булгач, алга китүләренә сокланып яшәвебез, безне һаман да борчып торды. Әтнә авылы, район беткәннән соң, район бар вакыттагы хезмәт күрсәтү тармакларын саклый алмады. Район бетү белән төзелеш тукталды. Район оешмаларында эшләүче кешеләр төрлесе төрле якка таралдылар. Алар артыннан шул оешмаларга хезмәт күрсәтүчеләр һәм колхозда эшлисе килмәгән кешеләр дә авылны ташлап китте. Авылда буш йортлар күбәйде, яналарын төзү кимеде. Гомумән, Әтнә авылы үз әйләнәсендәге авылларга караганда төзелеш буенча артта кала башлады. Авыл күзгә күренеп сирәкләнде. Ник Әтнә шулай тиз биреште соң? Әтнәдә кешене кайгырту җитмәүне беренче сәбәп итеп куярга кирәктер. Кешеләргә яктылык һәм җылылык бирә торган электр кертүне озак башкардылар. Аның өзлексез эшләвен тәэмин итә алмадылар. Соңгы вакытларга кадәр электр уты еш өзелеп, кешеләрдә ризасызлык тудырды. Су чыганакларын, сууткәргеч торбаларны, колонкаларны карау җитмәде. Ә элекке Кызыл Юл районының үзәге булган Яңа Кенәр яхшы сакланды. Алар район вакытында халыкка хезмәт күрсәтә торган оешмаларны саклап кала алдылар, үзләрендә кирпеч заводы төзеп, кирпеч белән байтак төзелешне тәэмин иттеләр. Кенәрдәге промкомбинатны да япмадылар, киресенчә, үстерделәр. Агачтан өй буралары, такта-токта, рәшәткәлекләр ясап саттылар. Бу чаралар шәхси хуҗалыкларның каралтыларын төзергә уңайлык тудырды. Төрле әртилләр эшләрен дәвам итте. Шуның өстенә, бәрәңге киптерү заводын эшләттеләр, азык комбинатын саклап калдылар. Үзләренең биләмәләрендә төрле җиләк-җимеш агачлары үстереп, вареньелар кайнатып, гөмбәләр җыеп тозлап, төрле тәмләткечләр җитештерделәр. Шундый юллар белән, район беткәннән соң, аның оешмаларыннан бушаган кешеләрне эш белән тәэмин итә алдылар. Кешеләр таралмады, туган авылларына булган мәхәббәтләре сүрелмәде. Әтнәләр шикелле төшенкелеккә бирелмәделәр.

Бу буталчык елларда алар Яңа Кенәр авылын саклап калу гына түгел, аны үстерүгә дә ирештеләр. Хәзерге көндә дә ул үз матурлыгын саклый. Ә Әтнәдә мондый бердәмлек булмады. Әтнәне саклап калу өчен тырышучы ихлас җитәкчеләр юк иде. Һәммәсе үзләре эшләгән оешмаларына бикләнеп, гомуми эшкә зыян китерделәр. Әлеге оешма җитәкчеләре алмашып торды, яңалары игътибарсыз булды. Шуның аркасында халыкның көнкүренешендә дә, төзелеш эшләрендә дә Кенәр белән чагыштырганда аерма бик зур иде.

Арча районы белән кушылып яшәү дәверендә утыз ел буена бер генә километр да асфальт юл салынмады. Бу юлсызлык Әтнә ягы колхозларын бик азаплады. Асфальт юлларның төзелә алмавын республика күләмендә зур төзелешләр баруга сылтау итеп килделәр. Янәсе, төзелеш материаллары шул төзелешләргә китә. Арча да, үзендә асфальт заводы булуга карамастан, яңа юллар төзүгә керешә алмады. Моннан күп еллар элек Тукай бәйрәме уңае белән Арчадан Тукай-Кырлай юлы асфальтланган иде. Бу эш республика ярдәме һәм көче белән башкарылды. Ә райондагы асфальт заводы ел саен шул юлның ватылган урыннарын ямаудан узмады. Җәй көне аз гына селкенсә,

күзге салкыннар җитү белән эш туктатыла иде. Соңга табарак Арчада еш кына республика, хәтта Россия күләмендәге семинарлар үткәрелде. Шул уңайдан семинарлар булган җирләрне асфальтлау хисабына юл төзү планы үтәлеп барды. Бер елда сельхозтехника, икенче елны сельхозхимия, төзелеш оешмалары, заготзерно, май заводы, шул семинарга узып китә торган Арча урамнары шикелле урыннар гына асфальтланды. Аннан, аерым колхозларда семинарлар үткәрелсә, шунда асфальт салынды. Без, Әтнә ягының колхоз җитәкчеләре, депутатлар сайланган вакытта наказлар да биреп карадык, нәтиҗәсе булмады. Райком секретарьларыннан (берләшкән елның башыннан) Закиров, Җиһаншин, Зәйнуллин, Каюмов эшләгән чорда юл мәсьәләсе буенча Әтнә ягына игътибар булмады. Әтнә районында райкомның беренче секретаре булып эшләгән, Арчага кушылган көннән озак еллар Арча райбашкармасы рәисе булып торган Борһановның да бу эшкә игътибары җитмәде. Юл газаплары кешеләрне гел борчып торды. Әтнәдән чыккач гел начар юлдан бара идек. Биектау районы чигенә җиткәч кенә асфальт юл башланып китә. Биектау аны без Арчага кушылган елларда ук төзеде. Соңга табарак Биектау җитәкчеләре колхоз үзәкләренә дә асфальт юл белән керә башладылар. Ә Мари республикасының безнең күрше Морка һәм Бәрәңге районнарында барлык колхозлар арасында да асфальт юллар салынды. Безнең Әтнә ягы кешеләренә шуларны күреп, кызыгып яшәү генә насыйп булды. Юлларны төзү буенча элекке Әтнә районы авыллары кулдан килгәнне азмы-күпме эшләделәр. Мәсәлән, Күнгәрдән Әтнәгә кадәр дамба күтәреп, таш җәеп, тимер-бетон күперләр төзеп чыктык. Шундый ук күләмдәге эшне Күәмнән Әтнәгә кадәр "Игенче" колхозы да эшләде. Кышлау, Яңа Шашы колхозлары да, Комыргуҗа авылы ("Шахтер" колхозы) Биектау районының Өмбе авылыннан Әтнәгә кадәр юл күтәреп, тыш җәеп чыкты. Ләкин Әтнә турында андый мисалны китереп булмый. Күрше тирәләрдә шундый төзелеш алып барган вакытта Әтнә авыл Советы, колхоз җитәкчеләре бу эшкә игътибарлы булмадылар. Хәтта авыл уртасыннан ага торган инеш күперен салу мәсьәләсендә дә юллар төзү оешмасы белән колхоз идарәсе ызгышып йөрде. Янәсе, аны кем салырга тиеш? Азак килеп, күпердән инде тәмам йөри алмас булгач кына, район көче белән, күрше колхозларның юл төзү планын үтәү хисабына күпер салынды. Әтнә колхозының клуб, мәктәп, балалар бакчаларын төзүгә һәм ремонтлауга да игътибары җитмәде. Бер мисал китереп үтәм. Әтнә колхозы хастаханәгә фатирлар житкерү буенча эш башкарды: бараксыман биналар салып бирде һәм ул эшне башкарганы өчен, хастаханәнең ике катлы бик яхшы бер бинасын, эш хакы итеп, үзенә алды. Ул бина соңгы елларга кадәр Әтнә колхозы фермасында терлекчеләр йорты булып хезмәт итте.

Әтнәдә төзелеш эшенең начар булуында Арча район җитәкчеләрен генә гаепләү дөрес булмас иде. Халык телендә: "Еламаган балага имчәк бирмиләр", — дигән әйтем нәкъ менә Әтнәгә туры килә. Төзү артыннан йөрмәсәң, беркем дә сиңа китереп бирми ләбаса!

*Дәвамы киләсе санда*

# ШИГЪРИЯТ



## Эльмира Шәрифуллина

### ТОЛЛАР ҖАНЫ

* * *

**Үз ишләрем әзлим кешелектән, —**
**Тол хатыннар — минем тиңнәрем,**
**Барчагызның кайгыларын җыйсам,**
**Күтәрәлер микән иңнәрем?**

**Кырык бердә ятим калган җаннар,**
**Ни хәл итеп сезгә булышыйм?**
**Терелтер лә идем ирегезне —**
**Дәва булса әгәр сулышым.**

**Кырык бердә,**
**Кырык биштә тол калган...**
**Сиксән биштә калды бәгъзебез.**
**Еласак та үкенеп еламыйбыз,**
**Ир кочагы күрде тәнебез.**

**Кимсенүдән сүнә нурлы күзләр,**
**Күпсенүне — авыр күтәрү.**
**Көне ярый, көне кеше белән,**
**Кыен кичне, төнне үткәрү.**

**Киңәшләшер һәм серләшер сүзләр**
**Хәл ителә ялгыз баш белән.**
**Шуңа микән толлар еш ялгыша,**
**Җавап ала ашка — таш белән.**

**Шуңа микән толлар бакчасында**
**Күсәк төшә, салкын боз ява.**
**Шуңа микән толлар җилкәсенә**
**Кеше күтәрәлмәс йөк ава.**

**Шуңа микән нахак бәла белән**
**Кыерсыткач, җаны таплана.**

Мәкерле сүз телә бәгырьләрне,
Сүз ярасы озак саклана.

Толлар елый башын бәрә-бәрә,
Үз-үзенә урын табалмый.
Аһ, яшәсә кеше —
Бер-берсенә
Утлы инә булып кадалмый...

Эчтән сыза,
Эчтән елый алар —
Дөрес аңлашылмас кемгәдер.
Тол хатынны тол хатыннар талый —
Хурлыклары үзәк өзәдер...

Бер Аллага сыгына ялгыз кеше
Кыен килсә төрле тарафтан.
Бөек Акыл һәрбер җан иясен
Так итмәгән,
Парлы яраткан.

Җирдә түгел,
Күктә матур була
Пар-пар булып очкан торналар.
... Толлар җаны
Хыял ирке белән
Күк катына бик еш юл ала...

## Ай сукмагы буйлап...

Су өстенә яткан ай сукмагы —
Асылмалы күпер, ныгытма.
Сөю назы тулган йөрәгемне
Юлларыңнан алып ыргытма.

Су өсләтеп, ай сукмагы буйлап,
Ал җилкәннәр тартып корабка,
Акчарлаклар булып мәхәббәтем
Сиңа оча, синең тарафка.

Су өсләтеп, ай сукмагы булып,
Колачларым җәеп җилләргә,
Очам, йөзәм,
Синең белән миннән,
Һәм Сөюдән торган илләргә.

## Былбыл булыр өчен

Сайрый былбыл, сайрый былбыл,
Өзә генә үзәкне.
Йә, кайсыгыз былбыл җырын,
Былбыл юлын күзәтте?

Җыр-моңнарсыз тора алмыйм,
Җырга гашыйк хәзер мин:
Былбыл булып сайрар өчен,
Кош булырга әзермен!

## Тагын кабынам

Кара кайгыларның охшашлыгы,
Хисле күңелләрнең йомшаклыгы
Якынайтты, ахры, җаннарны.
Авыр икән җую җир йөзеннән,
Авыр икән җую ил күзеннән
Газиз бала, хәләл ярларны.

Кайчагында барып яннарына,
Йолдыз булып моңсу таңнарына
Нур иңдермәк, сөймәк буламын.
Мин үзем дә ярты кеше бугай,
Мин үзем дә парын җуйган тургай,
Елмаям да тагын суламын.

Якынлыкны күңел сизгән кебек,
Бер-береңне күптән белгән кебек
Сагынам да сине сагынам.
Шәм-шәмдәлнең кыска гомередәй,
Учакларның кузлы күмередәй
Янып сүнәм, тагын кабынам.

## Сары коелган

Әле җәйнең башы гына
Сары коелган талга.
Сөйгән яры су буйлатып
Агып киткәнме "салда"?

Нинди сагыш, кайгы дисәм,
Күкрәп үскән шул талда, —
Сабышмассың сарыларга... —
Җәйләрдә ялгыз кал да...

*Tөrek xikәjәlәre*

## Өmәr Sәjfetdin

*(1864 — 1920)*

# BALACAQ YKENECE

Bez — balalar jortъbъznъn arqъ başъnda tәrle ujъnnar ujnъjbъz. Astan, kөmeş tallar arasъnnan aqъp jatucъ keckenә cişmәnen celterәwe bezgә işetelep tora. Işegaldъn, өj tirәsen aq şәm kebek cәcәklәr atucъ kaştan aqaclarъ colqap alqan. Şundъj maturlъk ecendә bulsaq ta, şunda jөgerep ujnasaq ta, bezgә kynelsez, cөnki әniebez Istanbulda. Şuna kyrә minnәn ber jәşkә kece enem Xәsәn belәn ikәylәşep Dadaruxnъn janъnnan kitmibez, ana iәrep jөribez. Dadarux — ber qart keşe, әtinen at qaraucъsъ. Irtәdәn kickә qәdәr anъn tirәsendә. In jaratqan xajwanъbъz — atlar. Dadarux belәn bergә, alarnъ su ecerergә alъp tөşәbez, sъrtlarъna atlanabъz. Monъn өcen bezgә syz әjtyce juq. Xәsәn kecerәk bulqanqa, Dadarux anъ aldъna utъrta. Dөresen genә әjtkәndә, bez Dadaruxqa bulъşcъ da idek әle. Atlarqa solъ salabъz, jәslelәrenә pecәn tutъrabъz, tireslәrne cъqarъşabъz. Bu eşlәr bezgә ujъnqa qaraqanda da qъzъqlъraq tojъla, ә in qъzъqъ — atnъ tarau, cistartu! Busъ bezgә qәçәjep ber eş bulъp kyrenә. Dadarux qulъna wak teşle qъrqъc ala da, şъtъr-şъtъr itep at өstendә jөrtә başlъj, atnъn bөten iәrgәn cyplәre, jabaqalarъ qъrъlъp, taralъp tөşә, rәxәtlәnep, mujъnъn suzъp tora, bөten өste jalъk-jъlъk itep jaltъrъj başlъj. Min tyzep-tyzep toram da Dadaruxtan:

— Min dә-ә... — dip jalъna başlъjm.

Şunnan son Dadarux mine atqa atlandъra da qulъma qъrqъcnъ birә:

— Әjdә alajsa, cistart!

Şul timer qъrqъc-taraqnъ atnъn arqasъna ъşqъj başlъjm, әmma min Dadarux kebek, şъ-tъr, şъ-tъr itkәn awazlar cъqara almъjm.

— Qojrъqъ selkenәme? — dip sorъjm yzem.

— Selkenә... — digәn bula Dadarux.

— Qaja, min dә qarъjm әle, — dim. Atnъn qojrъqъn yrelep qaramakcъ bulam, lәkin kypme yrelsәm dә, kyrә almъjm, art sanъ biek — tomalъj. Taraqanda rәxәt bulsa, at qojrъqъn selkә, ә min taraqanda — juq ikәn...

Irtәgesen bez taqъn atlar janъnda. Dadarux tarъj. Min dә qъsъlam:

— Dadarux, min dә tarъjm әle?

— Bulmas.

— Nigә?

— Başta beraz ys әle.

— Ni qәdәr?

— Bujъn at bieklege bulqancъ.

Ix, jalqъz yzem genә cistarta alsam!.. Bujъm atnъn qorsaq astъna qъna çitә şul. Dadarux menә atlarnъn bojъrucъsъ, icmasam! Ul cistartqanda, rәxәt betmәsen ide, digәndәj, ber lәzzәt belәn toralar, bөtenlәj ojъp kitkәnnәren Dadarux: "Һәjt!" — diep, sъrtъna ber şapъldatъp ujata da ikencesenә kycә.

Berkənne min əjdə jalƣьz ƣьna qaldьm. Xəsən belən Dadarux ineş bujьna təşep kittelər. Min, yzem genə cьƣьp, at əsten cistartьp qararƣa buldьm. Kьrƣьcnь ezlim. Tabьp bulmьj. Işegaldьnda Dadaruxnьŋ tərəzəsez ber keckenə əje bar ide. Şunda kittem. Kiştələrdən qarьjm — juq. Iərlər arasьnnan ezlim — tabьlmьj. Juq ta juq, juq ta juq. Urьnь astьnda ber jəşel sandьƣь bar, şunnan qararƣamь əllə?.. Anь tartьp cьƣarьp actьm. Səjenecemnən qьcqьrьp çibərə jazdьm. Monnan ber atna elek əniemneŋ aŋa dip alьp qajtqan byləklər arasьnda jaltьrap jatqan ərjaŋa qьrƣьc! Anь kulьma alьp, Tufan digən atьbьz janьna octьm. Qorsaq astьn ьşqьj başladьm. Ber də ise kitmi.

— Əllə awьrtamь? — dim.

Atьm borьlmьj da, qaramьj da. Annan soŋ kəmeş kebek jaltьrap torƣan qьrƣьcnьŋ teşlərenə kyzem təşte. Bik ytken, oclьlar. Monьŋ teşləre awьrttьra torƣandьr şul, dip qьrƣьcnь taşqa ьşqьj başladьm, jənəse, ytkerlege kimesen. Şunnan soŋ taƣьn da atqa ьşqьp qarьjm, rəxət cikkənlege kyrenmi. Acuьm cьktь. Kьrƣьc ƣəjeple. Un-unbiş adьmda ƣьna celterəgən cişmə janьna jəgerdem. Kьrƣьcnь şundaƣь taş jalaqqa saldьm da ajaq belən taptьj başladьm. Kьrƣьc sьndь, watьldь həm jalaq təbendə qaldь...

Ətiemneŋ hər irtədə işegallarьn qarap, andaƣь nərsələrne barlap cьgu ƣədəte bar. Tegesen qarьj, monьsьn... Cişmə janьna da tuqtala... Həm jalaq təbendə jaltьrap jatqan qьrƣьc kisəkləren kyrgəc, Dadaruxqa qьcqьra:

— Kil əle!

Min də yzem genə işegaldьnda idem, Xəsən xezmətcebez Pərwin belən əjdə qalƣan ide. Qotьm botьma təşte. Ni bulьr dip, kətep toram. Bilgele, xəldən xəbərdar bulmaƣan Dadarux aptьrap qaldь, kem sьndьrƣanьn belmim, dide. Ətiemneŋ kyzləre miŋa təşte, sinme, dip soraƣancь uq:

— Xəsən... — didem.

— Xəsənme?

— Əje, ul şul. Kicə Dadarux joqlaƣanda qьrƣьcnь aldь da jalaknьŋ təbendə taptadь...

— Nişləp Dadaruxqa əjtmədeŋ?

— Joqlьj ide...

— Caqьr Xəsənne!

Keckenə qapqadan kerep, əjgə taba jəgerdem. Bicara Xəsən berni belmi ide. Əti caqьra digəc, minem arttan jəgerde. Ətiemneŋ acuь nьq cьqqan ide. Ber qaraşьnnan jərəgebez qubarlьq ide. Xəsəngə əjtte:

— Jalƣan səjləsəŋ, suqtьrьrmьn, — dide.

— Səjləməm...

— Jaxşь, alajsa əjt, bu qьrƣьcnь kem sьndьrьp attь?

— Min tygel...

— Turьsьn əjt, timəm, jalƣanlasaŋ, nacar bulьr, — dide ətiebez.

Xəsən kənbaƣьştaj sarь cəcle başьn selekte. Ətiebez, ah, ojatsьz jalƣancь, dip, ərle-birle jərende, annarь Xəsən janьna tuqtap, jaŋaƣьna suƣьp çibərde.

— Ilt monь əjgə! Berqaja cьkmasьn, Pərwin belən utьrsьn! — digən bojьrьqnь birde. Dadarux jьlaƣan tuƣanьmnь kytərep aldь da əjgə taba kitte.

Şunnan soŋ min yzem genə ujnьj torƣan buldьm. Xəsən əjdə totqьnlьqta ide. Əniem qajtqac ta anь ƣafu itməde, forsat cьqqan sajьn, əj, aldaqcь, diə ide. Ə Xəsən, jaŋaƣьna suƣu xaləte isenə təşte isə, ilerep jьlьj, kəckə genə tuqtata idek. Bicara əniem, minem şundьj ələkce ikənlegemne başьna kiterə almьj ide, kytəseŋ. Qartajьp betkən Dadarux qьrƣьcnь atlardan taptattьmь ikən əllə, dip tə şiklənə ide. Ul jьlnь əniem çəj kəne jənədən Istanbulƣa kitte. Bez taƣьn jalƣьz qaldьk. Xəsəngə uramƣa cьƣarƣa əle haman da rəxsət juq ide. Kicləren ul minnən atlar turьnda, tajlarnьŋ ysyləre turьnda soraşa. Ə kənnərdən berkənne ul

xastalandь. Bistәgә at çibәrdelәr. Tabib kilep qaradь da: "Difterijә", — dide.

... Mәxәllәdәn bezgә xatьn-qьzlar kerep-сьҕьр jәri başladьlar. Alar jort qoşlarь calьp kilәlәr dә şular belәn Xәsәnne imlilәr. Әtiem qurkuҕa qaldь, Xәsәnnenꞑ jataҕь janьnnan kitmi dә. Dadarux baltasь suҕa tәşkәn keşe kebek jәri, Pәrwin jьlьj da jьlьj. Min:

— Nik jьlьjsьnꞑ? — dim.

— Qәrdәşenꞑ xasta.

— Ul terelәcәk.

— Terelmәjәcәk. Qәrdәşenꞑ ylәcәk.

— Ylәcәkme?!

Inde xәzer min dә qьcqьrьp jьlьj başladьm. Xәsәn awьrҕannan birle Pәrwin bylmәsendә joqlьj idem. Ul kicne kyzemә joqь kermәde. Kyz aldьmda Xәsәn. Qarşьmda minꞑa qarap: "Әlәkce! Әlәkce!" — dip, jьlьj sьman.

Pәrwinne ujattьm.

— Min Xәsәn bylmәsenә kitәm, — didem.

— Nigә?

— Әtiemә әjtәse syzem bar. Tege waqьtta qьrҕьcnь min sьndьrьp taşlaҕan idem bit. Şunь sәjlәp birәm, — didem.

— Nindi qьrҕьc?

— Tege waqьttaҕь inde... Şunьꞑ ecen әtiemnәn Xәsәngә elәkte...

Syzemne sәjlәp beterә almadьm, mine sulqьldau budь. Jьlьj–jьlьj Pәrwingә anꞑlattьm.

— Xәzer ҕәjebemne tanьsam, bәlki Xәsәn mine ҕafu itәr...

— Irtәgә sәjlәrsenꞑ.

— Juq, xәzer...

— Xәzer әtienꞑ joqlьj, Xәsәn dә joqlьj. Irtәgә irtә belәn әjtersenꞑ. Xәsәnne qocaklarsьnꞑ, ybәrsenꞑ, ul sine ҕafu itәr.

— Jarar alajsa...

— Әjdә, joqla!

Irtәngә caklь kyzem jomьlmadь. Kyk jәze aҕara başlau belәn Pәrwinne ujattьm. Tordьq. Min ecemdәge ҕazaptan buşanьr ecen aşьҕam. Ja Xoda! Şul tәnne totqьn qәrdәşem ylgәn: koridorda Dadarux belәn mәxәllә imamь jьlap toralar. Әtiemnenꞑ bylmәdәn сьqqanьn kәtәlәr ide...

## Nәçdәt Әkiçi

*(1954)*

## QARAMUQ*

Qaramuqnьꞑ gәnaһ- ҕәjeplәre barlьҕьn moꞑa qәdәr dә balalarьm әjtkәnnәr ide inde. "Juq la, bulmas la, arttьrasьz", diә, iҕtibar birmәdem. Әmma etnenꞑ qьnꞑҕьr eşlәre xaqьnda xatьnьm da әjtte. "Yz kyzlәrem belәn kyrdem, byrәnәlәr janьnda jomьrqa qabьklarь jalap tora ide", — dide.

Bu jaman xәbәr çanьma qort bulьp tәşte, ike qaşьm arasьna burazna bulьp suzьldь.

---

*Bu xikәjә Әmәr Sәjfetdin isemendәge xikәjәlәr jarьşьnda ikence urьnnь alҕan.

— Jalɣьş kyrgənsezder, xata səjlisezder. Sez nərsə, ul bit inglizlərnen̡ asьl nəselle au ete! Bulmaɣannь! Nişləp şunьn̡ işe waq- təjək belən yzenen̡ danьn satьp torsьn, — dim.

— Inglizme- minglizme, nəfesen tьja almьj ul eten̡, — di əniem. Bətenləj jərəgemə jara jasadь. Tik nişlisen̡, əniem bulmaɣannь səjləmi inde ul. Minem tuɣrь Qaramuɣьm! Nərsə buldь sin̡a?..

Şunnan ozaqlamьj əniem janɣan jərəgemə taɣьn ut əstəde:

— Tawьq ketəklegennən cьqtь bu kəfiren̡! Teləsən̡ nişlət ul nəstəkəjen̡ne! Yzen̡ qara ənə, ajaqlarьna qədər jomьrqa qabьɣь jəbeşkən.

Təmam aptьrauda qaldьm. Minem xьjənətsez au etem! Tuɣrьlьqlь dustьm, ni buldь sin̡a?.. Ə bez, jomьrqalarnьn̡ juɣaluьn uram malajlarь eşe genəder, dip, yzebez gənaнlь bulɣanbьz. Jə Alla, nişlərgə? Minem bolaj acьrɣalanuьmnьn̡ səbəbe — mon̡a qədər şundьj qьnɣьr eşlərne belməydəder, bəlki? Belməssen̡ et xalqьn... Juq, juq, Qaramuqtan andьj eş bulmas! Uɣrьlьq julьna basmas ul...

Işegaldьna cьqtьm.

— Qaramuq! — dip caqьrdьm.

Qolaqlarь çin̡elcə genə selkenep qujdь. Menə xajvan digen, kyn̡elemdə nilər barьn tawьşьmnan uq an̡ladь — işetməmeşkə salьşьp, minem jaqqa qaramadь. Şakal ɣəmələn qьluь kyz qabaklarьn jьş-jьş acьp jabuьnnan, astan ɣьna min̡a qarap aluьnnan, sizeler-sizelməs kenə qojrьɣьnьn̡ selkenyennən kyrenep, xətərnen̡ barlьɣь an̡laşьldь.

— Qaramuq! — didem min, qatьraq tawьş belən. Etnen̡ qolaqlarь ləpşerdek kytərelde, kyzləre uttaj jana. Ul qara borьnьn kykkə cəjep, neckə tawьş belən cinaɣandaj ulap aldь. Annan əllə nindi ьşanьcsьzraq tawьş belən ərep qujdь. Syzləremne teş arasьnnan qьsьp cьɣardьm.

— Janьma kil! — didem. Qarьşmьjca kilde. Kilgəc, salpь qolaqlarьn selekkələp qujdь. Annan art ajaɣьnьn̡ un̡ь belən qolaq artьn qaşьp aldь. Şunnan son̡ aculь qiəfəttə tənendəge jabьşqan nərsələrne qьrt-qьrt teşləp əzgəli başladь. Jənəse, jomьrqa urlaudan başqa da kəsəfətleklər bar bit əle dənjada! "Ɣəeben belə, xəjləkər" , — didem ecemnən. Нərwaqьt, tawьşьmnь işeter-işetməs borьn, janьma cabьp kilgən, şajan baladaj janьmda zьr-zьr əjlənep ujnaɣan etem, bygen arьp audan qajtqan sьman tizrək ьcqьnu jaɣьn qarьj ide. Zur awьzьn acьp, ece poşqan qiəfəttə ozaq itep isnəde, annan borьnьn çirgə tərtep, tirəmdə əjləngələde. Min anьn̡ kyzlərenə qaramakcь bulam, нaman başьn kytərmi. Annan son̡, niнajət, şəməxə kyzləren kytərep, minem ujlarnь belergə tьrьşqandaj, tekələp-tekələp qarap tora başladь. Min çirdəge taşqa utьrdьm, etem minem ike tezemə başьn qujьp, tirən-awьr sulьj başladь.

— Qaraq sin, — didem min mon̡a, — tor, nərsə kətep torasьn̡, ɣafu itərlərme dip qajɣьr, icmasa.

Xakim qarşьndaɣь qurqaklьq belən ajaɣьna bastь. Berni an̡lamaɣan qiəfəttə (bəlki qurqudan) art ajaɣьn kytərep, çirne "cəcəkli" başladь. Ə min isə başьnnan da sьpьrmadьm, tamaq astьn da qьtьqlamadьm. Şunnan son̡ ul aptьraɣannan çirgə jatьp aunьj — təgəri başladь.

— Tor, tor! Jəzen̡ qara buldьn̡ əle sin, — dim.

Tordь.

— Kyrsət alɣь təpilərenne!

Ike ajaɣьn da, tərtiple uqucь kebek, tiz-tiz uclarьma qujdь. Minem dulqьnlanuьmnь yzenen̡ şundьj dyrt ajaqlь dustь bulɣan keşe genə an̡lar. Əmma də jəzemə barьber şatlьq əsəre cьɣarmadьm. Əle tikşerəse bar bit! Çenteklәp tьrnaqlarьn, tьrnaq aralarьn, jonnarьn qaradьm. Nik ber jomьrqa sarьsь, nik ber

qabьǥь bulsьn...

— Awъzьnь ac, — didem. — Jalama mine, jalama. Berər ezen tapsam, birəm kirəgenne.

Awъzьn acarǥa teləməde. Qulьm belən qajьrьp actьrdьm. Awъzьnda da juq ide. Şaqtьj dorfa itep etep çibərdem. Minem xalətne aŋladь bulsa kirək, citkərək kitte də, kyzləren çemeldətep, jənə mine kyzətə başladь. Min iǥtibar itməgəngə salьştьm. Şunnan soŋ yz urьnьna kitep jattь.

Bernicə kennən soŋ ketəklektə jənədən jomьrqalar juǥala, ə ajaq astьnda jomьrqa qabьklarь aunap jata başladь. Əgər də uǥrь — Qaramuq bulsa, minem anь ərləylərem ike tien — ber aqca digən syz. Bu turьda kemgə səjləsəm də, qьjna, tajaq belən awъzьn təj, didelər.

Başьmnь uclarьma saldьm da utьram. Çanьm yrsələnə. Xatьnьmnьŋ, ul eteŋ, dip bitərləylərе, əniemneŋ zarlanularь, jomьrqalarnьŋ ələdən-əle juqqa cьguь həm şuŋa Qaramuqnьŋ qatьşь bulu mine tetrəndərə. Menə siŋa kirək bulsa, namuslь au ete! Juq, bolaj dəwam itə almas bu xəl.

Qulьma peşe cьbьq aldьm. Belsəgez ikən sez, aucь ecen yzeneŋ au eten suqtьrmaq nindi ǥazap, nindi awьr eş ikənlegen! Əstəwenə barь tik şebhə, faraz nigezendə genə. Əgər də ul ǥəjeple bulmasa? Etem ərekmən jafraqlarь qədər qolaqlarьna başьn qujǥan da jata, şundьj jabьq, qьzǥanьc. Qulьmdaǥь cьbьqnь kyrgən balalarьm da əle miŋa, əle qulьmdaǥь cьbьqqa qarьjlar. Əmma nişliseŋ, waqьtьnda qьzьn təjməgən, tezen təjər, dime? Ber bəla ikencesen səjrər, digən syz də bar. Qaramuq urьnьnda ber uram ete bulsa ikən əle, bu bit nəselle au ete, şulaj tybən təşərgə jarьjmь aŋarǥa?!

Qulьmda peşe cьbьq, Qaramuqnь janьma caqьrdьm. Yzem ectən, kilməsen, qacsьn ide dip telim. Kilde, art ajaqlarьna utьrdь. Jьlt-jьlt kilgən soraulь kyzlərе mində. Arabьzda salqьnlьq. Şulaj nicə minut ytkənder, belmim... Suǥarǥa qulьm barmadь. Berazdan başьma ber fiker kilde.

- Aldьna jomьrqa qujьǥьz, — dip bojьrdьm. Qujdьlar. Juq, aşamьj, isnəp qaradь da tanawьn citkə bordь. Miŋa da kytərelep qaramadь. Soŋьnnan ojasь janьna ike kən rəttən qujǥan jomьrqalarǥa da ise kitməde. Ni bu? Jomьrqa urlap aşaucь Qaramuq tygelme soŋ əllə?

Əmma bernicə kennən soŋ ojadan jomьrqalar taǥьn juǥala başladь.

Nihajət, şulqədər minem başьmnь əjləndergən məsələ, berkenne auǥa barǥac, cişelde. Qьr yrdəgenə bardьq. Qaramuq yz eşen bik tьrьşьp, bik pextə başqardь. Min atqan, ul alьp kilep birgən yrdəklərdən qarcьǥьm şaktьj qabardь. Ikebezneŋ də kəeflər şəp!..

Qaramuq nişləpter soŋǥь kityennən qajtmьj da qajtmьj. Is kitməle, ul hərber atьlǥan yrdəkne iŋ kybe biş minutta jalt itep alьp kilə ide. Inde jartь səǥətləp waqьt uzdь, ə ul juq ta juq. Endəşep qarьjm, tawъşьma çawap birmi. Qaj çəhənnəmenə olaqtь bu et? Acuьm kilep, ezli başladьm. Batqaqlьq-sazlьq qalmadь — juq. hawa da bozьlьrǥa tora, ofьqtan qara bolьtlar aǥьla, xəjerlegə bulsьn... Berazdan şakal cinaǥan kebek tawъşlar işetelə başladь. Өzek-өzek işetelə də tuqtьj. Mьltьǥьmnь alǥa qaratьp, əkren genə kittem. Minnən unbiş-jegerme adьmda, qujь ylən arasьnda ber qojrьq borǥalana-sьrǥalana. Torǥanь şul — Qaramuq qojrьǥь bu! Başь ylən arasьnda, yze ьrьldьj-ьrьldьj nider jalmana. Minem kilgənne də sizmi xətta.

- Qaramuq! — didem. Minem kilgənne hic tə kətməgənlegen qьrǥьj qaraşьnnan kyrdem. Awъzьnda yrdək tə, jьlan jəisə başqa bernərsə də juq, əmma kyrəse kilgənne kyrdem: beten awъz-borьn tirələre jomьrqa sarьsьna bujalǥan, ə ylənnər arasьnda dənja qədər watьlǥan waq jomьrqalar... hicni ujlamastan moŋa qulьmdaǥь mьltьq tytəse belən kiterep sьladьm. Qacmadь,

janьmda çirgə sьlaşьp, əjlənə başladь. Qulьma qatь qamьş alьp, balalarnь suqtьrƣan kebek qьzdьra başladьm. Ul nəq balalarca cəreldəwek tawъş belən cinap qьcqьra, əmma yze ħaman qacmьj.

Jul bujь ərləp qajttьm yzen.

— Dimək, ketəklekkə kerep jomьrqalarnь urlap ecyce, annan soŋ berni bulmaƣandaj beznen janda sьrpalanьp jөryce —sin?! Beznen bu eşlərdən baş qatqanьn kyrep torucь da sin! Mondьj eşne sinen kebek aucьlьq qanunьna bujsьnucь etlər genə tygel, ə uram bujlap jөgerə-jөgerə ber telem ipi ezləgən maħmajlar da eşləməs. Ac tottьqmь əllə juƣisə sine? Jə, əjt! Sin beləsenme mine nicek məsxərə itkənenne? Min kyрme maqtap səjləp jөrdem sine! Jөzemə qara jaqtьŋ. Sinen xəzer qaraq təlkedən jəisə ylət şakaldan ni ajьrmaŋ bar? Sinen bəħaŋ — ber jədrə, əmma qulьm barmьj! Işetəsenme?..

Өjgə qajtьp çitkəc, audan qajtucьnьŋ xoquqlarьnnan fajdalanьrƣa bazmadь, bilgele, jan-jaƣьna qaramьj ƣьna ojasьna kerep kitte də şunnan cьkmadь.

Təne bujь joqlьj almadьm. Atsaŋ, qьzƣanьc, qulьp cьƣarsaŋ, qaja barьr, bylək itsəŋ, anьŋ bu ƣədəte belən kemgə kirək ul?

Irtən irtyk tordьm. Kece jaqqa yttem də cile-peşle itep ber jomьrqa peşerdem. Isəbem — Qaramuqnь bu xurlьqlь xələnnən qotqaru. Ojasьnnan caqьrьp cьƣardьm. Ece eckə jəbeşkən. Yze isə məce kyrgən tьcqan kebek, ƣəjət өrkep, əle qulьmdaƣь jomьrqaƣa, əle kyzemə qarьj. Min, tiz genə awъzьn acьp, qajnar jomьrqanь alsu tele өstenə təgərətep çibərdem. Qajnar jomьrqa etneŋ awъzь ecendə cart itep şartladь. Et cinap çibərde, sikerergə, bərgələnergə, peşkən awъzьn bolƣarƣa, tuzan ecenə batьrьp ьşqьrƣa kereşte... Anьŋ cinau awazь jөrəgemə jəbeşte, ike ucьm belən qolaqlarьmnь tomaladьm. Qaramuq cinьj-cinьj, təgəri-təgəri qajadьr kitep juƣaldь.

Kitep juƣaluƣa uq diərlek, bez anь ezli başladьq. Əmma taba almadьq. Өjebezdə qajƣьlь tьnlьq urnaştь. Ħərberebez, qajda jьƣьlьp çan birde ikən, qajda aunap jata ikən, digən ujda ide bulsa kirək. Ə bit bez anь bala caƣьnnan satьp alьp ystergən idek. Yzebeznen balalar belən gel bergə ujnap yste. Өjebeznen, jortьbьznьŋ ber çanlь juanьcь bularaq iələşkən idek. Minem yzemdə gyjə ber balamnь nьqlap suqtьrƣanmьn da uramƣa qulьp cьƣarƣanmьn kebek xis urnaştь. Ja Xoda! Nişlərgə? Nicek təzətergə bu xatanь? Kaş təzətəm dip, kyz cьƣarƣan kebek buldь bit əle bu. Dyrt kөn uzdь. Jorttan məjet cьqqan kebek taştaj awьr dyrt kөn. Өmet qalmadь buƣaj inde...

Berkөnne baqcadaƣь fasol'lərgə baular bəjləp jөri idem, sulьşlarьna qapqan balalarьm cabьp kilde. Sulьş alьrlьq dərəçəgə kilgəc, alar ikese berjulь:

— Əti, Qaramuqnь kyrdek! — dip qьcqьrьp çibərdelər. Kyz aldьmnan jalt itep Qaramuqnьŋ yle gəydəse ytte. Yzem alaj da:

— Qajda kyrdegez? — dim.

— Tegermən janьnda, jar bujьnda!

Yleme, tereme dip sorьj almьjm, jөrəgem gөmbert-gөmbert itə.

— Caqьrdьq, bezgə qaramьj, kilmi, — dilər. Şunnan soŋ ƣьna ullarьmnьŋ anьŋ tere ikənlegen acьqlaƣanь ziħenemə barьp çitə.

— Teləsəŋ nicek alьp qajt anь, əti, sinnən qurqa ul, — dilər balalarьm. Qulьmdaƣь baularnь taşladьm da kittem. Өjdən jьraq ta tygel ikən. Qaramuq başьn kytərep, bu jaqqa qarap-qarap ala. Barьber kilep alьrlar dip kөtep torƣan, axrь, bicaraqajьm. Rənçetelgən adəm balasь kebek! Qarasam, əni də qapqa təbenə cьƣьp basqan. Jөzendə çanlьlьq өmet belən balalar kyrsətkən jaqqa qarьj. Min Qaramuq janьna kittem. Bilgele, miŋa kytərelep tə qaramadь. Xodajьm, yzenə qararlьq ta qalmaƣan: qabьrƣa da jon. Min tawьşьma ni bar çьlьlьƣьmnь quşьp: "Qaramuq!" dip dəştem. Selkeny juq. Zur qolaqlarь arasьna ajaqlarьn

suzƣan da şularƣa başьn qujƣan, gyjə inde ylem genə kətep jata. Taƣьn da "Qaramuq!" didem — nətiçə juq. Şunnan soꞑ min anь elekkege ƣədətem bujьnca kytərep aldьm da ɵjgə taba kittem. Qaramuq qocaƣьma seꞑde, gyjə sulamьj da. Şulaj uq yzem də, balalar da sularƣa da qurqьp qajtьp çittek. Ɵstən awьr taş, albastь təştemeni! Ullarьmnьꞑ şatlьƣьn aꞑlatьp betererlek tygel. Xatьnьm, jomşak ikmək turap, sət saldь, Qaramuqnьꞑ jaratqan azьƣь. Əmma bygen aşamьj. Min etneꞑ maꞑƣajьnnan sьjpadьm, cəbəklədem, juq aşamьj bit. Şunnan keckenə ulьm anьꞑ aldьna ielde də: "Qaramuq, onьt inde, bez sineꞑ ƣəjebeꞑne kicerdek, sineꞑ ɵjgə qajtuьꞑ bezgə zur şatlьq", — dip səjlənde. Xikməti Xoda, menə bit ul, gənaһsьz sabьjƣa et kybrək ьşana ikən. Qaramuq əkren genə qojrьƣьn selketep ujnata, az ƣьna kyꞑellelənə başladь. Şunnan soꞑ, anь tьnьcta qaldьrьjq, dip, bez ɵjgə kerdek. Kergəc, tərəz pərdəseneꞑ citen kytərep, əkren genə qarьjm — ber miskien jalaƣan, ikencesenə əkren-əkren genə telen tiderep ala.

Niһajət, bezneꞑ ƣailə tormьşь elekkege ƣədəti ezenə təşte. Tьnьclьqtan ajьrmasьn, Xodam! Beldek bez anьꞑ ni ikənlegen! Menə şundьj qimmətkə təşkən maçaralar belən jomьrqa juƣaludan qotьldьq.

## Məmdyx Şəykət Əzəndal

*(1883 — 1952)*

### Xezmət təbe — xɵrmət

Xəzinəce bulьp eşləyce Ali əfənde şəһərneꞑ səydə-bazar tirəsennən baqcasь belən bergə ɵj urьnь satьp aldь. Şunda matur ƣьna ɵj də salьp qujƣan ide də, əmma rəxəten kyrə almadь, təzy ɵcen alƣan burьc aqcalarьn da tyli almьjca ylep kitte. Çəməƣəte, balalarь aһ itte, aptьrap, qara qajƣьƣa qaldьlar. Ɵstəvenə, kreditorlar təmam aptьratьp betergəc, ɵjne satarƣa turь kilde. Ɵj igen belən alьş-bireş ityce Səlgi uƣlь Xəlil qulьna kerde. Ul isə anь arendaƣa birde. Xəlil yze də ɵj totunьꞑ nərsə ikənlegen belgən adəm tygel, arendator-larnьꞑ da rətlese sirək bula. Bernicə aj ecendə əlege ɵjneꞑ kyrməgənen kyrsətep, arendatorlar cьƣьp ta kittelər. Baqcanьꞑ qojmalarь qaj arada auƣan, qapqa da qьjşajƣan, pьjalalar qojьlƣan, ramnar da sьnƣan. Xəlilneꞑ isə, şul arendatorlar cьƣьp kitkəc, kyrşe-tirəneꞑ sьjьrlarь, ygezləre, kəçələre belən kərəşep, başь əjlənde, xəle qalmadь. Nəq şul kənnərdə əməkle (otstavkadaƣь meꞑbaşь) Ali Kysəneꞑ ɵje, bələdiəneꞑ* jul ytkəry ɵstenə turь kilep, sytelde, aꞑa ɵj kirək ide. Barьp Səlgi uglь belən səjləşte, ɵjne arzanƣa ƣьna kileşep, arendaƣa aldь.

Meꞑbaşьnьꞑ xatьnь, ɵjne kyrgəc, aptьraşta qaldь:

— I Xodajьm, monda dyrt divar ƣьna bar ic. Bu çimerek, buş ɵjdə nicek torьrbьz, — dip aһ ordь.

Meꞑbaşь syzne ozaqqa suzmadь:

— Torьrbьz, torьrbьz, sin yz eşeꞑne qara, — dide.

Beraz çьjьp-çьjьştьrьp, şul tərəzəsez ɵjgə kycendelər. Meꞑbaşь ozьn bujlь, qaqca gəydəle, calarƣan ozьn mьjьqlь, inde bajtaq ƣɵmer sərgən keşe bulsa da, əle ber də kɵcen çujmaƣan, һər eşkə qulь jatьp torƣan adəm ide. Janьnda ber ulь bulьp, ul da yze kebek eşkə uꞑƣan ide. Ata belən uƣьl iꞑ elek, qul-quldan tərəz ramnarьn təzətep, jənədən qujdьlar. Miclərne rətkə kiterdelər,

---

*Bələdiə — şəһər idarəse (borьnƣь tərki syze).

stenalarnьn, ştukaturlarьn jaŋartьp çibərdelər, bujadьlar. Ceregən tyşəm taqtalarь da alьştьrьldь, tybəne də rətlədelər. Annan soŋ tərəzə qaşagalarьn, idən-işek, qapqalarnь matur bujauga bujap ta çibərdelər. Augan-tyngən baqca qojmalarь da rətkə kerde. Baqcanь qazьdьlar, suqmaqlarga cista qom taşьp, tigezlədelər, əj ecendə isə keləmnər çəjelep, tərəzə pərdələre elende. Əj təmam kəlep torgan keşe qьjəfətenə kerde.

"Bolar bu çimerektə nicek torьrlar ikən?" — dip qьzьqsьnucьlar, kyrşelər yzgəreşlərne kyrep gəçəpləndelər. Əjneŋ xuçasьna şunda uq syz də çitkerdelər: "Əjeŋne qara, jərəgeŋ janarlьq, sudan da ocsьzraqqa birdeŋ bit!"

Səlgi uglь Xəlil də əjne barьp qaradь: cьnnan da əj cəcək kebek, jərəgeŋ janarlьq ide. Ozaqlamьj aŋa tagьn ber syz kilep ireşte. Imeş, agac eşkərty şirkəteneŋ xisapcьsь jegerme liraga almaqcь bulgan ikən arendaga, əle aqcasьn da altь ajga aldan birəse bulgan... Bazarnьŋ tellərenə şajtan təkergən tel botqasь peşerycelər, Xəlilneŋ jərəge jangaлlьgьn belep, utqa maj əstəp, syzne ozajtьp tordьlar. Meŋbaşь da, bu syzlərne işetep, bazarcьlarga jalwardь:

— Jərək majьm, nigə kirəkməgənne səjliseŋ, kontraktьm juq, cьnlap ta qurp cьgarttьrasьz bit!

Qajsь tьŋlьj, qajsь tьŋlamьj. Səlgi uglьn kyrygə ber yk syzne başlьjlar:

— Aqьlьŋ juq ikən, hаman berər nərsə qьlmьjsьŋ...

Ikence kənne ikencelərе:

— Əj-jəj, yzeŋne kemgə də kyrmiseŋ ikən... — dip, şul uq syzlərne talqьj-cəjnilər.

Xəlil aptьrap mьgьrdana gьna belde:

— Min nişlim... əjne kypme təzəttelər, jaŋarttьlar... annan min qьjmmətrək tə sorьj belmədem, axrь...

Şulaj itep, qьzu taşqa esse su çibərgən kebek əkrenləp Səlgi uglьn qьzdьrьp çitkerdelər, ul meŋbaşьna xəbər çibərde: "Jə aqcanь arttьrsьn, jə əjemnən cьgьp kitsen!" Meŋbaşь xəbərne endəşmi genə tьŋlagan da ber syz də əjtməgən ikən.

Berkənne meŋbaşь Sarac Ibrahimьnьŋ kafexanəsendə utьrganda işektən Xəlil kilep kerde də, meŋbaşьn kyrmicə, eckə uzdь. Meŋbaşь aŋa yze endəşte:

— Xəlil, bu nindi eş inde? Adəmne kəcek kebek uramga kuasьŋmьni? Xaqьn arzan dip əjtəseŋ ikən, ə əjeŋ ni xəldə ide, onьttьŋmьni?

Xəlil ojaldь. Əmma nişləsen? Bazar xalqьna aŋlatьp qara! Alar kyzenə kyreny genə də ni tora. Kyzeŋ acьrmьjlar. Şul yzeneŋ iske syzləren kəckə ojьştьrьp əjtep, qafexanədən cьgьp kitte. Cьqqac, bazar xalqьna: "Meŋ başьn kyrdem, əjttem syzemne, sudan da ocsьz buldь arenda bəhase, didem", — dip xəbər itte.

— Cьnnan da əjtteŋme, kit annan! — dip, islərе kitkəndəj itte bazar xalqь.

— Əjttem, əjttem!

— Maşalla, buldьrgansьŋ!

Bernicə kənnən meŋbaşьna tagьn xəbər saldь: "Əjdən cьqmasa, sudqa birəm!" Meŋbaşь: "Abaj, min Xəlilgə sagьz kebek jabьşьrga çьjьnmьjm, ber atna waqьt birsen, cьgarmьn", — dip, kilgən keşesenə əjtep çibərde. Yze eşlər belən cьgьp bargaнda ulьna bolaj dide: "Ulьm, eşləgən eşebezne qьzganma, monda keşelər jəşi ide, diərlek bulsьn, əjberlərne alganda ber çir də watьlmasьn, çimerelməsen, qarap qьna al, min tege Mandrac uglьnьŋ əjen barьp qarьjm əle". Əjne gəl kebek matur kəjencə, tərəz pьjalalarьn sərtep qaldьrdьlar. Meŋ başьnьŋ xatьnь yze tərəz sərtte, yze jьladь.

Ozaq tormьj Xəlil bəj əjne agac eşkərty fabrikasь xisapcьsьna unbiş liradan arendaga birde. Bazarga cьqqac, berence ocragan keşese timerce

Məxmətkə şatlanьp:

— Meŋbaşьnь ɵjemnən сьǥardьm, — dide.

— Сьǥardьŋmь? Nacar eşləgənseŋ. Ɵjeŋne ul jaŋarttь bit.

Annan taǥьn Taħir əfənde belən Şəyki ostaǥa eşləgən eşe turьnda xəbər itkən ide də, alar da xuplamadьlar:

— Jalǥьş bulǥan, andьj uŋǥan arendatornь nicek tabarsьŋ...

Ikence kənne başqalarь da iske awъzdan jaŋa syz səjləp, Xəlil bəjne qьzdьrdьlar. Ul aptьrap əjtte:

— Sez ic, barьǥьz da arzan birdeŋ də, arzan birdeŋ, dip, teŋkəgə tidegez, xəzer ikence tərle çьrlьjsьz. Əllə inde bɵtenləj buşqa birimme ɵjemne?

Taǥьn da bernicə aj uzdь. Xəlil bəjgə jaŋa xəbər kilde: "Ɵjeŋne barьp qara, ni xəlgə kilgən, kyrerseŋ", — didelər. Barsa, ja Xoda! Ɵj taǥьn betkən, qojmalar auǥan, qapqalar qьjşajǥan. Işek aldьnda kyrşelərneŋ sьjьrlarь, kəçələre rəxətlənep qьrqьnьp jəri. Ə ɵjneŋ tərəzəsennən burƶujkanьŋ morçasьn сьǥarǥannar! Adəm kəlkese! Ɵstəwenə, arendator əllə nindi coqьrlar kymərgə, tişeklər jamarǥa bojьra! Xəlil bəj: "Min bernindi coqьr da kymərgə çьjьnmьjm. Teləsəgez kymərsez, teləməsəgez сьǥarsьz", — digən ide də, tegelər: "Coqьrlar da kymmibez, сьkmьjbьz da, arenda aqcasьn da tyləmibez", — dip, ike də ujlamьjca çawapladьlar. Ber aj ytte, ike aj ytte, akca tyləyce juq. Çibərgən keşesenə, coqьrlarnь kymdersen, annan soŋ tylərbez, dip əjtep qajtarǥannar. Bazarda Xəlil bəjgə tərlese tərlecə kiŋəş itə başladь. "Advokat Zəħtyne tap, ul siŋa eşne əjlənderep сьǥarьr", — didelər. Qajsьlarь moŋa qarşь, ul aqcanь kyp qajьra, dip qьstьrdьlar. Ikencelərе: "Advokat Bilal əfəndene jalla", — dip qьstьj başlaǥac, bu təqdimgə də qarşьlar tabьlьp, anьŋ qulьna eləksə, ɵjeŋne yzenə sььrьp alьrǥa da kyp soramas, dip qurqьttьlar. Şunda Sarac Ibraħimь:

— Xəlil, kym şul kyməse nərsəlereŋne, aqcasьn tylərlər, beraz torǥac, yzləre də сьǥar əle, — dip kiŋəşləsə də, Xəlil bəj:

— Assьnnar, bernindi coqьr da kymmim, сьǥьp kitsennər! —dide.

Şunnan soŋ ozaq ta ytməde, bazarǥa jaŋa xəbər kilde: fabrika xisapсьsь Xəlil bəjneŋ ɵjennən сьqqan, xətta ǥəmer bulmaǥan xəl — moŋardan xatьnь da ajьrьlьp kitkən. Xalьq şau itte. Xəlilne də ɵjeneŋ buşawь belən qotladьlar. Ləkin Xəlil bəj ьǥь-zьǥьdan tьna almadь. Buş torǥan ɵjdən kemgə nərsə kirək, əkren genə taşьj başladьlar.

Berkənne Səlgi ulь Xəlil bəj bazarda meŋbaşь Ali Kysəne kyrde. Xəllər soraştьlar. Səlgi uǥlь meŋbaşьnьŋ qullarьna ike qullap yrelde: "Ali bəj, ber yk Adəm balasь zatьnnan, urtaq dində bulu xaqьna, xatьnьm, balalarьm xaqьna ytenep sorьjm, zinħar, şul ɵjne minnən bɵtenləjgə satьp al?!" — dide. Meŋbaşь berni aŋlamьj tordь. Şunnan beraz kəlemserəp torǥannan soŋ:

— Siŋa berərse minem ɵj alьrlьq aqcam bar dideme əllə? — dip soradь.

— Bulmasьn, kətərgə satam. Min yzem ɵjemne ille altьnǥa bəħalim, ə siŋa utьzǥa da birəm. Jegerme biş, disəŋ də riza. Nicek teliseŋ, şulaj bir.

Bu syzlərne tьŋlap torǥan ber kibetce, Xodavəndə, şulaj ɵj satalarmьni, dip, araǥa kerməkce ide də, Xəlil bəj aŋa: "Satalar şul, menə kyrerseŋ, Ali bəj alam ǥьna disen", — dip şaqqatьrdь. Tanьş-beleş şaħit buldь, şunda uq, aldьm-birdem, jasadьlar. Ali bəj bulǥan aqcasьn сьǥarьp birde, qalǥan bьrəcəgen soŋьnnan tylise itte. Xəlil bəjneŋ ɵstennən awьr tau təşkəndəj çiŋel sulьş aldь, niħajət.

Xəlil bəjgə taǥьn da aqьl birycelər tabьlasь ide də, bu julь ul alarnь tiz tuqtattь: "Bulmaǥannьŋ qulьnda cyplek başь bulьp torǥancь, bulǥannьŋ qulьnda gəl bulsьn!" — dide.

*Tərekcədən Bikə Rəximova tərçeməse.*

ШИГЪРИЯТ

# ДУСЛАРЫ КҮП ШАГЫЙРЬ ДУСТЫБЫЗ



*"Муса Галинең дуслары, фикердәшләре бик күп. Аны булган, йөргән бер җирендә яхшы аңгәмәче, шигырьләрен матур укучы, әдәпле, интеллектлы, ихлас күңелле шагыйрь, шәхес итеп танып, яратып өлгерәләр..." — бу сүзләрне шагыйрьнең башкорт телендәге калын юбилей сайланмасына кереш мәкаләсендә күренекле галим һәм әдип Гайсә Хөсәенов яза.*

*Әйе, әйе, күпләребез шулай сөйли алыр иде аның турында; бүгенге дуслары Әмирхан Еники, Гариф Ахунов, Илдар Юзеевлар да, үзе бик хөрмәт иткән, күп сәфәрләр юлдашы, яшь буенча энесе Равил Фәйзуллин да күп әйбәт сүзләр өстәр иде, дим. Хәтта үзенчә матур итеп аның холкын, сөйләшен юморга, әдәби мәзәкләргә керткән үткен-шаян телле Марсель Гали дә... Хәер, Муса агай үзе дә Татарстан, Казан мохитын яхшы белә — күп зыялыларыбыз тормышыннан, мәдәниятыбыз хәлләреннән хәбәрдар булып яши. Ул да, Мостай Кәрим, Нәҗар Нәҗмиләр кебек, дуслары хозурына — Казанга, Шигърият, Тукай бәйрәмнәренә еш килә, журналыбыз битләрендә дә шигырьләре күренә. Бу җәһәттән "Казан утлары" үзе дә дусларына, туганнарына һәрчак мәрхәмәтле һәм игътибарлы, киң күңелле басма булды дия алабыз. Менә хәзер дә каләмдәш дустыбызны, 75 яшьлек шагыйрь-яугирне, Башкортстанның Салават Юлаев исемендәге премиясе лауреатын чын күңелдән олы юбилее белән котлап, бу санда аның бер бәйләм шигырьләрен тәкъдим итәбез. Укучыларыбыз игътибар итәр: бу шигырьләр дә әлеге Дуслык турында, шигърият, халыклар, шагыйрьләр туганлыгы, Илһам һәм Моң турында һәм безләр бик разый моңа!*

Рәдиф ГАТАШ

## Муса Гали

### Көне килгәч

Сары көзем,
син килдеңдәмени...
Исләмәстән нигә ишек кактың?..
Мизгел-мизгел аккан елларымнан
Ничек күрә алдың, ничек таптың?!
Көз тусам да мин бит яз кешесе.
Хыялымда язлар яшеллеге.
Хәер, миңа икегез дә тансык
Яз давылы, тыйнак көз силлеге. *

* Силлеге — тынлыгы.

Чаганнарның алтын яфракларын
Якты хәбәр күреп, көтеп алам.
Асмандагы моңлы торналарның
Серле чылбырына карап калам.
Сары көзем,
син килдеңдәмени...
Күрмисеңме, эшем чиктән ашкан?
Уттай яна талган табаннарым,
Иңнәремә җир йөкләре баскан.
Сугылмаган көлтәләрем ята,
Әрни җаным, тапмый эмәлләрен.
Үрле-кырлы килеп, дала кыдырам —
Очланмаган әле кибәннәрем.
Сары көзем,
атламый тор түргә.
Син көт мине ишек артларында.
Көне килгәч, үзем чакырырмын.
Гомремнең бер хозур акланында,
Күз моңына тулган чакларымда,
Көне килгәч үзем чакырырмын.

## Сәфәр чыктым

Кояш нуры белән битем юып,
Сәфәр чыктым. Уңды сәфәрем.
Йончытса да мине дөнья йөге,
Екмый үтте җилнең хәтәре.
Кем кул болгый дисәм, нелә икән
Яшь наратның куе ылысы.
Ымлап-ымлап җаным сөендерә
Моннан ерак утның җылысы.
Сәфәр чыктым. Исәнмесез әле,
Тын күлләрем, күксел тауларым,
Бәлки йәнә бер кат балкып алыр
Яшьлектәге ярсу таңнарым.
Сәфәр чыктым. Һәр дүрт ягым кыйбла
Минем ише гашыйк җаннарга.
... Сез карагыз әле каен атлы,
Яшел утлы ап-ак шәмнәргә!
Түгелә-түгелә ажаганнар уйный...
Минеке бу дөнья, синеке.
Җирдән, күктән килгән һәрбер тавыш
Безнең йөрәктәге көйнеке.
Могҗизалар күреп, инде кайтам.
Туймады җан лэкин, туймады.
Оҗмахларның хәтта үзендә дә
Сагынырбыз тик бу дөньяны,
Шул гөнаһлы фани дөньяны.

## Тукай кошы

Иңрәп туа дәвер мизгелләре,
Йөрәкләргә уела бара яра.
Өзелгән өметләр заманында
Яшәп кара әле, яшәп кара.

Бөек Тукай, очкан күңелең кошын
Гүя бүген килеп без аңладык;
Азмы еллар безне сугып екты,
Дөнья кудык күпме без алданып.
О, бүген соң Тукай әрнүләрен
Кичермиме әллә күңел гелән?!
Ул юксынып, тарсынып ук очты
Иксез-чиксез дөнья читлегеннән.
Күкләр безгә: Җирдә көн күрегез
Һәм үрчегез, — диеп, боерса да,
Вәхшилеге фани бу дөньяның
Кануннарны җимерә, утка сала.
Ләкин исән ул кош — бөек иҗат!
Өметләрне ялгап, күккә аша.
Ул иректе, ул буйсынмый оча,
Үтерү, талау, геноцидлар аша.
Агыйделдә, Кырлай кырларында
Чыңлый ул кош, биеклеген белеп;
Ук төбәмә аңа, комсыз җәллад,
Үтереп булмый аны, булмый җиңеп.

## Күзләреңдә сагыш...

*Илһам Шакировка*

Чак сөйрәлеп ташлы сукмаклардан
Атлап кайта идем диңгездән.
Искәрмәстән шундый җыр яңгырады:
Нәкъ бер давыл үтте күңелдән.
Уйга калды Ялта каштаннары:
Чү, нинди моң, нинди җыр икән?!
Шушы җыр-моңнарны тыңлап кына
Дөньяларда бәйрәм кор икән.
Яңгырый "Уел"...
Илһам, синмени бу,
Алдый мәллә мине күзләрем?
Син баш кактың, ләкин газиз моңың
Азагына җитми өзмәдең.
...Хәтереңдәме, Илһам, шул минутлар:
Без яшәгән иҗат йортында
Синең моңнар дулкынына чумдык
Афәт кичкән таулар сыртында.
Баш кынаңа чалма урап киеп,
Аяк бөкләп утырып идәнгә,
Син ярсыдың сәнгать сәхрасында
Баш бирмәгән тайдай йөгәнгә,
Ярсыдың да капыл гына тындың...
Җырчы җанын авыр аңлавы.
Күкрәгеңне мәллә кысты капыл
Фани дөньяларның ялганы.
Тагы киттең дулап.
Без диңгезне
Алыштырдык ахры тауларга.
Канат алып газиз бу моңнардан
Ашкындырды әллә кайларга.
Һаман сине шул сыйфатта күрәм,
Булмый моны, булмый онытып:
Йөрәгеңдә үлмәс моңнар иңри,
Күзләреңдә сагыш болыт.

ПУБЛИЦИСТИКА

Фәүзия
Бәйрәмова

# ТӘГӘРИ КИТТЕ ЙОМГАГЫМ...

*«Кабул ителгән Хаҗның бүләге — җәннәт»*

(Хәдис)

**5 апрель.** Иртәнге намаздан соң, таң белән, юлга кузгалдык. Бүген бөтен дөньядан җыелган хаҗилар, безнең кебек үк, Мина тавына китә. Бүген зөлхиҗҗә аеның сигезенче көне һәм ул Әт-Тәрвия көне дип атала, ягъни, Хаҗның Тәммәтуг" төрен кылучыларга бүген Хаҗ кыла башларга мөмкин. Без төшкә кадәр Мина тавына барып җитәргә тиеш. Ул Мәккә шәһәреннән әллә ни ерак түгел, күп булса, 10-15 чакрым булыр. Ара ерак булмаса да, без автобуслар белән юлга кузгалдык. Юл буе карап бардым — бу урыннар гаҗәеп хикмәтле булырга тиеш. Як-якта кара кыя ташлар. Мина тавына якынайгач, бераз яшеллек тә күренде. Таңга каршы, кояш чыгышына каршы барабыз. Тау араларыннан сирпелеп чыккан яктылык та гадәти түгел, яшькелт-нурлы булып күренә. Бөтен автобуслар, машиналар, җәяүлеләр Минага ашыга, Минага бара...

Чатырлар шәһәрчегенә килеп тә җиттек. Безне 25 нче капкадан эчкә кертеп җибәрделәр. Һәр бүлем шулай койма-капкалар белән әйләндереп алынган. Койма эчендә чатырлар диңгезе — очы да, кырые да күренми. Бу чүпрәк чатырларның бары тик түбәсе генә бар, аска, җиргә бер кат брезент сымак нәрсә җәелгән. Һәр чатыр төбенә төркем-төркем хаҗилар укмаша, оеша башладылар. Канында күчмә тормыш күзәнәкләре калган безнең татар халкы монда да тиз җайлашты — чатырларның як-якларына җәймәләр элеп куйдылар, аш-су көйләп җибәрделәр, тәһарәт алып, намаз укый башладылар. Чатыр араларына электр чыбыклары сузылган, аларга җил җибәргечләр көйләнгән, теләсәң, гел эшләп торалар. Адым саен боз итеп катырылган зәм-зәм суы, ул уртача зурлыктагы бакларга салынган, эрегән уңайга эчә барасың...

Табигый җиле булмагач, биек койма эчендә барыбер түзеп булмаслык эссе, ул вакыты-вакыты белән 40-45 градуска җитә. Узган ел шушы урында зур янгын чыккан, татар хаҗилары чакка-көчкә качып котыла алганнар. Шуңа күрә көн яктысында керү-чыгу юлларын карыйбыз, өйрәнәбез, электр чәйнекләрен полициядән качырып кына кайнатабыз, җил җибәргечтән күзебезне алмыйбыз. Безнең янга гына кыргызлар һәм үзбәкләр урнашкан. Аларда да карт як күбрәк. Дөрес булса, Үзбәкстан Президенты 30 яшьтән өлкәннәргә генә Хаҗга барырга рөхсәт биргән, диләр. Яшьләрнең дингә килүеннән бөтен җирдә дә куркалар шул, ислам динен әби-бабайлар диненә генә әйләндереп калдырырга тырышу сизелә. Ә менә Малайзиядә киресенчә икән. Бу мөселман илендә Хаҗга барып кайтмыйча өйләнешергә дә рөхсәт итмиләр. Ягъни, тормышын башлаганчы яшь кеше кешелекнең ахырын — кыямәт көне күренешләрен дә күрергә, шушы сынауларга түзәргә, Коръәнчә яшәрлек булып ныгып кайтырга тиеш була. Ә бездә тормыш аракылы туйлардан, "баллы айлардан" башлана да, бик тиз җәнҗал,

**Ахыры. Башы журналның 9 санында.**

аерылу белән тәмамлана. Ерак, бик ерак шул әле безгә ислам әхлагына кайтырга...

Без итәгенә килеп урнашкан Мина тавы ислам дине тарихында нәрсәсе белән истәлекле һәм кадерле соң? Ибраһим Пәйгамбәрнең баласы булмаган. Аның ихлас догаларын ишетеп, Аллаһы Тәгалә Ибраһим Пәйгамбәргә изге бер бала биргән. Әмма Ибраһим Пәйгамбәрне сынап карау нияте белән, ул баланы корбан итүне аның төшенә керткән. Аллаһыга мәхәббәте һәм аннан куркуы көчле булган Ибраһим Пәйгамбәр улы Исмәгыйльне суяр өчен җиргә яткыра, пычагын аның бугазына ышкый, әмма пычак үтми. Ата кеше нишләргә белмичә елый башлый. Шул чагында улы Исмәгыйль әйтә: "Әтием, мине җиргә йөзтүбән яткыр. Битемне күргәч чыдый алмыйсың. Мине кызганып, Аллаһының әмерен җиренә җиткереп башкарудан мәхрүм калма. Мине Аллаһка корбан итүдән ваз кичеп, гөнаһлы булма."

Ибраһим Пәйгамбәр малаен тагы суярга тырышып карый, әмма пычак үтми. Шул чак Аллаһыдан хәбәр килә. **"Колына пычак алуга, без аңа кычкырдык: "И Ибраһим, төшеңдә күргән безнең әмерне тәсъдыйк кылдың, үтәгән хөкемеңдә булдың." Әнә шулай үзебезгә итагать иткән яхшы мөэминнәрне изге җәзалар белән нигъмәтлибез. Аллаһуның изге балаңны корбан итеп чал, дигән әмере, әлбәттә, зур һәм авыр сынаудыр. Без аңа Исмәгыйль урнына корбан итеп бугазлар өчен җәннәттән бер зур тәкә бирдек. Яхшылыгы белән искә алу өчен дөньяга соңыннан килгәннәргә Ибраһимның яхшы әсәрләрен калдырдык. Ул Ибраһимга барча галәм сәлам әйтер."** *("Саффат" сүрәсе, 104-109 аятьләр.)*

**6 апрель.** Дүшәмбе. ГАРӘФӘ көне... Без бүген, таң белән, Гарәфәт тавына китәргә тиешбез. Бу тау гарәпчә "Җәбәлүр-рәхмә", дип, ягъни, "Рәхмәт тавы" дип атала. Имам Газали бу тау турында болай дип әйткән: **"Кешенең шундый зур гөнаһлары бардыр, ул гөнаһларны Гарәфәттәге ике тамчы күз яше пакьләр."** Барыбыз да дулкынланып, шушы тауга кузгалуыбызны көтәбез. Иртәнге сәгать өчтә инде аякта идек. Иртәнге намазны укуга, тиз генә кирәк әйберләрне җыйдык та, автобусларга төялеп, Гарәфәт тавына кузгалдык.

Таулар арасыннан кояш чыгып килә... Мина тавыннан Гарәфәт ерак түгел — 6-7 чакрымнар чамасы. Минадан барганда уң кул якта зур-зур кара ташлы таулар кала. Таулар үзе биек түгел, аларда нинди дер кискен җыйнаклык, бөтенлек бар. Тауларның түбәләре очлы, аларны сөзәк дип әйтеп булмый. Таш араларында сирәк-мирәк кәрлә куаклар күренә. Әмма күпчелек —кап-кара ташлар...

Сул кул якта су, елга бар ахры — яшеллек күренә. Агачлар артында — тагы таулар, таулар, таулар... Автобуста Гарәфәт тавына якынлашкан саен, кеше саны да арта бара. "Әнә, Гарәфәт тавы", дип, уң кул якка төртеп күрсәтәләр. Әмма бу тау, башкалары кебек, кара түгел бит, ул ап-ак һәм хәрәкәтләнеп тора! Тауның итәгеннән түбәсенә кадәр ак киемле хаҗилар шыплап тулган икән, шуңа күрә Гарәфәт тә ак булып күренә. Әйтерсең лә, Гарәфәт тавы үзе дә кыйблага карап сәҗдә кыла, бәндәләр, өчен Аллаһка ялвара... Пәйгамбәребезне сагына... Пәйгамбәребез Гарәфәт тавын бик яраткан, **"Хаҗ ул —Гарәфәт тавында гыйбадәт"**, дип әйтә торган булган. 9 нчы Зөлхиҗҗә көнне, ягъни, иртәгә Корбан бәйрәме, дигән көнне иртәдән кояш баеганга кадәр Гарәфәт тавында булу — фарыз, мәҗбүри, шуннан башка Хаж юк, Гарәфәттә тукталыш ясау — Хажның иң мөһим йолаларыннан санала. Хаҗ кылырга килеп тә, авырып китсәң дә, хәтта үлем хәлендә булсаң да, син бу көнне Гарәфәттә гыйбадәт кылып уздырырга тиешсең. Узган ел Әлмәттән килгән бер хатын машина астына эләккән. Больницада аның сөякләрен бергә тәкләп җыйганнар, ямаганнар да, Гарәфә көнне, носилкалар белән, Гарәфәт тавына китереп куйганнар. Әлбәттә, янында караучылары булган, авыру игътибарсыз калмаган. Кояш баегач, носилкалар белән, аны яңадан больницага алып киткәннәр. Гарәфәт тавында пышылдаган догалары кабул булгандыр — хатын үз аягы белән туган ягына кайтып киткән... Әгәр Гарәфәттә көн уздырмаган булса, аның Хаҗы кабул булмас иде...

Вафатына өч ай кала, Пәйгамбәребез Хаж сәфәре кыла, шушы Хаж вакытында тиздән, бу дөньядан китәсен сизенеп, өммәттәшләре белән бәхилләшә. Шушы Хаж вакытында инде Коръәннең дә соңгы аятьләре иңдерелә... Коръән тәмам була... Мөхәммәт галәйһиссәлам вафатыннан соң, пәйгамбәрлек туктала, хәбәр киселә... Гарәфәт тавында, бәхилләшү Хажы вакытында, Пәйгамбәребез

хаҗиларга бер вәгазь укый. **“Әй, кешеләр! Кыямәт көнендә минем турыда сездән сорарлар, — ди ул. —Нәрсә сөйләрсез? Пәйгамбәрлегемне тәблигъ иттемме?Пәйгамбәрлек вазифаларымны үтәдемме?” Хаҗилар бертавыштан: “Әйе, Мөхәммәт! Тәблигъ иттең. Ачык, төгәл итеп таныттың. Безләргә васыять вә нәсихәт кылдың. Без таныклык кылабыз”,** — диделәр. Йөзмеңнәрчә тавыш Гарәфәт тавында яңгырый. Шулвакыт Пәйгамбәребез, шәһадәт бармагын югары күтәреп, өч мәртәбә: **“Таных бул, йә Раббы”,** — дип кабатлады һәм сүзләрен тәмамлады.” *(“Исламият” китабы, Анкара, 1996 ел. 44-45 бб.)*

...Гарәфәт тавындагы чатырлар шәһәрчегенә килеп кергәч тә, автобус белән шактый озак бардык. Агачлар арасына урнашкан гүзәл бу шәһәрчекнең иге-чиге юк иде. Миллионлаган кешене һәр төнне, һәр көнне бер урыннан икенчесенә күчерү өчен бик зур оешканлык, тәртип кирәк. Гарәпләр моны искиткеч төгәллек, житдилек, намус белән башкаралар. Безне 25 нче санлы автобус белән тагы 25 нче санлы капкага алып киттеләр, бу егерме биш саны безнең махсус үз саныбыз булды ахры. Бу чатырлар шәһәрчеге Минадагыга караганда яктырак та, чистарак та, биредә агачлар да үсеп утыра. Безне тау итәгенә урнаштырдылар, чөнки гыйбадәт Гарәфәт тавы чикләрендә, ягъни, территориясендә булырга тиешле. Хәллерәк, көчлерәк кешеләр Гарәфәткә үк менеп киттеләр, әмма анда менү мәҗбүри түгел, диделәр. Без монда көне буе, бер минутыбызны да әрәм итмичә, бары тик зекер әйтеп, гыйбадәт кылып кына утырырга тиеш икән. Шуңа күрә хәтта намаз вакытлары да кыскартыла, өйлә белән икенде бергә җыеп, икешәр рәкагать кенә укыла. Моны Пәйгамбәребез дога кылу өчен күбрәк вакыт булсынга шулай эшләгән. Калган бөтен вакыт — бары тик догага, зекергә, гыйбадәтләргә, Аллаһыдан сорауга һәм ялваруга... Эчкерсез күз яшьләре белән, ихлас күңелдән, бәндә түгел, Аллаһы күрсен, Аллаһы ишетсен, Аллаһы ярдәм итсен өчен... Иң хәерле, иң тиз барып ирешә торган дога — Гарәфәт догасы, бигрәк тә икенде вакытына кадәр теләгән догалар тоткарлыксыз Аллаһыга барып ирешәләр. Шуңа күрә, тынсыз-өнсез калып, барыбыз да догада, гыйбадәттә. Бу изге җирдә Пәйгамбәребезнең иң күп укыган зекере шушы булган: **“Ләә иләһә илләл-лаһу вәхдәһу лә шарикә ләһ, ләһул-мульку вә ләһул-хәмду вә һуа галә күлли шәйъин кадир. Ләә иләһә илләл-лаһу вәхдәһу әнҗәзә вәгъдәһу вә нәсара габдәһу вә әгаззә җундәһу вә һәзәмәл-әхзәбә вәхдәһу.”** Мәгънәсе: “Аллаһ Тәгаләдән башка һич тәнре юк, ул бердәнбер, аның һич тиңдәше юк. Барча хуҗалык-мөлкәт ана гына хас вә барча хәмед-мактаулар ана гына һәм Ул бар нәрсәгә дә көчекодрәте житүче. Аллаһы Тәгаләдән башка һич тәнре юк, Ул бердәнбер, вәгъдәсен үтәде, колына ярдәм, җиңү бирде, гаскәрен көчәйтте, фирка-төркемнәрне тар-мар итте.”



*Согуд Гарәбстаны короле Фәхд ибн Абдул Азиз Ааль Сауд*

... Кояш бөтен дөньяны эретеп бетерергә теләгән кебек кыздыра. Һаваның эсселеге 50 гә житә булыр. Тәннән гөрләп су ага, сизеп торасың — тән балавыз кебек эри, йомшара, тән һәм җан керле уйлардан арына. Күз яшьләре белән, ихлас күңелдән Аллага мөрәҗәгать итәсең, яңа туган бала хәленә кайтып, Аллага мөрәҗәгать итәсең, тирәягыңда беркемне, бернәрсәне күрмичә, Аллага мөрәҗәгать итәсең... И раббым, белеп һәм белмичә эшләгән гөнаһларымны, ялгышларымны, яшьлегем хаталарын кичерә күр, аларны янадан

эшләргә насыйп итә күрмә. Нәфес коткысыннан сакла, шайтан мәлгуньгә ияртә күрмә, иманымны ныгытырлык файдалы гыйлемнәр алырга, изге гамәлләр кылырга насыйп ит, Раббым Аллам! Холкымдагы начар гадәтләрне бетерергә ярдәмче бул, нурлы йөз, ачык зиһен, йомшак күңел, туры тел бир. Яхшы, иманлы юлдашлар насыйп ит, яман бәндәләрнең яманлыкларыннан, мәкерләреннән, сихерчеләрнең сихереннән, бозуларыннан сакла, Раббым! Алган белемнәремне, тормыш тәҗрибәмне милләтемне иманга кайтарырга сарыф итәргә язсын, ризалыкларыңны бир, Раббым Аллам?! Милләтемә бозык гадәтләреннән тизрәк арынырга, туры юлга — Коръән юлына кайтырга ярдәм ит, Раббым! Татар милләтенә бәхет бир, бәрәкәт бир, җәннәтләргә керерлек изге тормыш насыйп ит, Аллам! Динебез, милләтебез өчен барган тигезсез көрәштә рух ныклыгы, көч-кодрәт, гайрәт бир, мөселман кавемнәренә җиңү бүләк ит! Шушы юлларда көрәшеп шәһид китүчеләргә җәннәт ишекләренне ачсаң иде, Раббым Аллам!

И, газиз Аллам, балаларымның кайгысын күрсәтә күрмә! Шушы Гарәфә тауларында, ком чүлләрендә синнән тезләнеп сорыйм: балаларыма иман, тәүфыйкъ, сәламәтлек насыйп ит, намаз ияләре булып, синең яраткан колларың булып яшәү бәхетен бирсәнче аларга да... Балаларыма ике дөньяның да дәрәҗәләрен, ике дөньяның да бәрәкәтләрен насыйп итсәнче, газиз Аллам! Мина биргән тиңсез нигъмәтләреңне, бәхетне балаларым белән дә уртаклашсаңчы, Раббым!

И, Раббым, мине дошман итеп йөргән, мина күп зыян салган бәндәләрнең дә күңелләренә иман нурлары сал, аларга дөрес юлга чыгарга насыйп ит, тәкъва мөселман булу бәхетен аларга да бир, бу өч көнлек дөньяда ызгышып-талашып яшәргә язмасын. И, Аллам, тормышымда кичелгән кадерсезлекләр, авырлыклар, түбәнсетүләр инде бетсен иде, хаклык җиңсен, өскә чыксын иде. И, Раббым, бөтен изге теләкләремә һәм яхшы гамәлләремә юлларны ачсаңчы...

Карт атам-анама тәкъдирдә язган гомерләрен саулык-сәламәтлектә, кайгы-хәсрәтсез, иман белән яшәп бетерергә насыйп ит, Раббым, аларга балаларының хәсрәтләрен күрсәтмә. Бер карында яткан туганнарымның күңеленә иман нурлары сал, аларга саулык-сәламәтлектә, бәрәкәтле бәхетле тормышта яшәргә насыйп ит, мина биргән нигъмәтләреңне аларга да бир. Гаиләмә иминлек бир, пакьлек бир, хәерле, хәләл бәрәкәтләр бир, татулык, тигезлек бир, ирем белән бергәләп намаз уку, ураза тоту, Хаҗ кылу бәхетләрен насыйп ит...

И, Раббым, миннән дога өмет итеп яткан әрвахлар рухына да барып ирешсен иде бу догаларым! Гарәфәт тавында укыган шушы догалардан аларның кабер эчләре нурланып, кабер туфраклары җиңеләеп китсен иде, бу эчкерсез догалар аларга кыямәт көнендә сорау алу газапларын җиңеләйтсен, җәннәтләргә керергә ярдәм итсен иде. Динебез, милләтебез өчен көрәшеп шәһид киткән әби-бабайлар рухына, Казан өчен башларын салган милләттәшләрем рухына да барып ирешсен иде бу догаларым... Һәм дә бәйсезлек өчен көрәш юлында корбан булган замандашларымның рухлары да бу догаларны ишетеп куансыннар, җаннарына тынычлык тапсыннар иде... Амин.

... Кояш баегач, Мөздәлифә тавына алып киттеләр. Быел Хаҗда 7 миллионга якын кеше бар, диләр. Менә шушы миллионлаган кеше, берьюлы кузгала, хәрәкәткә килә, бер урынга юнәлә. Мөздәлифәгә, бары тик Мөздәлифәгә генә! Аллаһы Тәгалә бу хакта Коръәндә бик катгый итеп әйтә: **"Хаҗ вакытында Раббыгызның фазлы рәхмәтеннән сәүдә белән мал кәсеп итүегездә гөнаһ юктыр. Гарәфәт тавыннан Минага кайтканда Мөздәлифәдә тукталып Аллаһуны зекер итегез! Аллаһуны зекер итегез сезне туры юлга күндергәне өчен, әвәлдә адашуда булган булсагыз да. Аннары кешеләр кайткан юл белән кайтыгыз, ягъни, Гарәфәттән Мөздәлифәгә, аннан Минага, Минадан Мәккәгә кайтыгыз! Күрсәтелгән урыннарда Аллаһуны зекер итегез, намаз укып, гафу сорагыз! Аллаһ, әлбәттә, гафу итүче, рәхимле."** *("Бакара" сүрәсе, 198-199 аятьләр.)*

Мөздәлифә тавы — атабыз Адәм белән анабыз Һава очрашкан изге урын, ул Мина һәм Гарәфәт таулары арасына урнашкан. Атабыз Адәм белән анабыз Һава, җәннәттән куылганнан соң, берсе Һиндстан җиренә, икенчесе Җиддә таулары арасына килеп төшәләр. Алар озак еллар буе аерым яшиләр, бик сагынышалар, бик елашалар, Аллаһтан көн-төн кавыштыруны сорыйлар. Аллаһы Тәгалә аларның догаларын ишетә һәм фәрештәләре аша Адәм галәйһиссәламгә

Җиддә тауларына таба барырга куша. Һәм менә шушы Мөздәлифә тавында атабыз Адәм белән анабыз Һава очрашалар, кавышалар, тормыш итә башлыйлар, кешелекнең нәселен калдыралар. Без хәзер менә шушындый изге, хикмәтле урында. Төнне Мөздәлифәдә үткәрү Хаҗның важеб гамәлләреннән санала, ягъни, моны үтәмәү — гөнаһ, әгәр ул үтәлми калса, корбан чалу тиеш була. Мөздәлифәдә ахшам белән ястү намазларын бергә җыеп, ястүне ике рәкәгатькә калдырып, җәмәгать белән укыйбыз. Бу да тетрәндергеч, истә калырлык күренеш булды. Сул якта — чатырлар диңгезе, ак киемле хаҗиларның туктаусыз тибрәлеп торган ак дулкыны, унда — кара кыялар... Юл өстендә, үзәнлектә, үләннәре корыган ташлы чокыр-чакырлар... Һәм шунда без, татар хаҗилары, тезелешеп намаз укыйбыз, имамга оеп укыйбыз. Безнең алда да укыйлар, артта да укыйлар, бөтен тирә-як намазда, әйтерсең лә, бу кыя-ташлар да безнең белән бергә сәҗдә кылалар, Аллаһка ялваралар... Тау аралары, төнге күк, үзәнлекләр Коръән кодрәте белән тулган, Коръән кодрәте белән саклана...

Мөздәлифәдә төне буе вак ташлар җыйдык. Бу ташлар —алдагы көннәрдә шайтанга атар өчен, алар 49 данә булырга һәм зурлыклары борчак зурлыгыннан артмаска тиеш. Барысын да әзерләдек. Коры җиргә чыпталарыбызны җәеп, бераз черем итеп алдык. Монда инде чатыр да юк, коймалар да юк, коры җир өстендә күккә карап ятасың, Мәккә ягыннан искән җилләр хәлебезне белеп китә, Аллаһының фәрештәләре баш очыбызда сакта тора... Төннәребез тыныч булсын. Амин.

**7 апрель.** Бүген Корбан бәйрәме! Иртәнге өченче яртыда барыбыз да аякларга бастык. Бүген иң җаваплы, иң тыгыз, иң саваплы көннәрнең берсе. Мөздәлифәдәге бөтен халык, кубарылып, яңадан Минага кайта, аннан шайтанга таш атарга барасы, корбан чалдырасы бар. Хәер, без корбан өчен акчаларыбызны инде алдан биреп куйган идек, корбанны бездән башка гына чалачаклар. Бу корбан ите ачлыктан, фәкыйрьлектән, җир тетрәүләрдән интеккән мөселманнарга китәсе икән. Шушыларны уйлагач, Хаҗның әһәмияте тагы да үсеп китә, без дә, авыр хәлдә калган өммәттәшләребезгә, дин кардәшләребезгә ярдәм итә алуыбызны уйлап, сөенәбез...

Иртәнге намазны Минада, яңадан үзебезнең чатырлар шәһәрендә укыдык. Яшьрәкләр, хәллерәкләр шайтанга таш атарга киттеләр. Бүген анда кеше аеруча күп булганга, тапталу куркынычын искә алып, бүгенгә безнең ташларыбызны яшьләргә җыеп бирделәр. Китап буенча бу мөмкин иде, мин дә бүген атылырга тиешле җиде ташымны улымның иптәш егете Ленар шәкерткә бирдем. Иншаллаһ, бераз хәл алсам, иртәгә үзем барырмын, шайтанга таш ату әле өч көн бара.

Өлкән яшьтәге берничә хатын-кыз таш атарга дип чыгып киткәннәр иде, тапталып, изелеп, аяк тырнаклары сытылып, көчкә кайтып егылдылар. Кемнәрнедер, ахрысы Король кунакларын, таш ата торган кечкенә генә күпергә машина белән алып кергәннәр. Менә шунда мәхшәр башланган, кешеләр, борыла, чыга алмыйча, бер-берләрен таптый башлаганнар. Шул өермәгә безнең әбиләр дә эләккән. Бәхетебезгә, безнекеләр хәзергә барысы да исән-сау, борылган муен һәм аяклар, төшкән тырнаклар, йолкынган киемнәр хисапка керми. Берничә миллион кеше, бер мизгелдә, бер урында, Хаҗның фарыз гамәле булган эшне башкарырга — шайтанга таш атарга тиешләр. Таш атыла торган урын — тар гына күпердә өч багана — олы багана (иблис), кече һәм урта баганалар (кече һәм олы шайтаннар). Бу йола Ибраһим Пәйгамбәр заманыннан ук калган, Исмәгыйльне корбан итеп бирергә әзерләнгәндә, шайтан, кеше кыяфәтендә, аның улы янына килеп, атасына каршы котырта башлаган. Исмәгыйль атасына бу хакта әйткәч, Ибраһим Пәйгамбәр, "улым, шайтандыр ул, син аны таш атып ку", дигән. Исмәгыйль таш атып кугач, шайтан утка әйләнеп юкка чыккан...

Үземне иртәгесе көнгә әзерлим. Көчем җитәрме минем анда барырга, ул мәхшәргә түзәргә, шул мәхшәрдә исән калырга, кан тамырлары буйлап йөгергән шайтанны үземнән куып чыгарырга? Менә бу шикләнеп, шөбһәләнеп утыру — үзе үк шайтан вәсвәсәсе түгелме соң? 70 яшьлек әбиләр барганны, ник әле минем көчем, кодрәтем җитмәскә тиеш?! Нигә әле мин Алладан ярдәм сорамыйм, төрле юк-бар уйларга бирелеп, үз-үземә ышанмыйча, шушындый зур сынаудан читтә калам?! Әгәр мин бүген үз-үземне, мескенлекне, куркаклыкны җиңә алмыйм

икән, мин алга таба да бер мескен булып калырга мөмкинмен. Бу минем өчен иң куркынычы, хәтта таш ата торган мәхшәр күперендә тапталудан куркынычрак хәл иде. Мин тәвәккәлләргә булдым. Алладан шушы эшләрне башкарып чыгарлык көч-кодрәт, сәламәтлек сорадым. Ташларымны учыма кысып тотып, Мина тавы итәгендәге чатырымда бөгәрләнеп ятып, төнге йокыга талдым. Төшемдә таш янгыры күреп уяндым. Күк йөзе кара-соры икән. Башымны күтәреп карасам, жир йөзенә таш ява! Ләкин берсе дә мина зарар китерми, очып төшүләренә, ереп юкка чыгалар имеш... Бу — Аллаһының бер хәбәре, хәерле хәбәре кебек иде...


**8 апрель.** Корбан бәйрәме дәвам итә. Бүген дә таш атарга баралар. Кичәгедән аермалы буларак, бүген өч баганага жидешәр таш атарга, ягъни, егерме бер таш атарга кирәк иде. Икенде намазыннан соң, сафларга тезелеп, юлга кузгалдык. Без таш атасы урын бер-ике чакрым ераклыкта булып, анда эссе кояш астында, тоннельләр аша барасы икән. Халык коточкыч күп, күпергә житә барган саен, ул тагы да арта, сафлар тыгызлана, кысыла. Кичәге мәхшәрдән соң, безнекеләрне аерым-аерым жибәрмәделәр, рәткә тезеп, як-яктан имамнарыбыз, шәкерт егетләр безне саклап бара. Алла Татарстан байрагы жилферди, жуела башласак, күзләребез белән шул аклы-яшелле байракны эзлибез, шуна омтылабыз. Мин Ленар шәкерткә чытырдатып ябыштым, икенче ягымнан да бер шәкерт мине саклабрак бара. Кәфенлекләребезне муеннарыбызга урап, ташларыбызны учлап, үлемгә барган кебек, күпергә килеп кердек. Калганы — Алла кулында... барыбыз да Алла кулында... барысы да Алла кулында...

Таш ата торган күпер ике катлы булып, без икенче катына мендек. Өч урынга баганалар утыртылган, алар — символик шайтаннар. Таш атуны Мәккәдән иң ерак булган "Джәмәтрус-сугъра" дип аталган баганадан башлыйсың. Аннан читкә чыгып, кыйблага карап, теләгән догаларны укыйсың. Аннан "Джәмәратель-вуста" дип аталган уртадагы баганага "Аллаһу әкбәр" дип, жиде таш атасың, читкә чыгып дога укыйсың, теләк телисең. Аннан соң Мәккәгә иң якын булган "Джәмәратель-гакәбәһ" дигән баганага, "Аллаһу әкбәр" дип, жиде таш атасың да, дога кылмыйча гына китеп барасың. Әгәр шушы рәвешле ташлар атылмаса, Хажың кабул булмаска мөмкин, аннан корбан чалырга кирәк булачак. Кемнән генә сорашсаң да, Хажда иң авыры — таш ату, диләр. Бүген дә күпердә хәл коточкыч иде. Һавада таш яңгыры ява, һәркем үз ташын баганаңың нәкъ үзәгенә тидерергә тырыша. Багана турында күк йөзе соры булып күренә, күзләрне кисеп, әчеттереп, таш тузаны тула. Аяк асты сыңар сандаллар, сынык зонтиклар, тагы әллә нәрсәләр белән тулы. Мин дә аяк киемнәремне тиз генә муенымдагы капчыгыма салдым, киеп керсәң, барыбер төшеп калачак. Беренче баганага ташны кеше башлары аша аткан идек, ни хикмәт, икенче баганага атканда, мин инде чокырның кырыена, багананың каршына ук килеп баскан идем, дөресрәге, шунда этеп керткәннәр иде. Монда халык шулкадәр хискә бирелеп, ычкынып китә, кайберләре шайтанга дип аяк киемнәрен, зонтикларын ыргыта башлыйлар. Ә ул шайтанга түгел, синең башыңа да килеп тиергә мөмкин, чөнки ташны чокыр тирәли аталар, багананы үтеп китсә, ул каршыдагы кешегә тия. Узган ел шулай Татарстаннан бер хатынның күзен бәреп чыгарганнар. Бигрәк тә ислам диненә чагыштырмача яңа килгән африкалылар, негрлар чамадан уздырып жибәрәләр, аларның ташлары да йодрык кадәр, үзләре бөтен кешене таптап-изеп, өскә киләләр. Мин, кечкенә булгач, аларның култык асларыннан гына шуып йөрим. Ул негрларның битләре буразна кебек тырналып, сыдырылып беткән. Алар, хискә бирелеп, "Аллаһ, Аллаһ!" дип битләрен шулай тырныйтырный елыйлар икән. Ирләре дә, хатын-кызлары да шундый. Менә шушылар арасында безнең әби-бабайларыбызга да исән-имин фарыз гамәлләрне башкарып чыгарга кирәк, берни сәбәп була алмый...

Уйларыма бирелеп, башсыз кала яздым. Йодрык кадәр таш, шап итеп, чокыр кырына — барьерга килеп төште. Аз гына иелеп таш аткан булсам, теге зур таш минем башка тияce иде. Фәрештәләр канатларын куеп өлгергәннәрдер инде...

Ташларыбызны атып, барыбыз да бу мәхшәрдән исән-имин чыктык. Дөрес, бер хатыныбызның авызын терсәк белән бәреп канатканнар иде, кемнендер киемнәре ертылган, кемнендер аяк тырнаклары төшкән... Әмма болар — вак

нәрсәләр, иң мөһиме —барыбыз да исән, һәм без тагы кыр казлары кебек тезелешеп, үзебезнең чатырларга кайтабыз. Юлда берничә тоннель аша узабыз. Бу тоннельләрнең берсендә моннан берничә ел элек зур фаҗига булган иде — берничә йөз кеше шушында һава бетеп, тапталып, изелеп үлгән. Ул хакта бөтен дөнья газеталары язды, телевизорлары күрсәтте. Ул чакта җир асты юллары бер генә яклы булган, һава килү туктауга, кешеләр шөбһәләнеп, паникага бирелеп, бер-берләрен таптап, чыгу юлына ташланганнар... Бер-берләрен таптап үтергәннәр...



*Мөхәммәт пәйгамбәр мәчете*

Хәзер ул җир асты юлларында тәртип, анда салкынча, юллар киң, ике яклы, бары тик җәяүлеләр өчен генә. Монда теләнчеләр дә, сатучылар да юк, ә тоннельне чыгуга, алар сине сырып алалар, кулларына ябышалар, артыңнан киләләр. Хаҗда иң авыр тәэсир калдырган нәрсә, мөгаен, шушы гарипләр, теләнчеләр булгандыр. Ходаем, минем мондый гарип-горабаларны беркайчан күргәнем булмады һәм күрергә язмасын да. Бер гәүдәдән чыгып үскән ике башлы кешеләр дисеңме, өч куллы, ярты гәүдәле бәндәләр дисеңме, башның аркага борылып яки корсактан үсә башлаганнары дисеңме — барысы да бар... Алар барысы да дип әйтерлек кара тәнле кешеләр, бирегә читтән китерелгәннәр. Күрәсең, кемнәрдер Хаҗ вакытында шушы бичараларны файдаланып акча, бизнес ясый. Согуд Гарәбстаны Короле, боларны китермәс өчен, хәтта зур акчалар да тәкъдим итеп караган, әмма, юк, төрле юллар белән, хәтта Хаҗ кылу кебек изге эшне сәбәп итеп, ул гарипләр Согуд Гарәбстанына агыла һәм... аяк астына хәер сорашырга чыгып утыра. Хаҗдан алган бөтен тәэсирләрем юкка чыкмасын өчен, мин бу гарипләргә карамаска тырыштым... Йә, Хода, бәддогаларыңнан, каргышыңнан саклый күр, нәселемә шушындый афәтләрне җибәрә күрмә. Гыйбрәтләр алдык, гыйбрәтләрең акылдан шаштырырлык... Рәхмәтләреңнән ташлый күрмә, Раббым Аллам!..

**9 апрель.** Бүген Корбан бәйрәменең соңгы көне. Без 7 апрельне — Корбан бәйрәменең беренче көнен авыр көн дип уйлаган идек, баксаң, иң авыры, иң катлаулысы, иң соңгы сынаулар бүгенгә — бәйрәмнең соңгы көненә калган икән. Без бүген соңгы тапкыр шайтанга таш атарга тиеш булабыз, бүген соңгы көн булганга, бөтен кеше шунда булачак. Аннан соң без җәяүләп Мәккәгә кайтырга тиеш булабыз, чөнки транспортка утырудан мәгънә юк, халык ташкыны арасыннан ул машиналар барыбер бара алмый. Биредән без Һарам мәчетенә кайтып, фарызларның да фарызы булган тәвафны кылырга, ягъни, Кәгъбәтулланы җиде тапкыр әйләнергә тиеш булабыз. Аннан соң җиде тапкыр Сафа һәм Мәрва тауларын атлап-йөгереп үтәргә, мәчеттә намазларыбызны укырга, зәмзәм суы эчәргә тиеш булабыз. Һәм Хаҗ шушында тәмам була, саубуллашу тәвафы эшләргә генә кала. Бүгенге көннең һәр сәгате, һәр минуты бүленгән, без бүген кимендә 40-50 чакрым араны җәяүләп үтәргә, Хаҗның иң мөһим гамәлләрен башкарырга тиеш булабыз. Шуңа күрә иртән иртүк, таң белән, хәлсез карт-карчыкларны, авыруларны автобусларга төяп Мәккәгә озаттылар. Алар өчен ташны башкалар атачак, Кәгъбәтулланы тәваф кылырга аларны төнлә алып барырга уйлыйлар.

Барлык әйберләребезне автобуска төяп җибәрдек. Янныбызда нибары намазлыкларыбыз һәм бер-ике кабымлык ризык калды. Һәм, әлбәттә, бүген атасы ташларыбыз. Мин әле Чаллыдан Роза исемле хатынның да ташларын алып

калдым, чөнки беренче көнне таш атарга барып, ул бик нык биртелеп, аякларын авырттырып кайткан иде. Тәвәккәлләп, аның ташларын атуны да үз өстемә алдым. Хәзер минем кулымда 42 таш. Һәрберсенә берәр минуттан да 42 минут кирәк. Аллаһы Тәгалә ярдәмнәреннән ташламасын инде...

Белмим, язмыш булдымы, күрәчәк булдымы, шул чагында яныма Самара мулласы килеп, аның белән сөйләшеп киттек. Ул дүрт ел Мәдинәдә укыган гыйлемле кеше, әйтеп куйды: "Кәгъбәтулланы тәваф кылу бүген ахшамга хәтле тәгалләнергә тиеш, югыйсә Хаҗ кабул булмый", диде. Ә безнең исәп буенча, икендедән соң таш атып, Мәккәгә җәяүләп кайтып, без төнгә генә Кәгъбәтулланы тәваф кылырга тиеш идек. Инде нишләргә? Безнекеләр кояш сүрелгәнен, кеше азайганын көтеп, чатырларда утыралар. Күп кешенең, шул исәптән хәзрәтләрнең дә инде берничә тапкыр килүе, аларның фарыз Хаҗлары үтәлгән, кайбер хәзрәтләр инде төнлә барып, Кәгъбәтулланы тәваф кылып кайттылар. Әгәр мин Кәгъбәтулланы җиде тапкыр әйләнүне төнгә калдырам икән, димәк, минем Хаҗым кабул булмаячак? Самара мулласы бик өздереп әйтте бит. Нишләргә? Өйләдән соң ук китү турында уйлап та булмый, чөнки көннең иң үтергеч, эссе вакыты, кешенең дә иң күп вакыты шул чагында була диләр. Чөнки өйлә намазын шунда укыган һәр кеше тизрәк фарыз гамәлен башкарырга — соңгы ташларын шайтанга атарга омтыла. Мин бит әле үзем генә бара да алмыйм, иптәш кирәк, бу җирлекне яхшы белгән берәр кеше кирәк.

Өйлә намазын укыгач, көн бераз сүрелә төшкәнен көттем дә, Ижаудан Исмәгыйль шәкертне ияртеп, Киров өлкәсеннән Рәмзия исемле хатын, аның Мәдинәдә укучы абыйсы — бергәләп шайтанга таш атарга киттек. Әле минем бу кадәр дә күп халыкны, бу кадәр дә көйдергеч кояшны, бу кадәр дә мәхшәрне биредә дә күргәнем юк иде. Аны әйтеп тә, аңлатып та, язып та булмый. Күпергә кергәндә, безнең каршыга "Ашыгыч ярдәм" машиналары очрады, һавада вертолетлар бөтерелә иде. Соныннан билгеле булды — без килергә бер-ике сәгать кала, биредә зур фаҗига булган. Өйлә намазыннан соң шайтанга таш атырга дип күпергә тулган халык, ниндидер без белмәгән сәбәп белән, бер-берсен таптый, сыта башлый. Мөгаен, бу очракта да, беренче көндәге кебек, машиналарга утырып таш атарга керүчеләр булгандыр. Кыскасы, кыямәт көнен хәтерләткән бу фаҗига шул хәтле кисәк һәм кискен була ки, нәтиҗәдә 108 кеше бер-берсен таптап үтерә. Мәетләрдән торган бу чоңгылга керерлек тә, чыгарлык та булмый, без килгәндә мәетләрне вертолетлардан чүпләп бетереп килиләр иде... Шул ук вакытта күперне ябарга да ярамый — бүген таш атуның соңгы көне, кешеләр бирегә юлларны япсаң да, япмасаң да ыргылачаклар. Без дә, аяк астында аунаган кеше киемнәренә, чүп-чапракларга сөртенә-сөртенә, алга атладык, чөнки арттан килгән халык безне күпергә кысып диярлек кертте, монда дулкын белән бергә бөтерелеп барып, алар белән бергә генә керергә, алар белән бергә генә чыгып та китәргә мөмкин... Ә минем кулымда 42 таш, алар учымны яндыралар, тәнемә кисеп керәләр, тизрәк чыгып китәргә теләгәндәй, кулымда хәрәкәтләнәләр, кыймылдыйлар, ярсыйлар...

Дулкын безне бөтерә-бөтерә беренче баганаһың чокырына китереп бәрде. Әле генә күргәннәрдән, кичергәннәрдән, ишеткәннәрдән мин шул хәтле тетрәнгән идем, ташларымны берәм-берәм ярсып каршымдагы баганага ата башладым. Мин кырыемдагы ике метрлы негрларны да, калтыранып кына басып торган Индонезия мөселманнарын да, тирәкләрне, хәтта үзебезнекеләрне дә күрмәдем. Минем кулымда 42 таш, һәм аны өч җирдә өч баганага атып бетерергә тиеш идем...

Мин ул ташларны елый-елый аттым... 47 еллык гомеремдә, авырлыкларда, кадерсезлектә бәрелә-сугыла үткән көннәрем өчен идеме бу күз яшьләрем, яшьлектә җибәргән хаталарым, гөнаһларым өчен ачынып үкенү идеме, әле хәзер дә кан тамырлары буенча шашынып чапкан шайтанны, юл өсләрендә сагалап, көтеп утырган шайтанны ярсып-ярсып куарга, анардан котылырга теләү идеме — бер Аллаһы Тәгалә үзе белә... Баш очында кап-кара булып таш яңгыры ява, күзләрдән таш тузаны катыш ачы яшьләр ага, тирә-ягыбызда әле яңа гына вафат булганнарның җаннары леперди... Шуларның барысына да түзәргә, шуларның барысын да күтәрергә, шулардан соң да исән калырга, кеше булып калырга, көчле булып калырга ярдәмнәр итче, Раббым Аллам!!!

Бу сүзләрне бер мин генә түгел, бөтен хаҗилар күккә карап кычкыра,

сорый, ялвара... Без, исән-имин килеш, бөтен фарыз гамәлләрне үтәп, дулкын белән бергә бөтерелеп, читкә чыгарып ташланабыз... Үзебез белән алган шешәләрдән битләребезгә, өс-башыбызга су коябыз. Су җиргә төшеп бетми, очып парга әйләнә, киемнәр шул мизгелдә үк кибеп чыга. Әле безгә ничә чакрымнар барасы, Кәгъбәтуллага килеп егыласы, соңгы фарыз гамәлләрне үтисе бар...

Башта, тәвәккәлләп, җәяү барырга чыктык. Күпер асларыннан, тагы әллә нинди ташландык урыннардан барабыз. Аяк басарлык түгел — бөтен җирдә кеше башы, кеше гәүдәсе, кеше аяклары... Кайсы йоклый, кайсы ял итәргә ауган, кайсының торыр урыны — шушы. Болар — Хаҗга килгән ярлы мөселманнар, аларның бүлмәләрдә кунарлык акчалары юк, шуңа күрә Хаҗны урамда яшәп үтәләр. Бәлки газабы һәм савабы күбрәк булсын өчен шушындый юлга баралардыр. Безнең идәндә, бер кечкенә бүлмәдә унар-унберәр кеше аунавыбыз җәннәт булып күренә башлады. Шактый вакыт кешеләр арасыннан шулай азапланып бардык, әгәр Мәккәгә барып җиткәнче шушы хәл булса, без анда иртәгә дә барып җитә алмый идек. Ачыграк урынга чыгып, такси тотарга тырышып карадык. Теләсә нинди бәягә риза идек — алмыйлар. Йөгерә-ялына торгач, шактый бәягә бер машина ризалык бирде, әмма ул да Мәккәгә җәяүле адымнары белән генә кайтырга мәҗбүр булды. Бераз тын алып, хәл җыярга безгә бу да җитеп торды. Мәккәгә кергәч инде Һарам мәчетен үзебез эзләп таптык. Мәчет янындагы бәдрәфләрнең берсенә кереп, госел коендык, чөнки Кәгъбәтуллага госел-таһәрәтсез якын килергә ярамый. Ә алда әле кыласы гамәл бик күп, Хаҗның иң зур фарыз гамәле — Кәгъбәтулланы тәваф кылу нәкъ шушы мизгелләргә калган иде...

Юлдашларым белән Һарам мәчетенә кереп, бергәләп икенде намазын укыдык. Аннан безнең юллар аерылышты, алар инде алдагы көннәрдә тәваф кылганнар иде, шуңа күрә мәчеттән чыгып киттеләр, ә мин, чиста тәнем һәм җаным белән, тагы Кәгъбәтулла каршына килеп бастым...

Мин тагы Кәгъбәтулла каршына килеп бастым... Мин инде беренче көнне шәкерт итәгенә ябышып Кәгъбәтулланы әйләнгән Фәүзия түгел идем. Ничә көннәр буе Һарам мәчетендә намазлар укып, эсседә көеп, төнге суыклардан өшеп, иДәннәрдә, тау-ташлар араларында аунап, таш атканда тапталып, тырналып беткән, чыныккан, кырысланган, тәвәккәл, куркусыз Фәүзия идем... Кәгъбәтулла янында миллионлаган кешенең кайнашуы да мине куркытмады, иптәшләрсез, бер ялгызым калуыма да борчылмадым — миңа хәзер нәкъ менә ялгыз булырга, бу соңгы фарызны беркемнән дә ярдәм көтмичә, беркемгә дә салынмыйча, курыкмыйча-каушамыйча, бары тик Аллаһының ярдәме белән генә үтеп чыгарга кирәк иде. Миңа үз-үземне җиңәргә кирәк иде...

Кәгъбәтулланы берьюлы өч урында — аста, икенче һәм өченче катларда әйләнәләр. Мин дә өскә менеп китә ала идем, анда, барыбер, кеше азрак булырга тиеш иде. Ә мин аста, Кәгъбәтулланың каршында, миллионлаган кеше арасында тәваф кылырга ниятләдем. Бүген кайчан, нәрсә ашаганымны хәтерләмим, көч алыр өчен зәмзәм суы эчеп куйдым. Тән шундый җиңел, әйтерсең лә, очып китәргә җыенам... Кәгъбәтуллага —Аллаһының йорты каршына, Аллаһы каршына, язмышым каршына... Менә инде мин түгәрәктә. Миңа Кәгъбәтулланы җиде тапкыр әйләнергә кирәк. Иң мөһиме шул — бу фарыз гамәлне а х ш а м г а кадәр, ягъни, кояш баеганчы башкарырга кирәк! Кояш баерга 1 сәгать тә 15 минут вакыт калды... Һарам мәчете диварларындагы сәгать уклары шуны күрсәтә. Беренче түгәрәкне әйләнгәч, сәгатькә карадым — бер әйләнешкә 10 минут вакыт киткән. Димәк, җиде әйләнеш ясау өчен 1 сәгать тә 10 минут вакыт кирәк булачак. Минем минутларым түгел, һәр секундым санаулы, һәр мизгелем, һәр аяк атлавым санаулы, төгәл, тиешенчә булырга тиеш. Ашыгып, йөгереп китеп тә булмый, алда да, артта да кешеләр стенасы, алар, тыгыз рәт булып, бергә шуышалар, бергә баралар, бергә кыймылдыйлар... Аркама, кулларыма хәлсезләнгән карчыклар асылынган, аларның инде үзләренең атларлык хәлләре юк, алар безнең кебек яшьрәкләргә асылынып диярлек баралар...

Дөнья һәм ахирәт өчен булган иң газиз, иң изге теләкләремне теләп калырга ашыгам. Бөтен белгән догаларымны укыйм, Коръән аятьләре укыйм, шыпырт кына тәкъбир, тәлбия әйтәм... Икенче әйләнеш, өченче әйләнеш, дүртенче әйләнеш, бишенче әйләнеш, алтынчы әйләнеш... Ниһаять, җиденче әйләнешкә

— соңгы әйләнешкә керәм... Һәм... Алланың кодрәте! Җиденче түгәрәкне әйләнеп бетереп, яшел нур турына — җәннәт ташы турына килеп җитүгә... ахшам намазына азан яңгырый! Мин өлгердем! Кояш баеганчы Кәгъбәтулланы әйләнеп өлгердем, гомерем кояшы баеганчы, туры юлга — ислам юлына басып өлгердем! Аллаһы миңа бу юлы да ярдәм итте... Соңгы чиккә куеп сыный-сыный ярдәм итте... Ташламады.

Халык белән бергә, тизрәк ахшам намазына егылдым... Гаҗәеп мизгел — Кәгъбәтулла өстендә аяз күктә тулган ай карап тора... Шәфәкъ кызыллыгы мәчетнең мәрмәр диварларында чагыла... Миллионлаган кеше берьюлы Аллаһы каршында тезләнә, ялвара, сорый... Аяз күктә көн белән төн очраша... Көн белән төн хушлаша... Бу елның Хаҗы тәмамланып килә...

Ахшам намазыннан соң, тәртибе буенча, зәмзәм суы эчтем, аннан тагы бер намазымны укыдым. Аннан соң ике тау арасын җиде тапкыр үтәргә кирәк иде — халык дулкыны белән шул юлга кердем. Аяк табаннары инде ут булып яна, оекбаштан гына ике тау арасын үтәм. Тагы Алладан шул теләкләр, шул догалар, шул ялварулар... Тау арасын җиденче тапкыр үткәндә, и Алланың хикмәте — тагы азан — инде ястү намазына чакыру. Бер читкәрәк чыгып, ястү намазы укыдым. Аннан, йотылып, нәкъ Исмәгыйль сабыйның аяк астыннан чыккан урында зәмзәм суы эчтем. Бу су идәннәргә дә ташып чыккан иде, оекбашларым белән салкын суга кереп бастым. Битләремне, кулларымны зәмзәм суы белән юдым. Ут булып янган тәнемә зәмзәм суы сиптем... Аннан нәфел һәм витр намазларын укыдым...

Үзебез яшәгән йортка мин төнлә генә кайтып кердем. Бүлмәдәшләрем минем өчен инде ясин чыгып куйганнар иде. Чөнки бүген таш атканда 108 кеше тапталып үлгән, мәетләр арасында Россия кешеләре дә булуын инде радио-телевидение әйтеп өлгергән булган. Мин аерым киткәч һәм төн уртасына кадәр кайтмагач, алар мине, үлгәнгә санап, инде ясин да чыгып куйганнар... Әй Аллаһы Тәгалә мине бу юлы да саклап калырга уйлаган.

**10 апрель.** Бүген җомга көн. Ял иттем. Көнемне намаз укып, теләк теләп, дога һәм зекердә уздырдым... Мин әле кичәге хәлләрдән айнырлык, аңга килерлек түгел идем... Безнекеләр бүген дә Кәгъбәтулланы әйләнәләр. Дин әһелләре бүген тәваф кылуны да дөрес, диләр. Алла кабул итсен!

**11 апрель.** Бүгенге көннең истәлеге шул булды — без Пәйгамбәребезгә беренче тапкыр Коръән аятьләре иңгән Һира тавында һәм Пәйгамбәребез хиҗрәт кылганда Мәккә кяферләреннән яшеренеп яткан тауда булдык. Дөрес, Хаҗ сәфәрендә боларны үтәү мәҗбүри түгел, ләкин кемнең инде Пәйгамбәребез исеме белән бәйле урыннарны күрәсе килмәсен, бигрәк тә, Коръән иңә башлаган тауны?

Һира тавы каршына килеп баскач, мин тетрәнеп киттем, бөтен тәнем аша электр тогы үткәндәй булды. Бу тау — ике өркәчле булып, берсе шактый биек, шакмак рәвешендә, икенчесе инде бераз ингән, Мөхәммәт галәйһиссәламгә Пәйгамбәрлек килгән тау куышы да шушында икән. Һәр ел Рамазан аеның соңгы ун көнендә Пәйгамбәребез ураза тотып, шушы тау куышында уздыра торган булган.Ул биш ел шулай дәвам иткән. Пәйгамбәребезгә кырык яшь тулганда, 610 нчы елның Кадер кичәсендә, тау куышы кинәт яктырып китә... Һәм "Укы, әй Мөхәммәт!" дигән аваз яңгырый. Пәйгамбәребез һуштан язып, җиргә ава. Күзен ачкач, каршында Җәбраил фәрештәне күрә, ул тагы "Укы!", дип кабатлый. Мәгълүм булганча, Пәйгамбәребез укый-яза белми һәм шул хакта фәрештәгә дә әйтә, әмма, аңа карамастан, Җәбраил үзенең әмерен өченче тапкыр кабатлый. Җәбраил фәрештәнең ярдәме белән Пәйгамбәребез "Галәк" сүрәсенең баштагы биш аятен укып чыга...

**"Укы, әй, Мөхәммәт! Сине бар иткән Раббыңның исеме белән — укы! Ул кешене кан кисәгеннән бар итте. Укы — синең Раббың бик хөрмәтле һәм юмарттыр. Ул — кешегә белмәгәннәрен белдерткән, каләм белән язуны өйрәткән Раббың — иң бөек кәрәм ияседер."** *("Галәк" сүрәсе, 1-5 аятьләр.)*


Пәйгамбәребезгә башта хатыны хәзрәти Хәдичәдән кала беркем ышанмый, аннан соң хәзрәти Әбүбәкер, хәзрәти Гали һәм хәзрәти Зәйд ислам динен кабул итәләр. Башкалар аңа ышанмыйлар, "ул тиле шагыйрь" диләр, үтерү белән яныйлар, башына тизәкле мал карындыклары кидереп китәләр. Өч ел эчендә ул бары тик утызлап кына кешене ислам диненә күндерә ала. Калганнары һаман үзләренең мәҗүси диннәрен тоталар — сыннарга табыналар, зина кылалар, исерткеч эчемлекләр

әчәләр, яна туган кыз балаларны үтерәләр. Мәккә кяферләре белән унөч ел шушылай көрәшкәннән соң, динебезне саклап калу өчен, Пәйгамбәребез, мөселманнар белән бергә, Мәдинә шәһәренә күчәргә мәҗбүр була. Дин дошманнары, үтерү нияте белән, аның артыннан куа чыгалар...

Без каршында басып торган икенче тау — Саур тавы, ул да Мәккәдән ерак түгел. 622 нче елны, Мәккә кяферләренең явызлыгына түзә алмыйча, Пәйгамбәребез Мәдинәгә күчәргә, ягъни, һиҗрәт кылырга мәҗбүр була, дигән идек. Мәккә кяферләре, Пәйгамбәребезне үтерү нияте белән, аны куа чыгалар. Пәйгамбәребез, хәзрәти Әбүбәкер белән шушы тау куышына кереп кача. Ул арада, Аллаһының хикмәте белән, тау куышының авызына үрмәкүч пәрәвез кора, күгәрчен шунда йомырка сала. Куа килүчеләр тау куышы янына килеп туктыйлар, инде сөйләшкән тавышлары да ишетелә башлый. Шунда хәзрәти Әбүбәкер әйтә: "И, Рәсүлуллаһ, хәзер безне тотарлар инде", ди. Пәйгамбәребез әйтә: "Син монда безне икәү генә дип уйлыйсыңдыр, юк, без икәү түгел, өчәү", ди. "Беренче —Аллаһ, аннан син һәм мин", ди. "Курыкма, тапмаячаклар", ди. Куа килүчеләр тау куышының авызы пәрәвез белән капланганны, анда күгәрчен йомыркасын күргәч, "Юк, монда күптән кеше аягы басмаган", дип, кереп тә тормыйча, кире китәләр...

Пәйгамбәребезнең тормышында да, мөселманнар язмышында да тау куышлары, мәгарәләр аерым бер урын алып тора. Коръәндә хәтта "Кәһаф" — "Тау тишеге" сүрәсе дә бар. Кяферләрнең явызлыгына түзә алмыйча, жиде мөселман тау куышына кереп бикләнәләр һәм Аллаһының кодрәте белән 300 ел буе мәрткә китеп торалар. Дөньялар үзгәргәч, Аллаһ аларны яңадан терелтә, кешеләргә гыйбрәт итеп, Аллаһының барлыгына һәм берлегенә дәлил итеп күрсәтә, кыямәт көненең хаклыгын белгертә, һәм мөселман булганнары хәлдә, аларны бу дөньядан алып китә. Бу мөселманнарның 300 ел буе тау куышында бозылмыйча, тәннәре вә жаннары пакь килеш ятулары Коръәндә шул хәтле жентекләп язылган ки, медицинада шушы аятьләр буенча гына да зур фәнни ачышлар ясарга мөмкин. Кояш уң тарафтан төшсә дә, сул тарафтан төшсә дә мәрткә киткән бу мөселманнарга кагылмый, аларның күзләре һәрвакыт ачык, тәннәре бозылмасын өчен, Аллаһының фәрештәләре аларны уңга һәм сулга әйләндереп торалар...

Килә бер көн, тирә-юньдәге бозыклыкка, имансызлыкка каршы адәм баласы күңелендә булса да Т а у к у ы ш ы корырга мәҗбүр була. Бу — һич кенә дә тау куышына кереп качу түгел, бу — күңелендә тау куышы корып булса да, дөньядагы пычраклык белән араны өзү, шулай итеп иманыңны, жаныңны саклап



*Изге Мәккә шәһәре*

калу дигән сүз. Бу юлны безгә Аллаһы Тәгалә үзе күрсәтә: **"Бер Аллага гыйбадәт кыласыгыз килсә, тау куышына кайтуны теләгез. Раббыгыз сезгә үзенең рәхмәтен киң кылыр. Һәм Раббыгыз сезгә эшегезгә карата файданы хәзерләр."** *("Тау тишегe" сурәсе, 16 нчы аять.)*

**12 апрель**. Иртәгә төнлә без Мәккәдән китәргә тиешбез. Без инде бу шәһәргә, бу урамнарга, бу тауларга, үзебез торып яткан менә бу йортка да ияләнгән идек. Мәккәнең үзендә даими 600 меңләп кеше яши, ягъни, кеше саны ягыннан Чаллы кадәрле бер шәһәр ул. Мәккәнең мәйданы исә 4800 гектар җирне алып тора икән. Ул инде Ибраһим Пәйгамбәр заманында ук төзелә башлап, тарихта "Өм Әль Кура", "Вубка", "Әль Бәләд Әль Әмин" исемнәре белән дә йөртелгән, бу хакта Коръәндә хәбәрләр бар. Мәккә — Согуд Гарәбстанының башкаласы түгел, ә бәлки бөтен дөнья мөселманнарының рухи башкаласы. Бу шәһәрдә чисталыкка, бәдрәф һәм канализацияләрне тәртиптә тотуга, халыкны даими рәвештә су белән тәэмин итүгә зур игътибар бирәләр. 23 мең кеше көне-төне бары тик урамнарны чистарту, мәчетләрне тәртиптә тоту, чүп чыгару белән генә шөгыльләнә икән. Согуд Гарәбстаны диңгез суын төчеләндерү буенча дөньяда беренче урында тора, шуңа күрә ком чүлләрендә дә, тау араларында да суга мохтаҗлык юк, Гарәбстанның теләсә кайсы почмагына Кызыл диңгезнең бетмәс-төкәнмәс суы, төчеләндереп, торбалар аша куылып тора. Хәтта 70 градус эсселектә дә бөтен җирдә дә су бар, тереклек бар, чисталык бар...

Бу җирләргә Аллаһы Тәгалә пәйгамбәрләр, изге китаплар гына җибәреп калмаган, ком чүлләренең асларын иксез-чиксез байлык белән дә тутырган. Әмма бу байлыкны халык тәмам ислам диненә кайтып, Коръәнчә яши башлагач кына ачкан. Сүзем — Согуд Гарәбстанының төп байлыкларының берсе булган нефть турында. Бүгенге көндә нефть сатудан кергән акча дәүләт кеременең 92 процентын тәшкил итә, ягъни, бу ил нигездә нефть саткан акчага яши, чәчәк ата. 1987 елга Согуд Гарәбстаны 225 миллион тонна нефть чыгарган булган, шушы акчаларга аякка баскан, дөяләрдән "Мерседес"ларга күчеп утырган, чатырлардан, җир куышларыннан мәрмәр сарайларга чыккан, дөньяда иң алга киткән илләрнең берсенә әверелгән. Ә Татарстан җиреннән 2 миллиард тонна нефть чыгарылган иде бит! 2 миллиард тонна!! Шуңа карамастан, күп татар авылларында һаман коеяннтә белән су ташыйлар, урманнан урлап утын ягалар, яз-көз җитсә, пычрак-сазда йөзәләр... Аллаһы безгә дә байлыкны бирде, әмма, иманыбыз зәгыйфь булу сәбәпле, без аның кадерен белмәдек, җилгә очырдык, сарыф иттек, һәм, нәтиҗәдә, Аллаһының ачуына дучар булдык. Нефть безгә бәрәкәт түгел, бәла китерде, суыбызны, һавабызны, үзебезне, нәселебезне агулады... Без бу сынауны да үтә алмадык.

Согуд Гарәбстанының әле 23 миллиард тонна чыгарасы нефть запасы бар икән. Бирсен ходa, бәрәкәте булсын. Әмма гарәпләр бер нефтькә генә салынып, аркаланып ятмыйлар. Соңгы ун-унбиш елда Согуд Гарәбстаны авыл хуҗалыгы өлкәсендә бөтен дөньяны таң калдырырлык уңышларга ирешә... Ул хәзер үзе дөньяга ашлык сата торган илгә әйләнде, моның буенча җир шарында алтынчы урында тора. Яхшы сортлы бодайдан тыш, дөнья базарына сусыл җәннәт җимешләре, ит, сөт, май, балык та чыгарыла, үз халкының өстәле дә шушы нигъмәтләрдән сыгылып тора. Аллаһы Тәгалә иманлы бәндәләренә ике дөньяның да бәрәкәтләрен, ике дөньяның да дәрәҗәләрен бирә шул...

Дәүләт җирдә эшләүчеләрне бик нык яклый һәм саклый. Әйтик, ул эшләргә теләгән кешеләргә җирне бушка бүлеп бирә, аларга процентсыз кредитлар бирә, ашламаның ярты бәясен дәүләт үз өстенә ала. Шулай ук җирдә, авыл хуҗалыгында эшләүчеләрне су насослары, авыл хуҗалыгы техникасы белән тәэмин итүне дә дәүләт яртылаш үз өстенә ала, моннан тыш дәүләт авыл хуҗалыгы продукцияләрен саклау өчен склад-суыткычлар төзүгә даими рәвештә ссудалар биреп тора, әзер продукцияне сатарга да булыша. Кыскасы, эшлә генә, үзеңә дә, илеңә дә сөенеч китер, бает, рәхәттә яшә. Күргәнебезчә, дәүләт моның өчен бөтен шартларын тудырган. Гарәбстанда җиргә хуҗа эзләп йөрмиләр, җирнең дә, бөтен дөньяның, галәмнәрнең Хуҗасы — Аллаһы Тәгалә икәнен алар бик яхшы беләләр, шуңа күрә Аллаһ кушканча, Коръән буенча яшиләр. Шуңа күрә Аллаһы Тәгалә дә аларга байлыкны, бәрәкәтне мене белән бирә, нигъмәтләренең берсен дә хакыйки мөселманнардан кызганмый. Аллаһы Тәгалә рәхимле, рәхмәтле, шәфәгать иясе...

...Бүген мине бик нык рәнҗеттеләр... Адәм баласы кайда да адәм баласы шул... Урамда да кинәт кенә җил-давыл кузгалды. Әйтерсең лә, минем җаным булып, табигать үзе кайный, үзе бәргәләнә иде...

**13 апрель.** Бүген төнлә без Мәккәдән аерылырга тиешбез... Бүген без Кәгъбәтулла белән саубуллашырга, ягъни, "саубуллашу тәвафы" кылырга тиешбез. Олы Хаҗда ул — важеб гамәл, аны үтәү шарт. Саубуллашу тәвафын кылганнан соң инде Мәккәдә берни сатып алырга да, дөньяви ыгы-зыгылар белән шөгыльләнергә дә ярамый. Әйберләребезне алып, без Мәккәдән чыгып китәргә тиеш булабыз. Мин Кәгъбәтулла белән саубуллашуны иртәнге намаздан соң кылырга уйладым. Иртәнге намазны җәмәгать белән йортыбызның ишегалдында укыдык, аннан соң мин иртәнге салкынчада Һарам мәчетенә ашыктым. Кояш чыкканчы, төн белән көн тәмам очрашканчы, соңгы тапкыр Кәгъбәтулланы күрәсем, соңгы тапкыр иң изге теләкләремне әйтәсем, Кәгъбәтулла белән табигатьнең серле бер мизгелендә саубуллашасым, бәхилләшәсем килде...

Мин саубуллашу тәвафын Һарам мәчетенең түбәсендә кылырга ният иттем. Бу урын күкләргә якынрак кебек тоелды. Мәчетнең түбәсе дә, икенче кат та, бөтен яклары да Кәгъбәтулланы чорнап алган. Биредә дә тәваф кылучылар күп, ләкин астагы кебек үк түгел. Ә аста бер дә кеше кимеми, мөгаен, алар да безнең кебек соңгы тәвафларын кылалардыр, Кәгъбәтулла белән саубуллашалардыр...

Түбәгә менеп баскач, күкрәкләрем киңәеп китте. Күз алдымда илаһи манзара ачылды. Бер яктан тулган ай мөлдерәп карап тора, икенче яктан шәфәкъ кызыллыгы беленеп килә.. Кояш әле чыкмаган, әмма хәбәре бар. Күктә каурый болытлар йөзә... Минем мондый вак, тетелгән, төтен кебек болытларны беркайчан да күргәнем юк иде әле. Таң яктысы ныграк таралган саен, ай тоныклана бара, чигенә, галәм киңлегенә кереп чума... Мин, сызылган махсус юл буенча, Кәгъбәтулланы әйләнә башлыйм. Таң җиле минем керфекләремдә эленеп торган яшь тамчыларын таулар арасына алып китә, ул эчкерсез күз яшьләрем Гарәфәт тауларына, Нур тауларына, Мина һәм Мөздәлифә тауларына бәлки иртәнге чык булып төшәр, таш араларында үскән гөлләргә яңгыр тамчысы булып тоелыр, таңнарда сайраган былбылларга зәмзәм суларын хәтерләтер... Хуш, Кәгъбәтулла, хуш, Мәккә, хушыгыз, инде яратып өлгергән кырыс тауларым! Сез мине — яшел болыннардан, кара урманнардан дөреслек, хакыйкать эзләп килгән бер авыл баласын, татар кешесен чит итмәдегез, серләрегезне ачтыгыз, көч-гайрәт бирдегез, үзегездәге нурны һәм хикмәтне минем белән дә уртаклаштыгыз. Мин сезнең хакта илемә дә кайтып сөйләрмен, сагынып, елап, сокланып сөйләрмен... Мең ел иман белән, кыйбла белән, Коръән белән




*Король Абдул Азиз исемендәге аэропортның хаҗга килүчеләрне каршылау залы*

яшәгән милләтемнең НӘРСӘЛӘР югалтуын, шушы изге төшенчәләрне НӘРСӘЛӘРГӘ алмаштыруын аңлатып, ачына-ачына сөйләрмен. Аңламасалар да, тыңламасалар да, хәтта дошман итсәләр дә, динебез турында, Мәккә турында, Кәгъбәтулла турында — сезнең хакта сөйләрмен. Мин бирелән шушы изге амәнәтне алып, илемә китәм. Раббым, юлларымны хәерле кыл сана...

Без китәбез... Мәккәдән Мәдинәгә китәбез, аннан, Алла кушса, Казанга... Кичкә таба Мәккә күген болытлар каплап алды, көтмәгәндә генә жил-давыл чыкты. Аннан, Мәккә күген төрле урыннан кискәләп, яшен кылычлары уйнаклый башлады. Бөтен Мәккәне дер селкетеп, күк күкрәде, Мәккә өстенә тоташ гүләү җәелде. Кичке энгерне яшен уты торган саен ныграк яктырта барды...

Күк күкрәүне җиңеп, Мәккә өстендә азан тавышлары яңгырады. Яшен яктысы астында, барыбыз да, бердәм булып, ишегалдына ахшам намазына тезләндек. Бу безнең Мәккәдә укыган соңгы намазыбыз иде. Күк күкри, яшен яшенли, давыл уйный. Ә без намаз укыйбыз! Башыбызга, битләребезгә, аркаларыбызга яңгыр тамчылары бәрә — ә без намаз укыйбыз!! Көчле җилдән агачлар каерылып чыга, йорт почмагыннан дөбердәп ташлар коела — ә без намаз укыйбыз!!! Йөзләребездән, яңгыр тамчылары белән аралашып яшь ага, намазлыкларыбызны жил алып очыра, ә без, Мәккә урамында яңгыр суына тезләнеп, намаз укыйбыз... Бу безнең Мәккәдә соңгы намазыбыз, саубуллашуыбыз, бәхилләшүебез... Рәнҗемә безгә, изге кала, рәнҗемәгез безгә, кырыс таулар, бәхил булыгыз, сау булыгыз, имин булыгыз...

**14 апрель.** Төнге сәгать икеләрдә, өч автобуска төялеп, Мәдинә шәһәренә кузгалган идек. Мәккә белән Мәдинә арасы — 450 чакрым. Без бу араны төнлә үтәргә тиешбез, чөнки көндез бик эссе, көнне дә юлга әрәм итәсе килми. Мәккә шәһәре безне күз яшедәй чиста яңгыр тамчылары белән озатып калды. Без хәзер менә, тулган айны юлдаш итеп, Мәдинә шәһәренә барып ятабыз. Юллар киң һәм чиста, ялт итеп тора. Шуңа күрә автобусларның тизлекләре бик зур. Автобус эчендә, гүләп, конденционерлар эшләп тора, алар бертуктамый салонга суык һава кудыралар. Автобус эче шулкадәр суынды ки, әбиләр, калтыранып, үзләре белән алган бишмәт-пальтоларына, мамык шәлләренә урана башладылар. Аларны кызганып, салкынны туктаткан идек, автобус эче бер мизгелдә кызу мунчага әйләнде дә калды. Йоклау түгел, сулыш та алып булмый. Шулай бер туңып, бер пешеп, өйлә турында Мәдинә шәһәренә килеп егылдык. Ун сәгать кыймылдамый утырып килеп, аяклар төбе кебек шешенгән, билләр каткан, баш миңкегән иде. Кызу кояш астында, шыбырдашып, шәһәр урамнарына коелдык. Күзгә иң беренче ташланган нәрсә — шәһәрнең гаять чисталыгы һәм яшеллек булды. Мәккә шәһәрендә һәр агач төбенә кран куеп, агачларны су сибеп кенә үстерсәләр, Мәдинә урамнарында яшеллек урыны-урыны белән урмандай кебек иде...

Мөселман кешесен барлык юллар да кая илтә? Мөселман кешесен барлык юллар да мәчеткә илтә. Без дә, ару-талуларыбызны, ашамаган-эчмәгәнне онытып, Пәйгамбәребез мәчетенә юнәлдек. Бу мәчет, әһәмиятлелеге ягыннан, Мәккәдәге Баш мәчеттән кала, икенче урында тора. Башта, мәчет янындагы заманча бәдрәфләргә кереп, госел коендык. Аннан ирләр —аерым, хатын-кызлар аерым ишекләрдән кереп, мәчеттә өйлә намазын укыдык. Мәккәдәге Һарам мәчетеннән аермалы буларак, Пәйгамбәребез мәчетендә ирләр һәм хатын-кызлар заллары аерым, бик уңайлы. Мәчетнең эчендәге чисталыкны, матурлыкны сөйләп тә аңлатырлык түгел. Идәннәргә затлы келәмнәр җәелгән, түшәмнәр шәрыкъчә зәвыклы итеп бизәлгән. Рәт араларында зәмзәм суы салынган савытлар тезелеп киткән...

Мин көнемне шушы мәчеттә намаз укып уздырдым. Пәйгамбәребез бу мәчеттә укыган намазны башкаларныкыннан мең мәртәбә хәерлерәк, савaплырак, дигән. Өйлә, икенде, ахшам намазлары арасында, Иран, Индонезия, төрек хатыннары белән бергәләп, зекер әйтеп, тәсбих тартып утырдым. Арып киткәч, башымны кыйблага куеп, бераз ял да итеп алдым. Бу мәчет бүген минем йортым да, гыйбадәтханәм дә, сыеныр, ял итәр урыным да иде.

Шушы мәчеттә үк Пәйгамбәребезнең кабере, аның янәшәсендә — хәзрәти Әбүбәкернеке, хәзрәти Гомәрнеке. Барысының да рухлары шат булсын, дип догалар кылабыз. Пәйгамбәребез үзе исән чагында ук әйтеп калдырган: **"Мине вафатымнан соң зиярәт иткән кеше, әйтерсең, саулыгымда зиярәт иткән кеше кебектер"**, дигән. Аның Кaберемне зиярәт иткән кешегә шәфәгатем вәҗиб булыр , дигән хәдисе дә

бар. Пәйгамбәребез дә үзенең өммәтенең — мөселманнарның догаларын көтә, ислам динен дөрес итеп, үзе өйрәтеп калдырганча алып баруларын өмет итә. Әмма, кызганычка каршы, ислам диненә дә төрле мәҗүси элементлар, бидегать гамәлләр көннән-көн ныграк үтеп керә башлады. Пәйгамбәребез кабере тирәсендә барган ыгы-зыгылар да вакыты-вакыты белән мәҗүсилекне хәтерләтә башлый. Кешеләр, берсен-берсе этә-төртә, каберлеккә омтылалар, хискә бирелеп, битләрен тырныйлар, елыйлар, кулллары белән орынырга тырышалар. Болар барысы да гөнаһ эшләр, диннән чыгу, мәҗүсилек. Пәйгамбәребез баш очында тыныч кына укыган бер дога — иң саваплы эш булачак. Хатын-кызга исә, кабер тирәләрендә йөрү, гомумән дә килешә торган эш түгел... Шуңа күрә мин Пәйгамбәребез рухына догаларымны да аның изге мәчетендә кылдым, мәчеттә сорадым...

Кичкә таба шатлыклы хәбәр җиткерделәр — безне Казанга алып китәсе самолет туп-туры Мәдинәгә килә икән! Әле Җиддәгә барып, шуннан очу каралган иде, менә хәзер самолетны Мәдинәгә үк китертергә булганнар. Тилмергән, арыган әбиләр куанышалар. Ястү намазыбызны укугач, туп-туры аэропортка юл тоттык. Әмма барысы да без уйлаганча булып чыкмады. Автобусларга төялеп, Мәдинә шәһәре аэропортына килеп төшкәндә, сумкаларына "Казан" дип язылган яп-яшь ир-егетләр без очасы самолетка утырырга баралар иде. Соңыннан билгеле булды, "Король кунаклары"ның бер өлеше, кайта алмыйча, аэропортта калган. Россия консулы үзе килеп, безгә дигән самолетка аларны утыртып җибәргән. Безне кире бордылар...

Безнең Мәдинәдә кунар урыныбыз юк иде. Шоферларыбыз төнгә юлга чыгудан баш тарттылар. Без, чыпталарыбызны җәеп, Мәдинәнең таш урамнарына сузылып яттык...

300 мең кешелек бу шәһәр төнлә бер дә йокламый ахры —урам тулы халык. Әллә болар да безнең кебек килгән кешеләр микән? Мәккәдә урамда яткан кешеләрне күреп, гаҗәпләнгән һәм кызганган идем. Урамда калу бик тиз икән. Һәм бер дә авыр, уңайсыз хәл түгел. Мәдинә урамнарында сандалларым тузып, ертылып төшеп калды. Янымда башкасы юк, алырга акчам да юк. Кайда оекчан, кайда яланаяк йөрим. Мин бу халәтемне күп еллар элек төшемдә күргән идем инде, кайсы шәһәрдә шулай яланаяк йөресемне генә чамаламаган идем. Ул, менә, Мәдинә булып чыкты. Тәкъдирнең яхшысы да, яманы да — Аллаһы Тәгаләдән. Безнең арыган, хәлсезләнгән, авыру килеш таш урамнарда аунавыбыз да Аллаһының бер сынавы. Егерме көн буе авырлыкларның төрлесенә түздек, сынауларның төрлесен кичердек, менә хәзер, сукбай хәленә куеп, Аллаһы безне урам белән сыный. Шушы хәлдә дә су табып, тәһарәт алырга, намаз укырга, сабыр булырга кирәк. Халык түзә. Кемдер шаярган була, кемдер үзендә булган соңгы ризыгы, суы белән уртаклаша. Кемдер әле бушка чәй өләшкәннәрен күреп кайткан, без, татарга, чәй генә булсын, барыбыз да шунда йөгерәбез...

Төнге күккә карап, Мәдинә урамнарында ятам. Аста — бер намазлык, өстә юка күлмәк... Аның каравы мин Пәйгамбәребезне якын иткән, үзенә сыендырган, исламның беренче башкаласы булган бөек шәһәрдә төн кунам. Минем туктап уйланырга, күргәннәремә бәя бирергә, нәтиҗә ясарга вакытым күп. Пәйгамбәребезнең язмышы, ул үзе туганчы ук, шушы мөбарәк шәһәр белән бәйләнгән була. Пәйгамбәребезнең әтисе Габдулла сәүдә эше белән шөгыльләнә торган була. Шушы максат белән ул Мәккәдән Мәдинә шәһәренә китә һәм шунда үлеп кала. Бу хәл Пәйгамбәребез туарга ике ай кала була — Аллаһы аны туганда ук ятимлек авырлыгы белән сыный. Пәйгамбәребез, алты яшьләрендә, әнисе Әминә белән Мәдинә шәһәренә, әтисенең каберен күреп кайтырга китә. Алар анда бер ай чамасы яшиләр. Юлда кайтканда Пәйгамбәребезнең әнисе авырып китә һәм үлә. Кечкенә Мөхәммәт бөтенләй ятим кала... Әмма бу әдәпле, эчкерсез кешене, тәкъдирендә үк Пәйгамбәрлек язылган бәндәсен Аллаһы ташламый, дөньяның иң авыр сынауларын биреп сыный-сыный да, аңа кешелек дөньясында булган иң зур, иң бөек, иң авыр, әмма иң саваплы эшне — ислам динен тарату бурычын тапшыра.

Иң авыр вакытларда Мәдинә шәһәре Пәйгамбәребезне үзенә сыендыра. Мәдинә халкы йомшак күңелле, ихлас мөселманнар булалар, әмма дин өчен сугышларда алар үзләрен арысланнарча тоталар, Аллаһы ризалыгы өчен үлемнән курыкмыйлар, Пәйгамбәребезгә ияреп, берничә тапкыр Мәккәгә сугыш белән

баралар, Мәккәне алалар, Кәгъбәтулладагы сыннарны чыгарып бәрәләр, Мәккә өстенә ислам байрагын кадыйлар... Пәйгамбәребез шушында, Мәдинә шәһәрендә картаеп үлә, шушында күмелә, рухы әти-әнисеннән ерак китми, истәлеге мөселманнар күңелендә мәңгегә кала...

...Сәгать иртәнге 4 ләр тирәсе. Иртәнге намазга кисәтү азаны яңгырый, әмма әле намазга иртәрәк булырга тиеш — күк читендә әле таң яктылыгы күренми. Ул арада безне автобусларга төйи башлыйлар. Шәһәр читендәге бер чәйханәгә кереп, юынабыз, чистарынабыз, иртәнге намазга әзерләнәбез... Һәм таң вакыты кергәндә, Мәдинәне калдырып, юлга кузгалабыз...

**15 апрель**. Һәм таң белән без тагы юлга кузгалабыз. Автобуста иртәнге намазыбызны укыйбыз. Кузгалып китәр алдыннан безгә игелекле бәндәләр бушка азык-төлек, зәмзәм сулары таратып чыгып киткәннәр иде, бераз капкалап алдык. Без хәзер Җиддә шәһәренә — халыкара аэропортка барабыз. Безгә дигән самолет йә бүген төнлә, йә береаздан килергә тиеш, диләр. Иншаллаһ, монда яткырмаслар, калам дисәң дә калдырмаслар, ул яктан монда тәртип бик нык, хәтта Мәдинә шәһәренә дә һәрберебезне санап керттеләр, санап чыгардылар. Биредән Җиддә аэропортына 400 чакрымнар, диләр. Әбиләр батырларча түзә. Көн кызуында юлда бару шактый авыр икән. Конденционерлар еш кына ватыла, эштән чыга башлады. Мунчада барган кебек барабыз. Аяклар гөбе кебек шеште, аларны кая куярга да белмибез. Мин фәкыйрегез, гомумән, яланаяк, мин аны сизмим дә, әсәрләнеп, тәрәзәдән тирә-якны күзәтәм. Мин, юлда йөрергә бик яратам, бер генә мизгелемне дә бушка әрәм итәсем килми, йотлыгып, изге җирләрне карыйм, бу манзараларны күңел түренә салып куям, шушыларны күрә алуыма куанам...

Мәдинә белән Җиддә арасында да таулы урыннар күп, әмма мондагы таулар Мәккәдәге кебек түгел, алар шактый тәбәнәк һәм күбрәк таш-балчык катламыннан торалар, ахры. Һәрхәлдә, кара мәрмәр кыялар түгел инде. Тау араларында сирәк-мирәк кәрлә куаклар күренеп кала. Тигезлек дигән урыннарында да көйгән каты балчык кына күренә. Моның кай төшендә арыш-бодай үстерәләр дә, кай төшендә җәннәт җимешләре җитештерәләр икән соң? Хәер, сирәк кенә яшел утраучыклар — оазислар да очрый. Алар тирәсендә озын муенлы дөяләрнең һәм тагы нинди дер хайваннарның йөргәннәре күренә. Безгә юл өстендә шәһәрләр, авыллар, кеше заты очрамады диярлек...

Шулай итеп, көндезге сәгать 11 ләр тирәсендә Җиддә аэропортына килеп җиттек. Әйткәнемчә, бу аэропорт мәйданында алдан ук бөтен урыннар иле-иле белән бүленгән була, безнең урын инде, һәрвакыттагыча, юк, без бу юлы төрекләр янына барып баш төрттек. Кая барсаң да, әле дә ярый шул төрекләр бар, беркайчан татарны ярдәмнәреннән ташлаганнары юк. Төенчекләребезне дә бушаткач, шактый зур урынны алып, иркенәеп, аякларыбызны сузып, Җиддә аэропортының таш мәйданында самолет көтә башладык. Монда бездән башка да хаҗилар күп, барысы да илләренә ашыга, илләренә ашкына... Шунысын да әйтергә кирәк, аэропортның бу терминалыннан бары тик хаҗилар гына оча. Монда барысы 310 павильон бар икән. Аэропортта атлаган саен ялт итеп торган бәдрәфләр, душ керү урыннары, намаз уку өчен махсус урыннар, ашханәләр, чәйханәләр, медпунктлар, банклар, тагы әллә нәрсәләр... Кыскасы, Җиддә аэропорты үзе бер шәһәрчек, үзе бер дөнья...

Инде өйлә, икенде, ахшам намазларын да укып куйдык. Караңгы төште, мәйданда утлар кабынды. Самолет кайчан килер, билгеле юк. Без инде аңа да бик борчылмыйбыз. Ахыры хәерле булсын, әле беркемнең дә юлда утырып калганы юк, насыйп булса, илләргә дә кайтырбыз... Инде ястү намазын да укыдык... Гарәп җирләренә төн килде. Әбиләребез, башларын төенчекләренә төртеп, сабый балалар кебек йокыга киттеләр. Төшләрендә бәлки алар әле һаман Кәгъбәтулла тирәсендә әйләнеп йөриләрдер, Гарәфәт тавында намаз укыйлардыр, бәлки инде, хыялларында, төшләрендә генә булса да илләренә кайтып, яраткан оныкларын сөяләрдер, аларга дип алган Хаҗ күчтәнәчләрен тараталардыр... Илгә имин кайтып җитсәгез иде, газиз әбиләр...

Төн уртасында безне самолетка утырта башладылар. Бер генә кешебезне дә югалтмыйча, җуймыйча, исән-имин килеш, кулларыбызга зәмзәм сулары тотып без үзебезне алып килгән Башкортстан самолетына яңадан аяк бастык. Таң әле атмаган

иде... Без әле илләргә кайтып житмәгән идек... Төнге күк безне, Хаждан кайтып килүче татар кешеләрен, үз кочагына алды, без, Аллага тапшырып, юлга кузгалдык...

**16 апрель.** Без бик озак кайттык... Тагы Берләшкән Гарәп Әмирлекләрендә тукталыш ясадык, тагы көттек, тагы сабыр иттек... Иртәнге намазны самолетта укыдык, көндезге намазны самолетта укыдык, кыйбладан Казан тарафына карап, очтык та очтык. Безгә бу юлы самолетта ашарга да бирмәделәр, эчәргә дә бирмәделәр, кемдә нәрсә бар, шуның белән бүлештек, шуңа канәгать булдык. Мәккәдән чыгып киткәнгә өч тәүлек булганда, кичке якта, ниһаять, исән-имин Казан каласына кайтып життек. Казан безне ап-ак карлары, әле эремәгән бозлары, салкынча жилләре белән каршы алды. Монда жәй түгел, әле язның да эзе юк иде. Шуңа карамастан, һәр кешене кочаклап үбәсе, һәр каенны кочаклап елыйсы, тун булса да, үз жиреңә, үз туфрагыңа ятып сабый бала кебек аунаысы килә! Хаждан кайтучының күңелендәге хисләрен сөйләргә әле сүзләр табылмаган, аны сөйләп тә булмый, ул хисләрне үзеңә кичерергә, үзеңә татып карарга кирәк... Күбебез нык кына чирләсә дә, кайберләребезне самолеттан ике яктан култыклап алып чыксалар да, бу мизгелләрдә дөньяда бездән дә бәхетле кеше юк иде, без күп газаплар үтеп, жәннәткә эләккән кешеләр кебек куанычтык, безнең күңелләребез, кош булып, очып китәргә әзер иде, без әле, әйтерсең лә, һаман жиргә төшмәгән, һаман Мәккә-Мәдинә өсләрендә очабыз, мәңгелеккә таба очып барабыз кебек иде...

*Хаж көндәлегем тәмам. Мин аны, июньнең иң чиллә көннәрендә, 35-38 градус эсселектә ак кәгазьгә күчереп утырам. Барысы да яңадан күңелемдә терелә, уяна, хәрәкәт итә башлый... Минем ак кәгазьдән, бу хатирәләрдән, бу илаһи манзарадан аерыласым килми, кипшергән иреннәремне зәмзәм суы белән чылатам да, милләттәшләремә тагы күңелемдә булганнарымны, Хажда күргәннәремне сөйли башлыйм. Мин ул хакта гомер буе сөйләргә әзер. Бу көндәлегемне дә халыкка житкерүемнең төп сәбәбе — башкаларны да Хаж белән кызыксындыру, күңелләрендә бу изге урыннарга карата мәхәббәт уяту, аларны ислам диненә тарту, иманга чакыру иде. Әгәр минем бу язмам бер генә кешедә булса да динебезгә мәхәббәт уятса, намаз укырга этәрсә, иманын ныгытырга ярдәм итсә, мин бик бәхетле булыр идем. Каргалган, бозылган, жимерелеп барган бу дөньяда бер мөселман кешесенең булса да артуы, тагы бер якты нурның барлыкка килүе, ислам диненең таралуы миңа алга таба яшәремә көч, дәрт бирер иде, бу газапларның, бу интегүләрнең юкка гына булмавын, Аллаһы ризалыгы өчен, халкыбызны иманга кайтару өчен дә булуына мин тагы бер тапкыр инаныр идем...*

*Бу изге сәфәрне оештырган һәм исән-имин башкарып чыккан Габдулла хәзрәт Галиуллага рәхмәтләрем зур. Шулай ук татар хажиларына, хәлсез карт-карчыкларга һәрвакыт ярдәм итеп йөргән Габдрәшит хәзрәткә, Камил хәзрәткә, татар шәкертләренә Аллаһының рәхмәтләре булсын. Бу көндәлектә барлык юлдашларымны да телгә алып бетерергә мөмкин түгел, әмма алар барысы да минем күңелемдә, хәтеремдә, күз алдымда... Ялгышып рәнжеткән, хәтерегезне калдырган булсам, мине кичерегез, күңелләрегездә үпкә-рәнжеш тотмагыз. Мин исә сезнең барыгыздан да бәхил, барыгызны да кичерәм, барыгызны да яратам. Без барыбыз да мөселманнар, без барыбыз да кардәшләр, без барыбыз да т а т а р л а р ...*

*Гомер йомгагым, язмыш йомгагым һаман тәгәри дә тәгәри... Бөтен ил күз алдында, милләт күз алдында... Раббыбыз каршында һәм аның тәкъдире белән.*

*— Тәгәри китте, йомгагым, күрмәдегезме, агайлар?*

*Агайлар дәшми... Ил дәшми... Милләт дәшми... Ком чүлендә ялгыз калган юлчы кебек, мин тагы бөтен дөньяга ачыргаланып кычкырам:*

*— Тәгәри китте йомгагым, күрмәдегезме, агайлар?!!!*

*Жавап юк. Исерек ил корылык афәте каршында, ачлык афәте каршында, имансызлык афәте каршында телсез булып басып тора...*

*— Тәгәри китте йомгагым, күрмәдегезме, агайлар...*

*Күктән бер аваз ишетелә:*

*... ТАУ КУЫШЫНА КИЛ... ТАУ КУЫШЫНА КИЛ... ТАУ КУЫШЫНА КИЛ...*

*Үз-үзеңне тап, Аллаһыга кайт...*

*Чаллы-Казан-Мәккә-Мәдинә-Казан-Чаллы.*
*27 март — 16 июнь, 1998 ел.*



*Тукай исемендәге*
*Дәүләт премиясе*
*булдырылуга 40 ел*

# КАЗАНЫШЛАРЫБЫЗ ЕЛЪЯЗМАСЫ

Тукай премиясе — Дәүләт бүләге буларак (элегрәк Республика премиясе дип атала иде) — Татарстан Республикасының иң югары һәм иң абруйлы премиясе. Аның башлангычы 1958 елга барып тоташа. Мәгълүм булганча, тоталитар режим йомшый, җәмгыятьтә демократик яралгылар шыта башлаган чор бу.

**“Әдәбият һәм сәнгать өлкәсендә иҗат активлыгын тагын да күтәрү максаты белән, КПСС өлкә комитеты бюросы һәм Татарстан АССР Министрлар Советы әдәбият, музыка һәм сынлы сәнгать өлкәсендә идея эчтәлеге һәм художество дәрәҗәсе ягыннан аеруча әһәмиятле әсәрләр һәм сәхнә әсәрләрен иң яхшы башкару өчен республика күләмендә Г. Тукай исемендәге премияләр билгеләргә кирәк дип таптылар... Премияләр ел саен Татарстан АССР төзелү еллыгы көнендә — 25 июньдә — Республика премияләр комитеты карары белән биреләчәк”.**

Шулай итеп 1958 елда кабул ителгән бу карар нигезендә, премияләрне бирү тәртибе билгеләнә, Республика премияләре комитеты раслана. Комитетның беренче рәисе — К. Ф. Фасиев. 14 кешедән торган комитет әгъзалары арасында Г. Бәширов, Н. Җиһанов, Н. Даутов, Х. Якупов, Н. Якушенко, Г. Камай кебек күренекле шәхесләрнең исемнәре бар. Шул ук елны комитет тарафыннан беренче лауреатлар билгеләнә һәм Республика җитәкчелеге тарафыннан раслана. Беренче лауреатлар шактый ишле — әдәбият, музыка, сынлы сәнгать, театр өлкәсеннән җәмгысы 11 кеше. Дөрес, кайбер елларда (1961 — 1965, 1975) премия (сәбәп-мотивлары безгә төгәл анык түгел — ред.) бөтенләй бирелмәгән. Кырык ел эчендә бу мактаулы исемгә 118 кеше һәм 1 иҗади оешма (Татарстан Дәүләт җыр һәм бию ансамбле) лаек булган. Шунысы да гыйбрәтле: лауреатлар арасында төрле милләт кешеләре бар — татар, рус, үзбәк, немец, башкорт, яһүд... Бу факт премиянең демократик рухта, интернациональ асылда булуы турында сөйли. 1979 елдан Тукай премиясе Дәүләт премиясе статусын алды. Соңгы дистә елларда Премия алган кешеләрнең исемнәре, Тукай туган көнне — 26 апрельдә — игълан ителә. Яңа лауреатлар, кагыйдә буларак, шул ук көнне Шигырь бәйрәмендә җыелган халык алдына чыгалар һәм нотык тоталар.

Г. Тукай исемендәге Дәүләт премияләре 1991 елга кадәр партия өлкә комитеты һәм Татарстан Министрлар Советы карары белән бирелде, ә 1992 елдан Татарстан Президенты Указы белән бирелеп килә. Лауреатларга лауреатлык дипломы һәм медале, гадәттә, Республика көне (30 август) алдыннан тапшырыла.

Кырык ел эчендә, табигый, премияләр бирү комитеты составы кат-кат үзгәрде. Бу уңайдан, Комитет рәисе булып ике дистә елга якын эшләгән М. Х. Хәсәнов (ул озак еллар Татарстан Министрлар Советы рәисе урынбасары булып эшләде, хәзер — Татарстан Фәннәр Академиясе президенты) исемен аерым атап китү урынлы булыр. Хәзер комитетны Татарстан премьер-министры урынбасары И. К. Хәйруллин җитәкли.

Без түбәндә 1958 — 1998 елларда Тукай премиясенә лаек булган лауреатларның исемлеген һәм премиянең нинди әсәр яки гамәл өчен бирелгәнлеген аңлаткан язма урнаштырабыз. Әдәбият һәм сәнгатебезнең дүрт дистә ел эчендәге казанышларын шактый ук объектив күрсәткән бу материал укучыларыбыз өчен кызыклы булыр дип ышанабыз.

### 1958 ел

**Яруллин Фәрит Заһидулла улы** — композитор ("Шүрәле" балеты өчен).

**Җиһанов Нәҗип Гаяз улы** — композитор ("Җәлил" операсы өчен).

**Фәйзуллин Әхмәт Сафа улы (Әхмәт Фәйзи)** — язучы ("Тукай" романы өчен).

**Сарымсаков Ширияздан Мөхәммәтҗан улы** — режиссер (Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында К. Тинчуринның "Җилкәнсезләр" пьесасын куйган өчен).

**Тумашев Әнәс Ибраһим улы** — рәссам (К. Тинчуринның "Җилкәнсезләр" спектаклен бизәгәне өчен).

**Әбҗәлилов Хәлил Гали улы** — артист ("Җилкәнсезләр" спектаклендә Мисбах ролен уңышлы башкарганы өчен).

**Колбарисов Фатих Әкрам улы** — артист ("Җилкәнсезләр" спектаклендә Батырҗан роле).

**Хәйруллина Асия Хәсән кызы** — артистка ("Җилкәнсезләр" спектакелендә Рокыя роле).

**Фәттахов Лотфулла Әбделмән улы** — рәссам ("Татар халык әкиятләре" китабына (русча) иллюстрацияләр).

**Якупов Харис Габдрахман улы** — рәссам ("Татар халык әкиятләре" китабына иллюстрацияләр).

**Даутов Нияз Курамша улы** — режиссер-сәхнәгә куючы (М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрында "Алтынчәч" һәм "Евгений Онегин" операларын сәхнәгә куйган өчен).

### 1959 ел

**Әпсәләмов Габдрахман Сафа улы** — язучы ("Сүнмәс утлар" романы).

**Провоторов Николай Сергеевич**, артист (Казанда В. И. Качалов исемендәге театрда куелган "Третья патетическая" спектаклендә Ленин образын иҗат иткән өчен).

**Мозаффаров Мансур Әхмәт улы** — композитор (Г. Тукай һәм М. Вахитов истәлекләренә багышланган симфоник поэмалар).

**Яхин Рөстәм Мөхәммәтхаҗи улы** — композитор ("Дулкыннар, дулкыннар", "Күңелем өзгәләнгән минутларда" һ. б. җырлары, романслары өчен).

**Насретдинов Фәхри Хөсәен улы** — җырчы (актив концерт эшчәнлеге һәм совет композиторлары әсәрләрен пропагандалаганы өчен).

### 1960 ел

**Хәкимов Сибгат Таҗи улы (Сибгат Хәким)** — шагыйрь ("По зову Ленина" (русча), "Җил исми, яфрак селкенми" исемле шигырь җыентыклары).

**Бурлай Алексеей Петрович** — рәссам ("Беренче нефть" картинасы).

**Вахитов Габделхәй Каюм улы (Хәй Вахит)** — драматург (Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында куелган "Беренче мәхәббәт" драмасы өчен).

**Бикчәнтәев Рәфкать Әхмәтҗан улы** — режиссер ("Беренче мәхәбәт" драмасын сәхнәгә куйганы өчен).

**Өметбаев Сабир Гаделҗан улы** — режиссер (Минзәлә Татар дәүләт театрында "Язылмаган законнар" һәм "Тамырлар" спектакльләрен сәхнәгә куйганы өчен).

**Татарстан АССР Дәүләт җыр һәм бию ансамбле** (татар хор культурасын һәм СССР халыкларының музыкаль иҗатын актив пропагандалаганы өчен).

**1961 — 1965** елларда Г. Тукай исемендәге премияләр бирелмәде.

### 1966 ел

**Туфан Хәсән Фәхри улы (Хәсән Туфан)** — шагыйрь ("Сайланма әсәрләр" китабы).

**Фәйзи Җәүдәт Харис улы (Җәүдәт Фәйзи)** — композитор (яңа җырлар циклы).

### 1967 ел

**Урманче Бакый Идрис улы (Бакый Урманче)** — сынчы, скульптор (татар мәдәнияте эшлеклеләре: Г. Тукай, М. Җәлил, Ф. Әмирхан, Г. Кариев, Г. Ибраһимов һ. б. ның скульптур портретлары өчен).

**Ходжаев Ташходжа Омар улы** — режиссер (Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында Ч. Айтматовның "Гүзәлем Әсәл" спектаклен сәхнәгә куйганы өчен).

**Гельмс Эрнест Брунович** — театр рәссамы (Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында "Гүзәлем Әсәл" спектаклен бизәгәне өчен).

**Гәрәева Наилә Хәким кызы** — актриса ("Гүзәлем Әсәл" спектаклендә Әсәл роле).

**Биктимеров Шәүкәт Хәсән улы** — артист ("Гүзәлем Әсәл" спектаклендә Байтимер роле).

**Әсфәндиярова Шәхсәнәм Ибраһимбәк кызы** — актриса ("Гүзәлем Әсәл" спектаклендә Хәдичә роле).

**Таҗетдинов Ринат Арифҗан улы** — артист ("Гүзәлем Әсәл" спектаклендә Ильяс роле).

## 1968 ел

**Исәнбәт Нәкый Сиражи улы (Нәкый Исәнбәт)** — галим, язучы, фольклорчы ("Татар халык мәкальләре" дигән өч томлы хезмәте өчен).

**Хәбибуллин Заһит Вәли улы** — композитор ("Казах кызы сөйгәнем", "Солдат жыры", "Бормалы су" һ. б. җырлар циклы).

## 1969 ел

**Миңгазиев Ибраһим Зариф улы (Ибраһим Гази)** — язучы ("Онытылмас еллар"" роман-трилогиясе).

**Арсланов Айрат Гәрәй улы** — артист, нәфис сүз остасы ("Туган ягым — Татарстан" — дигән һ. б. әдәби концерт программалары).

## 1970 ел

**Ключарев Александр Сергеевич** — композитор ("Канатлы яшьлек" исемле җырлар җыентыгы һәм татар халык музыкаль иҗатын җыюы һәм пропагандалавы өчен).

**Шакиров Илһам Гыйльметдин улы** — җырчы (1968 — 1969 еллардагы концерт программалары, татар халык җырларын һәм композиторларының әсәрләрен пропагандалавы өчен).

## 1971 ел

**Сәлимҗанов Марсель Хәким улы** — режиссер (Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында К. Тинчуринның —"Американ", "Сүнгән йолдызлар", Г. Ибраһимов әсәре буенча "Тирән тамырлар" спектакльләрен уңышлы куйганы өчен).

**Кузнецов Николай Дмитриевич** — рәссам (индустриаль пейзаж рәсемнәре).

## 1972 ел

**Хөснетдинов Фатих Хөснетдин улы (Фатих Хөсни)** — язучы ("Гыйльмениса һәм аның күршеләре" дигән китап).

**Һидиятуллин Шәүкәт Галимулла улы (Шәүкәт Галиев)** — шагыйрь ("Гаҗәп хәлләр, мәзәк хәлләр", "Котбетдин мәргән", "Шәвәли", "Тәмле йорт", "Кызык" һ. б. китаплары).

## 1973 ел

**Ахунов Гарифҗан Ахунҗан улы (Гариф Ахунов)** — язучы ("Чикләвек төше" повесте, "Хәзинә" романы).

**Бакиров Әнвәр Закир улы** — композитор ("Су анасы" балеты).

**Смирнов Игорь Валентинович** — балетмейстер (М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрында куелган "Су анасы" балеты һәм либреттосы өчен).

**Фазлуллин Хәсби Вәли улы** — дирижер (Ә. Бакировның "Су анасы" балетын куюда музыкаль җитәкчелеге өчен).

**Садыйков Ревдар Фәиз улы** — балет артисты ("Су анасы" балетында Алмай роле).

## 1974 ел

**Әмиров Мирсәяф Мәсәлим улы (Мирсәй Әмир)** — язучы ("Агыйдел" пьесасы).

**Юзиев Нил Гафур улы** — әдәбият галиме, тәнкыйтьче ("Шигырь гармониясе", "Хәзерге татар поэтикасы" дигән китаплары).

1975 елда Г. Тукай исемендәге премияләр бирелмәде.

## 1976 ел

**Вәлиев Диас Назыйх улы** — драматург ("Дарю тебе жизнь" (русча) пьесасы).

**Шабаев Марс Садри улы** — шагыйрь ("Җикән камыш", "Онытма", "Сине эзлим" дигән китаплары).

**Тумашев Равил Рәхим улы** режиссер (Татар дәүләт күчмә театрында И. Юзеев пьесасы буенча "Сандугачлар килгән безгә", Т. Миннуллин пьесасы буенча "Үзебез сайлаган язмыш", А. Гыйләҗев пьесасы буенча "Көнбагышлар" спектакльләрен куйганы өчен).

## 1977 ел

**Афзалов Гамил Гыймазетдин улы (Гамил Афзал)** — шагыйрь ("Айлы кичләр" шигырьләр җыентыгы, "Борылам да ка-рыйм" дигән шигырьләр циклы өчен).

**Хәкимова Ирина Шәриф кызы** — балерина ("Шүрәле" балетында — Сөембикә, "Су анасы" балетында — Сәрви, "Аккош күле" балетында Олетта-Одиллия партияләрен башкарганы өчен).

**Беспалов Виктор Иванович** — кинорежиссер (телевидение өчен "Кырлай", "Татар гармуннары", "Н. Җиһанов музыкасы" дигән музыкаль фильмнар).

## 1978 ел

**Фәйзуллин Равил Габдрахман улы** — шагыйрь ("Шигырьләр һәм поэмалар" китабы).

**Лывин Сергей Осипович** — рәссам (В. И. Ленинга һәм Г. Тукайга багышланган картиналар сериясе).

### 1979 ел

**Миңнуллин Туфан Габдулла улы** — драматург ("Ай булмаса, йолдыз бар" драмасы).

**Хөсәенов Гали Кәрим улы** — режиссер (Әлмәт драма театрында "Ай булмаса, йолдыз бар" спектаклен куйганы өчен).

**Кузаева Дамира Нәҗмиҗан кызы** — артистка ("Ай булмаса, йолдыз бар" спектаклендә Мәдинә роле).

**Ибраһимов Ренат Ислам улы** — җырчы (1976 — 1978 еллардагы концерт программалары).

### 1980 ел

**Юзеев Илдар Гафур улы** — шагыйрь ("Таш диварлар авазы", "Өзелмәс кыллар" поэмалары).

**Маликов Васил Малик улы** — сынчы, скульптор, ("Чекист Голубятников", "Соңгысы", "М. Җәлил" дигән скульптуралар).

### 1981 ел

**Рәсүлов Атилла Кадыйр улы (Атилла Расих)** — язучы ("Язгы авазлар", "Ике буйдак", "Сынау" трилогиясе һәм "Ямашев" романы).

**Кузин Евгений Андриянович** — артист (В. И. Качалов исемендәге театрда "Большевиклар", "Астория" кунакханәсе" һ. б. спектакльләрдә төп рольләрне башкаруы өчен).

**Федотов Юрий Степанович** — артист (В. И. Качалов исемендәге театрда "Большевиклар", "Астория" кунакханәсе" һ. б. спектакльләрдә төп рольне башкарганы өчен).

**Бакулин Герман Алексеевич** — архитектор (Казанда Татарстан Рәссамнар берлегенең Күргәзмә залын проектлау һәм төзү).

**Зәкиев Әуфар Зәки улы** — инженер-төзүче (шул ук бинаны төзү).

**Парамонов Игорь Петрович** — инженер-төзүче (шул бинаны төзү).

**Фәйзуллин Әнәс Нурулла улы** — бинаны эшкәртү-бизәкләү остасы (шул ук бинаны төзү).

**Хисаметдинова Сания Шәкүр кызы** — бинаны эшкәртү-бизәкләү остасы (шул ук бинаны төзү).

### 1982 ел

**Нуруллин Ибраһим Зиннәт улы** — язучы ("Тукай" ("Атаклы кешеләр тормышы" сериясеннән) һәм "Габдулла Тукай" дигән китаплары).

### 1983 ел

**Гыйләҗев Аяз Мирсәет улы** — язучы ("Җомга көн кич белән", "Әтәч менгән киртәгә" повестьлары).

**Еникеев Ренат Әхмәт улы** — композитор ("Муса Җәлил истәлегенә" дигән вокаль-симфоник поэмасы һәм соңгы еллардагы әсәрләре).

### 1984 ел

**Еникеев Әмирхан Нигъмәтҗан улы (Әмирхан Еники)** — язучы (повестьлары һәм хикәяләре).

**Мулюков Бату Гатаулла улы** — композитор ("Кара йөзләр" операсы авторы).

**Родионов Григорий Васильевич (Гәрәй Рәхим)** — шагыйрь ("Кара йөзләр" операсы либреттосы авторы).

**Сөнгатуллина Зилә Даян кызы** — опера җырчысы ("Кара йөзләр" операсында Галимә партиясен башкарганы өчен).

**Бигичев Хәйдәр Аббас улы** — опера җырчысы ("Кара йөзләр" операсында Закир партиясе).

**Васильев Владимир Михайлович** — дирижер (М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрында куелган "Кара йөзләр" операсы дирижеры).

### 1985 ел

**Арсланов Нури Газиз улы** — шагыйрь ("Иделем — илем" исемле шигырьләр һәм поэмалар китабы).

**Нигъмәтҗанов Мәхмүт Нигъмәтҗан улы** — музыка белгече ("Татар халык җырлары" һәм "Идел буе татарларының халык җырлары" һ. б. хезмәтләре өчен).

### 1986 ел

**Камалов Хисам Нуретдин улы (Хисам Камал)** — язучы ("Һәркемнең гомере бер генә", "Безне өйдә көтәләр" китаплары).

**Кудelькин Виктор Иванович** — рәссам (Татарстанның хезмәт алдынгыларына, мәдәният эшлеклеләренә багышланган күп сандагы картиналары).

### 1987 ел

**Зарипов Марсель Харис улы** — язучы ("Поступь моей республики" һәм "Выгодный оборот" дигән (русча) очерклары, матур әдәбият теле белән язылган публицистик китаплары).

**Хаҗиәхмәтов Тавил Гыйният улы** — рәссам (1981 — 1985 елларда басылган китапларны нәфис-график бизәү өчен).

### 1988 ел

**Хәсәнов Мәхмүт Максуд улы** — язучы ("Язгы ажаган" романы).

**Әхмәтов Фасил Әхмәтгали улы** — композитор (соңгы еллардагы әсәрләре, симфониясе һәм "Мин гармун булыр идем" дигән җырлар җыентыгы).

### 1989 ел

**Надиров Илбарис Нурислам улы** — фольклорчы, авторлар коллективы җитәкчесе ("Татар халык иҗаты" дип исемләнгән унике томлык фәнни хезмәт өчен).

Шул ук унике томлы фәнни хезмәт өчен фольклорчылардан:

**Әхмәтова Флора Ваһап кызы,**
**Җамалетдинов Ленар Шәйхи улы,**
**Мәхмүтов Хуҗи Әхмәт улы,**
**Ярмөхәммәтов Хәмит Хөснетдин улына (Хәмит Ярми**; үлгәннән соң).

**Вәлиуллин Хөснулла Вәлиулла улы** — композитор ("Самат" операсы, соңгы еллардагы җырлары тупланган "Ел артыннан ел" дигән җыентыгы).

### 1990 ел

**Мәһдиев Мөхәммәт Сөнгат улы** — язучы ("Кеше китә — җыры кала" (1979), "Торналар төшкән җирдә" (1983), "Бәхилләшү" (1989) повестьлары).

**Садыйкова Сара Гариф кызы** — композитор (үлгәннән соң; җырлары өчен).

**Салахов Ибраһим Низами улы** — язучы ("Колыма хикәяләре" романы).

### 1991 ел

**Кәримуллин Әбрар Гыйбадулла улы** — галим ("У истоков татарской книги" ("От начала возникновения до 60-х годов XIX века") (1971), "Татарская книга пореформенной России" (1983), "Татарская книга XX века" (1974) дигән трилогиясе өчен).

**Зәйнашева Гөлшат Хисам кызы** — шагыйрә ("Илле җыр" китабы).

**Монасыйпов Алмаз Закир улы** — композитор ("Муса Җәлил" дигән симфония-поэма (1973), "Тукай ритмнарында" исемле вокаль-симфоник поэма (1976), Салих Сәйдәшевкә багышланган симфония-поэма).

### 1992 ел

**Афзалова Әлфия Афзал кызы** — Татар дәүләт филармониясе җырчысы (1989 — 1991 елларындагы концерт программасы).

**Әгъләметдинов Мөдәррис Зөфәр улы (Мөдәррис Әгъләмов)** — шагыйрь ("Киләчәккә кайту", "Мин әйттем" дигән китаплары).

**Липкин Семен Израилевич** — шагыйрь (татар халык эпосы "Идегәй"нең (1990) һәм татар поэзиясе классиклары әсәрләренең тәрҗемәсе өчен).

**Шәрәфиев Равил Шиһабетдин улы** — артист (Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында иҗат иткән күп кенә образлар (Хуҗа Насретдин, Кочкорбаев, Робинзон, доктор Ламбарди, Ислам өчен).

### 1993 ел

**Мөхәммәдиев Ринат Сафа улы** — язучы ("Сират күпере" романы).

**Фәтхетдинов Әхсән Сәрим улы** — ("Ияләр" дигән художество әсәрләре циклы өчен).

### 1994 ел

**Зарипов Илдар Касыйм улы** — рәссам ("Буяуларда — халык моңнары" дигән сериядәге картиналары өчен).

**Мансуров Фуат Шакир улы** — дирижер (Татарстан Республикасы Дәүләт симфоник оркестрының 1991 — 1993 еллардагы концерт программасы өчен).

**Фәттахов Нурихан Садрилмән улы (Нурихан Фәттах)** — язучы ("Сызгыра торган уклар" роман-трилогиясе).

### 1995 ел

**Яруллин Фәнис Гатаулла улы** — язучы ("Җан авазы" китабы).

### 1996 ел

**Бәширов Гомәр Бәшир улы** — язучы ("И язмыш, язмыш" китабы).

**Кудашева Фәридә Яһүд кызы,** җырчы (Татар халык җырларын һәм Г. Тукай шигырьләренә иҗат ителгән җырларны башкарганы өчен).

### 1997 ел

**Абзгильдин Абрек Әмир улы** — рәссам ("Г. Тукай", "Дәрдмәнд", "Урманче" триптихы әсәрләре сериясе өчен).

**Ганиева Венера Әхәт кызы** — җырчы ("Дж. Вердиның "Риголетто" операсында Джильда, Дж. Россининың "Сивилья чәчтарашы" операсында Розина, Н. Җиһановның "Алтынчәч" операсында Алтынчәч партияләрен башкарганы өчен).

**Ренат Харис (Харисов Ренат Мәгъсүм улы)** — шагыйрь ("Хйсемнен жисеме" дигән шигырьләр һәм поэмалар жыентыгы).

**1998 ел**

**Миңнуллин Роберт Мөгаллим улы** — шагыйрь ("Күчтәнәч" дигән балалар китабы).

Т. Миңнуллин пьесасы буенча Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында куелган "Хушыгыз" спектакле өчен:
**Бикчәнтәй Фәрит Рәфкать улы** (режиссер).
**Ихсанова Нәҗибә Гимай кызы** (актриса).
**Дунаев Николай Иван улы** (артист).
**Шакиров Әзһәр Шәфикъ улы** (артист)

# Игътибар!

## *Хөрмәтле укучыларыбыз!*

Үткән ел, журналыбызның юбилее уңае белән, 75 ел эчендә чыккан барлык нөсхәләрне дә (алар 900 дән артык!) редакциябездә булдыру максаты белән, үзегездә сакланган "Безнең юл", "Яңалиф", "Атака", "Совет әдәбияты" басмаларының элегрәк елларда чыккан саннарын җибәрүегезне үтенеп мөрәҗәгать иткән идек. Безнең бу теләкне аңлаучылар һәм хуплаучылар байтак табылды. Алар хәерле гамәл кылып, безгә кирәкле йөзләгән данә журнал җибәрделәр. Олуг рәхмәт аларга! Әмма 76 ел буе чыккан барлык саннарны әлегә туплап, җыеп бетерә алмадык. Бигрәк тә, сугышка кадәр чыккан саннарның күбесе юк. Төгәлрәк әйткәндә, түбәндәге саннар җитешми:

**1966** — 1,5,8,9 с.; **1965** — 9 с.; **1963** —3 с.; **1960** — 11 с.; **1958** — 11 с.; **1957** — 12 с.; **1955** — 10 с.; **1954** — 1, 6, 9, 10, 12 с.; **1953** — 1, 2, 3, 4, 9, 12 с.; **1952** — 1, 2, 5, 8, 9, 10 с.; **1951** — 2, 5, 12 с.; **1950** _ 1, 2, 5, 6, 7, 8, 9, 10, 11, 12 с.; **1949** — 2, 4, 5, 6, 7, 8, 11 с.; **1948** — 3, 5, 8 с.; **1947** — 1, 2, 3, 6, 7, 8, 9, 10, 11, 12 с.; **1946** — 5, 7, 8, 9 с.; **1945** — 3, 4, 8, 11, 12 с.; **1944** — 1, 2, 3, 4, 5, 7, 8 с.; **1943** — 1, 4, 5, 7, 8, 9, 10, 11, 12 с.; **1942** — 1, 2, 3, 4, 5, 11, 12 с.; **1941** — 1, 2, 3, 4, 6, 9, 11, 12 с.; **1940** — 1, 2, 5, 6, 8, 9, 10, 11, 12 с.; **1939** — 6 с.; **1938** — 1, 3, 11, 12 с.; **1937** — 1, 2, 4 с.; һәм аннан алдагы еллардагы саннар (**1922** елга кадәр).

Тагын бер мәртәбә мөрәҗәгать итәбез: Сездә бу саннар сакланган булса, боларны безгә юлласагыз икән!

Әгәр Сездә югарыда күрсәтелгән журнал нөсхәләре булып та, һәдия итәргә ниятегез йә җибәрергә мөмкинлегегез булмаса, безгә хәбәр итегез. Без бу изге гамәлне бәхилләтер өчен, журналыбызны бушка яздыру яки бүтән формада хак түләү юлларын үз өстебезгә алыр идек.

**Журналыбызның адресы:** *420066 — Казан, Декабристлар урамы, 2 йорт, "Казан утлары" журналы редакциясе, а/я 49.*

# ТАТАР ТЕАТР ЯРАТА

*Иҗат кешеләре бергә җыелса, сүз, әлбәттә, сәнгать язмышы, аны билгеләүче шәхесләр турында була. Мәдәниятебезнең өч олпат заты: СССР ның халык артисты, Татарстанның һәм Русиянең Дәүләт бүләкләре лауреаты артист* ***Шәүкәт Биктимеров****, Татарстанның һәм Русиянең атказанган сәнгать эшлеклесе, Дәүләт бүләкләре лауреаты язучы* ***Туфан Миңнуллин****, СССР ның халык артисты, Татарстанның һәм Русиянең Дәүләт бүләкләре лауреаты, Г. Камал исемендәге Татар академия театры баш режиссеры* ***Марсель Сәлимҗанов****ларның әңгәмәсе дә шул турыда иде. Шәүкәт Биктимеровның 70 яше тулу, очрашуга сәбәп булса да, сөйләшүләре киңәеп китеп, зыялыларыбызны борчыган бик күп мәсьәлә-ләрне үз эченә алды.*

**Туфан Миңнуллин:** Сүзебезне Шәүкәт абыйны олы артист иткән театрдан башлау дөрес булырдыр. Театрны театр иткән татар халкы язмышына да кагылмый булмас. Чөнки татар театры — татар халкы үзе тудырган театр. Аннан соң, театрдан, ягъни мәсәлән, иҗаттан кала, Шәүкәт Биктимеров яшәгән мохит, заман да бар бит әле. Ул турыда сөйләшмәсәк, әңгәмәбезгә тирәнлек җитмәстер.

**Марсель Сәлимҗанов:** Сәнгать дөньясында театр мәктәбе дигән төшенчә бар. Ул мәктәпнең нидән гыйбарәт икәнен төгәл билгеләве дә авыр. Аерым театрга гына хас уйнау, стиль, фикерләү рәвешедер инде ул. Урыс театрында МХАТ театры мәктәбе, Малый театр мәктәбе, Вахтангов театры мәктәбе дигән төшенчәләр яшәп килде. Бара-тора алар үз йөзләрен югалттылар. Алар барысы да "русская советская школа" дип атала башлады.

Безнең үз мәктәбебез сакланып килә. Театрыбызның 90 еллык тарихы бар. Һәм шушы тугыз дистә ел дәвамында үзебезгә генә хас татар театр мәктәбе яшәп килә. Бу бигрәк тә артистларыбызның үзенчәлекләрендә күренә.

Шакир Шамильский дигән артист бар иде. Ул махсус уку йортында театр белеме алмаган. "Нур" һәм "Сәйяр" труппаларындагы артистларның уенын күреп, театрга гашыйк булган, үзе уйный башлаган. Беренче татар артисткасы Сәхибҗамал Гыйззәтуллина-Волжская аңа бик зур тәэсир итә. Ә үзенең биографиясендә Шамильский: "Кариевтан бик күп өйрәндем", — дип яза. Татар театрына бу артистның йогынтысы бик зур. Ул Кариев белән бергә безнең милли сәхнә сәнгатебезгә нигез салучы шәхес.

Шамильскийның уен алымнарын Фуат абый Халитов куллана башлый. Аннан соң Ринат Тажетдинов. Ринат үзе Шамильскийның уенын күрмәгән, ләкин Халитов белән бергә уйнаган кеше. Хәзер исә яшь буынга Ринат Тажетдинов зур йогынты ясый. Шулай итеп, мәктәп сакланып бара.

Шәүкәттә мин Хәлил Әбҗәлилов һәм шул ук Шакир Шамильский уен алымнарын күрәм.

**Шәүкәт Биктимеров:** Үзенчәлек турында сөйләгәндә, мин аны театр кешеләреннән аерып ала алмыйм. Алар бит үзләре бер дөнья иде. Мина татар театрын тудырган шактый өлкән бөек әһелләр белән эшләргә туры килде. Яшь

вакытта тәҗрибә юк, сәләт ияләренең иҗатларын лакмус кәгазе кебек сендереп барасың. Аны еш кына аңлап та эшләмисең.

Баштарак Зәйни Солтанов, Касыйм Шамил белән бергә кечкенә генә рольләрдә чыгарга туры килде миңа. Фатыйма Ильская, Гөлсем Болгарская, Гөлсем Камская, Галия Нигъмәтуллина, Галия Булатова, Хәким Сәлимҗанов, Фуат Халитов, Хөсәен Уразиков, Камал III ...Режиссерлар: Габдулла Йосыпов, Ширияздан Сарымсаков, Кәшифә Тумашева... Шулар белән рухланып яшәдек, аларның уенын сокланып күзәттек.

Сәхнә осталарыбызның уеннарын урыс һәм башка милләт артистларының уеннары белән чагыштырып карыйм әле, безнекеләр берсеннән дә ким түгел.

Ул вакыттагы сәхнә таләпләре бүгенге күзлектән караганда бәлки примитив булып күренәдер. Әмма, иманым камил, аларда фидакарьлек, сәхнәне изге урынга санау, ихласлык күбрәк иде.

**Марсель Сәлимҗанов:** Син бик күп артистларны санап киттең, Хәлил абый Әбҗәлилов турында әйтмәдең.

**Шәүкәт Биктимеров**: Хәлил абый — аерым шәхес. Ул сәхнәдә гаҗәеп кеше иде. Күз карашы искиткеч тирән иде аның. Миңа Хәлил абыйның уены эталон булып килде. Ул сәхнәдә алдый белмәде. Бернинди арттырып җибәрү юк иде.

**Туфан Миңнуллин:** Татар театрының үзенчәлеге, традициясе бәлки аның дөньяга туу тарихы белән дә бәйләнгәндер. Театр кемнәр тарафыннан тудырылган? Ул милләткә хезмәт итәргә кирәк, татар милләтен башка милләтләр дәрәҗәсенә чыгарырга кирәк, дип янган чын мәгънәсендә энтузиастлар, фидакарьләр тарафыннан тудырылган театр бит. Салон театры да, аристократия теләге яки дәүләтнең махсус указ белән оештырылган театр да түгел. Чын мәгънәсендә халык театры. Һәм шушы традиция өлкән буын артистлардан яшьләргә күчеп, йогып килгән. Минем карашымча, ул бүген дә дәвам итә. Театрның төп миссиясе — татар халкына, милләткә хезмәт итү. Бу инде, татар булабыз, милли булабыз дип, түбәтәй киеп, яулык бәйләп йөрү генә түгел.

Уйнау дәрәҗәсе, артистлык осталыгы, пьесалар мәсьәләсендә урыс театрының йогынтысы булган, әлбәттә, сүз дә юк. Әмма рухы халкыбызныкы булган. Бүгенге көндә дә театр шушы рухны саклап килә. Тамашачының тулып йөрүе, хәтта бик үк уңышлы булмаган спектакльләрне дә кабул итүе, театрны яратуыннан, мәхәббәтеннән килә. Бу, Шәүкәт абый, сезгә кадәр эшләгән, сезнең белән бергә эшләгән, сездән соң эшләячәк артистларның иң зур бөеклеге, дип саныйм.

**Марсель Сәлимҗанов:** Минем иҗатымда, тормышымда Шәүкәт белән бәйле бик күп вакыйгалар бар. Мин аны бала чагымнан беләм. Безгә бер йортта яшәргә насыйп булды. Театр училищесында уйнаган чорларын да хәтерлим. Мин аның уйнаган һәрбер ролен, диплом спектакленнән башлап, беләм. Бер ара Шәүкәтне бер төрле рольләрдә күп уйната башладылар. Яшь, чибәр, характерсыз герой-любовникларны көн саен уйный иде.

Шулкадәр уйнаттылар моны, тавышы бетте. Ә мин Шәүкәтне юморга бай кеше итеп беләм, шуңа күрә, театрда эшли башлагач та, аңа иң беренче итеп кабәхәт, начар герой Дәүли ролен (Н. Исәнбәт — "Миркәй белән Айсылу") бирдем. Бар труппа аптырады. Ә ул шушында үзенең характерлы герой икәнлеген дә күрсәтте.

Һәм шуннан бәйләнеп китте. Бик тиз арада олы яшьтәге кешеләрне уйната башладым. Әйтик, "Ташкыннар"да (Т. Гыйззәт) — Биктимер.

**Шәүкәт Биктимеров:** Тора-бара ишанга барып життек. (К. Тинчурин — "Зәңгәр шәл").

**Марсель Сәлимҗанов:** Шулай итеп, төрле пландагы, иң катлаулы образларны тудырырлык артист Шәүкәт Биктимеров дөньяга килде.

Туфан Миннуллин: Шәүкәт абый, сез — авыл малае. Театрга килеп керү ничек булды соң?

**Шәүкәт Биктимеров:** Әти укытучы иде. Әни мәрхүмә дә укытучы булган. Ул вакытта авылга театрлар бик килмиләр, кино да юк. Авылның интеллигенциясе укытучы иде. Бәйрәм булса, концерт ясаучы да ул, спектакль куючы да ул, доклад сөйләүче дә ул.



*Ш. Биктимеров Фаюнин ролендә*

Укытучыларның күбесе — мулла балалары. Әтиемнең әтисе дә мулла иде. Кайберәүләрне алып киткәннәр. Безнең гаиләгә ничектер тимичә калганнар. Авыл ике мәхәлләле иде, бер мулла юкка чыккан, ә безнең бабай исән калган. Икенче тормыш башлангач, әти укытырга мәдрәсәдән мәктәпкә күчкән. Мәһабәт кеше иде, озын буйлы, минем эше түгел. Театрны бик ярата, спектакльләр оештыра иде. Аның йогынтысы белән скетчларга катнашып кереп киттем.

Авылга артистлар килгәч, безгә кертәләр иде. Мулла йорты бит — иркенрәк. Авылыбызга килгән артистларның һәрберсе безнең өйдә кунып чыккан кеше. Шулар арасында туганнан туган апам Галимә Ибраһимова да бар иде. Әтинең апасының кызы. Казанга килгәч, ул, бүген репетиция, бүген сдача, дип әйтә иде. Мин, бәләкәй малай, бик аңламый идем. Театрга кереп шуларны карап утырганым хәтердә. Галимә апа балетмейстер Гай Таһировка кияүгә чыккач та, мин аларга, җизни дип бара идем. Шулай итеп, опера театрына да билетсыз керә-керә, спектакльләрне эшләү вакытыннан алып карый идем.

Кайбер артистларны төшемдә кебек хәтерлим. 1938 елны, икенче сыйныфта укыган чак, Казанга килеп Фатих Хөснинең "Урманда" дигән әсәрен караган идем. Бу минем беренче спектаклем. Хәлил абый Әбҗәлилов та, Касыйм абый Шамил дә уйнадылар. Шул хәтердә сакланган.

Артист тормышы читтән бик җиңел күренә бит. Ул вакытта тормыш авыр бит инде, авылга килгәч, артистларга ит-катык, ондыр-фәләндер бирәләр. Тегеләр коймаклар пешереп ашыйлар. Ә без — авыл халкы — ач. Болар бәхетле кешеләр икән, дип уйлый идем.

Күчмә театрның бөтен артистын бик яхшы беләм. Шулар белән сөйләшеп йөргәндә театрга димләндем дә. Бер артистка безгә квартирга төште. Коймак пешереп ашады, безгә дә өлеш чыгарды. Ач вакыт бит. Эх, мин әйтәм, коймак ашыйсың килсә, артист булырга кирәк икән.

**Туфан Миңнуллин:** Сез үзегезгә хас юмор белән шаяртып сөйлисез. Коймак ашау өчен генә булмагандыр инде, Шәүкәт абый. Сезнең заманда тормыш ифрат авыр булса да, кешеләрнең рухы сәламәтрәк иде. Безнең яшьлектә дә артистларга хөрмәт һич кенә дә аларның матди тормышы белән бәйләнмәде. Алар авылга килгәндә, иң кадерле кунакны каршы алгандай каршылыйлар иде. Аларга урынны түрдән җәйделәр, могҗиза күрсәтүчеләргә караган кебек сихерләнеп

карадылар. Һәр татар авылында авыл кешеләре җыелып үзләре театр уйныйлар иде. Хәзер дә артистларга хөрмәт зур. Әмма элеккечә мөкиббән китмиләр. Артистка "синдәй, миндәй бозау"га караган кебек карый башладылар.

**Шәүкәт Биктимеров:** Анысы шулай инде. Мөнәсәбәт бераз үзгәрде. Билгеле, кырык бишенче елның язында яңа ачылган театр училищесына укырга килгәндә тамак кайгысы түгел иде миндә. Артист булып, сәхнәдә уйнау хыялы алып килде. Минем белән бергә инде фронттан кайткан егетләр дә булды. Күбесе яраланган, култык таягы белән йөриләр иде.

Укытучыларыбыз Сәет Булатов, Шириаздан Сарымсаков, Луиза Сәлиаскарова (Хәсән Туфан хатыны), Габдулла Шамуков, Латыйф Җәләй — барысы да театрда эшләүче кешеләр, артистлар, режиссерлар.

Шунысы кызык, безнең этюдларны карарга беренче курстан ук Фатыйма Камалова, Галия Нигъмәтуллина, Галия Булатова кебек танылган артистлар киләләр иде. Имтихан спектаклен карарга академия театры тулысынча килеп утыра иде. Димәк, алар безгә өмет белән караганнар, театрның киләчәге турында уйлаганнар.

Театрда беренче ролем 47 елны Кәшифә Тумашева куйган Сергей Михалковның "Кызыл галстуклар" дигән бер әйберсендә иде.

**Туфан Миңнуллин:** Шәүкәт абый, гафу итегез, сез бит карап торышка чибәр кеше түгел. Һәрхәлдә, чибәрлек эталоны дип әйтеп булмый инде. Әмма, ни гаҗәп, сәхнәдә чибәр булырга тиешле мәхәббәт геройларын уйнадыгыз. Һәм чыннан да чибәр булып күренә идегез.

**Марсель Сәлимҗанов:** Бу чын могъҗиза инде. Яшь чагында Шәүкәт урамнан барганда аңа кызлар карамый да иде. Гади генә кыяфәтле, кыска буйлы. Ә сәхнәгә чыккач, бөтенләй үзгәрә. Шәүкәтнең бу сыйфаты хәзер дә бар. Тормышта буе зур булмаса да, сәхнәгә чыкса — баһадир.

Моның сәбәбен берәү дә аңлата алмастыр. Кемгәдер бу сыйфат табигать тарафыннан бирелә, кемгәдер — юк. Тормышта кеше хисләрен яшерә төшә. Ә сәхнәдә күзләре ялтырый, тавышы яңгырабрак чыга, матур итеп сөйли башлый — бөтенләй үзгәрә. Һәм киресенчә, тормышта бик матур булган, сәхнәгә чыккач ямьсезләнгән кешеләрне беләм. Табигать тарафыннан бирелгән бер серле әйбер инде бу.

Ике йөзләп кеше укып чыкты Шәүкәт белән, ә чынлап торып безнең театрда эшләп китүче — бары тик ул гына. Театр бик кырыс урын. Кайбер артист, аны ялгышрак алганнарын үзе сизеп китә, кайберсе...

**Туфан Миңнуллин:** Кайберләрен китәргә дә мәҗбүр иттерәләр...

Ул вакыт театрның бик авыр чакларына туры килә. Тамашачы театрга йөрмәгән чак. Театрның репертуарын да конфликтсыз пьесалар тәшкил итә. Тамашачылар ул әсәрләргә ышанмаган...

**Марсель Сәлимҗанов:** Режиссура белән дә ул вакытта буталчык иде. Бер режиссерны куялар, икенчесен алмаштыралар. Театр эчендәге атмосфера да сәламәт түгел.

Театрдан биздерү бик җиңел. Тамашачыны кире кайтару бик авыр. Моның өчен күп вакыт һәм көч сорала. Ә бизү өчен бер-ике сезон җитә. Академия театрында кызык түгел —бетте-китте шуның белән. Мин яшьләр театрында эшләгәндә керә идем — елыйсы килә иде. Залда дүрт-биш рәт тамашачы утыра.

**Шәүкәт Биктимеров:** Театр училищесын бетергәч, яшьләргә кытлык икәнен күрдек. Олы артистлар составы әйбәт, көчле. Репертуар —очраклы, өстән төшкән күрсәтмә белән төзелгән. Мәҗбүри рәвештә урыс драматургиясен куйдыралар иде. "Модный" язучылар булды, әсәрләре бармый, әмма аларны куярга кирәк. Бер-ике милли спектакль, калганнары — Мәскәү тәкъдим иткән пьесалар.

**Туфан Миңнуллин:** Истәлекләр белән уртаклашабыз икән, шул чордан бер хатирәне сөйләп китим әле. Бик яхшы беләсез, Татар академия театрына баш режиссер итеп Михайлов дигән урысны билгеләделәр. Шул кеше театр

коллективын жыеп: "Я выбью из вас татарщину", — дигән иде. Аңа каршы чыгып сүз әйтүче табылмады шикелле. Безгә, яна гына укып кайткан щепкинчыларга, бу бигрәк авыр тәэсир иткән иде. Әйе, сүз әйтмәдек Михайловка. Ләкин театр үз юлыннан да тайпылмады. Озакламый килмешәк урыс театрдан китәргә мәжбүр булды.

**Шәүкәт Биктимеров:** Дөресен әйтим: "Артист тормышы белән яшәп булмас, халык йөрми, ана бу сәнгатьнең киләчәге юк, театр бетәр", — дип уйлаган чакларым булгалады. Хәтта үзем теләп армиягә киттем, офицер булырга ниятләгән идем. Ләкин театр үлмәде. Чишмә кебек үз юлын тапты. Театрыбызда үзгәреш башланды. Бу үзгәреш баш режиссер булып Марсель килгәч аеруча сизелде.

Ул Мәскәүдә театр сәнгате институтында зур осталарда укыган, театрның традицияләрен белгән кеше. Аңа диплом спектаклендә үк игътибар иттек. А. Островскийның "Котырган акчалар"ын куйды. Бу үзенә бер ачыш булды. Шул ук артистлар, урыс әйберсе, ләкин театрга рух керде, җан керде. Безнең өчен театрны Марсель Сәлимҗанов җитәкләргә тиешлеге ачык булды. "Сүнгән йолдызлар" (К. Тинчурин), "Миркәй белән Айсылу" (Н. Исәнбәт), "Соңгы хат" (Х.Вахит)...

Шул вакытта Рәфкать Бикчәнтәев тә спектакльләр куя башлады. Аның үз карашы, үз интуициясе бар иде.

**Марсель Сәлимҗанов:** Миңа олылар бик нык ярдәм иттеләр. Нәҗип Гайнуллин, Ибраһим Гафуров белән дуслык зур иде. Хөсәен абый Уразиков белән, ул үлгәнче, бик яхшы мөнәсәбәттә идек. Һәм минем бәхеткә, алтмыш беренче елда Щепкин училищесын тәмамлап кайткан студия. Яшьтәшләр. Фикердәшләр. Алар булмасалар, бәлки язмыш башкарак булыр иде. Бер-беребезне җиңел аңладык. Хәй Вахитның "Соңгы хат"ында үзара аңлашуның нигезе төзелде. Заманның йогынтысы да бар әле. Безнең буынны бит "шестидесятники" дип, ягъни "алтмышынчы елларныкылар" дип йөртәләр.

Тагын бер әйбер бар. Яңа режиссер килгәч, театрда өстен-аска әйләндереп үзгәрешләр кертә башлый. Күп артистларны пенсиягә озата, элеккеге спектакльләрне уйнатмый. Ничектер акылым житте, бер спектакльне дә репертуардан чыгармадым. Үз традицияләре, үз мәктәбе булган театр белән сак булырга кирәк иде.

**Туфан Миңнуллин:** Адәм баласының кемгәдер күбрәк симпатиясе була, бу табигый. Синең дә, Марсель, кемнәргәдер симпатияң бар. Шәүкәт абый шундый артистларның берсе. Син аны сүгеп тә ташлыйсың, әмма яратасың. "Әлдермештән Әлмәндәр"не башка театрлар куярга сорагач, мин бу спектакльне Шәүкәтсез куймыйм, диюең үзе ни тора. Бервакыт мин Шәүкәт абый өстеннән сиңа "жаловаться" да иттем әле. "Әйт әле Шәүкәт абыйга, кайвакыт ул минем пьесаларда арттырып җибәрә", — дидем. Син: "Шәүкәт Биктимеровка сәхнәдә нишләсә дә килешә", — дип җавап бирдең.

**Марсель Сәлимҗанов:** Артистка мәхәббәт, симпатия эштә туа. Тормышта дус булып була, әмма эштә — юк. Анда бер-береңне аңлау бик мөһим. Шәүкәт миңа артист буларак бик охшый. Репетиция дәрескә охшамаска тиеш, дип саныйм. Анда шаяру да, уен да, җиңеллек тә булуы шарт. Шәүкәттә шул сыйфат бар. Ул репетициягә җиңеллек кертә.

**Шәүкәт Биктимеров:** Миңа төрле режиссерлар белән эшләргә туры килде. Һәм бер нәтиҗәгә килдем. Иҗат чикләүне яратмый. Мәсәлән, кайбер режиссер теория белән шөгыльләнә. Сәнгать белән түгел. Ул спектакльне репетициягә хәтле үк куеп кила. Мизансценалар сыза, бу сүзләр болай әйтелер, бу кеше монда басарга тиеш, дип конструкция төзи дә, артистны шул кысага куып кертә башлый. Артист бу очракта попугайга әйләнә. Сәхнәдә үзеңне томкын шикелле хис итәсең.

Бу яктан Марсель Сәлимҗанов та, Празат Исәнбәт тә әсәрнең идеясен һәм артистны ачарга тырышалар, аның шәхесенә иҗади мөмкинлек бирәләр. Әгәр дә артист шундый иҗади иркенлекне сизә икән, ул ачыла.

Чын иҗатым Марсельдән соң башланды, мин шуның белән бәхетле. Минем

стихиямә ирек бирелде. Ләкин ирек чамасыз түгел. Марсель мине контрольдә тота. Тикшерә, юнәлеш бирә, әмма диктаторга әйләнми. Шуңа бар рольләремне дә яратып уйныйм.

Режиссер диктатор булырга тиеш, диләр, бәлки шулайдыр, сәхнәдә диктатурасыз булмый. Әмма һәр нәрсәнең чамасы бар.

Драматургия турында да әйтәсем килә. Туфан Миңнуллин, Хәй Вахит, Аяз Гыйләжев, Шәриф Хөсәенов — бүгенге драматургиянең олы затлары. Театрның зур бер чорын, эпохасын тәшкил иткән кешеләр. Аларның әсәрләрендә халык тәрбияләнде, артистлар үсте, театр яшәде. Бик зур рәхмәт. Минем иҗатым шушы әйтеп киткән драматурглар иҗаты белән бик нык бәйләнгән.

**Туфан Миңнуллин:** Тамашачы яки тәнкыйтьчеләр тарафыннан бәяләнүгә карамыйча, эшләү процессында тәм китергән, артист булуым белән бәхетле дип эшләгән рольләр, мизгелләр бардыр...

**Шәүкәт Биктимеров:** Тәмле ризыкны ашыйсың да ашыйсың бит. Ничек пешергәнне дә уйлап тормыйсың. Тәмле — бетте-китте. Шәриф Хөсәеновнең "Әни килде"сендәге Исламны ничек онытасың? Начар кешене яхшы итеп уйнаганым өчен тамашачылар мине каһәрлиләр. Ләкин миңа рәхәт. "Әни килде"не Баулыда уйнаганда бер хатын беренче рәткә утырган да, шуннан миңа таш атып утыра, ә мин сөенәм.

**Туфан Миңнуллин:** Театр сәнгате өлкәсендә кибәкне орлыктан аера белүемә карамастан, минем дә шул рольдән соң сезгә карата бер тискәре карашым туып, интегеп йөрдем. Шулай шәп итеп уйнадыгыз.

**Шәүкәт Биктимеров:** Леоновның "Ябырылу"ында да шундыйрак роль. Автор үзе карады, кабул итте. Тискәре булса да, рәхәтләнеп уйнадым. Горбатовның "Бер төн"ендә Кривохатский да яратып уйнаган рольләрнең берсе. Тискәре, әмма бик кызыклы. "Зәңгәр шәл"дәге ишанны да әйтмичә булмый.

**Марсель Сәлимҗанов:** Гел тискәреләрне уйнатканмын икән. Шушында өстәп китәсем килә, Кривохатский-Биктимеровны күргәч, Мәскәүнең билгеле тәнкыйтьчесе Анастасьев: "Это лучший Кривохатский в Советском Союзе", — дип әйткән иде.

**Шәүкәт Биктимеров:** Тискәреләрнең холыклары кызыграк, шуңа алар беренче булып искә төшәләр. Уңай рольләрне дә күп уйнадым. Әлмәндәр минем өчен бик кадерле. Марсель пьесаны укуга, сиңа бирәм, дип әйтте. Башка сораучылар бар, тик сиңа гына бирәм, ди. Кот алынды бит. Әсәрне укырга бирде. Үзем генә өйдә укыйм, көләм дә, көләм генә. Куелышын ук күз алдыма китердем. Әсәр бик яхшы укылды. Озын гомерле бу роль миңа бик зур популярлык китерде.


Туфан, синең әсәрләреңдә Бәхтияр Канкаев, "Ат карагы"ннан Шәкүр карак та миңа якын.

**Туфан Миңнуллин:** Берничә театрда "Әлдермештән Әлмәндәр"не куярга туры килде. Карый алмыйм бит. Шәүкәт абый комачаулый. Аның Әлмәндәре килә дә баса. Башка уйнаучылар әллә кая китеп югалалар.

Элегрәк артистның дәрәҗәсе классикада нинди роль уйнавы белән билгеләнә иде. Совет чорында бу — Ленин роле иде. Аны теләсә кемгә бирмәделәр. Ленинны уйнау өчен Үзәк Комитеттан рөхсәт алырга кирәк иде. Хәтерләвемчә, элегрәк сез сүзегезне Ленин роленнән башлый идегез. Һәм ул табигый да. Заман өчен, конъюнктура өчен дә кирәк булгандыр.

Ленин роле дигәндә, мин һич кенә дә ирония сүзе кулланмыйм. Акыллы кеше, бөек шәхес, аның ролен уйнавы җиңел булмагандыр. Бүгенге күзлектән карап, фикерегез ничегрәк?

**Шәүкәт Биктимеров:** Ленинны уйнау бик җаваплы эш иде. Мин кинодубляждан, радиодан башладым. Аннан соң Марсель Сәлимҗанов миңа бу рольне (Н. Погодин — "Баһадирлар") тапшырды. Мәскәүдә парикларны махсус эшләделәр, бөтен шартларны тудырдылар.



*Ш. Биктимеров Ленин ролендә.*

Ленин — егерменче гасырның бөек шәхесләренең берсе. Әйе, аны бик нык идеаллаштырдылар. Хәзер төрле архивлардан, төрле мәгълүматлар тартып чыгаралар. Ләкин, игътибар итегез, ул бит революциядән соң озак яшәмәгән. Агачын гына утырткан, җимешен күрмәгән. Шәкертләре исә бер-берсен ашап, үтереп бетерделәр.

Минем аңа мөнәсәбәтем... Бүгенге көндә Ленинга шундый караш миндә канәгатьсезлек хисе тудыра. Без яшьтән Ленин исеме белән үстек бит.

Күптән түгел Казан педуниверситеты студентлары белән очрашырга туры килде. Шунда Русия дәүләтенең бүгенге башлыгы Ельцин турында сүз чыкты. Аннан да надан итеп сөйләшүче юк бит. Ун сүзенең берсе: "Знаете, понимаешь". Ленин: "Укырга, укырга, укырга", — дигән. Менә бүгенге президент ничә ел Русия башында утыра, укырга кирәк дигән сүзен ишеткән юк әле. Яшьләргә үрнәк, укырга өндәү юк.

**Туфан Миңнуллин:** Без бүгенге көн сәясәтенә кереп киттек. Һәм бу табигый да. Без сәясәттә яшибез, ансыз булмый. Үзгәртеп корулар башлангач, безнең үтә булдыклы милләтчеләр дә барлыкка килде. Милләт турында кайгыртып сөйләшкәндә безнең театрга гаеп ташланды. Үтә унган милләтпәрвәрләр театр милли көрәштә катнашмый, митингларга чыкмый, диделәр, пассивлыкта гаепләүләр дә ишетелде. Шушы чор аша да үттек. Ә театр, минем уемча, бары тик милли көрәш белән яшәде. Шуңа күрә, бу мәсьәләдә дә сезнең фикерегез матбугатта басылырга тиеш дип уйлыйм.

**Шәүкәт Биктимеров:** Безгә урамга чыгарга кирәк түгел. Безнең янга кич саен меңгә якын кеше җыела. Карарга, тыңларга киләләр. Без көн саен халык белән сөйләшәбез. Шушы шартларда лозунг ташлап йөрү кирәкме? Без фикеребезне сәхнәдән җиткерәбез.

Театрның эш юнәлеше, сәясәткә карап, беркайчан да үзгәрмәде. Хәтта торгынлык елларында да, милләт диеп кычкырып әйтергә ярамаган вакытта да, ул халыкның университеты булды. 1906 елда ачылган халык театры позицияләрен саклады, халыкның мәнфәгатенә тугры калды, шуңа яшидер дә.

**Туфан Миңнуллин:** Шул уңайдан бер вакыйганы искә төшерик әле. Бервакыт Марсель Сәлимҗанов җитәкчелегендә театрның өлкәннәре Үзәк Комитетка керделәр. Чит илгә гастрольгә чыгарга сорагач, ҮКнең идеология бүлегендә: "Ә сез анда кемгә спектакль уйнарга җыенасыз?" — дип сораганнар. Чит илләрдә татарлар күп яши, аларга уйныйбыз, дигәнне ишеткәч: "Ә сез беләсезме, чит илләрдә татарлар берсе дә пролетар түгел, буржуйларга спектакль уйнамакчы буласызмы?" — дип рөхсәт бирмәгәннәр.

**Марсель Сәлимҗанов:** 90 еллык тарихы дәвамында театр милләт өчен көрәште. Татар халкы йөзен югалтмасын, шушы дөньяда татар булып калсын дип яшәде. Һәрбер спектакле шуңа юнәлдерелгән иде. Хәзерге актив милләтчеләр "милләт" сүзен әйтергә курыккан вакытта да, театр авыз тутырып татарча сөйләшә иде. Туфан, синең иҗатыңны гына алыйк. Җитмешенче елларда милләтчеләрнең кайсысы, урыстан курыкмыйча, халык алдына чыгып: "Татар түбәтәен башы белән бергә генә сала", — диде икән. ("Бәхтияр Канкаев")

**Шәүкәт Биктимеров:** Шул сүзләргә Мәскәү гастрольләре вакытында тамашачы кул чапты.

**Марсель Сәлимҗанов:** Урыс белән татар мәсьәләсе иң кискен итеп куелган вакытта без "Илгизәр + Вера"ны уйнадык. Милләтара мөнәсәбәтләр белән шаярырга ярамый, бик сак кыланырга кирәк, бу проблема дөньяда бар, дидек. Ул заманда бу турыда берәү дә әйтми иде. Митингларга да чыкмыйлар иде.



*Сулдан уңга Г. Камал театры артистлары: Алсу Гайнуллина, Шәхсәнәм Әсфәндиярова, Шәукәт Биктимеров, Зөлфия Зарипова. Белгород шәһәре, 1989 ел.*

Үзгәртеп корулар башлангач, күпләр аптырап калды, ә без "Вөждан газабы" спектаклен куйдык. Үзгәртеп коруны без дә әзерләдек, дип әйтер идем әле. Һәм бу нинди дер купшы сүз түгел. Татар классикасында аңлаган кешегә аңларлык сүзләр таба идек. Г. Камалның "Американ"ында, мәсәлән, шундый җөмлә бар: "Властьне алуы җиңел, ә идарә итүе авыр". Ул сәхнәдән әйтелеп килде.

Без урамга чыгып кычкырып йөрмәдек, әмма һәрвакыт татар теленең чисталыгы өчен көрәштек, татар моңын, гореф-гадәтен күрсәттек. Театрны урамга тезеп бастырып: "Азатлык! Азатлык!" — дип кычкыру — ул очсызлы популизм. Тирәнрәк ысуллар белән эш итәргә кирәк.

**Туфан Миңнуллин:** Заманында андый хәрәкәт тә кирәк иде, әмма ул театр эше түгел.

**Марсель Сәлимҗанов:** Әлбәттә. Театрның үз вазифалары бар.

**Туфан Миңнуллин:** Әгәр әйтәсе сүзен театр мәйданда кычкырса, ә сәхнәдә шул сүзне әйтмичә калса, аның кирәге булмас иде. Матбугатта шушы сүзләрнең басылуы бик мөһим, чөнки бүген дә театр белән уйнаучылар бар. Театрга барлы-юклы гаеп ташлау һаман дәвам итә.

Үзгәртеп кору дигәнне дә, демократиянең дә төрле якларын күрдек. Демократиянең нәрсә икәнен иң надан кеше дә аңларлык итеп күрсәттеләр. Шулай да театр яшәвен дәвам итә. Труппасы көчле, режиссурасы, аллага шөкер! Драматургия дә, минемчә, үкереп еларлык түгел. Күптән түгел үткән пьесалар конкурсына 65 сәхнә әсәренең килүе күңелле хәл. Аларның сыйфаты төрледер, әмма иҗат дәвам итә, язалар.

**Марсель Сәлимҗанов:** Әлбәттә, яхшы пьесаларга беркайчан да туеп булмый. Ләкин бүгенге көндә урыс драматургиясе белән чагыштырганда, безнең хәлебез бераз яхшырак. Безнеңчә болай була ул дип, заман проблемалары турында үз сүзебезне әйтеп киләбез. Бер генә теләк — күбрәк язсыннар, батыррак булсыннар, бүгенге көннән курыкмасыннар иде. Катлаулы, авыр чор, әлбәттә, әмма аның кызык ягы да бар бит. Шуны тота белергә кирәк. Буталчык вакытта татарның позициясе ничек булган, нәрсә белән яшәгән. Бу заман тарихыбызда калырга тиештер.

Элегрәк репертуарны төзү бик катлаулы иде. Үзеңнең худсоветың, мәдәният министрлыгы, обком. Аннан соң бара идек Мәскәүгә, анда татарга нәрсә кирәк икәнен бездән яхшырак "беләләр" иде. "Приемная комиссия" дигән нәрсә булды. Драматург пьесасын бер ел уйлап йөри, ярты ел яза, спектакль өстендә өч ай эшлисең... Нәтиҗәдә — шул комиссиягә җыелган кешеләр (күп очракта дилетантлар) бер сәгатьтә сиңа: "Моны болай ит, тегене тегеләй ит, драматург монда шулай язарга тиеш", — дип китәләр иде. Бу бик рәнҗетеп килде. Аллага шөкер, алардан котылдык. Атнага бер-ике мәртәбә обкомга чакыртудан да котылдык — монысы бик әйбәт. Соңгы елларда минем өлешкә төшкән ин зур бәхетләрдән берсе, дип саныйм.

Әмма мондый азатлыкның икенче ягы проблемалар да тудыра — социаль мәсьәләләр бөтенләй диярлек чишелми. Менә Шәүкәт Биктимеров — СССРның халык артисты, Дәүләт премияләре лауреаты. Әгәр дә аны пенсиягә чыгарсак, 300 тәңкә пенсия белән нишли ул? Вакыт җитә — яшьләрне алырга, кайбер артистларны пенсиягә чыгарырга кирәк. Әмма алар белән гомер буе эшләнелгән, аларны өч йөз тәңкә пенсиягә калдырырга кул бармый. Шушы проблеманы ничек хәл итәргә — мин белмим.

**Шәүкәт Биктимеров:** Бүген артистның гына тормышы катлаулы дип әйтеп булмый. Гомумән, сәнгать, фән өлкәсендә эшләүчеләргә барысына да авыр. Сәнгатьтә, иҗатка якын килмичә, акча эшләү өчен генә җырлап йөрүче чүпләргә генә җиңелдер.

Шулай да, аллага шөкер, республикабызда ничә театр бар, ничаклы артист, икътисади авырлыкларга карамастан, әле яшәп киләләр. Халкыбыз да, дәүләт башлыклары тарафыннан да яратуны, ихтирам итүне сизеп яшибез. Тормыш президентыбызга да, башка җитәкчеләребезгә дә авырдыр, театрга, шәхсән, артистларга, язучыларга игътибар булу бик зур әйбер, матди бүләкләрдән дә кыйммәтрәк, дип әйтер идем.

Бәлки әле тормышлар үзгәрер...

**Туфан Миңнуллин:** "Зәңгәр шәл"дә әйтелгәнчә, бәлки наследник туар...

**Марсель Сәлимҗанов:** Бәлки манифест чыгар...

**Шәүкәт Биктимеров:** ...артистларның, язучыларның, фән эшлеклеләренең хәлләре яхшырыр.

**Туфан Миңнуллин:** Шәүкәт абый рәхмәтле кеше ул. Гомумән, театрда кул чапканга сөенеп яши торган зат кына эшли ала. Ач торса тора, кирәклеген белсә, шуңа шатлана. Әмма тирәнтен, тулаем алганда сәнгатькә игътибар җитеп бетми.


Мин Татарстан Дәүләт Советы депутаты буларак, бюджет кабул иткән вакытта сәнгать турында чыгып үземнең сүзләремне әйтә киләм. Без барыбыз да — язучы-депутатлар бу турыда сүзебезне бик кискен әйтәбез.

Тагын бер проблема бар, хәзер профессиональ сәнгать беркадәр чигенде. Ә үзешчән сәнгать күтәрелде. Бигрәк тә бу эстрадада нык сизелә. Театрга бик кагылмады кебек, әмма аңа да бу куркыныч яный. Шуны йоктырмаска иде. Эстрадада яхшы белән начарын бергә карап талымсызланган тамашачы театрга килә башлады. Шаккаттым — спектакльдә сызгыралар. Бу стадионнан, эстрададан кергән әйбер. Шуңа күрә театрга традицияләрне саклап эшләү авырлаша.

Хөкүмәтебез чыннан да татар театрларын саклап калды. Кайбер җирләрдә яңа театрлар ачылды да. Әмма милли театрның флагманы булган Академия

театрына игътибар күбрәк булса да ярар иде. Чөнки ул сакланса, янәшәсендәге башка театрлар, аңа карап, ниндидер эталон рәвешен саклыйлар. Хоккей командасына игътибар зур бит. Нигә театрга булмаска тиеш?

Күптән түгел бер мәкалә укыдым, шуның ахыры бик кызыклы. "Минем әтием үлде, күп кешеләр кайгымны уртаклашып шалтыраттылар, ничек ярдәм итик, дип сорадылар. Шалтыратмаган бер генә кеше булды, әмма ул килеп миңа әтине җирләргә булышты", — дип язылган анда. Бәлки кайгы уртаклашу гына түгел, конкрет ярдәм дә кирәктер. Театрны яшәтү безнең бай республикага проблема булмаска тиештер. СССР таркалгач барлыкка килгән чит илләрдә калган татарлар белән аралашмый башладык. Чыннан да Урта Азиягә, Казакъстанга, Русиянең ераграк төбәкләренә бара алмыйбыз. Ә милләттәшләр безне көтәләр бит. Аудио һәм видеокассеталар гына аз. Тере артистны күрү — үзе бик зур нәрсә.



*Ш. Биктимеров Әлмәндәр ролендә*

Бүгенге очрашуны йомгаклап, шуны әйтәсем килә. Сез, Шәүкәт абый, зур шәхес, сәнгать тарихында бер чорны билгеләүче оста, 50 ел театрда хезмәт иткән кеше. Сезгә, сезнең белән бергә эшләгән кешеләргә исәнлек-саулык телим. Чөнки театрда бер үзең генә исән-сау булып йөрсән, театр юк — кызык түгел.

Сезгә саулык белән бергә милләтебезгә рухи сәламәтлек телисем килә. Сез һәм сезнен кебек талантлар халкыбызның исәнлеген билгеләүче кешеләр.

**Марсель Сәлимҗанов:** Мин дә Шәүкәт Биктимеровка беренче чиратта сәламәтлек телим, аның иҗади сәләте ташып тора, чишмәсе кипмәгән, саекмаган.

**Шәүкәт Биктимеров:** Теләкләрегез өчен бик зур рәхмәт!

Без эшлисен эшләгән, театрның киләчәге ничек булыр — безне иң борчыган мәсьәлә шул. Безнең театрыбызның яна буыны әйбәт кенә эшләп килә, сәнгать академиясе яшь артистлар әзерли — димәк, театрыбызның киләчәге бар дигән сүз, театр яшәячәк. Әмма ничек?

Театр алга китсен, тагын да яшь кешеләр килсен, татар театр сәнгате, гомумән, татар сәнгате чәчәк атсын! Чөнки милли сәнгать, милли әдәбият яшәгәндә генә халкыбыз яшәячәк.

*Театрга гомерләрен багышлаган олпат затларның бөек артистыбыз Шәүкәт абый Биктимеров юбилее уңаеннан җитди сөйләшүенә өстәп, үземнең дә кайбер фикерләремне әйтергә батырчылык итәм.*

*Беренчедән, әлбәттә, Шәүкәт абыйны чын күңелдән котлыйм, исәнлек-саулык телим, таланты алдында баш иям.*

*Әйе, театрның тарихы бай, традицияләре искиткеч, яулаган биеклекләре бәхәссез. Бүгенге көндә дә ул үзенең абруен саклап килә. Ләкин театр күге чалт аяз дип әйтмәс идем. Алда җиң сызганып эшлисе эшләр бихисап. Театрның үзенә дә, татар театрына теләктәшлектә торган, җаны булган һәрбер кешегә дә.*

*Әңгәмәдә кузгатылмаган проблеманы билгеләп үтәсем килә.*

*Иң мөһиме — тамашачы мәсьәләсе. Татарстаннан читтә, Башкортстанны исәпләмәгәндә, күмәкләшеп яшәгән татарлар театрдан аерылды. Элек ил буйлап гастрольләргә йөргән Академия театры хәзер Казан һәм Татарстан*

*тамашачысы белән генә очраша. Мохит тарайганнан тарая. Нәтиҗәдә, милләттәшләребезнең күпчелеге милли мәдәнияттән читләшә, икенче бер халыкның мәдәниятен кабул итә һәм киләчәктә татар буларак үз йөзен югалтачак.*

*Бу сак-соклыкның объектив сәбәпләре дә бар, билгеле. Илдәге акча кытлыгы театрның мөмкинлекләрен чикли, "өйдә генә утырырга" мәҗбүр итә. Шулай да элемтәләрне өзмәскә тырышырга, заманга яраклашып, читтәге тамашачы белән очрашу юлларын эзләргә иде.*

*Татар театр ярата. Шуны онытмаска кирәк.*

*Казанның үзендә һәм аның тирәсендә яшәгән тамашачы проблемасы да бар. Бәхеткә күрә, тамаша яратучы татар театрны үз итә. Тере артистны күрергә театрга килә. Әмма бик күп гаиләләр суррогат белән канәгать булып яшәүгә күчәләр, бөтен дөньяны басып алган видеокассеталар әйләндереп, шуннан тәм табалар. Бу ярышта җиңүче булып калыр өчен дә театрга нык эшләргә кирәктер. Янә дә килеп, хәзерге егерме-утыз яшьләрдәге тамашачының мәктәптә тулысынча диярлек урыс мохитында тәрбияләнгән буын икәнен дә онытырга ярамас. Алар белән уртак тел табып, аларны иманга кайтару да театрыбызның бурычы.*

*Театрның нигез ташын драматургия, режиссура, артист уены белән бергә тамашачы да тәшкил итә. Талантлы тамашачы гына Шәүкәт абый Биктимеров кебек талантларны бәяли, хөрмәтли һәм үстерә ала. Татарча сөйләшүче яшьләр саны аз. Димәк, татар театрына булачак артистларны сайлау да кыенлаша.*

*"Халыкка дәрсе гыйбрәттер театр,*
*Күңелдә йоклаган дәртне уятыр", —*

*дигән бөек Тукай. Шуны истә тотып эшләргә дә эшләргәдер.*

*Әңгәмәне матбугатка* ***Әлфия МИҢНУЛЛИНА*** *әзерләде.*

---

## АЛДАГЫ САНДА УКЫГЫЗ:

*"Минем куен дәфтәрләремдә яшүсмерләрнең дистәләрчә җинаятьләре хакында бик күп язмалар теркәлгән. Алар арасыннан мин аеруча шәфкатьсезлек-миһербансызлык белән, әйтергә кирәк ки, кансызлык белән эшләнгәннәрен җентекләп тикшерәм, өйрәнәм, нәтиҗәләр ясыйм. Чөнки мондый җинаятьләр һәрвакыт авыр тойгылар уята, күңелдә тиз генә җавап таба алмаслык күп төрле сораулар кузгата. Ни өчен, ни сәбәптән, бу кадәр шәфкатьсезлекнең нигезләре кайда? Әллә соң кешелек дөньясы алга киткән, тәрәккый иткән саен деградациягә — үзенең бетүенә таба юл тотамы?*

*Менә бер мисал.*

*Е. В. Турилин дигән бер бәндә коточкыч җинаять эшли: исерек хәлендә әле балигъ булмаган ундүрт яшьлек кыз баланың башына күп мәртәбәләр чүкеч белән сугып, аны үтерә. Аннары, җинаятен яшерү нияте белән, корбанының гәүдәсен тураклап-кискәләп үзе яшәгән йортның подвалына яшерә.*

*Әлбәттә, мондый җинаятьчеләр төрмәдә утырганда да үзләреннән көчсезрәк-юашрак үсмерләрне кыерсытырга, аларны төрлечә мәсхәрәләп-газаплап ләззәтләнергә юл эзлиләр".*

Бу юллар Казан шәһәре эчке эшләр идарәсе башлыгы, милиция полковнигы **Н. Г. Әкбәровның "Шәфкатьсезлек"** дип исемләнгән язмасыннан алынды. Тәрбиягә авыр бирелә торган яшүсмерләр белән озак еллар эшләү тәҗрибәсенә таянып язылган күләмле мәкалә журналның 11 санында дөнья күрәчәк.

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Фәрит Бәшир

# ЮЛЫН БЕЛГӘН — АРЫМАС!

НУРИХАН ФӘТТАХНЫҢ ТУУЫНА 70 ЕЛ ТУЛУ УҢАЕННАН

Егерменче гасыр узып барганда татар әдәбияты ирешкән уңышлар, яулаган биеклекләр турында горурланып сөйләр хакыбыз бар икән, без моның өчен иҗат өлкәсендәге олуг шәхесләребезгә бурычлыбыз. Гомеренең өченче чирегендә дә үткен каләмен кулыннан төшермичә, әсәрләре белән милләт укучысын даими кинәндерә килгән Нурихан ага Фәттах әнә шундый мөхтәрәм затлар кабиленнәндер.

Нурихан Фәттахның иҗат дөньясына юл башы күп язучыларныкыннан аерылмый диярлек: мәктәп елларында ук шигырьләр, хикәяләр яза, әдәбиятка булган мәхәббәт хисе аны байтак каләм әһелләренә фатиха биргән Казан дәүләт университетының мәшһүр татар бүлегенә алып килә. Студент елларында ул фольклор экспедицияләрендә катнаша, халык иҗаты әсәрләрен җыя, бик бирелеп халкыбызның йолаларын, гореф-гадәтләрен өйрәнә, сөйләм үзенчәлекләрен үзләштерә. Бу рәвешле мавыгу булачак язучыга әдәбиятның әлегә беркем дә ирешә алмаган биеклекләренә күтәрелүдә хәлиткеч роль уйный.

Н. Фәттахны язучы итеп таныткан, аның исемен киң җәмәгатьчелек арасында яңгыраткан әсәре — 1955 елда язып тәгәлләнгән “Сезнеңчә ничек?” романы булды. Роман иң әүвәл 1956 елда “Совет әдәбияты” журналында басылып чыга, аннан 1957 елда аерым китап булып дөнья күрә. Роман тиз арада укучыларның иң яратып укый торган әсәрләреннән берсенә әверелә. “Сезнеңчә ничек?” әсәренең абруе әдәби җәмәгатьчелек каршында шул кадәр зур була ки, роман тиз арада русчага тәрҗемә ителеп Мәскәүдә басылып чыга.

Н. Фәттах, әнә шулай итеп, бер талпынуда татар әдәби хәрәкәтендә үз юлын булдырган, үз дөньясын тудырган язучы сыйфатында танылa.

“Сезнеңчә ничек?” романының бу рәвешле дан казануы мәгълүм шартлар һәм эчке сәбәпләр йогынтысында булды. Беренчедән, роман дөньяга килгән чор Сталин терророннан соңгы дәвер иде. Роман тудырырга сәләтле күп әдипләр юк ителделәр яки әлегә сөргеннәрдә иза чигәләр иде. Г. Ибраһимов, М. Галәү романнары тыелып, архивларның караңгы почмакларына бикләнгәннәр. Аннары Бөек Ватан сугышы... Бик өметле, әммa иҗатлары бөредә килеш харап булган, мәңгегә “башлап язучы” сыйфатында калуга дучар ителгән байтак иҗат көчләребез яу кырларыннан кайта алмадылар. Сугыштан соңгы татар әдәбияты боз суккан иген кырын хәтерләтә иде. Бу дәвердә язылган романнарны да бармак белән санарга мөмкин: К. Нәҗминең “Язгы җилләр”, Г. Бәшировның “Намус”, И. Газиның “Гади кешеләр”, “Онытылмас еллар”, Г. Әпсәләмовның “Алтын йолдыз”, “Газинур” әсәрләре — менә бар булганы шушылар булса кирәк. Шуңа күрә дөнья күргән һәр романның ихлас кызыксыну уятуы, вакыйга итеп кабул ителүе гаҗәп түгел. “Сезнеңчә ничек?” әдәбият зур эпик әсәрләргә аеруча кытлык кичергән бер заманда дөньяга килде. Коргаксыган күңелләргә шифалы дым булып ятты ул роман.

Янә шул да мөһим, “Сезнеңчә ничек?” романы укучылар төркеменнән иң житез, хәрәкәтчән, эзләнүчән катламга — яшь буынга адресланып, Казан университеты егет һәм кызлары тормышын бәян итүгә багышланган иде.

Студентлык темасы безнең әдәбиятта иң өйрәнелмәгән темаларның берсе булды һәм хәзер дә шулай кала бирә. Ни сәбәптәндер, татар әдипләре бу темага мөрәҗәгать итәргә бик атлыгып тормыйлар, язарга алынган вакытта да эпизодик сурәтләүләр яки кыска-кыска хикәячекләрдән ары китмиләр. Бу әле шуңа да бик гаҗәп, бүгенге татар язучылары арасында студент икмәге "кимерәп" карамаганнары юк та бугай. Хәер, бу юнәлештә эшләр бигрәк мөшкел икән дип аһлар орырга җыенмыйм. Сәбәбен аңлап булмый торган моңдый өнсез тынлыкны чатнаткан ике әсәрне атау зарур. Болар — Г. Ахуновның "Яшьлек яме" һәм аеруча М. Мәһдиевнең "Без — кырык беренче ел балалары" исемле повестьлары. "Сезнеңчә ничек?" романы әнә шундый буш яткан бәрәкәтле туфракка тап булып, тиз арада укучы күңелендә тамыр җибәрә алды. Әсәр язылуга инде 40 елдан артык вакыт узган, китаптагы кайбер аспектлар үткән заман фәлсәфәсе булып калган, ә кайбер карашлар хәзер инде елмаю уятырга гына сәләтле. Әмма шушыларга карамастан, китапның төп кыйммәте уңмаган, югалмаган һәм ул бүген дә яратып укый торган әсәрләрдән санала килә.



*Нурихан Фәттах. 1985 ел.*

"Сезнеңчә ничек?" романының сюжеты гади һәм ул мәгълүм бер вакыт аралыгындагы хәлләрне сурәтләүгә нигезләнгән. Үзе дә кайчандыр шул тирәлектә кайнаган кеше буларак, Н. Фәттах студент тормышын белеп яза, әлеге үзенчәлекле даирәнең рухын укучыга мавыктыргыч алымда китереп житкерә ала. Ул имтихан чорын тасвирлыймы (дулкынлану, җинелчә генә ыгы-зыгы, ашыгып китап актарулар, шатланып кычкырулар, яки аһ итеп көрсенүләр), студентларның җәйге ял вакытларын сурәтлиме (авыл кешеләренең булачак "зур кешегә" сынап та, сокланып та караулары, үз чиратында "зур кешенең" үз фәлсәфә югарылыгыннан торып авылдагы хәлләргә бәя бирүе, акыл сатуы, вакыты белән көлкегә дә калуы), яки инде яшь йөрәкләрнең хисләрен бәян кыламы (хыянәт, тугрылык, ихласлыктан гыйбарәт сынау күперләрен узулар) — болар барысы да бик җанлы, кызыктыргыч картиналар аркылы укучыга барып ирешәләр.

Язучыны иң әүвәл олы тормышка беренче адымнарын гына атлаган яшьләрнең эш-гамәлләре кызыксындыра: кемнәр булырлар алар? Нинди юлны сайларлар? Ният-максатлары нинди? Бу сорауларга җавапны автор ике яшь йөрәк — Ида белән Сәгыйть язмышын сурәтләү аркылы укучының үзенә эзләргә тәкъдим итә. Бу яктан Н. Фәттах дикъкатькә лаек алым куллана: ул күп очракта әзер чишелешләр, нәтиҗәләр бирергә ашыкмый, укучыны уйланырга чакыра, геройларның теге яки бу адымын кабул итәргәме, яисә инкяр кылыргамы икәнен үзенә хәл итәргә калдыра. Романның исеме үк фикер уртаклашу рәвешендә "Сезнеңчә ничек?" дип атала бит.

Вакыйгалар агышында һәркем үзенең чын асылына ачыла бара, тормыш сынавына һәркем үзенең әхлакый багажы белән килә.

... Җәйге сессиядән соң егетләр-кызлар өйләренә таралырга әзерләнәләр. Шул вакыт группа комсоргы көтелмәгән тәкъдим белән чыга. Эш шуннан гыйбарәт: Шәһәрдән ерак булмаган бер колхозда ясалма күл булдырмакчылар икән. Дәүләт колхозга бу эш өчен акча биргән, ә эшче көчләр житми. Колхоз ярдәм сорап университетның комсомол комитетына мөрәҗәгать иткән. Бер группа ризалыгын биргән дә инде һәм өстәвенә әле башкаларны да үзләренә кушылырга чакырып өндәмә белән дә чыккан. Табигый ки, шул заманның идеологик таләпләре югарылыгыннан караганда бу чакыру кичектергесез үтәлергә тиешле фәрман булып яңгырый: ничек инде коммунизм төзүдә партиянең уң кулы булган комсомол яшьләр бу өндәмә-боерыктан читтә кала алсыннар ди?! Сәгыйтьләр группасы да

"Бөтенебез дә барабыз! Берәү дә калмый!" дигән карар чыгара. Бары тик зур сәбәбе булганнарны гына азат итәргә дигән фикер әйтелә. Шул вакыт Ида, "хат алдым — әни авырый" дигән сылтау белән колхозга китүдән баш тарта. Бу ялган Ида белән Сәгыйть арасындагы мөнәсәбәтне киләчәктә чәлпәрәмә китерәчәк беренче чатнау була. Шул рәвешле язучы геройларын хәтәр борылышлардан гыйбарәт әхлак сукмагына бастыра. Һәм ул сукмак һәрберсен кылган гамәлләренә, уй-ниятләренә мөнәсәбәттә яки упкынга тарта, яки инде тагын да югарырак мораль биеклекләргә күтәрә.

Тормышта иркен яшәргә өйрәнгән Ида хис дөньясында да мәгълүм калыпларны танырга теләми, тормыштан һәрвакыт алырга гына өйрәнгәнгә күрә, үзе дә ниндидер бурычлар үтәргә тиешлеге аның башына сыймый. Җәйге ялга аерылыр алдыннан кыз белән егет көн саен хат язышып торырга килешәләр. Сәгыйть, чын гашыйкларга хас булганча, дүртәр-бишәр битле хатлар юллап тора. Ә ял ләззәтенә бирелүгә, вәгъдәсен оныткан Ида нибары бер өтек хат кисәге язып салырга вакыт таба, анысы да әле "монда страшно күңелсез, эч поша, просто ужас!" дигән зарланудан гыйбарәт бер язма булып чыга. Бу — егет белән кыз арасындагы хисләрнең икенче мәртәбә һәм җитди чатнап ярылуы була.

Автор, Иданың мондый адымнарын аңлау өчен, ул тәрбияләнеп үскән мохиткa зур игътибар бирелергә тиешлеген ачыктан-ачык сиздерә. Ида, районны "үз кулында тота" торган башлыклардан берсенең бердәнбер, иркә кызы икән. Әнисе исә, "начальник хатыны", "иптәш Мәхмүтов хатыны" булуга күнегеп китеп, һәртөрле йорт эшләрен кешедән эшләтергә өйрәнгән бер ялкау зат булып тасвирлана. Ида менә шундый атмосферада тәрбияләнә. Бу урында язучы, күрәсең, роман кебек катлаулы жанр белән беренче эш итүе дә сәбәпчедер, кызга үз характеристикасын бирергә ашыга. Аңлашыла ки, мондый хәл хикәяләүнең эчке киеренкелеген киметә төшә. Роман башында ук Иданың тискәре холкын тасвирлап, әдип аны вакыйгалар агышында әзлекле ачылу процессыннан мәхрүм итә. Мисал өчен Иданы сурәтләгәндә автор түбәндәге билгеләмәне укучыга житкерергә ашыга: "Әнисе кебек ялкаулык һәм кайбер бүтән нәрсәләр аның күп кенә яхшы якларына ныклап тамыр җәеп китәргә комачау булды. Ул әнисе кебек, бик холыксыз, бик үз сүзле булып һәм, гомумән, күп кенә начальник балалары кебек, кыртык, иркә, эшлексез булып үсте". Бетте! Кызга хөкем карары чыгарылды дигән сүз. Укучыга инде бары тик ул кылган гамәлләрнең ахырда һичшиксез күренәчәк күңелсез нәтиҗәләрен генә көтәргә кала.

Сәгыйть образында исә язучы күпкә эзлеклерәк эш итә һәм ул героен туган төбәгенә, якыннарына, якташларына мөнәсәбәттә өйрәнүне үзәккә ала. Ида белән Сәгыйть, гәрчә романның әүвәлге битләрендә мәхәббәт хисе белән бер-берсенә нык береккән охшаш җаннар итеп тасвирлансалар да, нәкъ менә туган җиргә мөнәсәбәттә капма-каршы кешеләр булып укучы алдына китереп бастырылалар. Шау-шулы Казан урамнарыннан соң тын, тузанлы туган төбәге Идага гаять авыр тәэсир ясый, гомере буе монда яшәү уе аның котын ала. Ә Сәгыйтькә исә, киресенчә — туган ягы үз, якын. Биредә ул җаны-тәне белән ял итә, хисләре сафланып, күңеле пакьләнеп кала. Ул хәзер туган җиренә дә, авылдашларына да башка күзлектән карый башлый. Алар риясыз, ихлас, Сәгыйтьнең кайтуына чын күңелдән шатланалар; шул ук вакытта сынаулы караш ташларга да өлгерәләр: янәсе, нинди уй-ниятләрдә бу "кала кешесе?" Уен-көлке арасында егеткә — ни әйтсәң дә шәһәрдән кайткан бит — сәясәткә кагылышлы сораулар бирәләр, сак кына колхоз турында, яңа законнар чыгу турында сүз юкмы, җир, салым буенча үзгәрешләр көтелмиме икәнен сорашалар. Авылдашлары белән бергә печән чабу рәхәтлегеннән күңеле изрәгән Сәгыйть уянып киткәндәй була: авылның әлегә кадәр күренми йөргән никадәр авыр проблемалары бар икән бит! Тышкы сабырлык артында авыл кешесенең борчуы, әрнү-газаплары, чарасызлыгы хәттин ашкан икән. Гүзәл табигатьле манзара күләгәсендә хәерчелектән, башбаштаклыктан алҗыган авыл ярдәм сорап ыңгыраша түгелме соң?

Биредә автор заманның иң үткен бер мәсьәләсенә —сугыштан соңгы авылның авыр, газаплы хәленә кагыла. Дөрес, бу мәсьәлә роман үзәгендә тормау сәбәпле, язучы аны артык җентекләми (ул заманда бу мөмкин дә булмас иде).

Колхозларның аянычлы булуына сәбәпче итеп унмаган, булдыксыз житәкчеләр күрсәтелә. Әмма мондый берьяклы караштан да язучы шәхсән бик оста гына итеп тайчана алган. Бу кычкырып торган беркатлы сәбәпләрне ул Сәгыйть исеменнән әйттерә, һәм шуның белән үзе нейтраль позициядә кала.

Колхоз сәясәтендә гаделсезлекләрдән жаннары арыган авыл кешеләренең кайберләре инде эшкә эленке-салынкы карый башлаган. Шунысы куркыныч, бу битарафлыкны акларга нигез бар: эшләдең ни, эшләмәдең ни — нәтиҗәсе бертөсле, хакы бер "таяк"! Әнә шул рәвешле Н. Фәттах героеның уйланулары, күзәтүләре аркылы, ерак тамырлары белән жир эшенә береккән кешеләр арасында төрле типларны күрә һәм күрсәтә башлый. Бу жәһәттән романда капма-каршы тарафларда торган ике характер аеруча калку тасвирлана. Бер төрле яшәү фәлсәфәсен язучы Әхнәф образы аша бәян итә. Әхнәф — күптән түгел генә армия хезмәтен тутырып кайткан һәм яңарак кына өйләнгән яшь ир —колхоздагы вәзгыятьне тиз аңлап алган. Тамырларың шартлаганчы эш йөген тартсаң да, әҗере булмаячак. Авылда социализмның төп принципларыннан берсе булган тигезлек лозунгысы гарип формасында чәчәк ата: түләүсез хезмәт хөкем сөргәндә, барысы да — тырыш жанлысы да, ялкау хәрәсәне дә —бер дәрәжәдә була түгелме соң? Шуна да эш өчен янып, борчылып йөрүчеләргә Әхнәф кебекләрнең жавабы әзер: "Жукка кычытынасың калхуз өчен, барыбер артыгын язмаслар". Шул сәбәпле Әхнәф "булсынга" түгел, "узсынга" йөрүчеләрнең берсе булуны кулай күргән. Аның күңеле инде жирдән бизгән, уе хәзер башкада, жай чыгу белән Урта Азиягә китү нияте белән яши. Әлбәттә, мондый хәлне Сәгыйть бик авыр кабул итә. Яшь герое белән бергә яшь автор үзе дә борчыла, Әхнәфнең шул рәвешле "бер нинди кайгысыз-борчусыз үз туган авылын ташлап китәргә теләве өчен" ачуы килгәнлеген ачыктан-ачык белдерә. Язучы шуңа да Әхнәфнең сурәтен ясаганда тискәре хисләр уята торган төсләрне генә куллана, килеш-килбәтенең ясалма, эч пошыргыч булуына басым ясый. Ә инде аның хатынын тасвирлаган чакта (чөнки Әхнәфне читкә китәргә котыртучы ул бит!) автор тоташ карикатур алымнар белән генә эш итә. Романда Әхнәф жиргә табынып яшәүчеләр арасында ялгыш кына килеп эләккән сынар чүп үләне кебегрәк тәэсир калдыра. Кызганычка



*Нурихан Фәттах кызы Чулпан белән үзе утырткан алмагач янында. 1996 ел.*

каршы, татар хәятында әлеге образ очраклы бер тип түгел иде. Моны раслау өчен иң әүвәл шул чорның эчтәлеген күз алдына китерергә тырышыйк.

... Әсәрдә вакыйгалар илленче еллардагы татар авылында бара. Сугыш беткәнгә дә инде байтак узган, ә хәлләр һаман да аяныч. Исәпсез-хисапсыз налоглар, бер караңгыдан икенчесенә кадәр эшләп тә ичмасам кеше сымак яшәрлек хезмәт хакы ала алмау авыл кешесендә өметсезлек хөкем сөргән яшәү философиясе тудыра. Өлкәннәр, хәттә ки әле урта буын да ата-баба туфрагы, нигезе дип сабыр итә, "язмыштан узмыш юк" дип түзәргә, җан асрарга тырыша. Иң кыен хәлдә — яшьләр. Аларның әле олы тормышка кереп килгән мизгелләре — әти-әниләре кебек алар да шулай ярым хәерче, хокуксыз, мәсхәрәле тормышта гомер кичерерләр микәнни? Әнә шул вакытта инде яшь буын бәхет дигәннәрен читтән эзләү юена кила. Нәтиҗәдә йөз меңләгән татар егетләре, татар кызлары яхшы тормыш эстәп чит-ят төбәкләргә юл алдылар. Ул заманда телләрдән төшмәгән Урта Азия егет-кызларның күңелен җилкендергән ил-җир булды. Китүчеләрнең беренче дулкыныннан өметле җавап алынгач: икенче, өченче... дулкын татар яшьләрен туган төбәкләреннән суырып кына ала башлады. Бу дәвер татар тарихында иң драматик сәхифәләрнең берсе иде. Татар халкын инде ничәмә гасырлар таралырга, чәчелергә мәҗбүр иткән вәзгыять әллә нинди эчтәлеккә, төсләргә төрелеп үзенең кара уенын дәвам итә килә. Бер Үзбәкстанда гына да бүген әллә ничә йөз мең милләттәшебез яши. Тукай, Җәлил, Туфан телендә сөйләшүче татарлар микән соң инде алар? Әллә милләт агачыннан өзелгән, җилгә ияреп еракларга очкан, югалган яфрак хәлендә микән алар?

Романдагы Әхнәф әнә шушы туган илдә яшәүнең мәгънәсен югалткан кеше буларак күз алдына килеп баса. Бәхет эзләп киткәннәрнең ымсындыргыч кайтавазы ("Җимеш белән буа буарлык... Оҗмах инде, оҗмах...") аны да туган төбәген ташлап китәргә чакыра. Шуңа да Әхнәфне ялгызак бер характер дип атап булмый, ул гомумкешелек, ә төгәлрәк әйткәндә, бу очракта ул гомумтатар тибы.

Н. Фәттах романда Әхнәф позициясенә каршы Мәрдәнша агайның яшәү фәлсәфәсен куя. Мәрдәнша агай бөтен барлыгы белән җир кешесе. Колхозның бүгенге аяныч хәленә ихластан борчыла, гел болай бармас, кайчан да булса тормыш яхшыланыр әле дигән өмет белән яши. Колхоз эшен дә ул вөҗданы кушканча җиренә җиткереп башкара. Ул гына да түгел, кеше эшенә дә ул үзенекенә караган кебек карый, эленке-салынкы башкарылган хезмәткә җаны белән әрни. Сәгыйть җәйге ялга кайткач, Мәрдәнша агайның шушы характерын аңлап, беренче кат күргәндәй аңа исе-акылы китеп карап тора: "Ул, дүрт класслык белеме дә булмаган гади колхозчы, аннан, студент Сәгыйтьтән дә, зур урында утыручы һәм шуңа күрә зур җитәкче булырга тиешле Булатовтан да югарырак, биегрәк иде, аңлырак һәм дөрес, аек фикер йөртүдә сәләтлерәк иде". Шул рәвешле ачы тормыш тәҗрибәсе кырыс хакыйкать булып егетнең аңына үтеп керә, тормышка, кешеләргә карата булган карашларын формалаштыра. "Мәрдәнша агай кебекләр кирәк, чын-чынлап кайгыра, борчыла белә торган кешеләр кирәк!.." — бу Сәгыйтьнең генә түгел, авторның да кешелеккә әрнү катыш өмет белән эндәшүе иде. Язучы авылның төп тересе Мәрдәнша агайлар булуын раслый — нинди авырлыклар чигүгә карамастан карганмый, зарланмый тормышны алып барган мондый ил агаларына аның хөрмәте бик зур. Шушы мөхтәрәм затларга лаеклы алмаш булачак саф күңелле, әхлак кыйбласыннан тайпылмаган Сәгыйть, Зәйтүнәләргә дә зур өмет баглый язучы. Бу җәһәттән шундый уй-хис туа: Н. Фәттах авыл тормышын тасвирлап, аның киләчәген уйлап, еракка карый торган фикер-карашларын да уздыра булса кирәк. Яшерен-батырын түгел, татар милләтен башлыча авыл төбәгендә сакланып калды һәм бу шулай килә дә. Телнең, гореф-гадәтләрнең төп сакчысы — авыл. Димәк ки, татар авылының проблемаларын хәл итәргә алыну, ул бер үк вакытта милләт язмышына кагылышлы мәсьәләләрне дә күтәрү иде.

Әнә шул рәвешле Н. Фәттах беренче романы белән үк —гәрчә әсәр яшьләрнең әхлакый һәм хезмәт тәрбиясенә багышланган булса да — халык тарихыннан гыйбрәтле дәрес бирә, сиздерми генә гамьле күңелләрне милләт язмышы турында уйланырга өнди.

Авыл, аның кешеләре Н. Фәттах өчен гомерлек горурлык та, мәңге төзелмәс әрнүле яра да булдылар. "Сезнеңчә ничек?" романында колхоз тормышындагы авыр хәлләргә ишарә генә булган мизгелләр язучының "Артта калган юллар" повестенда бар кырыслыгы белән укучы алдына килеп баса. Әсәр беренче тапкыр 1965 елда "Казан утлары" журналының 12 санында басыла һәм язучының бер генә җыентыгына да кертелми. Бары тик 30 ел узгач кына, 1995 елда "Кырык дүртнең май аенда" дип аталып, әдипнең "Кичү" исемле китабына урнаштырыла. Мондый эчтәлекле әсәрнең дөнья күрүе "җепшетү чоры" дип аталган 60 еллардагы иркен сулыш алу дәверенә бәйле иде. Аннары янадан катырып ташлады — рухи "бозлану чоры" башланды һәм "Артта калган юллар" кебек кырыс чынбарлыкка нигезләнгән әсәрләрнең укучыга бару юлы киселде.

Н. Фәттах бу әсәрендә сугыш чоры авылының иң авыр бер вакытын — 1944 елның язын тасвирлый. Бу — сугыш афәтеннән, фәкыйрьлек, мохтаҗлык изүеннән соңгы чиккә җиткергән авылның "ач үлем куркусыннан" көзге яфрактай калтырап, менә-менә өзеләм дип торган бер дәвере иде. Повесть беренче битеннән үк дәһшәтле киеренкелек белән башлана һәм бу борчылу, гаҗизләнү, ачу, ачынуларның тыгыз бергәлегеннән туган хис ахырга кадәр тетрәнүле халәттә тота. Әсәрнең баш каһарманы Хәмдия образы аркылы язучы шул заманның кырыс картиналарыннан гына торган тормыш сурәтханәсенә алып керә. "Колхоз күтәрәмдә... Җирне сыер белән сөрәләр... Басуда утырып калган ашлыкны ашаучылар агуланып үләләр... Бәрәңге басуларын актарып бетергәннәр.... бер черек бәрәңге табарлык түгел..." Сугышка хәтле авылда кеше затына да исәпләнмәгән әтрәк-әләм властька үрмәләп, карт-карчыклар, хатын-кыз, бала-чагаларны изүдән ләззәт табып яши. Сугышка хәтле авылда ударница булган, Мәскәүгә күргәзмәгә барырга хыялланган Хәмдияне яшьтәшләре белән Себергә урман кисәргә озатканнар. Газаплы хезмәткә түзә алмый качып кайткан дус кызларын төрмәгә япканнар. Хәер, Хәмдиянең Себердәге бараклары да биек койма, тимер чыбык белән уратып алган төрмә янәшәсендә булып, тоткыннар да, иректәләр дә бер үк эштә — урман кисүдә. Тимер чыбык артындагылар әле нәрсә өчендер, ни өчендер хөкемгә тартылган булсыннар да ди, ә Хәмдия кебек яшь кызларны шуларныкына тиң язмышка дучар итү кемнәргә кирәк булды икән сон? Хәмдия бит биредә дә үләрен, өзелерен белми эшли, ирләр көче җитмәслек агачларны аударып дөнья күргәннәрне дә шаккаттыра.

Авылдан аларны башта алты айга дип алып китәләр, аннан янә ярты елга калдыралар, бераздан "сугыш беткәнче эшләячәксез" дип белдерәләр. Әнә шулай "гаепсездән гаепле" Хәмдия борын-борыннан явыз җинаятьчеләр генә хөкем ителгән мәхшәрле язмышка тарый. Ул әле түзгән дә булыр иде, тик биредә аның баласы туа. Бу шартларда нарасыеннан мәңгегә аерылу куркынычы килеп баскач, ул качып кайтырга була. Авылда аңларлар — ул бит эштән тайчынмый, биредә ул көн-төн тир түгәргә риза, аңа күкрәк баласын гына саклау кирәк. Әмма яшь ананы туган җирендә коточкыч хәбәрләр көтә. Авыл күзгә күренеп бетеренгән; ачлык-мохтаҗлыктан карт әнисе ниндидер куркыныч бер битараф шәүләгә әверелгән; әтисе белән абыйсы сугышка һәлак булганнар, кече энесе ерак госпитальдә аяксыз ята; җиңгәсен бер кесә яшел кузак өчен биш елга төрмәгә утыртканнар; салым, заем, ит, май, тире, тагын әллә нинди планнар, "недоимка" кебек шомлы афәтләр хәлсез карчык җилкәсенә күтәрә алмаслык авыр йөк булып яткан... Туган җирендә дә яклау таба алмаган, эзәрлекләнүгә, качып яшәүгә дучар ителгән яшь ана физик һәм рухи газаплар чигү соңында акылыннан шаша, баласын югалта һәм бераздан авылдашлары салам өеменнән Хәмдиянең үле гәүдәсен табып алалар...

Хәмдия сугыш чорының тылдагы корбаны, каргышлы язмыштан, газаплы тормыштан һәлак булган татар хатын-кызларының (аларның санын инде без беркайчан да белә алмаячакбыз) җыелма образы. Ирексездән М. Әгъләмов шигыреннән юллар хәтергә килә:

Ә аның шикелле илемдә
Меңләгән хатыннар үлгәндер...

Н. Фәттахның "Кырык дүртнең май аенда" повестен укыгач, күңелдә

авыр хисләр катыш әрнү кала. Бер үк вакытта ачу да килә, без дә сугыш чоры турындагы әдәбиятны укып, шул заманны беләбез дип йөргәнбез инде! Эшкә жырлап бара, жырлап кайта торган егет-кызлар, көр күңелле Миңле-Җенлекамаллар янәшәсендә фажигале язмышлы Хәмдияләр дә булган икән ләбаса! Ясалма пафослы, заман боеруына ярашып язылган роман, поэма, пьесалар кысасына сыя алмаганга күрә, Н. Фәттах повесте өч дистә ел буе журнал вариантында калырга мәжбүр ителде дә инде.

Әлбәттә, язучы тасвирлаган фажигале хәлләрне сугыш чорының кырыс законнары белән аңлатып булыр иде булуын. Әмма аклап булмас иде! Кемнәрдер газаплы үлем белән дөньядан киткәндә, балда-майда йөзүче шөкәтсез бәндәләрнең кыланмышларын бер генә кырыс закон да сыйдыра алмас иде. Аннан килеп, бу кырыс чынбарлык — гомум халык фажигасе дип киң таралыш алган гыйбарә дә кайбер искәрмәләр таләп итә. Дөрес, тоталитар режимның гаделсез законнары һәр милләтне изү, кол итү сәясәтен алга сөрә. Ләкин изелүчеләр арасында да катлауларга бүленү бар икән әле.

... Хәмдияләр яши торган барак тоткыннарныкыннан һич тә аерылмый, ул әле хәтта төрмә өчен махсус салынган да булган. "Нишләптер анда менә аларны китереп тутырдылар. Барысы да авылдан, барысы да юаш. Татар, удмурт, мари, мукшы..." Россия империясенең рус булмаган милләтләрне икеләтә кысу, рухын сындыру, ахырда юкка чыгару сәясәте булмады микән бу?!

Н. Фәттах татар милләтенең, аеруча яшь буынының, аянычлы язмышын бәян итеп ачыргаланса, татар егет-кызларының эшчән, тырыш, ышанычлы булуын тасвирлап горурлану хисе дә кичерә. Кайда да югалмый икән татар баласы, читят төбәкләрдә дә эшлекле холкы белән ихтирам казана ала икән. Бу мотив Н. Фәттахның "Бала күңеле далада" исемле романында да үзәккә алынды. Чирәм жирләрне үзләштерү чорын сурәтләүгә багышланган бу әсәр зур хезмәт романтикасына дан жырлау булып дөньяга килде. Күтәренке рух белән кузгалган ташкында, бер көнлек "күбәләк" әсәрләрдән аермалы буларак, күзәтүчән автор төрле уй-ниятле кешеләрне таный һәм күрсәтә алды. Зур, купшы эчтәлекле лозунглар ышыгында Ислам сыман кыек эшләрен яшерү максатыннан "чирәм жирләргә" юл тоткан әхлаксызлар да, Фәридә кебек романтикага кызыгып ялгыш килеп эләккән жилбезәкләр дә очрый. Әлбәттә инде, авторның төп сурәтләү объекты болар түгел, әсәр үзегенә жиргә жаны-тәне белән бирелгән Һарун образы алына. Роман каһарманы чыкылдап торган авыл егете, бик гади дә ул, урыны-урыны белән тупасрак та. "Чирәм жир" шау-шуына да ул табигый крестьян философиясе белән ияргән: акча эшләргә, аннан йорт салып өйләнеп жибәрергә. Әмма жиргә булган мәхәббәте, хезмәтне яратуы, бернинди авыр, кара эштән дә тайчанмавы белән ул ялтыравыклы нотыкларга оста, әмма буыннары сыек "энтузиастлардан" нык аерылып тора. Бу юнәлештә ул бригадасындагы кайберәүләр белән каршылыкка да керә. Әйтик Беренче Май бәйрәме уңаеннан аларның табигатькә китеп кәеф-сафа чигеп утырулары Һарунның башына сыймый. Ничек инде, көннәр түгел, минутларның шундый да кадерле, кыйммәтле вакытында чәчүне туктатып, мәжлес корып утырмак кирәк ди? "Язның бер көне елны туйдыра" дигән халык акылы канына сеңгән Һарун — аны никадәр "индивидуализмда", "капиталист калдыгы" булуда гаепләмәсеннәр — жиргә, икмәккә булган чиксез мәхәббәте аркылы формаль карашларны, ялган бердәмлек калыпларын жимереп ташларга үзендә көч таба. Ахыр чиктә яткан жирләр — хәзер инде офыктан-офыкка сузылган иген кырлары — буразнада үскән Һарунның икенче ватанына әверелә. Романның сөземтәсеннән аңлашылганча, Һарун, аның якын, фикердәш дуслары беренче тапкыр үзләре сөргән, үзләре чәчкән казакъ далаларыннан беркая да китмәячәкләр. Роман исеменең русчага "Джигиты остаются в степи" дип тәржемә итеп бирелүе дә бу хакта ике төрле уйларга урын калдырмый. Язучы белән бергә татар егетләре өчен горурлык хисе дә кичерәсең, аларның уңышларына сөенәсең дә. Әмма автордан аермалы буларак, бер сискәнүле уй да күңелдән йөгереп уза: тагын... Инде бу дулкын да асыл татар егетләрен илдән еракларга алып китеп, язмышларын башка төбәк жирләренә бәйләп куя. Тагын! Ярты гасыр эчендә генә дә инде ничәнче мәртәбә! Һарун, Барый, Мансур, Вәгыйз кебек жир язмышын үз язмышлары итеп кабул иткән төпле, эшлекле

егетләр Татар иленең үзенә дә бик таман булыр иде дә бит кана! Кайвакыт аптырап уйлап та куясың: карале, Татарстаныбыз ничә еллар буе Себергә, тугандаш республикаларга яшь эшче көчләр үстереп бирүче бер тәрбияханә сыйфатында яшәгән икән бит! Үзе хәлсезләнгән, әмма башкалар өчен сәламәт кан бирүдән



*Нурихан Фәттах үзенең якташлары — Яңавыл районыннан чыккан әдәбият-сәнгать эшлеклеләре арасында. 1993 ел.*

туктамаган донор булып торган! "Изгелек җирдә ятмас" диләр дә бит... Хәерлегә булсын инде, хәерлегә...

Үз халкының язмышын шәхси мәнфәгатьләреннән аерып карамаган Н. Фәттах аның аянычлы хәлен уйлап сызланса, тарихта җуелмас эзләр калдыруын фикерләп горурлык хисе дә кичерә. Милләт угылларын, кызларын гафләт йокысына бирелмәскә өндәп, ерак бабаларыннан үрнәк вә гыйбрәт алырга чакырып ул аларга данлы да, канлы да булган тарих битләренә узарга тәкъдим итә. Тормышка ашырылуы гаять тә кыен шартларда башкарылган шундый изге ниятләрнең күркәм нәтиҗәсе булып 1970 елда "Итил суы ака торур" исемле роман дөнья күрә.

Романда сурәтләнгән вакыйгалар X гасыр башына карый һәм татар тарихында гаять мөһим этапларның берсен — болгар бабаларыбызның рәсми рәвештә ислам дине кабул итү дәверен бәян кыла. Татар тарихы буенча Пугачев фетнәсеннән ераккарак карарга җөрьәт итмәгән әдәбиятыбыз өчен бу бик зур вакыйга булды. Н. Фәттахка кадәр милли тарихка бары тик караңгылык патшалыгына караган кебек кенә күз салырга өйрәткән рәсми аңлатмаларның череклегең раслап, "татар ренессансы Октябрь инкыйлабыннан соң гына булды" дип раслап һәм шуның өчен бирелгән медаль, мактау кәгазьләрен санап утырган ялагай әсәрчеләрнең өнен алып килде дә, исеменә тиң Идел кинлеге белән коргаксыган җаныбызны инләп, кинәндереп сугарды да, орлыкта килеш шыта алмый яткан милли хисләрне уятып, тиздән сузылачак тамырларына бәрәкәтле җирлек әзерләде. Н. Фәттах бу романны язуга этәргән төп көчләрнең берсе итеп туган халкына, туган теленә, мәдәниятенә чиксез мәхәббәт тойгысын атый. "Бу тойгы булмаганда гомумән бер нәрсә дә иҗат итеп булмый", — дип раслый әдип. Ә ни өчен нәкъ менә Болгар дәвере? Язучы бу хакта ачыклык кертүне кирәк таба. Онытмыйк, роман 60 еллар ахырында язылган. Ә бу заманда "Казан ханлыгы яки Алтын Урда турында уйлап та булмый. Язсаң, шундук алып китәчәкләр, милләтчелектә, пантюркизмда, тагын әллә нәрсәләрдә гаепләячәкләр". Ә Болгар чоры исә ул, язучы раслаганча "күпмедер дәрәҗәдә нейтраль чор. Рус-

лар белән канлы бәрелешләр дә күп түгел, булганы да инде онытылып беткән".

Романда сурәтләнгән эчтәлек чынлап та тарихта булган: 922 елда Багдадтан Болгар иленә барлык мөселманнарның дин башлыгы хәлифәдән илчелек килә. Нәтиҗәдә уртак дин — ислам дине кысасында таркау кабиләләрне туплау, көчле дәүләт системасын булдыруга җитди нигез салына. Әнә шул рәвешле Болгар идарәчесе Алмыш хан үз өстенә бик тә четерекле, әмма кирәкле заман таләбе булган бөек бурычны йөкли. Иң көчсез дошман да җиренә-суына дәгъва белдергән бер вакытта иске йолалар, гореф-гадәтләр белән инде яшәү мөмкин түгел — олуг хан моны яхшы аңлый. "Элеккечә ил тотып булмый, — ди ул үз мөрәҗәгатендә. — Безгә бердәмлек кирәк, иминлек кирәк, көч-байлык кирәк". Шул ук вакытта яңа идея, үзгә принципларына күчү дә җиңел генә хәл ителә алмый. Гасырлардан бирле килә торган ата-баба гореф-гадәтләреннән җәһәт кенә баш тартып кара әле! "Аллаларны бер көнгә генә сайламыйлар", дип уйланган, "башка дингә күчү бит ул яңадан туу, бөтенләй башка кешегә әверелү", дип әрнегән ил агасы Майчан аксакалны да аңларга була. Әмма заман Болгар дәүләтен шундый шартларга китереп куйган ки, инде бары үткәндә генә калачак яшәү рәвеше белән алга барып булмаячак. Киләчәк буыннарның исәнлеге, азатлыгы, ил-йортның иминлеге хакына Алмыш хан бу бөек ниятне һич тайпылмый тормышка ашыра килә: кайда үгетләү, ышандыру юлы белән алдыра, кирәк урында көч куллана... Кызы Аппак ханнан ата-баба йоласына кайтырга рөхсәт итүен үтенгәч, Алмыш хан аңа җавабында әйтә: "Үткәнгә кире кайту юк. Ител кирегә акмаган кебек, сиңа да, миңа да, бөтен Болгар йортка да кирегә кайту юк".

Романда бу хәлиткеч вакыйга эзлекле рәвештә бәян ителә. Кискен борылышлы тасвирлар, мавыктыргыч күренешләр, мәхәббәт романтикасы, кызыклы да, драматик киеренкелеккә дә бай эпизодлар төп фикерне укучыга җиткерүдә үтемле алым итеп файдаланыла.

"Итил суы ака торур" романының "кул арты" җиңел булды. Илдә башланган үзгәрешләрнең саф җилләре исеп кенә куйды: татар әдипләре дәррәү кубып әлегәчә тыелган өлкәнең "чирәм җирләрен" үзләштерергә керештеләр. Бу җәһәттән, Казан ханлыгы, аеруча аның соңгы идарәчесе Сөембикә ханбикә образы язучылар өчен тәмләп сурәтли торган "шлягер" темага әверелде. Болгар дәүләте хакында да иркенләп, бар байлыгына сурәтләргә мөмкинлекләр ачылды. Ә Нурихан Фәттах исә, бу дулкын кузгалганчы ук, үзеннән соң киләчәк әдипләргә ашлы, бәрәкәтле иҗат кыры калдырып, тагын да ераккарак чорларга сәфәр чыккан иде инде. Әдипнең 70 елларда башланып, 80 еллар уртасында тәгәлләнгән күләмле ике китаптан гыйбарәт "Сызгыра торган уклар" исемле романы безнең эрага кадәр III-II гасырларда булган тарихи вакыйгаларга нигезләнгән. Хәзерге бүленеш буенча Монголия, Төньяк Кытай территориясендә яшәгән борынгы төрки кабиләләрнең тормышы, җир-су өчен алып барган көрәше тасвирланган бу роман-дилогия масштаблыгы, миллионга якын кеше катнашкан вакыйгаларны колачлый алу мөмкинлеге белән таң калдыра. Төрле эчтәлектәге максатлар хакына (азатлык, бәйсезлек, шөһрәт-дан, җир-су, байлык...) ырулар, кабиләләр бәрелешә. Идарәче тарханнарның, каганнарның әмере белән эреле-ваклы халыклар һәлакәтле яуга кузгалалар. Җиңүчеләрне рәхимсез кыра, талый, хатын-кызларны, балаларны коллыкка ала. Роман битләреннән ерак-ерак гасырлар артында күмелеп калган кырыс вакыйгаларның җанлы сурәтләре күтәрелә, хәзерге төрки халыкларның борынгы бабалары сөннәр тормышы һәм аларның көчле, дошманнары белән ирек өчен, яшәү өчен алып барган тинсез көрәшләрен тасвирлаучы баталь картиналар калка. Бу күп тармаклы, күп образлы эчтәлек автор тарафыннан бер тотрыклы хикәяләү рәвешенә салынып, мавыктыргыч итеп һәм бик тә үтемле ысулда укучыга китереп җиткерелә. Язучы сугыш-орышларда хәлиткеч рольнең гаскәр күплегендә түгел, ә хәрби осталыкта, көчтән бигрәк, акыл, тәҗрибә белән эш итүдә икәнен үтемле картиналар аркылы раслый килә. Эреле-ваклы бәрелешләр, конфликтлар аерым кешеләрнең эш-гамәлләре белән дә тыгыз үрелеп бара. Теге яки бу тарихи вакыйга мәкерлелек һәм затлылык, хыянәт һәм тугрылык, мәхәббәт һәм нәфрәт, тәхеткә омтылу һәм ватанпәрвәрлек хисләренең кискен каршылыгы белән тыгыз бәйләнгән хәлдә яктыртыла. Бу исә романга үзгә җылы фон бирә, күпсанлы тарихи дәресләрне ялыкмый күңелгә сеңдерә барырга ярдәм итә.

Тарихта чынлап та булган вакыйгаларга нигезләнеп, кискен хәлләргә, көтелмәгән борылышларга бай "Сызгыра торган уклар" романы кышкы ау күренешен тасвирлау белән башланып китә. Сөн дәүләтенең башында торган Туман тархан гадәт буенча ауны башларга тиеш. Ау кызып килгән бер мизгелдә тарханның гомерен куркыныч астына куйган очрак була һәм аны котылгысыз үлемнән улы Албуга коткарып кала. Романда үзәк конфликт әнә шул ата белән улы — тархан һәм тәхеткә законлы варис Албуга арасында бөреләнеп, киңәя вә тирәнәя бара-бара гади кешеләрне, дәүләт югарылыгындагы затларны үз даирәсенә тартып кертә, ахыр чиктә зур-зур гаскәри берләшмәләрне, бөтен бер ыру-кабиләләрне кузгалырга мәҗбүр итә. Төрле астыртын эш йөртүләрдән зиһене чуалган Туман тархан Сөн дәүләтенең катгый канунын боза: төп варисы Албуганы тәхеттән читләштереп, ерак бер төбәккә озатырга әмер бирә. Кол кытай кызын кече хатыны дип, аннан туган баланы үз дәвамчысы итеп игълан кыла. Дәүләт тотрыклылыгының нигезе булган кануннарны бозу ил эчендә ризасызлыклар китереп чыгара, чуалышларга сәбәпче була. Халык акылы әйтә: "Үзара сугыш — дошман илә сугыштан күпкә яманрак". Сөн дәүләтендә бердәмлек какшавын сизеп алган явыз ниятле күршеләре хәлсезләнгән илне төрле яклап таларга керешәләр. Туган жиреннән куылып, җинелеп, хурлыклы хәлгә калган Туман тархан, изге киңәш эстәп Баргынтай бабага килгәч, ил агасы әрнеп ана дәшә: "Нинди киңәш?! ... Элегрәк колак салырга иде ил-көн сүзенә. Инде эш узган. Туйлап, калым түләп алган бичәләреңне таратып бетердең, тәгин углыңны читкә тибәрдең. Илсез-көнсез килмешәкне үз яныңа биеккә утырттың. Сөн иленең бер як кабыргасын Чин умырып алды, икенче як кабыргасын дунху алды. Анда тукмыйлар, монда тукмыйлар сине. Күпме ирләр яуда ятып калды. Әйт, нинди киңәш бирим мин сиңа, Туман улым?"

Романда сөннәр язмышына тигән бәла-казалар, авыр хәсрәтләр күп очракта килмешәк Исәнтәй-Банхуа образы белән бәйләнгән. Еландай шома, зәһәр, төлкедәй хәйләкәр бу бәндә искиткеч осталык белән тархан тирәсендәге бердәмлекне какшата ала: ил агаларын үзара ызгыштыра, әллә ниләр кыланып, дәрәҗәле хәрбиләрне ачуланыштырып бетерә, бер-берсенә кан дошман булуларына ирешә, затлы катлау кешеләрен зинданнарга ташлата... Ахыр чиктә Албуга угланның тәхеттән читләштерелеп, илдән сөрелүенә дә шул мәкерле Исәнтәй сәбәпче була. Роман-дилогиянең буеннан-буена ул бары тик чиркану катыш нәфрәт кенә уятырга сәләтле тип итеп тасвирлана. Әмма шәхсән мин шушы алама бәндәнең эш-гамәлләрендә, аклап булмаган очракта да, аңларлык бер мантыйк күрәм. Аны хыянәттә гаепләп булмый — ул төркиләрдән түгел, Сөн дәүләтенең язмышы аның ике ятып бер төшенә дә керми. Ул гаять зур саклык белән, һәр адымын бик төпле уйлап, һәр сүзен үтә төгәллек белән үлчәп үз сәяси уенын алып бара. Аның бөтен максаты — туган төбәген, ул башында торган Таштугай үзәнен бәла-казалардан аралап калу. Икс бөек, бинеһая көчкә ия дәүләтләр — Сөн белән Кытай мәмләкәтләре арасына кысылып калган бу бәләкәй ил-йорт кайсы якның булса да бер селтәнүеннән үк җир йөзеннән юкка чыгарга мөмкин. Гигантларның үзара сугышып хәлсезләнүе Исәнтәйгә бик кулай һәм ул җайлы шартлар туган бер вакытта үз таләпләрен дә куя алуына өметләнә. Бу — зур ауда яраланган арысланның хәлсезләнүен күргәч, тешен ыржайтып әрсез, оятсыз кыланучы шакал гамәлләрен хәтерләтә башлый. Нәкъ менә Исәнтәй Туман тарханны Кытайга каршы яу чыгарга күндерә, ә үзе сөннәрнең һәр адымын каршы якка җиткерә тора. Бер үк вакытта ул Кытайның да җиңүче булуын өнәп бетерми. Ике араны бутап, ахырда үзе дә буталып беткән Исәнтәй гамәлләренә тиң җәзасын ала — халыкта "яман саз" дип шомлы дан алган баткаклыкта әҗәлен таба.

Романда төп идея, сурәтләнгән заманның әхлакый, сәяси эчтәлеге нигездә Албуга углан образы белән бәйләнгән. Беренче китапта әле ул — тәҗрибәсез яшүсмер. Тәкъдир аны баштан ук кырыс сынауларга дучар итә: Албуга әтисе тарафыннан читкә тибәрелә, Кытайга уңышсыз яу вакытында әсир төшә... Мең бәла белән туган җиренә кайтса, таланган, яндырылган, ятлар башбаштаклыгыннан иңрәп ятучы газиз ил-йортын күрә...

Диологиянең икенче кисәгендә инде ир-ат буларак ныгыган, ачы тормыш тәҗрибәсеннән кырыслана төшкән Албуга угланга шушы тар-мар китерелгән

ватанны торгызу, күңелләренә өметсезлек сарган илдәшләрен азатлык өчен көрәшкә күтәрү бурычы йөкләнә. Иң әүвәл ул гаскәрләрендә ныклы хәрби тәртип урнаштыра, буйсынмасларны хөкемгә тарта, беренче булып дошманнарының өнен алган шомлы сызгаручан ук куллана. Роман ахырында бөжра формасында корылган сюжет әсәрне ачып җибәргән кышкы ау вакыйгасына алып килә. Традиция буенча ауны илбашы ача. Әмма дөнья тарафыннан да, вакыт тарафыннан да шактый типкәләнгән, бетерешкән Туман тархан үз гомерендә беренче тапкыр киеккә тидерә алмый. Бу — хәбәр, бу — символ: картайган тархан көчен генә түгел, инде идарә итү хокукын да югалткан дигән сүз. Тархан вафатыннан соң сөннәрнең юлбашчысы булып калган Албуга ватандашларын азатлык өчен изге яуга житәкли. Кайда көч белән, кирәк урында акыл белән оста эш итеп, Албуга тархан илне ятлардан чистарта бара һәм нәтиҗәдә дошманнарның төркиләр көчен, өстенлеген танымыйча чарасы калмый. Эш шуна барып житә ки, төркиләрнең иң көчле сәяси "көндәше" Кытай империясе дә сөннәр белән килешү төзергә, ел саен аларга ясак-калан түләп торырга мәҗбүр була.

"Сызгыра торган уклар" романы беренче чиратта нинди авыр шартларда да азатлыкларын, якты кояш астында горурланып яшәргә хокукларын саклап, яклап кала алган ерак бабаларыбызга рәхмәт хисе булып кабул ителә. Шул ук вакытта ул бүгенге укучыга да адресланган: кыен вакытларда да илен, бәйсезлеген, телен югалтмаган төрки кавемнең бүгенге дәвамчылары ни хәлдә, традицияләрне тиешле югарылыкта тоталармы, гореф-гадәтләргә тугрылыклымы алар? Гәрчә, безнең заманда куркынычлы сугыш-яулар күзәтелмәсә дә, телебезгә, димәк ки асылыбызга гасыр башында кисәткән "инкыйразы" алтмыш, житмеш, сиксән, туксан ... елдан соң да татар милләтен эчтән таркатучы, җимерүче көч буларак төрле калыпларда яши бирә. Н. Фәттахның илленче елларда языла башлап та, озак вакытлар хәрәкәтсез яту сәбәпле (автор үзе искәрткәнчә моңа "бар нәрсәне буып торган милли террор" ирек бирмәгән), 1995 елда гына басылып чыга алган "Кичү" романы әнә шул хакта кисәтә, чаң суга. Әсәрнең баш каһарманы Габделхәй образы аркылы язучы тоталитар режимның җинаятьчел сәясәтен —рус булмаган милләтләрнең телен, мәдәниятен бетерү ниятен фаш итә. Бу максатны режим гаять яшерен башкара һәм милли горурлыгын җуйган, үз халкыннан, гореф-гадәтләреннән баш тарткан заман манкортлары аша тормышка ашыра. Шундый мескен типларның берсе — мәктәп директоры Василий Михайлович —чынлыкта Вәсби Муллахан улы — татар әдәбиятына гашыйк Габделхәй алдында фәлсәфә корып болай ди: "Сезнең кебек талантлы кешеләрне татар мәктәпләре харап итә... Татариядә, Башкириядә, чит өлкәләрдәге татар авылларында да күп мәктәпләр урысчага күчте... Без кемнән ким? Нигә безгә артта калырга?"

Барысын да күрә Габделхәй: кол рухлы җитәкчеләрне дә, татар теленә кан дошман рус әдәбияты укытучысы Семенованы да, паспортына "башкорт" дип яздыруларын да ("урыс арасында кыерсытмаслар ичмасам" дип юаталар аны), кыйналуларны да, мыскыл ителүләрне дә кичерә ул — әмма иманыннан, димәк ки теленнән, дененнән, ата-баба гореф-гадәтләреннән баш тартмый. "Без сугышта юлбарыстан көчлебез, без тынычта аттан артык эшлибез!" — Габделхәй роман ахырында Тукайның әнә шул сүзләрен кабатлый. Бу исә бүгенге татар канында Албуга угланнар, шагыйрь Галиләр рухы яши дигән сүз.

Татар милләте җанына бөтен барлыгы белән береккән Нурихан ага Фәттах моннан ярты гасыр элек башлаган иҗат юлыннан ышанычлы адымнар белән баруын дәвам итә: тарихның галим-академиклар керә алмаган, капкасын кагарга да җөрьәт итмәгән ерак дәверләрендә йөри, милли вәзгыятьтән гыйбрәт вә үрнәк дәресләре бирә.

РЕДАКЦИЯДӘН:

**Халкыбызның олуг әдибен 70 яшьлек юбилее белән кайнар котлыйбыз! Аңа ныклы сәламәтлек, күтәренке күңел, яңадан-яңа иҗат шатлыклары телибез!**

*Абдулла Алишның тууына 90 ел*

# ИСТӘЛЕКЛӘР АЛЬБОМЫННАН...

*"Альбомнан" дисәм дә, ул истәлекләр бер генә альбом белән чикләнми. Абдулла Алишка багышланган шактый зур һәм калын 5 альбомда барысы 97 истәлек-хатирә тупланган. Аларның барысы да диярлек истәлек бирүченең үз кулы белән язылган.*

*Бу кыйммәтле хәзинәне җыюда, барлауда мәктәбебездә эшләп килгән Абдулла Алиш музеена йөрүче укучы балалар актив катнашты. Шул зур альбомнарны күтәреп, истәлек язуны сорап, өйләренә килгән малайлар һәм кызларны хәтерләүчеләр бардыр әле... Ничә еллар буена күпме укучы катнашкан бу изге эштә! Берәүләре, адреслар буенча өйләргә йөреп, истәлекләр яздырып кайткан, икенчеләре, шулардан файдаланып, музейда экскурсияләр үткәргән. Хәзер шуларның кайберләрен, республикада танылганнарын санап китсәң генә дә, зур бер исемлек килеп чыгар иде: Алсу Гайнуллина, Ләйсән Низамиева-Мөхәрләмова, Газинур Шиһапов, Илшат Әминов һ.б. Рәхмәт аларга!*

*Абдулла Алиш турындагы истәлекләргә беренче булып игътибар бирүче, үземне дә шул юнәлешкә кертеп җибәрүче Спас педагогия училищесыннан элекке укучым Әнәс Хәсәнов булды, дисәм, бер дә ялгышмамдыр. Хәзер Татарстан Президенты Аппаратының матбугат үзәге җитәкчесе, Абдулла Алишның авылдашы-якташы, талантлы журналист һәм язучы Әнәс Хәсәнов 60 нчы елларда телевидениенең балалар редакциясендә эшли иде. 1963 нче елның сентябрендә, язучының тууына 55 ел тулу көненә багышланган тапшыруга чакырып, Абдулла Алиш турында истәлекләр сөйләтте. Ниләр сөйләгәнемне ачык хәтерләмим инде, бу минем телевидениедән беренче чыгышым иде. Әмма үзем өчен әһәмияте гаять зур булды: шуннан соң истәлекләр белән кызыксынуым артты. Алиш абыйны якыннан белүчеләрдән сораштыра, йә язып алгалый башладым. Ә инде 1968 нче елда мәктәбебездә Абдулла Алиш музее ачылгач, бу эш оешкан төс алды һәм шулай шактый истәлекләр җыелды. Язучыларыбызга рәхмәт: бу эшне бик хуплап-күтәреп алдылар һәм, кадерле вакытларын бүлеп, матур-матур истәлекләр яздылар. Әмма шунысы кызганыч — аларның күбесе дөнья күрмичә альбомнарда ята. Бүгенге авыр заманда китап итеп чыгару мөмкинлеге дә күренми, аерым-аерым матбугатка биргәләсәң генә инде...*

*Абдулла Алишның тууына 90 ел тулу уңае белән, инде үзләре дә вафат булган кайбер дусларының истәлекләрен матбугатка тәкъдим итү урынлы булыр дип уйлыйм.*

**Илсөяр СӨНКИШЕВА,**
*Казандагы 55 нче мәктәпнең А. Алиш музее җитәкчесе.*

## Бергә үткән яшьлек еллары

Мин Абдулла Алиш белән Казан җир төзү техникумында бергә укып, аннан Казгрэс төзелешендә бергә эшләп, хәтта ул семьялы булганчы, бер квартирада яшәдем.

Техникумда уку елларында Алиш иң актив укучылардан санала иде. Техникумда чыгып килгән кульязма журнал һәм газета эшләрендә катнаша, төрле түгәрәкләргә йөри, еш кына иптәшләренә ярдәм итәргә дә вакыт таба иде.

1929 нчы елдан ул үзенең язган әйберләрен техникум газета-журналында гына түгел, "Яшь ленинчы", "Кызыл яшьләр" кебек газеталарда, "Авыл яшьләре",

"Атака", "Яналиф" журналларында бастыра башлады. Шул ук елдан, яшь язучы буларак, әдәби кичәләргә, очрашуларга йөрде.

Менә шулай кеше арасына кереп, күтәрелеп барган вакытында да ул һәрвакыттагыча тыйнак, гади, якын сабакташ һәм иптәш булып калды. Кызлар белән дә бер дә чытыкланмыйча-кәпрәймичә, иптәшләрчә дуслык мөнәсәбәтендә була белә иде. Кадрия Ишукованы аеруча якын итте (соңрак Фатих Кәримнең тормыш иптәше). Кадрия үзе дә каләм сынап әсәрләр язгалагангамы, аларның уртак фикерләре, сөйләшер сүзләре күп була торган иде. Аларның бу дуслыклары семьялы булгач та өзелмәде.

Вакыты белән шаян йә җитди, эшкә гаять дәрәҗәдә җаваплы карашлы, иптәшләренә мөнәсәбәттә кешелекле һәм таләпчән, һич тиктормас тынгысыз иде ул безнең Алиш. Барлык эшләре өстенә күп укырга да өлгерә иде.

Бу чорда яшьләр арасында Һади Такташ бик популяр булды. Абдулла аның белән якыннан таныш, аның һәр шигырен көтеп ала, аны чиксез ярата, хөрмәт итә иде. Такташның күп кенә шигырьләрен яттан белә иде. Шагыйрьнең үлемен ул бик авыр кичерде. Үз туганын югалткандай ятим калуы турында сөйләгәне истә.

Такташ белән хушлашу истәлеге итеп, без шул көнне фотога да төштек.



*Абдулла Алиш үзенең дуслары Х. Гыйльметдинов һәм С. Гайнанов белән. 1931 ел.*

Алиш ул рәсемнәрне үзе ясатып алып, артына да үзе язып, һәрберебезгә бүләк итте. Миңа биргән рәсемнең артына болай дип язган:

*"Мәрхүм шагыйрь Һади Такташны күмү мәрасиме вакытында алдырган рәсем. 10 нчы декабрь, 1931 нче ел. Казан.*

*Уңда "Сабир Гайнанов, уртада — Хәмит Гыйльметдинов, сулда — Абдулла Алишев".*

Үзендә калдырган рәсемдә мондый шигырь язып куйган:

Бар йөрәкләргә үзенең шатлыгын биргән йөрәк,
Кайгысын уртаклашып, безнең белән көлгән йөрәк.
Шул йөрәкне без бүген туфракка күмгән көн бүген,
И әҗәл! Алганга җанын син аның үкен, үкен!..

Бөтен гомерем буена мин Абдулла Алишны иң якын дустым итеп күңелемдә сакладым. Аның белән бергә үткән яшьлегем искә төшкәндә, күңелем яктырып киткәндәй була...

**Хәмит ГЫЙЛЬМЕТДИНОВ.** *1968 ел.*

## Якын дус иде

Абдулла Алишны мин бик якын дус, яхшы иптәш итеп хәтерлим. Мина аның белән беренче тапкыр 1938 нче елның сентябрь башларында очрашырга насыйп булды. Әле бакчаларда аллы-гөлле чәчәкләр корып-шиңеп бетмәгән, җәй бирешмәскә тырышкан чак иде. Ә мәктәпләрдә инде укулар башланган. Урам тулы ал галстук таккан балалар. Мин үземә бәхет алып килгән ул кояшлы сентябрь көннәрен якты истәлек итеп хәтеремдә саклыйм. Чөнки мин әнә шул көздә, мул уңышлар биргән көз башында, беренче тапкыр хезмәт юлына керештем. Мине "Яшь ленинчы" газетасы редакциясенә әдәби бүлек мөдире итеп билгеләделәр.

Матбугат йортының икенче катында "Яшь ленинчы" белән "Пионер каләме" (хәзерге "Ялкын") журналы редакциясе янәшә урнашкан иде. Эшне оештыру ягыннан алар бөтенләй бер редакция кебек, уртак уй-фикер белән, бер киңәштә эшлиләр иде. Газета белән журналның икесенә бер редактор булды. "Пионер каләме" журналында матур әсәрләре белән танылган хөрмәтле балалар язучысы Абдулла Алиш эшли иде.

Хезмәткә керешкән көннәремдә Абдулла Алиш еш кына минем эшнең барышы турында сораштырды. Бүгенгедәй хәтеремдә, уртача буйлы, чем-кара чәчле Абдулла дус безнең редакциягә нәрсәдер сөйләп, үзе белән шатлык алып килергә теләгәндәй, шаулап килеп керде. Бүлмәдә кинәт рухи җанлылык, жылылык бөркелгәндәй күңелле булып китте. Ул ак күлмәгенең җиңнәрен бераз сызганып куйган, изүе дә бер сәдәпкә чишелгән иде бугай.

Алиш дусны беренче күргәч тә ачык йөзле, киң күңелле, шаян сүзле кеше икәнен аңладым. Көләч кара күзләре кара тутлы йөзенә нур сирпеп тора иде аның. Менә ул, елмаеп, минем эш өстәле янына килеп утырды һәм йомшак кына эндәште:

— Нихәл, сеңлем, Әминәкәй, син шулай балалар әдәбиятын яратасыңмыни? Әйдә, бик яхшы. Укытучылыкка укып чыккан кешегә балалар газетасы бик якын тоела шул. Язгалыйсың да икән. Син бер дә уңайсызланма, белмәгәнеңне сораш, ярдәм итәрбез. Белмәү гаеп түгел — белергә теләмәү гаеп, — дип, бик ачык күңел белән, якын күреп сөйләште.

Эшне ничегрәк башлап җибәрергә дип уңайсызланып торган чагында, Абдулла Алиш мина шулай үзенең җылы сүзләре белән канат бирде, эшкә дәрт кузгатты. Озак та үтмәде, ул мина үзенең яңа язган әкиятләрен укып күрсәтте. Әкиятләрендәге кызыклы мажараларга үзе дә сабый кебек канатланып, дәртләнеп укый иде ул. Берәр төзәтмә кертсәң, шунда ук игътибарга алып төзәтә иде.

— Син балалар рухын, психологиясен дияргә була, сизәсең, кызый. Вакытың булганда, шулай мин укыштыргалармын сиңа, яме, — дип, көләч күзләре белән елмаеп карады.

— Бик рәхәтләнеп укыгыз. Әдәби әсәрне дөньяга чыкканчы беренче тыңлаучы булу бәхет ич ул, — дип җавап бирдем мин.

— Шулай, шулай, нәкъ эзенә генә бастырдың, — диде ул. Ә мин, күңелемнән генә, үземнең язган әсәрләремне укып, киңәш алырга исәпләдем.

Абдулла Алиш белән иҗади дуслар булып бергә эшләү дәверендә мин аның бервакытта да кешегә, иптәшләренә тупас эндәшүен ишетмәдем. Ул үз эшен бик яратып башкара иде. Журнал белән газетаның бик таләпчән редакторы Гомәр иптәш Хәбибуллин да Абдулла Алиш оештырган, аның редакциясендә чыккан материалларны мактап, үрнәк итеп сөйли иде.

Редакциядә әдәби киңәшмәләр бик җанлы, кызыклы үтә иде. Абдулла Алиш һәр номерга балалар күңеленә үтеп керерлек материал табарга тырыша иде.

— Менә, Әминә, безнең редакциягә килгән балалар шигырьләрен укып кара әле. Матур гына язганнар бит. Яхшы үрнәкләрен биргәләргә кирәк, — ди иде ул. Редакциягә шигырьләр күп килә, барысына да җавап яза идек.

— Балалар беренче әдәби мәктәпне үзләренең газета-журналлары аша алалар. Аларга бик яхшы консультация бирү кирәк. Балаларда әдәбиятка мәхәббәт уятырлык әсәрләрне генә урнаштыру урынлы булыр, — дип сөйләгән сүзләре минем редакторлык эшемдә гомергә хәтеремдә калды.

"Пионер каләме" журналы редакциясенә килгән балалар Абдулла абыйлары янында бик рәхәтләнеп сөйләшеп утыралар иде. Без аның белән мәктәпләргә очрашуларга да йөрдек. Ул балаларга белемнәрне тирән үзләштерү кирәклеген кызыклы мисаллар белән аңлатып бирә иде.

Менә шулай иҗади дуслар булып гөрләшеп эшләгән чагында, дәһшәтле сугыш башланды.

Озак та үтмәде, Абдулла Алиш, шинель киеп, биленә каеш буып, редакциягә килде. Аз гына вакытка кергән арада ул безнең белән бик якын туганнардай хушлашты. Һәм, гадәтенчә, очкынланып торган күзләре белән барыбызга күз йөртеп чыкты да:

— Исән булыгыз, дуслар! Без дошманны тар-мар итәчәкбез. Ә сез электәгечә кайнар дәрт белән эшләгез, — диде.

— Йә, Әминәкәй, нигә син курыккан кош баласы кебек бер кырыйга постың. Кара, Алиш абыең нинди матур солдат булды, — дип, билендәге каешын тартып, төзәтеп куйды. Миңа бу минутта, чыннан да, монсу, уңайсыз тоелды.



*Абдулла Алиш үзенең каләмдәшләре Әминә Бикчәнтәева һәм Нури Арсланов белән. (Кырыгынчы еллар).*

— Исән булыгыз, — дидем мин. — Чыннан да, сиңа солдат пилоткасы бик килешкән, — дип, аның сүзен раслап куйдым.

Бу безнең каләмдәш дустыбыз Абдулла Алиш белән соңгы саубуллашу икәнен кем уйлаган...

**Әминә БИКЧӘНТӘЕВА**. *1973 ел.*

## Асыл зат иде

Инде әдәбиятта исеме киң таралган Абдулла Алиш белән мин 1936 елның кышында таныштым. Мин үзебезнең институт яшьләре тормышыннан "Яшь сталинчы" газетасына хәбәрләр ташый идем. Ул вакытта әле яшь язучы Сөббух Рафиков яшьләр газетасында эшли иде. Мин язган нәрсәләрне аңа алып барам. Беркөнне Сөббух минем шигырьләремне укыды да:

— Монысы безгә ярый, ә менә монысы балалар өчен бит. Әйдә әле, мин сине Абдулла Алиш янына алып төшәм, — дип, матбугат йортының икенче катына җилтерәтеп алып төшеп китте.

Алишны читтән генә күргәнем бар, әмма үзе белән якыннан күреп сөйләшкәнем юк иде. Керү белән мин, бераз тартынып, кызара төшеп, ишек янында тукталып калдым.

— Менә, мин сиңа, Абдулла, бер егет алып килдем. Исеме Галимҗан, институтта укый, студент, безнең хәбәрче. Шигырьләре дә чыккалый. Укып кара әле менә бу шигырьне, — диде.

Мин бер агардым, бер кызардым. Алар шигырьне икәүләп укыдылар, төзәттеләр, кыскарттылар да машинкага басарга бирделәр. Ул "Пионер каләме" журналының чираттагы санында басылып та чыкты. Шуннан соң Абдулла Алиш сугышка киткәнче шактый шигырьләремне бастырды. Тәрҗемәләр биреп эшләтте.

Беренче очрашуда ук Абдулла Алиш минем белән бик жылы итеп күреште. Үз янына утыртып, кайсы яктан булуымны, ничек укуымны, кайчан яза башлавымны сорашты.

— Вакытың булганда, безгә гел кереп йөр, Галимжан. Яз, мин сиңа заданиеләр бирермен, — диде.



*Г. Латыйп А. Алишның 70 еллык юбилей кичәсендә язучы исемен йөрткән пионерлар сараенда, 1978 ел.*

Шушы күрешүдән соң мин аның янына еш керә башладым. Ул минем белән үз туганы кебек сөйләшә, кайда нинди кичәләр, очрашулар буласын әйтә, кил, тыңлап утырырсың, язучыларны күрерсең, ди. Абдулла Алиш, Сөббух Рафиков, Гали Хужи, Рәхим Саттарлар, Әгъзам Камаллар минем якын танышларым, дусларым булып киттеләр. Гажәп дәрәжәдә кешелекле, олы жанлы, ярдәмчел кешеләр иде алар. Мондый иптәшләр белән бер күреп, бер сөйләшү минем өчен үзе бер бәхет булды. Кайда ул аларда һавалану, кылтаю, кемгәдер карата йөз жыеру?! Мин гомерем буена аларның сафлыгына, олы жанлы, һәр жирдә тугрылыклы, гадел булуларына сокланып яшәдем...

Абдулла Алишның эчендәге тышында иде. Ул сиңа да бик нык ышана, бернәрсәсен дә яшерми, кайгысын да, шатлыгын да, эч серләрен дә бүлешә. Аның өчен дөнья матур,киң, олы, мәрхәмәтле иде. Гаделсезлеккә каршы бик нык нәфрәтләнә белә иде. Ялагайлык, кемгәдер ярарга тырышу, үз даның кайгырту кебек нәрсәләрнең әсәре дә юк иде аңарда. Асыл зат иде ул Абдулла! Шуңа күрә гомеренең актык сулышына кадәр, фашистлар тырнагы астында да, үзен чын ирләрчә горур тоткан, дошманы алдында баш июне, куркуны белмәгән ул...

Барысы өчен дә сиңа мең рәхмәт, кадерле дускай! Безнең синең кебек үрнәк алырлык дусларыбыз күп. Кадерле язучыбыз, батыр солдатыбыз, бөек гражданиныбыз идең син, Абдулла!

... Сине, Абдулла Алиш, дусларың, укучыларың сагыналар, әледән-әле искә алалар. Синең турында жырлар, шигырьләр чыгаралар. Мин дә, үземчә, синең музеенда булып кайткач, бернichә юл шигырь язган идем. Ул ничек чыккандыр. Мин аны синең альбомыңа күчереп язам:

Музееңда булдым бүген синең,
Бүлмәләргә тулган яктылык.
Апрель ае язлар ясап йөри,
Жәй таңнарын үзенә чакырып.

Залда кояш, залда синең яшьлек,
Солдат чагың, тоткын чакларың.
Күзләреңдә сагыш һәм мәхәббәт,
Туган якка кайткан хатларың.

Мин үзеңне күргән кебек булдым:
Нәшрияттан чыктык бергәләп.
Черек күлдә шигырь укыдык без,
Яшь юкәләр төбенә чүгәләп.

Барысы да истә бүгенгедәй,
Зыңлап тора яшьлек ялкының.
Үз йортына алып кайтты Ватан
Моабитның тоткын батырын.

Кайнар йөрәкләрне суырып алып,
Утка атты дошман. Янмадың.
Кара сөрем — фашист жәһәннәме
Ал таңнарны каплый алмады.

Янар факел кебек синең йөрәк
Якты сирпеп тора дөньяга.
Буыннардан күчеп буыннарга,
Үлемсезлек жыры жырлана.

**Галимжан ЛАТЫЙП**. *1973 ел.*

## Чәчмә әсәрләр



**Алмаз Гыймадиев**

# БАЛАЛАР ӨЧЕН ХИКӘЯЛӘР

## Чемодан, Пистон һәм... Шәмәй

Әле кичә генә алар студентлар иде. Бүген юридик бүлекнең деканы кулларын каты итеп кысып аларга диплом тапшырды, уку йортын уңышлы тәмамлаулары белән тәбрик итте. Диплом бирү чираты Бариевка килеп җиткәч декан көлемсерәп, бераз пауза ясап алды. Башкалар да тын гына елмаештылар — әлеге егетнең юрфакны ничек тәмамлавын һәммәсе чамалый иде. Укытучылар телендә бу термин “тартып-сузып-өстерәп” дип атала...

— Йә, Бариев, — диде декан ирен чите белән елмаеп. — Бу көнне син дә, мин дә күптән көттек инде, ә... Ничә ел көттек! Баштагы ун елы бигрәк тә озак тоелды... Киләчәктә нишләмәкче буласың? Сөйләп җибәр әле безгә планнарыңны!

Бариев оптимист егет иде.

— Кайгырмагыз, абый, — диде ул деканга авылча, гади генә итеп. — Минем эш урыны күптән хәл итеп куелган. Үзебезнең төбәктәге бер шәһәрдә тикшерүче булачак укучыгыз!..

— Кем булсаң да намуслы кеше бул, ярыймы?!

Соңгы сүзләрен декан җитди итеп әйтте.

* * *

Берничә ай буе шәһәрчекне өркетеп, дер калтыратып яшәткән җинаятьчел яшүсмерләр төркеме , ниһаять, фаш ителде! Унике бандиттан торган әлеге төркемне шәһәр милициясе яңа җинаять кылып ятканда — шәһәрдәге бердәнбер чиркәүнең алтын тәресен кисеп маташканда эләктерде. Бу эшне тикшерүне лейтенант Бариевка йөкләделәр. “Әйдә энем, шушыны очлап чыга алсаң, бездән сиңа берсүзсез хәер-фатиха!” — диде чал чәчле полковник егетнең аркасыннан аталарча кагып.

— Фамилияң? — дип сорады Бариев беренче булып кертелгән малайдан.

---

Алмаз ГЫЙМАДИЕВ (1972) — *балалар өчен язган хикәяләре белән вакытлы матбугатта байтактан катнашып килә. Ә беренче китабы — шаян хикәяләрне туплаган «Тә-нә-фес яки маҗаралы хәлләр» дип исемләнгән җыентыгы 1997 елда Татарстан китап нәшриятында басылып чыкты. Ул 1998 елдан Язучылар берлеге әгъзасы. Хәзерге вакытта редакциябездә эшли, җаваплы сәркәтип вазифаларын башкара.*

— Не понял? — малай авызын бераз ача төшеп, уң колагын лейтенантка якынрак сузды.

— Фамилияң ничек дим, исемең?!

— Ә-ә-ә... Пистон...

— Нәрсә-ә-ә?.. — бу юлы лейтенантның авызы ачык килеш калды. — Фамилияң ничек дип сорыйм мин синнән, сарыктан туган нәрсә! Кушаматың кирәкми миңа!

Малай нихәтле генә интекмәсен — исемен дә, фамилиясен дә хәтеренә төшерә алмады. Пистон тек Пистон инде...

Бариев кульяулыгы белән тирләгән маңгаен сөртте дә, бусын чыгарып, икенче малайны кертергә кушты.

— Исемең?

— Дөя...

— Син үзең ишәк! — дип акырды лейтенант пеләш башлы, зур колаклы әлеге малайга. — Вон моннан! Следующий!!.

"Следующий" ның исеме Пешка булып чыкты. Бариев аңа күзенең агы белән карады:

— Король дә бармы?

— Бар.

— Чакыр...

Аның фикеренчә, король атаманнары булырга тиеш иде. Кабинет ишегеннән сөлек кебек озын, нечкә малайны керттеләр.

— Синме король?

— Әйе.

— Башлыкларымы?

— Юк.

— Кем соң башлыгыгыз?

— Чемодан... — диде малай шикләнеп кенә.

Бариев чүт кенә өстәлдәге пыяла графинны малайның башына тондырмады — үзен вакытында кулга алырга өлгерде.

— Уф... Ярый, үзеннең чын исемеңне беләсеңме?

— Әлбәттә! Толик мин. Толик Воробьев!

— Аллага шөкер! — лейтенант җиңел сулап куйды. — Сөйлә Воробьев, соңгы көннәрдә ниләр майтардыгыз?

Толик маңгаен җыерды:

— Ну... ни инде... ниттек... бер нине шомарттык...

— Нәрсәне, нәрсәне шомарттыгыз?

— Нине инде...бер куышны...

— Нинди куыш тагын?

— Ну... квартирны инде...

Берничә сорау биреп караса да, Бариев бу малайдан квартир басу турында тиешле мәгълүмат ала алмады.

— Дөяне кертегез! — дип боерды ул дежур сержантка.

— Нинди дөяне, иптәш лейтенант?

— Тфү лә... Теге, пеләш башлы, зур колаклы малайны инде...

— Сөйлә, Дөя! — диде ул малайның күзенә туп-туры карап. — Куышны ничек шомарттыгыз?

— Ә-ә-ә... теге, Пушкин урамындагы куышнымы? Аны бит Пистон белән Пешка икесе шомартырга тиеш иде... Ну анда тегенең пушкасы булган и ул төкерттергән безнекеләргә... Ярый, Шәмәй килеп чыккан әле...

— Кем ул Шәмәй? — дип сорады Бариев малайга арыган күзләре белән карап.

— Шәмәй Шәмәй инде, —диде малай гади генә. — Пионер Шәмәй...

— Әле үзе пионер дамыни???

— Вәт дурак, пионер булмыйй кем булсын, сигез дә тулмаган ич әле аңа!

— Араларында бер кечкенә малай бар, — дип аңлатма бирде ишек

төбендәге сержант. — Шуны пионер дип йөртәләр.

"Ә без яшь чакта пионерга ун яшь тулгач кына алалар иде..." дип күңелсез генә уйлап куйды лейтенант.

— Йә, йә, дәвам ит. Шәмәй килеп чыккан...

— Әйе, Шәмәй килеп чыккан да, и рраз — самопал белән тегеңә! И шабаш! Шито-крыто! Чао-какао!

Дөяне дә чыгарып җибәрергә туры килде. Яшь тикшерүче уфтанып сәгатенә карады. Бер сәгать сорау алу нәтиҗәсендә беркетмәгә язарлык бер генә җөмлә дә төшмәгән иде әле.

— Следующий! — диде Бариев башын тотып. Кабинетка сул күзе бераз читкәрәк караган малайны керттеләр.

— Син кем?!!

— Мюллер.

— Бик яхшы. Хайль Гитлер!

— Хайль! — диде малай кулын алга сузып.

— Менә нәрсә, иптәш Мюллер... Йә син миңа соңгы көннәрдә кылган җинаятьләрегез турында кешечә тел белән сөйләп бирәсең... йә мин сине... — лейтенант кобурасына тыгылды, — атам!

Мюллернең күзләре киерелеп ачылды.

— Сөйлим, сөйлим... — дип калтырады ул. — Кайсыннан башлыйм?

— Куыштан!!! — дип акырды Бариев.

— Куышта металл барлыгын Чемодан күргән, — дип сөйләп китте малай. — Без төнлә шунда шудык. Пулеметлар кесәдә — проблема юк...

"Ничек пулемет кесәгә сыйсын инде?" дип уйлады Бариев артык башын эшләтми генә. Мюллер исә дәвам итте:

— Куышта металл гына түгел, порошок та күп икән. Чемодан Жирафка кәлти-мәлти килмәскә кушты. Пистон белән Пешка шомартырга киткәннәр иде, аларга төкерттергәннәр. Ярый әле Шәмәй килеп чыккан...

"Тагын Шәмәй!" дип уйлады Бариев һәм каушый-каушый бик тырышып сөйләп маташкан малайга:

— Во-о-он!!! — дип кычкырды. Өстәлдәге графин да малай артыннан очты.

Кабинетка килеп кергән полковник пыяла ватыкларына игътибар итмичә, башын тотып утырган Бариев янына килде:

— Ну, нәрсә, иптәш тикшерүче? Булыр күкме?

— Ә... Иптәш полковник... Ни... Була... — дип мыгырданды егет.

— Йә, нишләтәбез инде ул борын асты кипмәгән шпаналарны?

— Болай итәбез! — диде Бариев кульяулыгы белән мангаен сөртеп. — Болай итәбез... Жираф белән Дөягә биш елга — Зөя! Король белән Пешкага — вышка! Мюллерга — карцер! Чемодан белән Пистонга дүрт-биш ел гарнизон! Пионер Шәмәйгә грамота бирик. Грамотасын тотып әти-әнисе башта сберкассага, аннары милициягә килерләр... И шабаш! Все!

Полковник ишек төбендәге сержантка Бариевны өенә озатып куярга кушканда, тегесе һаман башын тотып:" Шито-крыто! Чао-какао! Кәлти-мәлти..." дип мыгырдана иде әле.

## Бүләк

Мине мәктәптә "Дезодорант Рәсим" дип йөртәләр. Бигрәк ямьсез кушамат инде, иеме?

Гел уйламаганда ябыштырдылар миңа аны. Шул, бәйрәмнәр аркасында килеп чыкты инде. Кем уйлап чыгаргандыр аларны!

23 февраль көнне классташ кызларыбыз һәрберебезгә берәр одеколон бүләк иттеләр. Без — егерме ике малай — кызларга чын күңелдән рәхмәт әйттек. Гомумән, ул көн күңелле узды үзе. Алдан сөйләшү буенча бер-беребезгә начар сүзләр әйтешмәдек, талашмадык. Хәтта мәктәптә явызлыгы

белән даны чыккан Дию Фоаты да түзде. "Егерме өче генә үтсен, иртәгә барыбер берсен тотып тукмыйм!" дип йодрыгын кашып йөрде.

Бәйрәм ашы — кара-каршы, диләр. Без дә кызларыбызны әйбәт бүләк белән сөендерик, дидек. Өч кенә бөртек ич алар! Ничек котламыйсың ди инде шуларны 8 март белән!

Яхшы гына суммадан җыелыштык та, бүләк алырга булдык. Авыл кибетендә юньле нәрсә юклыгын үзегез дә беләсез. "Рәсим, синең урысчаң да яхшы, шомалыгың да бар. Давай, иптәшкә Бөтнек Әмирен ал да, Казанга сыпырт!" — диеште малайлар.

"Бүләкнең шәбен ал!" — дип кычкырып калдылар арттан.

Шулай итеп чыгып киттек без Әмир белән. Кесә тутырук акча. Әле әти белән әни дә өстәде. Шәһәргә барып ач йөрмәссең бит инде! Ул акчага өч бөртек кызга әллә ниләр алырга була. Беразын туздырсаң да сизелми әле. Шунлыктан, автобус көтеп тормадык, бер "Жигули"не туктаттык та — "выжт!"

Казанда булмаганга өч-дүрт ел бар иде. Бөтен нәрсә үзгәргән. Тимер юл вокзалында, бер багана төбендә пычрак киемле, битен сакал-мыек басып бетергән ике абыйны күреп "дерт!" итеп киттек. Алларында буш шешәләр. Мөгаен, шешә тапшырырга барган җирләреннән егылып калганнардыр. Берсе күзгә керердәй булып, инәлеп акча сорый. Бик кызгандык без боларны. Биш сум биреп калдырдык. Икесенә дә.

Ике адым гына атлаган идек, каршыда морожный киоскысы пәйда булды. Шәһәргә барып морожный ашамый кайталар димени! Мал-лай! Морожный да үзгәргән икән хәзер — шоколадка төреп тә, төрмичә дә саталар. Нindиләре генә юк! Сатучыга акчаны сузган гына идем, әллә каян гына күз явын алырлык чибәр ике кызчык пәйда булды.

— Мальчики, безне дә угощайте, — диләр, чырык-чырык киләләр.

Әмирнең дә авыз ерылды. Шту син! Шәһәр кызлары белән танышу теләсә кемгә тәтеми ул! Бәлки кино-фәләнгә алып керербез үзләрен, дип и-и план корабыз эчтән генә.

Тагын кесәгә кереп киттек.

— Мальчики, без берьюлы икешәр мороженое ашыйбыз, — диләр болар.

Каршы килеп булмый бит инде! Гуләт тек гуләт! Кайткач малайларга мактанып сөйләргә бер нәрсә булыр хет.

Ие, мактандык... Кулларына икешәр морожный тоттыргач, кызларыбыз "спасибочки" дип чыркылдаштылар да, әллә каян гына килеп чыккан ике малай белән култыклашып китеп тә бардылар. Калдык авыз ачып.

Ярар, кепкаларны батырып кидек, кулларны кесәгә тыктык та, бераз бөкрәя төшеп, Казан малайлары кыяфәтенә кергәч, дәлше киттек.

Урамның бер почмагында җыелып торган төркемне күреп якынрак барырга булдык. Анда нindидер уен уйныйлар икән. Аю чаклы бер егет чүгәләгән дә, асфальтка каплап куйган өч зур уймакны әвеш-тәвеш китерә.Берсенең астында бәләкәй шарчык тәгәрәп йөри.

Уймакларны әвеш-тәвеш китерүдән туктагач :

— Шар кайсы уймак астында? — диде. Әмир түзмәде, "менә монда!"дип бер уймакка китереп төртте. Күтәреп карасак — буш. Теге аю гәүдәле егет Әмирнең җилкәсеннән эләктереп тә алды:

— Отылдың. Синнән илле сум!

Бирдек инде. Аннан соң грузиннар пешергән ике таяк шашлык, дүрт пирожки, ике стакан кока-кола һәм бер стакан һава кукурузын исәпләмәгәндә, бүтән акча туздырмадык.

Көн кичкә авышканда санап карасак... Акчабыз кайтырга автобус билетына да җитми икән инде. Бүләк тә алынмаган...

Бер кибеткә кердек. Балта, кадак, идән буявы белән беррәттән әллә ничаклы матур духи, дезодорантлар тезелеп киткән.Вәт малай бәхет басты! Иң арзаны — өч сум гына! Шунысын, "карбофос" дигәнен өчне алдык та, "куян"нар булып кына автобуска кереп чумдык. Ничек кысыла-

кысыла кайтуыбызны, төшкәндә минем сыртка, Әмирнең артына тибүләрен сөйләп тормыйм.

Мәгәр, малайларның без алып кайткан дезодорантка исләре китмәде:

— Кызларга үзең тапшырырсың! — диештеләр төксе генә.

Тапшыруын тапшырдым... Әмма ахыры ни белән бетәсен белгән булсам! Кызларыбызның берсе, Гөлчәчәк исемлесе дезодорантны шунда ук муенына сиптереп тә карады.

Мал-ла-ай! Класста берәү дә калмады! Ул карбофос дигән нәмәрсә тараканнарга, коңгызларга каршы сиптерә торган сасы исле бер әйбер икән.

Менә шуннан соң "Дезодорант Рәсим" дип йөртәләр мине. Бигрәк ямьсез кушамат инде, иеме?

## Китереп куй!

"Коммунизм" колхозындагы ат карауччы Гаптери абзый беркөнне шифер урлады. Ферма түбәсен ябарга дип китереп куйган шиферның бер өлешен ат арбасына салып, өстен салам белән маскировать итеп өенә алып кайтты — беркем күрмәде, беркем ишетмәде...

Ярый, болары бер ай элек булган хәлләр. Ә бу көннәрдә "Коммунизм" колхозына телефон керттеләр. Колхоз председателенең төпчек кызы Лилия әй рәхәтләнде соң сөйләшеп! Әле өченче генә класста укыса да теле-телгә йокмый чукынчыкның. Йә дус кызына шалтырата, яисә "Мәрфуга апа, җаным, ни хәлләрең бар?" дип, түбән очта торучы җиңгәсе белән сөйләшеп маташа.

Өченче көн генә Лилиягә эт баласы алып кайттылар. И куанды инде кызый көчекне күргәч — сөтләр эчерде, кәтлит ашатты һәм "Фишер" дип исем кушты. Юк, юк, бер дә гаҗәпләнмәгез, этнең шахмат дөньясына бер кагылышы да юк, бары тик Лилиянең гадәте шундый — өйдәге җан ияләренә атаклы кешеләрнең исемнәрен кушарга ярата ул. Аның инде Майкл Джексон исемле тутый кошы, Марианна исемле ап-ак песнәге, Ромона исемле кап-кара тычканы һәм гел урам песиләре белән сугышып, көн саен башын кутырлатып кайтып керә торган Горбачев исемле мәчесе бар. Бүген менә шулар янына "Фишер" өстәлде. Әгәр дә ул ана эт булып чыгып, бала китерсә, менә күреп торырсың, ул көчегенә һичшиксез "Каспаров" кушачак. Ие-ие, кушачак!

Ярый, болары өченче көн булган хәлләр. Ә кичә әлеге гөнаһсыз аклы-каралы көчекне Лилиянең түбән очта яшәүче җиңгәсе алып киткән. Нигә дисезме? Хикмәт шунда, җиңгинең сандалиен үзе кия белми торган өч яшьлек малае бар. Шул бик елак икән. Кичә тагы да каты елаган, хәтта телевизордан һава торышын әйтеп маташкан диктор да, түзә алмагач, күзлеген салып: "Җитәр Мансур, укырга мишәйт итәсең", — дигән имеш. Ләкин шул елак Мансур "Кукла-неваляжка"ның чайкалганын карап утырганда еламый ди. Чайкалудан туктагач кына, авызын табак хәтле ачып, акырып җибәрә икән. Димәк, аңа гел хәрәкәтләнеп тора торган уенчык кирәк! Җиңгәсе "Фишер"не шуңа алып киткән икән...

Ярый, болары кичә булган хәлләр. Ә бүген... Лилия мәктәптән үк этен сагынып кайтты һәм кайту белән телефонга ябышты:

— Мәрфуга апа, менгер инде эт баласын, җаным, яме?

— Ашыкма әле, нәнәм, безнең Мансурчик бик яратты аны, әнә, куыш-куыш уйныйлар...

Җиңгәсе телефон трубкасын куйды. Лилиянең җен ачулары чыкты. Аныкы, түлке аныкы гына булган эт баласы белән Мансурчик куыш-куыш уйнасын имеш! Ул, аның номерын яңадан җыйды, ләкин, ялгышып, колхозның каравыл йортына эләкте. Лилиянең ачуы соң чиккә житеп ашкан иде, шунлыктан, каравыл йортында трубканы алган саңгырау Гаптери

абзыйның “әлү” дигән тавышын да көтмичә тезәргә кереште:

— Урынына китереп куй “Фишер”не! Әтигә әйтсәм үтерә бит ул сине. Бүген үк китереп куй, хәзер үк! Ату әтигә әйтәм!

Гаптери абзый мескен, председательнең чәрелдек кызының тавышын әллә каян таныды һәм сүзләрен ишетүгә урындыкка лапылдап килеп утырды.

“Берәү дә күрмәде бит инде югыйсә”, — дип мыгырданды ул.

Ике сәгатьтән шифер үз урынында ята иде инде.

## Ниязның рекордлар китабы

Элеккеге командир Гамилә Төркиягә укырга китү сәбәпле, Ниязны бүген класс командиры итеп сайлап куйдылар. Шулай итеп әлеге җаваплы эш Нияз кулына күчте. Малай уйлар дөньясына чумып өенә кайтты.

Иртәгесен ул класс җыелышы җыйды.

— Әйдәгез, безнең алтынчы класс өчен “Гиннеснең рекордлар китабы”н ачып җибәрәбез, — дип башлады ул үзенең чыгышын. — Кызык бит, мәсәлән, Сәлим алты сәгать буе бертуктамый сөйләшә ала, укытучылар тикмәгә генә “ватык патефон” димиләр аңа. Әхәт исә любой ераклыктан, любой язуны укытучыга сиздермичә күчерә ала. Мисалга Тәслиманә алыйк — ул безнең сагыз чәйнәү остасы. Әнә, авызындагы кызыл төстәге сагызын декабрь башында чәйни башлаган ие ул... Йә, нинди фикерләр бар?

Класс Ниязның идеясен бердәм хуплады. “Писер” итеп сары чәчле Наиләне куйдылар. “Алтынчының рекордлар китабы”на шулай итеп яшь рекордчылар теркәлә башлады.

“... 1. Фәнис мәктәпкә кыш уртасында ай да унсигез көн яланбаш килде, колаклары өшемәгән булса, тагын да шулай йөрер иде әле.

2. Хәмит — класста иң озын малай. Аның буе — метр да алтмыш.

3. Тәслимә ярты ел дәвамында мәктәптә гел бер үк “му-му” конфетын суырып йөрде. Дөрес, энекәше Мәрдәннең әйтүенә караганда, аның кәгазе генә “му-му”ныкы булып, эчендә башка конфет яисә бөтенләй ипи катысы гына булган, чөнки әтиләре Чаллыдан ярты гына кило “му-му” алып кайткан булган. Ләкин “тотылмаган — карак түгел” ...Тәслиманә барыбер китапка кerттеләр.

“Рекордлар китабы” класс почмагындагы зур кадакта эленеп торды, Наилә бик тырышып аны тутырып барды. Китапка кемнәрне кертү мәсьәләсен Нияз класс җыелышында хәл итте.

Тора-бара рекордчылар шулхәтле артты, кайберәүләр бу китапка көнгә өчәр тапкыр язылды. Мәсәлән, шул ук Сәлим бер сәгатьтә чәпләшке белән туксан биш чебен үтергән, шул ук Сәлим физика дәресендә алты тапкыр бәдрәфкә чыгып кергән... Соңга таба, укытучыларны да китапка кертә башладылар: “Сабира апа бер дәрестә сиксән дүрт тапкыр “әгәр дә мәгәр” диде, Хәләф абыйның унбиш мәртәбә тәмәке тартканын күргәннәр, Гайния апаларның сыеры бер ай эчендә дүрт бозау китерде...”

Ә беркөнне рекордлар китабына әләгергә теләп, алтынчының малайлары төкерү ярышы оештырганнар. Мәктәп почмагында тәнәфестә үткәрелгән әлеге ярышта Фидаил җиңгән. Ул дүрт метр ераклыкка төкергән, әмма... Төкерек һавада матур гына траектория белән очып барганда, почмактан директор килеп чыккан ... Калганын сөйләү түгел, күз алдына китерүгә үк аркалар чымырдап китә... Шул вакыйгадан соң Ниязның рекордлар китабы кабат ачылмаска ябылды.

## *Укучы сүзе*

* * *

Татар теленең кириллица белән ярашмавы тел белгечләренә шиксез ачык. Күрәсең, бу латин әлифбасына кайтырга дигән фикернең төп сәбәпләренең берседер.

Бу мәсьәләгә икенче күзлектән дә карарга мөмкин. Сүз — кулдан язу һәм кулъязманы уку уңайлыгы турында бара.

Латин һәм кириллица хәрефләрен чагыштырганда беренчеләренең язу өчен байтак уңайлырак һәм, шуның нәтиҗәсе буларак, бу хәрефләр белән язылган кулъязманы тану да җинелрәк икәнлеге күзгә ташлана. Латин хәрефләре гадирәк, "экономлырак" кул хәрәкәте белән языла. Кириллица хәрефләре исә бертөрлерәк, алар үзара охшаш конструктив элементлардан төзелгән, аларның язылышы артык катлаулы һәм мәшәкатьле.

Әйтик, кириллицаның *г, и, й, п, т, ш* — алты юл хәрефе бер-берсенә бик охшаш сызык-штрихтан төзелә. Алар шул сызыкларның саны һәм шуларга кечкенә генә өстәмә сызык кую белән генә аерылалар. Бу группага әлегеләреннән аз аерыла торган тагын алты хәреф өстәргә була. Алары: *к, л, м, н, щ, ц*. Юл хәрефләре ***е*** һәм ***с*** икесе дә бер үк сурәттә дип әйтергә була.

Кириллица алфавитының яртысы диярлек артык бер төрле языла. Кулъязмада бергә туры килгәндә алар тиз генә танып та булмаслык башка сурәткә әйләнәләр.

Югарыда әйтелгәннәрне раслау өчен берничә мисал алып карыйк: ***пишите, мининтгит, лигитимный.*** Әлеге артык озын булмаган өч сүз беррәттән бер-берсеннән бик аз аерылышлы 12 дән 19 га хәтле гади сызык белән языла. Тагын шул сурәттә охшаш берничә сүз — ***милиция, шимбә, пилигрим, тимер, иптәш, ит, ишетелми, шик, миллимикрон, тимгел*** һ.б.

Мондый сүзләрне яхшы каллиграфик почерк белән язганда гына җитез укырга мөмкин. Чынлыкта исә әлеге сүзләрне арадагы башка төгәлрәк языла торган хәрефләргә карап кына танырга кала.

Кириллицаның тагын бер уңайсызлыгы — юл хәрефләрендә вак элементлар күп булуында. Язма хәрефләрнең төзелеше артык катлаулы. Арада өчәр-дүртәр конструктив элементлардан төзелгәннәре дә бар. Болары — ***Ж ж, Т т, Ф ф, Ш ш, Щ щ, Ю ю, Я я.***

Кириллица һәм латин хәрефләрен объектив күрсәткеч белән төгәл чагыштыру өчен каллиграфия катлаулыгы индексы кулланырга булыр иде.

Катлаулылык индексы бирәмлеге итеп хәрефнең биеклегенә тигез туры сызык-штрих алырга мөмкин. Һәр хәрефнең бөтен конструктив элементлары шушы бирәмлек белән чагыштырылып, тулай индекс хисаплана. Шушы ысул белән тикшергәндә ***"А а"*** хәрефенең индексы 3,5 һәм 4,0, ***"Б б"***ның 3,7 һәм 3,6 итеп билгеләнә. Хәреф никадәр катлаулырак язылса, аның индексы да зуррак билгеләнә. Әйтик, ***Ж*** хәрефенең индексы 5,1 бирәмлек булса, иң гади языла торган ***С***ның ул 1,7 генә тәшкил итә.

Шушы ысул белән хәрефләрнең индексын исәпләп чыгарганнан соң кириллица алфавитының катлаулык индексы уртача 3,42, ә латинчаның 3,12 икәнлеге күренә. Кириллицага гына хас булган һәм еш кулланыла торган аеруча катлаулы ***Ж, Ш, Щ, Т, Ф, З, Ю, Я*** хәрефләре иң югары индекс белән билгеләнә.

Югарыда ясалган анализ кириллицага хас булган тискәре үзенчәлекләрне җитәрлек дәлилли. Шулай итеп, латин хәрефләренең гадирәк һәм төрлерәк төзелүе бу алфавит нигезендә кулдан тизрәк язарга, ә кулъязманы җиңелрәк укырга ярдәм итә дигән нәтиҗә ясап була.

Гамәлдәге татар алфавиты бернинди үзгәрешсез, бу телнең үзенчәлекләрен игътибарга алмыйча, кириллицадан күчереп ясалган. Аңа татарга бөтенләй хас булмаган хәрефләр дә өстәлгән ***(Е, Щ, Ц).*** Шул сәбәпле хәзерге татарча алфавит кириллицаның уңайсыз якларын тулысынча үзенә җыйган.

Татарча алфавитны үзебезнең телгә җавап бирерлек итеп, әмма артык катлауландырмыйча төзү мәслихәт.

Үзбәк ЛОТФУЛЛИН.
*Казан.*



*Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан*

## ҖӨМҺҮРИЯТ КӨНЕ

30 августта — инде менә сигезенче тапкыр — Татарстан күләмендә Җөмһүрият көне зурлап билгеләп үтелде. Бу көнне Казан шәһәрендә дә күпсанлы бәйрәм тамашалары булды. Ат чабышларын карарга яратучылар ипподромда, су спорты белән кызыксынучылар Кабан күлендә, аэрошоуга мөкиббән китүчеләр Казансу елгасы ярында, шигърият сөючеләр Г. Тукай мәйданындагы бакчада, сәнгатькә гашыйклар Камал театры, цирк янында, Болак буенда, "Казан" милли-мәдәният үзәгендә, Үзәк стадионда булып, үзләренә җан азыгы таптылар.

Бәйрәмне, меңләгән кешеләр белән бергә, Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиев, ТР Дәүләт Советы Рәисе Ф. Мөхәммәтшин, Премьер-министр Р. Миннеханов, Санкт-Петербург мэры В. Яковлев, Ставрополь крае губернаторы А. Черногоров, Япониянең Россиядәге илчесе Такэхиро Того, Мисырның Россиядәге илчесе Рида Әхмәт Шихәт һәм башка кунаклар да тамаша кылды.

## ТАТАРСТАН ПРЕЗИДЕНТЫ УКРАИНАДА

7 — 10 август көннәрендә Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиев, Украина Президенты чакыруы буенча, Кырым Республикасында булды. Татарстан делегациясен Симферополь аэропортында Кырым Республикасы Югары Советы Рәисе Л. Грач һәм Кара диңгез флоты командующие вице-адмирал В. Комоедов каршылады.

Визит барышында Җөмһүриятебез Илбашы Украина Президенты Л. Кучма, Украинаның Югары Радасы Рәисе А. Ткаченко һәм Украина Премьер-министры В. Пустовойтенко белән очрашты. Сөйләшүләр барышында үзара сәүдә-икътисади, фәнни-техник, мәдәни хезмәттәшлек һәм "УкрТатнафта" трансмилли компаниясен төзү турындагы хөкүмәтара килешүләрне үтәү мәсьәләләре кузгатылды.

## ИЧКЕРИЯ КУНАКЛАР ЧАКЫРА

Чечня Республикасы - Ичкерия Президенты Аслан Масхадов чакыруы буенча, Татарстан Республикасының Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, шагыйрь Ренат Харисов һәм Татарстан мөселманнары мөфтие Госман хәзрәт Исхакый җитәкчелегендәге делегацияләр Грозный-Җәүһәркалада булып кайтты. Рәсми делегация составында Казан шәһәренең Вахитов районы хакимияте башлыгы Сабирхан Мөхәрләмов тә бар иде.

Татарстан кунаклары 6 сентябрь көнне Ичкериянең бәйсезлек алуына 7 ел тулуга багышланган тантаналарда катнаштылар.

## Ш. МӘРҖАНИ ИСТӘЛЕГЕНӘ

Халкыбызның атаклы тарихчысы һәм мәгърифәтчесе Шиһабетдин Мәрҗанинен якты истәлеген һәм кылган изге гамәлләрен мәңгеләштерү юнәлешендә мәркәзебездә матур эшләр башкарыла. Күптән түгел генә Кабан күле буендагы Комсомол урамына аның данлы исеме бирелде. 30 августта исә, әлеге урамга күпсанлы кунаклар килеп, Ш. Мәрҗани истәлегенә куелачак һәйкәл урынына язулы таш кую тантанасында катнаштылар.

## АКСАКАЛЛАР ШУРАСЫ ОЕШТЫ

Башкалабыз Казанда Татар халкының Аксакаллар Шурасын оештыру корылтае булып узды. Ул Татарстан Аксакаллар Шурасы башлангычы белән, Бөтендөнья Татар конгрессы башкарма комитеты ярдәмендә җыелды. Бу җыенга 27 төбәк оешмаларыннан вәкаләтле вәкилләр — атаклы кешеләр килгән иде.

Корылтай, Татар халкының Аксакаллар Шурасын булдырырга карар итеп, 11 кеше составында аның башкарма комитетын сайлады. Татар халкының Аксакаллар Шурасы Рәисе итеп Р. Хәмидуллин, аның урынбасарлары итеп Алматыдан академик М. Кәримов, Мәскәүдән генерал-полковник Р. Акчурин сайланды.

### "ХӘТЕР ҖЫЕНЫ"

Елдагыча, быел да 25 августта Казан Кремле каршындагы каһарман шагыйрь М. Җәлил һәйкәле һәм аның көрәштәш дусларына куелган барельфлар янында "Хәтер җыены" булып үтте. Моннан 54 ел элек Алманиянең Плетцензее төрмәсендә башлары киселгән ватандашларыбызны искә алырга Абдулла Алишның улы Алмаз Алишев, Абдулла Батталның туганы Мөбәрәк Батталов, Рәхим Саттарның улы Ил Саттаров һ. б. килгән иде. Матәм митингысында Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе Ринат Мөхәммәдиев, каләм әһелләреннән Рафаэль Мостафин, Равил Фәйзуллин, Кави Латыйпов, Лена Шагыйрьҗан, Әхмәт Гадел, Шаһинур Мостафин һ. б. чыгыш ясады.

"Хәтер җыены"нда шулай ук Татарстанның Берләштерелгән дәүләт музее, Казандагы М. Җәлил музей-йорты хезмәткәрләре, җәмәгатьчелек вәкилләре катнашты.

### КОМПОЗИТОР БЕЛӘН ХУШЛАШУ

8 сентябрьдә Татарстан халкы, республика җитәкчеләре мәшһүр татар композиторы — Татарстан Республикасының һәм Россия Федерациясенең халык артисты, Татарстанның һәм Россиянең атказанган сәнгать эшлеклесе, республикабызның Г. Тукай, Россиянең М. Глинка исемендәге Дәүләт премияләре лауреаты Фасил Әхмәтовны соңгы юлга озатты.

Башкалабызның Зур концерт залына мәрхүм белән хушлашу өчен Җөмһүриятебез Илбашы М. Шәймиев, ТР Дәүләт Советы Рәисе Ф. Мөхәммәтшин, Премьер-министр урынбасары И. Хәйруллин, Казан шәһәре мэры К. Исхаков килде. Матәм җыенында Татарстан Композиторлар берлеге идарәсе рәисе Р. Кәлимуллин, ТР Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, шагыйрь Р. Харисов, Татарстанның халык язучысы Г. Ахунов, композиторлардан М. Яруллин, Ш. Монасыйпов, җырчы В. Гыйззәтуллина, дирижер Ф. Мансуров, Кукмара районы хакимияте башлыгы, Татарстан халык депутаты М. Гатиятуллин һ. б. чыгыш ясады...

Ф. Әхмәтов Казанның Яңа бистә зиратында, "Милләтебез зыялылары аллеясы"нда җирләнде.

### ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕНДӘ

9 сентябрьдә Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең чираттагы утырышы үткәрелде. Анда республикабыз әдипләренең 1999 елның маенда булачак чираттагы корылтаена хәзерлек мәсьәләләре каралды. Идарә утырышында Ш. Усманов, А. Алиш, Х. Вахит, Ф. Сафин кебек мәрхүм язучыларга багышлап искә алу кичәләре үткәрү планлаштырылды. Алда торган юбилейлар һәм быел Карелиядә үтәчәк "Татар әдәбияты көннәре"нә хәзерлек турында да эшлекле сөйләшү булды.

### ЯҢА КҮРГӘЗМӘЛӘР

27 августта Татарстан Берләштерелгән дәүләт музеенда Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының кульъязмалар һәм текстология мирасханәсе фәнни хезмәткәре, күренекле галим, каллиграф- рәссам Нәҗип Нәккашның тугралар күргәзмәсе ачылды. Беркемне дә кабатламаучы әлеге үзенчәлекле күргәзмәдә Нәҗип әфәнденең милләтебез зыялыларына, олуг шәхесләргә багышланган бихисап әсәрләре урын алган.

* * *

Татарстан Республикасының Сәүдә-сәнәгать палатасында урнашкан "Камил" иҗат остаханәсе галереясында Казан рәссамы Марат Яушев әсәрләреннән торган күргәзмә эшли башлады. Казан дәүләт педагогика университетының төп бинасын һәм мәркәзебездәге Зур концерт залын бизәү эшендә катнашкан бу оста тамашачыларга "Капма-каршы хыяллар" дигән исем астында үзенең яңа иҗади эшләрен тәкъдим итә.

### КИТАП НӘШРИЯТЫНДА — ЯҢА ДИРЕКТОР

Татарстан китап нәшриятына яңа директор итеп Дамир Шакиров билгеләнде. Моңарчы ул әлеге нәшриятта директор урынбасары булып эшләгән иде.

*Тышлыктагы сурәтләр*

**Тышлыкның беренче битендә:** «Ромашкино төбәгендә». Рәссам Мәхмүт УСМАНОВ картинасыннан фоторепродукция.

# "КАЗАН УТЛАРЫ" ҮЗ ЯКТЫСЫНА ЧАКЫРА

1 сентябрьдән 1999 ел өчен вакытлы матбугатка язылу башланды. Быел ул, соңгы еллардан аермалы буларак, беренче тапкыр тулы бер елга үткәрелә һәм җирле гәзит-журналларга язылу Татарстанда 1 декабрьгә кадәр дәвам итәчәк. Табигый ки, ярты елга яки аннан азрак вакытка язылырга теләүчеләр өчен дә мөмкинлекләр тудырылган: алар үзләре теләгән кадәр срокка языла ала.

"Казан утлары"на язылу бәясе Русия һәм Татарстандагы башка басмаларныкына караганда шактый арзан — елына нибарысы 48 сум, ярты елга — 24 сум. Журналның аерым саны 4 сум.

Халкыбызның бай тарихлы, абруйлы журналы "Казан утлары" Сезне яңадан үз яктысына чакыра. Күпьеллык дуслыгыбыз элеккечә матур дәвам итсен.

Ф. СП-1

Министерство связи СССР
«Союзпечать»

АБОНЕМЕНТ на газету / журнал 73210 (индекс издания)

„Казан утлары" (наименование издания)

Количество комплектов:

на 1999 год по месяцам:

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | |

Куда (почтовый индекс) (адрес)

Кому (фамилия, инициалы)

ДОСТАВОЧНАЯ КАРТОЧКА

ПВ | место | литер

на газету / журнал 73210 (индекс издания)

„Казан утлары" (наименование издания)

Стоимость: подписки ____ руб. ____ коп.; переадресовки ____ руб. ____ коп.

Количество комплектов:

на 1999 год по месяцам:

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | |

Куда (почтовый индекс) (адрес)

Кому (фамилия, инициалы)

## ЖУРНАЛЫБЫЗ — ИҢ ЯХШЫ БҮЛӘК!

Алдагы елларның уңай тәҗрибәсен һәм күпсанлы укучыларыбызның теләкләрен искә алып, журналыбызга язылуны җиңеләйтү максатыннан, 1999 ел өчен хәзерләнгән әбүнә кәгазен (абонемент үрнәген) тәкъдим итәбез. "Казан утлары"н алдырырга теләүче һәр кеше, шушы квитанцияне кисеп алып, аңа үзенең тулы адресын, исем-фамилиясен, язылырга теләгән айларын күрсәтеп, аны үзе яшәгән җирдәге элемтә бүлегенә тапшырырга тиеш. Журналыбызның индексы — **73210**. Ул Татарстан һәм Россия күләмендәге каталогларга кертелгән. Мөмкинлектән файдаланып, урыннардагы хакимият башлыкларының, предприятие-оешма җитәкчеләренең, авыл хуҗалыгы, урман хуҗалыгы һәм мәдәният-мәгариф һ. б. өлкәләрдә эшләүчеләрнең исләренә төшерәбез: "Казан утлары" журналы — алдынгыларны хөрмәтләү өчен иң яхшы бүләк, үзенчәлекле китапханә ул!

## ПРОВЕРЬТЕ ПРАВИЛЬНОСТЬ ОФОРМЛЕНИЯ АБОНЕМЕНТА!

На абонементе должен быть проставлен оттиск кассовой машины.

При оформлении подписки (переадресовки) без кассовой машины на абонементе проставляется оттиск календарного штемпеля отделения связи. В этом случае абонемент выдается подписчику с квитанцией об оплате стоимости подписки (переадресовки).

Для оформления подписки на газету или журнал, а также для переадресования издания бланк абонемента с доставочной карточкой заполняется подписчиком чернилами, разборчиво, без сокращений, в соответствии с условиями, изложенными в каталогах Союзпечати.

Заполнение месячных клеток при переадресовании издания, а также клетки «ПВ — МЕСТО» производится работниками предприятий связи и Союзпечати.

# ЯҢА КИТАПЛАР




**Көмеш чишмәләр җыры** (Песня серебряных родников). — Әлмәт: "Рухият" нәшрияты., 1998. — 239 б. Тиражы — 5000 данә.

"Татнефть" ярдәмендә әле бер ел элек кенә оешкан "Рухият" нәшрияты инде дистәгә якын китап басып чыгарды. Алар арасында проза һәм шигырь китаплары, шулай ук альбом, буклет рәвешендә чыккан басмалар да бар. "Көмеш чишмәләр җыры" — бай эчтәлеге, зәвык белән бизәлеше ягыннан аерым бер затлы альбом-китап булып чыккан.

"Чишмәне савыктыру, иң башлап, күңелләребезне савыктыру ул. Чөнки чишмә — су чыганагы гына түгел, рухыбыз көзгесе. Чишмә суларыбыз алдагы буыннарга аларны яңартучыларның рух җылысын алып барыр. Көмеш агымнар авыруларны сихәтләндерер, хезмәт кешесенә көч-куәт бирер, милләтнең рухын ныгытыр. Татарстан нефтьчеләре үзләрен халык алдында бурычлы саныйлар. Чишмәләрне яңартып, без халкыбызның бәхиллеген алабыз..." Китап — "Татнефть" АҖ генераль директоры, "Рухият" фонды советы рәисе Ринат Галиевнең шундый сүзләре белән ачыла.

Җаваплы редактор һәм төзүче буларак күп көч куйган Илсөяр Хәйруллина белән бергә тагын бик күп каләм ияләренең — шагыйрьләрнең, журналистларның, атаклы нефтьчеләрнең, шулай ук, фото һәм дизайн осталарының зур хезмәте кергән бу китапка. Текст татар, рус, инглиз телләрендә басылган.

Индекс 73210



Шагыйрә Бикә Рәхимова

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARЬ
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)